ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2000



# YAZUÇILARIBIZ ÇİT İLLƏRDƏ



**Renat Xaris, Safuan Əlibayev**. Tərki xalıqlar şiğriəte festivalendə. *İstanbul. Sentəbr, 2000 yıl.*



Professor **Xatip Minnegulov** həm Finləndiə «İslam cəmğiəte» prezidentı **Oqan Tahir** tatar ziratında. *Helsinki. Avgust, 2000 yıl.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2000

# 11

(937)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎ Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Күңелем серләре. *(Куен дәфтәрләреннән)* ..... 5
Роберт ӘХМӘТҖАН. Шәҗәрәм тирәге. *Шигырьләр* ..... 42
Радик ФӘИЗОВ. Гаделлек иясе. *Хыялый повесть* ..... 48
Рөстәм МИНГАЛИМ. Котлаулар - багышлаулар. *Шигырьләр* ..... 86
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Су бирегез! *Шигырьләр* ..... 91
Нурулла ГАРИФ. Ул үлде... *Яшәү турында баллада* ..... 95

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Гомәр ТОЛЫМБАЙ. Фамилия ясаучылар. *Хикәя. (Р. Рахмани кереш сүзе белән)* ..... 101

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Туфан МИҢНУЛЛИН. «Бетте көч, сынды кылыч...» *(СССР халык депутаты истәлекләре)* ..... 106
Абдулхан ӘХТӘМҖАН. Ватаннан еракта туган җырлар *(Ү. Науруз шигырьләре)* ..... 120

**ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Илшат ВӘЛИУЛЛА. Мәңгелек бәхет эзеннән ..... 124

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Сәлах ШӘРИПОВ. Тәкъдирдән узып булмагач... *(Рецензияләр конкурсы)* ..... 131
Илһам ФӘТТАХ. Асылыбызга кайту ..... 134

**СӘНГАТЬ**

Кояш ТИМБИКОВА. Мәхәббәт — бер генә! ..... 137

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

4 — Ниса (Хатыннар) сүрәсе ..... 143

**ХӘТЕР**

Фронт хатлары *(И. Газиның А. Шамовка язган хатлары)* ..... 162
Татар шагыйрьләре — Сәйдәшкә ..... 172

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Зурлык ..... 179
Ренат ХАРИС. Алтын ачкычлы «резидент» ..... 181

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

Кыям МИҢЛЕБАЕВ. Гуманистлык үрнәге ..... 184

**БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ**

Нәҗифә КӘРИМОВА. Ипи пешердек . *Хикәя.* ..... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: А. ГИЛЯЗОВ. «Сокровенные мысли» (из записной книжки писателя); фантастическая повесть Р. ФАИЗОВА «Правдоискатель»; баллада Н. ГАРИФА «Он умер...»; рассказ Н. КАРИМОВОЙ «Мы печем хлеб»; стихи Р. АХМЕТЗЯНОВА, Р.МИНГАЛИМА, Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ.
«Из сокровищницы татарских рассказов»: рассказ Г. ТУЛУМБАЯ «Новые фамилии» *(с предисловием Р. Рахмани).*
«Публицистика»: Т. МИННУЛЛИН. «Иссякла сила, сломался меч»; А. АХТЯМЗЯН. «Песни рожденные вдали от родины».
«К 100- летию Х. Туфана»: статья И. ВАЛИУЛЛЫ «По следам вечного счастья».
«На конкурс рецензий»: С. ШАРИПОВ рецензирует роман М. Амирханова «Судьба».
«Литературная критика»: И. ФАТТАХ. «Возвращение к истокам».
«Искусство»: К. ТИМБИКОВА. «Любовь - одна».
«Коран на татарском языке».
«Память»: письма И. Гази А. Шамову.
«Татарские поэты - Сайдашу».
В номере отмечаются 70 - летие Э. Нигматуллина, Э. Касымова и 60- летие З.Фатхутдинова.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: портрет С. Сайдашева - работа художника В. Шарафутдинова; писатель Рауль Мирхайдаров.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": A.GILIAZOV «Innermost thoughts» (from writer's note book), R. FAIZOV'S fantastic novel «Searcher of truth»; N. GARIF'S ballad «He is died...», N. KARIMOVA'S story «We bake bread»; the verses of R. AKHMETZANOV, R. MINGALIM, A.SHARIFULLINA.
"From treasury of Tatar stories": G. TULUMBAY'S story «New names» (with R. RAKHMANI'S preface).
"Journalism": T. MINNULLIN «The strength is dried up, the sword is broken»; A. AKHMETZAN «Songs written far from native land».
"Commemorating the 100 th anniversary of H. Tufan": I. VALIULLA'S article «By the tracks of everlasting happiness».
"Review competition": S. SHARIPOV'S review of M. Amirkhanov's novel «The fate».
"Literary criticism": I. FATTAH. «Return to source».
"Art": K. TIMBIKOVA «Love is one».
"Koran in Tatar language".
"Memory": I. Gazi's letters to A. Shamov.
"The verses of Tatar poets to Saidash"
The diary of social and cultural life.
In our covers: portrait of S. Saidashev - artist V. Sharafutdinov's work; writer Raul Mirkhaidarov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 24.10.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7542 Заказ Э-435
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Аяз Гыйләҗев

## КҮҢЕЛЕМ СЕРЛӘРЕ...

КУЕН ДӘФТӘРЛӘРЕННӘН

*4 июль 1992 ел, Займище, кич.*

Беренче июльдә коега суга барам, якындагы сүзсез урманны уятып күке кычкыра. Язын, үз вакытында күкеләр курка-курка гына аваз салып, җиһанда барлыкларын белдергәннәр иде. Ин гаҗәбе, күкеләр түбәндә, куак астында кычкыргандай булдылар. Бүген минем хәсрәтемне арттырып, биек агачның нәкъ очыннан тилереп кычкыралар. Шомлы яз! Шомлы күкеләр! Быел сыерчыклар килмәде, ничәнче яз Займищела оя кормыйлар алар. Чәпчекләр ашык-пошык кына күренделәр дә, югалдылар. Керәшәләр дә күз нуры ирешмәслек югарылыкта чаж-чож очалар. Тугры чыпчыклар күренми, якын дусларым—чибәр песнәкләр, мөгаен, урмандадыр. Тимер юлга юл күрсәтеп үскән рушада пар сандугачлар адым саен диярлек сайрашалар, дөньяны матурлыкка өндиләр иде. Быел ник берәвесе ялгышып сайрап җибәрсен. Безгә язган югары күк астында карга белән саескан гына калды. Ә каргалар иблис сызган план нигезендә, бомба ташларга әзерләнгән шомлы күләгәләр булып күкне бүлешеп алдылар. Элгәрге елларда тимер тешле саесканнар кеше тораклары янына якынаерга шүрләп читтән-читтән гына яныйлар иде... Быел!.. Күзенә карап кылыч койрыкларын селки-селки баш түбәнне чукырга җыеналар. Кая ул курку! Кая ул сагаю! «Сайрар кошларыгызны ашап симердек, хәзер үзегезне чукырга тотынабыз!» диләрме? «Ин элек бала-чагаларыгызның күзләрен чукып чыгарачакбыз!» диләрме?

Июньнең соңгы көннәрендә Кызыл Байракка барган идем. Ике көнгә Нәкыя белән. Сихри урыннар! Иделнең аулак диярлек ягасы. Нарат урманнары. Текә ярлы тирән чокырлар. Мең төрле чәчкә-гөлләр көнгә карап тирбәләләр. Болын җилләренә сөенешеп кылганнар йөгерешә. Безнең якларда әз-мәз качып калган сихри дала кылганнары. Учак урыннары. Төтен исләре. Каяндыр, Үр өстеннән тимер очлымнарын ялтыратып атменәр болгар яугирләре килеп чыгар төсле. Тик... тукта! Тарихка юнәлтсәң хәтерне... куркыныч! Идел ярындагы бердәнбер татар авылы... Табигать гүзәл булса да күнелдә ШОМ. Идел ятим. Идел буп-

буш. Пароходлар йөзми. Корсагына алагаем мал тутырган дәү-дәү баржалар чайкалмый. Юл сабуны сорап, карлыккан тавышка бер-берсен сәламләгән теплоходлар Идел төбенә чумганмы? Төптә дә зәңгәрсу-кара радиацияле ләм белән балыклар каберлеге икәнен белмәгәнме әллә алар? Дачабызда ике тәүлек яшәдек, күз карашын ияртеп китәрлек хәрәкәт күрмәдек. Тынлык кадерле кунак булса да киң Идел өстенең шыргый бушлыгы күңелне телем-телем турый, куркыта. Идел—хәрәкәт! Яшәргә тиеш ул! Ә быел Идел үксез, ятим, җан бирергә сузылган арык гәүдә. Кызыл Байрактан кайткач, ике көн рәттән Гарәф белән балыкка чыктык—кирәк бит! Идел безнең янда да үксез, караучысыз калган үксез баладай, кызганыч. Акчарлаклар юк. Идел утрауларының хуҗасы сандугач сайрамый. Әле кайчан гына «куак саен сандугач!» дип сокланып язган идем. Көймәгә утырып барганда ян-яклардагы яшел утраулардан уннан, сулдан пар-пар челәннәр очып күтәрелә, алар авыр, салмак канатлары белән көймә йөреше уңаена очып иярә торганнар иде. И нинди хозур булган ул чаклар! Моркваш күленнән Олы Иделгә чыга торган тар бугаз өстеннән каршы якның ермачланган текә ярлары, Иделне дулкыннары белән сөендереп, йокыдан уятып үтеп-сүтеп йөргән таудай ак пароходлар, дәү-дәү чуртан баржалар күңелне әллә кайларга чакырып, өзлексез үтеп, күренеп торалар иде. Теге як яр астына кармак салырга теләгәндә кара-каршы йөзгән баржаларның, теплоходларның җәһәннәм ындыр табагыдай җәелгән салларның үтеп киткәнен көтеп чират житкерә алмыйча зарланыша торган идек. Бүген көзгедәй Идел өстен дулкыннар чатлатмый, көттереп кенә ракеталар узгалый, алар житез, күз сенеп өлгергәнне көтмичә, аулак өйдә йоклап калып, кинәт сикереп торган үшән егетләр ындыр артлатып ашыккан кебек тиз-тиз югалалар. Моркваш күленә дулкыннары да кереп житәлмый. Берәүгә дә юл сапмыйча дулкыннарны постырып басып узган киң-киң саллар кая киттеләр икән? Бушлык, жансызлык. Димәк, ил хуҗалыгында эшләр кәкәй. Идел илгә хезмәт итми, кангырып-жылап бушка ага. Иделдә эш сүнгән икән, бу—бетү, бу—ярлылык, хуҗасызлык галәмәте. ШОМ!

Займищеда янәшәбездән тимер юллар сузыла. Андагы җанлылыкка, теңкәгә тигән көне-төне хәрәкәткә күз иярми торган иде. Соңгы атна-ун көндә тимер юллар да парлашып ялга чыктылар. Электровозларны кайдадыр күгәреп бәйдә торган тепловозлар алыштырды, баш очына тагын төтен, сөрем кайтты. Вагоннарның тәгәрмәчләре май сорап чиныйлар. Элек караватка ятсаң җир тетри, ярлар ишелә, идәннәр исерешеп бии торган иде. Хәзер—юк. Тынлык белән куанасы килгән күңелгә ШОМ бөселеп ята, тел тешләнә. Усал сүзләрне әйтеп котыласы килә, кемгә атап әйтәсене белмәгәнгә тешләрне тимер койма итәсең дә иреннәрне йомасың.

Әйе, дөньяның бар мәшәкатьләрен, җиһанның сулышын аңлатыр өчен өч хәрефле бер сүз житә икән: ШОМ!

Байтактан яңгыр төшкәне юк иде, бүген шөкер, ат ялыдай юллы-юллы, яшен камчылары сузылышкан баганалы-баганалы болытлар өстерәлеп килеп життеләр дә безнең баш очына казык кагып, тышау салдылар. Сәгать икедә яварга тотынган ташкын кичкә кадәр тоташтан койды. Әле хәзер дә китеп өлгермәгән болыт кибәннәре мыгыр-мыгыр килеп һаман шәбәртәләр. Инде кичке сигезләр булып килә. Шәһәр маржалары явымны, дымны сөйми, алар шәһәрдәге тартмаларына ашыгалар, күлләвекләрнең болганчык күзләрен сытып, лай чәчеп, аллы-артлы поездга чабалар. Җилфердәгән күлмәк итәкләренә күз иярми. Таза балтырларына, сихри тез асларына яшьлекне сагыну ияреп китә. Чап-чап! Мин икенче катта. Маңгаемны суынган пыялаларга терәп, әле бер якка, әле каршы тарафка чыгып, бакчамны күзәтәм. Күбрәк маржалар чабышкан юл ягына чыгам икән!.. Оялып, читенсенеп Яхиннар ягына чыктым. Ходәвәндәм, алтмыш бишне тутырып килгәндә әле һаман күз зинасы кала микәнни?!

Янгырга сөенергә кирәк тә, булмый. Болыттай кабарынган, болыттай салынган ШОМ күңелдән агып чыгарга юл таба алмыйча һаман әйләнә, тулгана, богырдый. Ага вакыт, әллә жаннан, әллә тәннән умырып-умырып тере ярчыкларны каезлый. Җәйнең иң асыл, иң хозур көннәре ләбаса, сөен, сикер, кинән! Хәлем түзәрлек, шөкер, шикәр авыруым әллә ни сиздерми, авызым кипми, кадерле даруым «Букарбан» бар әлегә. Сөенә алмыйм гына бит! Шатлыгымнан да хәзер кара күләгә төшә.

*5 июль 1992 ел, Займище, иртә.*

«Uerba uolant, seripta manent»

«Сүзләр оча, язган кала!» Сизелә башлаган корылык, үзе бер ШОМ иде. Янгыр кинәндереп үтте. ШОМ кимемәде. Идел-йортның зәһәр дулкыннарын ияртеп килеп нинди әче кислоталар, кай заводлардан үтергеч агулар калдырып китте икән бу юлы болытлар дип, үзем басып торган, улларым, балаларым яшәгән сүзсез жиргә иеләм. Болганып яткан нәни дулкынчыклар чуарлаган, чит-читләре күкерттәй сарыланган күлләвекләргә карыйм. Табигатьнең һәр ымыннан гап-гади үзгәрешләреннән ШОМ көтәсең, инде безнең уртак өметләр дә үлеп бара бугай. «Надежда умирает последней», диләр урыслар. Әллә бу безнең соңгы өметләрнең тайпылышымы?.. Гәрчә бөтән сүзләр дә бар!

«Noch am urabepxlanz er lie Hox ningait»

«И на могиле пробиваются ростки надежды», дигән, киләчәккә өмет белән караган Фридрих Шиллер. Ышаныргамы? Юк, әлбәттә. Шиллер безнең заманның шушы кадәр өметсез, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез булырын бер генә тапкыр да күз алдына китермәгән. Шагыйрь кеше адәми затның дөньядагы иң явыз, тиңдәшсез ерткыч булып үзгәрәчәген белмәгән... ШОМ коммунистлары Пушкин шәһәренә жыелып, XXIX съездларын үткәрделәр. «Янарыш съезды» дип атадылар аны. Исеменә кара: «янарыш». Әле кайчанрак кына безнең әдипләр дә: «Мин коммунист!» дип күкрәк каккан иде. Яфрак астыннан күпме бөжәк, ничаклы хаиннар баш калкытып чыгачак әле... Нәни генә үзгәреш башланса да канэчәр коммунистлар жирне басачак. Фашистлар-шовинистлар да туктаусыз үрчи тора. Илдәге һава, сасы дым аларга ашлама, нур, дым биреп тора. Үрчиләр, үсәләр, калкыналар, борчак сабаклары кебек бер-берсенә жеп сузалар, укмашалар... Берзаман шул йомшак жепләрне безнең муенга бау итеп салырлармы? Мөмкин. Бик ихтимал. Фашист, коммунист—ике чабата бер кием, бүгенге чабата, иртәгә тевтон рыцарьларының тимер табанлы корыч башмаклары. Илне сытып кына үтәчәкләр. Кеше жаны—аяк киеменә ияргән тузан гына ләбаса. Кагып төшерәчәкләр... Көне килгәнне көтәләр, әзерлиләр. Шовинист-фашист-коммунистлар ал таңнарның берсендә сикереп торып, тотаклашып, житәкләшеп ирек хәрәкәтенә каршы чыгып басарлар да Рәчәйне янадан бер капчыкка тутырып бәйләп, безләрне рәттән суя башларлар әле. Коммунистлар алар фашистлар гына да түгел, аларда мең явызлык, мең шәфкатьсезлек! Бигрәк тә хәзерге шартларда, ил аксаганда, икътисад тилмереп жан биреп ятканда, халык гамь белән ваем эчендә саташып йөргәндә, буш вәгъдәләр эленгән әләмнәрен болгап мәйданга тагын большевикларның өрәге коммунистлар калкып чыкса... аңгырайган адәмнәр алар артыннан ияреп чапмас дисеңме? Үпкәлисеңме, юкмы, тарихы дәвамында бер чакта да демократияне татымаган урыс халкына бары тик корыч кул, тимер богау вә кан эчкеч хакимият кенә тәс! Халык, хакимияткә ялланган философлар каршы килсә дә, кара сарык ул!

Ельцин, эчә-эчә күбенеп беткән буш бугаз булып чыктымы, өзеп әйтү әлегә кыен. Шушы арада буп-буш ямаулы капчыгын селкеп Мюнхенга, без гасыр буена каһәрләгән капиталистларга теләнергә бара. Горбачевны шулай бер, аркасыннан кагып, сүз белән юатып озатып

калганнар иде инде. Хәлсезләнгән, бетәшкән, үләргә йөз тоткан коммунистик режим җимеше Рәсәй калкынырга, җиде сыерны да имеп аякка басарга җыенамы? Һаман-һаман чит илләр хәзинәсенә күз тотып рәтләнеп булырмы? Нигә хөкүмәт көрсиләрендә урын биләгән урыс-улак арасыннан бер акыллы баш күтәрелеп: «Җитте! Үзебез эш тотып карыйк!» дип оран салмый?! Үз иледә үз көненне күрерлек акылың калмаган икән, акылны импорт итеп алып кайтып булырмы икән?

Янгыр шашынып китеп, түбә тишеге аша өйгә үтте, кухня түшәменә сары ашъяулык җәйде. Түбәмне япкан бимитнең көче тәмам. Бимитне каерып алып түбәне шифер белән ябарга кыҗрап йөрдем. Йолдыз Вагизович Курмашев шифер да бирәм дигән иде, өлгермәдем. Хәзер көчәнергә, иза чигәргә туры киләчәк. Без яшәгән, без җайлашкан заман үтте, хәзерге заманга, бүгенге базар мөнәсәбәтләренә, икътисадка без яраша алмыйбыз. «Кияү булсак та бу туйга түгел» инде без. Түбәгә үтеп кергән су—адәм әгъзаларына үтеп кергән рак күзәнәге ул.

Торам да аптырап як-ягыма күз ташлыйм—дачаларда басып яшәүчеләр калмады, бик күпләр алдан ук аякларын киенделәр, Казан тирәсе авылларыннан йорт-кура сатып алып, шул нигезләрдә тормышларын дәвам итәләр. Бәрәнге утырталар, кош-корт асрыйлар. Альберт Яхин Шәледән—җөмһүриятнең бәрәнге патшалыгыннан—25 сутый җир алды. Шәле бәрәңгесе!.. Ярмалы, коры, күзәнәкләре тирән түгел, чубыргалы бәрәңге. Альберт хәзер дачасына шпион шикелле яшеренеп кенә кайтып керә дә дәшми-тынмый чыгып сыза. Икенче күршем Марсель Зарипов та унбер умартасын багып, кайдадыр карурманда качкын булып ята. Көзгә берсе бәрәнге сәүдәсе, икенчесе чәчәк балы базары ачып җибәрәчәк. Оттымы алар? Откаңнардыр, мөгаен. Йорт аралаш шул хәл, Зәки белән Мәрьям югалды, Фатыйма апа төтен булып очты. Күпчелек картлар өй саклап шәһәрдә яталар. Тимер ишекләр куйдыралар да, өйдән чыкмыйлар. Төн саен зур йортлардагы квартирларның берсен басмый калмыйлар икән. Нибуч, сагаерсың. Адәмдә оят бетте. Оят беткәч адәмдә курку да калмый. Курку калмаган илдә кансызлар үрчи. Фәкыйрьлек, ачлык, билгесез киләчәк моңарчы юаш күренгәннәргә дә усаллык тамыза. Моңарчы дәшми-тынмый эшләп йөргәннәр дә билләренә хәнҗәр, куеннарына алтатар тагып юлбасар булып китәләр. Моңарчы җинаятьләр төрлелегенә багышланган дәреслекләрдә язылмаган хикмәтле җинаятьләр эшләнә. 53 баланың башына җиткән Чикотило берүзе ни тора! Шул үләтнең судтагы капризларына түзеп торалар бит! Ике йөз мең кеше ун ел дәвамында эзләгәч кенә таба алдылар ул иблисне. Күпме җан кыйды, күпме адәмнәрне кара хәсрәткә күмде, безнең кесәдән аның өчен күпме акча чыкты! Менә җәй үтеп бара, урманга кергән юк диярлек. Урман ШОМ оясы. Әлерәк кенә Казан төрмәсеннән биш явыз качты, рецидивист урыслар. Ил күләмендә яңа амнистиягә ияреп 60 мең тоткын ireккә чыкты. Амнистия булмасын димим, үземнең дә аны өзелеп көткән чакларым бар иде. Кем чыга бит, кемнәр кемнәрне азат итәләр! Җәнҗаллы төбәкләрдән качаклар кайта. «Аларның күпчелеге, шул җөмләдән борыны канаган, үч алырга ярсыган кара урыс-улак та сыйлы табынлы, тыныч түрле Татарстанны сайлый», дип шөбһәләнеп яза газеталар. Ә качаклар—дөрләп янган учакта очлы башлары белән тырпаеп аркылы-торкылы яткан коры-сары ботаклар алар. Тырпаеп торырлар, торырлар да гөлт итеп кабынырлар.

Чиләгемә чын көмеш су тутырып тын иртәдә сөенә-сөенә коедан кайтып барам. Каршыма Рәсим Сәйдәшев килә. Якынаюга буш чиләген төбе белән әйләндерде... Буш чиләк белән очраштырмый, янәсе.

—«Иске сукыр күнеккән, яңа сукыр дөмеккән».

—«Тозсызны күзсез дә күрә».

*5 июль 1992 ел. Займище, көпә-көндез.*

Анда-монда барганда каршыма берәү очрады исә, адымнарымны акрынайтам да уйларымны тәртә арасына кертеп эшкә кушам: «Йә, житмешенче яшь белән барасың, күпне күрдең, бел: нинди уйлар асрап яши бу адәм? Йөз кыяфәтең өйрән, әйтеп бир!» Адәм балалары эш күплектән иза чиксәләр дә, табигый буларак, аларның аратирә буш вакытлары да кала, кеше буш вакытына асылда үзе төп хужа. Тәүлек дәвамында адәм балаларының япа-ялгыз калган чаклары да була. Ялгызлык—уй ул. Йә, әйт: нинди тәмамланмаган уйлар аларның баш мие шартларында тузгый соң? Элек, моннан өч-дүрт ел элек тә, мин уйсыз бер минут та яши алмый идем. Елның кайсы фасылында, көннең кайсы бүлемтегендә булмасын, төрледән-төрле уйлар шакып-нитеп тормыйча чиксез озын жеп булып башыма уралалар да, ми шарларым йомгак булып авыраялар иде. Берьюлы өч-дүрт әсәр тирәсендә була иде кайнар уйларым. Хәтерлим, иртә-кич Переделкиноның аулак сукмакларын адымнарым белән үлчәгәндә, йорт кысасы мәшәкатьләре, Казан тормышының бимазалы ыгы-зыгылары чак кына онытылып торганда, һәр яңа адымым аңыма нидер тартып китерә, хатирәләр казанында кайнап онытыла язган кадерле истәлекләрне уятып чыгара да, язылачак әсәрләремнең берсенә жилемләп беркетеп куя торган иде. Урманның һәр борылышында мине ачыш, һәр куак артында көтелмәгән кадерле уйлар өермәсе сагалап тора иде. Япа-ялгызлык һәм зарыктырган тынлык миңа уйдан канат тага иде. Оча идем мин уй-фикернең ташыган дәрьялары өстеннән! Урынга ятып өлгермисең, ми үзенә хас алымнар белән уйны йөгертә башлый, каулый, ашыктыра, уем үтеп кермәгән почмак юк дөньяда, хәтер ачык, аек, уй жебен нинди давыллар кагылганда да өзми саклый ала, азагына кадәр дилбегәне кулдан ычкындырмый. Күпме әсәрләр әнә шул уйлар өермәсе уртасында туган вакыйгалар нәтижәсендә дөнья күрде. Арыпталып ятсам да мин ял итмим, акыл үзеннән-үзе уй тегермәнен әйләндерә, уйның жылы оны мөшкәдән өзлексез ага, тонна-тонна фикерләрем акылның кыл иләге аша кат-кат үтеп чүп-чардан арына. Ниһаять, каткат иләгәннән соң гына акылга ятышлы, йогышлы саналган уйнәтижәләрем әсәр юллары булып иркен тезеләләр иде. Минем бер чакта да уйлар торгынлыгына әсир төшеп, каләм очы чәйнәп тинтерәп утырганым булмады. Уйлар күңелемнең давыллы дингезендә яралдылар, шунда туып, шунда ныгыдылар, бер чакта да онытылмадылар. И хәтеремнең көчле, әтрафлы чаклары! Күңелемнең күзәнәкләренә килгән фикерләрнең сакчысы аек хәтерем! Мин уемның ял иткәнен, фикер сугыш-көрәшләреннән арынганымны хәтерләмим. Бары тик бер урында—Идел тугайларында балык тотканда—су асты дөньясы белән нәзек жеп аша якыннан аралашканда гына, вакыт-вакыт онытылып, жаным күбәләк булып очканда мин табигатьнең бер кисәкчәсенә әйләнгәли торган идем. Бүтәнчә уй шарламасының тынганы юк, ул гаярь вулкан кратеры сыман кайный, дөберди, ыргыла, вулкан кратерына сыеша алмыйча тышка бәреп чыга. Әсәрләргә әзерлек туктаусыз дәвам итә, яшисең, йөрисең, сак күз һәрчак маңгай астында, дөньяның минутларын жыеп ала, чагыштыра, туплый, барлый, хәтернең вак күзәнәкләре житмәсә, уйларның эресен-вагын сөзә бара, артык-портыклардан арына, яңа тәэсирләргә, туачак уйларга урын әзерли. Кино карыйсың, телевизор алдында утырасың, күз алдында әллә нинди хәлләр туып жимерелә, ә аң, уй, фикер һаман үзенекен үти, ми шарлары алга тәгәрәп үз сюжетыңны алга сөрәләр, уең өзелмәс берничә юнәлештә үзенә юл сала. Тормышта ишеткән мәгънәле вә гыйбрәтле вакыйгаларны хәтер тозагына төшерәсең дә тамга салып аларны алдагы эшләрнең нигезенә чәпеп куясың. Әһә, дисең, бу гыйбрәтле сүз фәлән әсәргә кулай булачак икән... Әһә, дисең, адәмнең бу гамәле төгән әсәрнең агышына ипләнә икән, шуңа ятып тора... Болар асылда әдип акылы белән үзеннән-үзе эшләнә. Әдипнең акылы шундый гажәп,

могҗизалы орган ул, аның хәрәкәттән тукталганы юк, эшли-эшли ул ял итмәскә күнеккән, күзне күрсен өчен көчләргә кирәк булмаган шикелле, акылны да тәртә арасына кертеп чыбыркыларга кирәкми. Әдип акылы туктаусыз шаулап ага торган ут елгасы ул. Күп вакыт күргәннәргә игътибар да итмәгән кебек буласың, үтә-китә, мәгәр әдипләргә генә хас акыл үзенекен эшли: уй-тойгыларны хәрәкәткә китереп, күргәннәрдән иң кыйммәтлесен сайлап ала, беркетә, хәтергә нығыта. Һәм һич көтмәгән мизгелләрдә, эш кызып барганда, иң кирәк чагында гына әдипнең яшерен акылы—хәтер киштәсеннән зарури хәзинәне алып бирә. Әдәбият эше, асылда, яшерен, астагы акыл хәзинәсенә ия булу ул. Әгәр шундый, синең ихтыяр көченә баш бирмичә тупланган яшертен, астагы акыл хәзинән юк икән—син көнлекче! Син колак артын кашып, төчкереп-йөткереп, хатынынны сүгеп, балаларына ырлап илһам көтеп утырасың. «Йа, хода, бир мәдәт!» Ә илһам килми, илһам яшерен, астагы акылның зурлыгыннан, аның заманча тере булуыннан тора. Әдип—тырыш, мәнге ял белмәс бал корты ул. Әдипнең гомере—яз, җәй. Үтә кыска. Шул кыска җәйдә ул кәрәзләренә мул табыш җыеп калырга тиеш. Мин монарчы уйсыз яшәмәдем. Уй белән тотаклашып яшәү әдип өчен иҗади бәхет китерә. Синең астагы яшерен акылың бай икән, син—бәхетле. Син үзең сөйгән, җаныңны җылыткан хезмәт белән гомереңне уздырасың. Син бай икәнсең, уең туктаусыз хәрәкәтләнә дигән сүз. Акылдан тамып ак кәгазьгә төшкән уйны хисләр бизи, аны кирәк төсләргә мана. Әдәбият табигатьнең үзе сыман мең төсле ул, чөнки чын әдип сихерче рәссам.

Ни үкенеч, бәхетле җәй томырылып үтә-китә икән. Иртә-кичләрем хәзер уйсыз уза диярлек. Нәтиҗәле уйларымның тамыры корыды. Уйсыз яшим димим, уйларым бар, тик алар миңа канат куя алмый, уйларым адымымны акрынайталар, гәүдәмне җиргә сөйриләр. Артка борылып-борылып карыйм, күздә кара томан, акылда өермәдәй ШОМ. Ымсынып алга текәләм—анда да кара пәрдә. Пәрдә артында ни, белә алмыйм, сизгерлегем, үткенлегем юк. Аргамакларым, йөгерек чабышкыларым үткән гомер сукмакларында таралып-югалып беттеме?! Уйлар дуамаллыгына ия булмаган адәм уллары ничек яши икән? Уйсызлар буламы? Мин трамвайга кереп басуга кемнедер сайлап алам да, башыннан-аягынача җентекләп, туктый-туктый күзәтәм. Газапланам: ни уйлый бу кеше? Нинди уйлар йөртә аны? Арада угрылар, җан кыючылар, фахишләр, мөртәтләр дә бар ич. Бар гынамы сиңа, андыйлар—бүгенге көн җимешләре, күп алар... Алар күңеленә уй ничек инә? Кем кодрәте белән? Җәйге таңнарда, сандугач моңын тыңлаганда алар нинди уйда булалар? Балаларын ничек, нинди өметләр белән иркәлиләр? Күкрәкләренә җылы диңгез дулкыннары үрмәләгәндә алар нинди уйда коеналар икән? Сөйгәннәренең мәхәббәт җылысын тойганда алар кем булып кала? Табигать биргән рәвешләренә әйләнеп кайта алалармы? Әллә аларның иркәләү алымнары бүтәнчәме? Уйларның чиге, үлчәве юк, ул канатлы тулпар, ул дошманнарын бер селтәнүдә кырып салучы Салсал батыр... Тик угрыга уйның мондый гаҗәеп сыйфатлары кирәкме икән? Табигатьнең адәм уен чикли торган бер-бер хикмәте бардыр. Менә хәзер, гомеремнең салкынаеп калган көзендә, талпынып-талпынып аяк өстендә калырга, тәкмәрләп китмәскә тырышканда тере уй чыганагын каян алыйм? Кемгә таянсыннар уйларым, кемгә?.. Бу максат кынамы?!

*6 июль, Займище.*

Ялгызлык зарыктырып килгән рәхәтлек ул... Бер үк вакытта, ара-тирә, ялгызлык шомлы уйлар үрчегән упкынга тотып чөя! Шөкер, димен, бөтен кеше дә минем хәлдә яшәми, миндәй уйламый, алар офыгын салкын бөҗра буып куймагандыр... Салават күперендә кап-кара, йөнтәс дуга күрмиләрдер алар! Шунысы шөкер! Әле бүгенге ишелеп-

жимерелеп барган җәмгыятьтә бәхет татый торган яшьләр бардыр, кеше күңеленең иң югары эсселеккә ирешеп кайнаган ноктасы—сөю-мәхәббәт бардыр. Шиллер әйткәндәй, каберстанда да өмет шытымнарын абайлый алырлык якты күзләр бетмәгәндер. Хак, сизәм, таныйм бүген, мине биләгән шомлы уйларның дөресләре дә бардыр! Мәсәлән, мин туа-туышка үземне язучы итеп тойдым. Тора-бара үземнең татар әдәбиятында яңа сүз әйтә алырлык олы талант иясе дип исәпләп йөрттем. Хата булган! Рәхмәт тәңрегә, ул миңа талантны кызганмыйча мул итеп каерып биргән. Ләкин минем акыл үсешем заманнан һәрчак артта килде. Нәтиҗәдә, мин: «поздно созрел». Дөньяның дүрт ягын, милләтне, милләт язмышында әдип тоткан урынны бик тә үземчә тар вә ялгыш аңлаганмын. Мин фәкыйрь «милләт бер бөтен ул, ул бердәм булырга тиеш. Тарих милләтне туплый, аның төрледән-төрле катламнарын калыплый, ныгыта», дип инанып яшәдем. Янәсе, милли әдип аның тоткасы, әдип—вәкил, ул милләтне борчыган мәсьәләләргә җавапны тизрәк таба белә, милләттәшләрен үз артыннан өнди, ияртә дә, җитәкли дә... Иң мөһиме: әдип белән милләт арасында берлек, бердәмлек булырга тиеш, янәсе, табигать әдипнең урынын таң яралганнан ук билгеләп куйган. Һәм мин, янәсе, табигать күтәреп алган ир-егет, татарны алга илтүчеләрнең берсе булам... Милләттәшләре ана рәхмәтле булырга тиеш, аны аңларга, ниндидер бер дәрәҗәдә аңа табынырга да бурычлы дип исәпли идем... «Җиз кыңгырау», «Киек каз юлы», «Энгер-менгер», «Югалган көн» пьесаларында мин әнә шул юнәлештәрәк тырышып маташкан идем. Ялгышканмын! Томана зирәк булганмын! Шыр тиле! Кырык ахмак! Алты-биш Сапый икәнмен! Утыз-кырык ел күпме көч, егәр сарыф иткәннән соң гына мин үз хезмәтемнең бәясен аңладым шикелле.

Чын әдип белән милләт арасы бер чакта да тыгыз була алмый. Милләт ул адәмнәр төркеме. Кемнәр генә юк ул төркемдә! Белем җәһәтеннән булсын, тормышта тоткан урыннары югарылыгыннан булсын, байлык-муллык хисабы юнәлешеннән булсын, аерым кешеләр бер-берсеннән бик еракта һәм капма-каршы яссылыкларда гомер кичәләр. Акыл төзелеше ягыннан да ерак алар, уй-фикер сөрелеше җәһәтеннән дә яшәгән саен бер-берләреннән аерыла, читләшә, ерагая баралар. Кешеләр төркемен бер бөтен итеп, илдә куелган законнар гына яшәтә. Ә закон-канунннарга буйсынып кына бер өергә тупланган җан ияләрен ялгыз әдип куенына сендерә вә сыйдыра аламы? Күпме тере зат сыя бер әдип куенына? Фи-и-и... Кыскасы, язучыны үз итеп милләтнең бик санаулы, нәни генә төркеме кабул итә ала. Чикләнгән, тар төркеме генә! Җиде миллион татар дибез... Шул саннан күпме кеше Әмирхан Еникине белә? Нуриханны? Мөхәммәтне? Мине?.. Күпчелек әдәбиятны укымый, ана тәкереп кенә карый, әдип сүзенең зарурлыгын тоймый, ул әдәби сүзгә бөтенләй мохтаҗ түгел! Хәзерге заманда бигрәк тә. Адәмнең сәнгатькә, әдәбиятка булырга тиешле тойгыларын телевидение йомарлап тота, кинотеатрлар үз тирәсенә туплый, хоккей чәкәләшләре йотып ала, футбол бәрелешләре. Тормышны бөтен, үзләрен бәхетле итеп тотар өчен мең-миллионнарга әнә шул кайнар ярышлар, бокс сугышлары, баскетболистларның тиргә чумып ыргылулары тәмам җитә! Америка профессионалларының темпераментлы ярышларын юкка гына күрсәтә башладылармы бездә?.. Өер-өерләр бер-берсенә кызып-кызып ташлана, берәүләр өскә чыга, бүтәннәр аста яньчелеп кала. Тамашачы һәрчак җиңүчеләр ягында, тамаша караганда аның да каны кайнарлана, пары җитмәсә ул таш өстенә бер-ике чәркә аракыны кушып җибәрә... Һәм адәм оҗмах бакчаларына күчә! Нәни генә, орчык башы хәтле генә җаны тантана итә! Футбол, хоккейлар алар тоташ гипноз, өерләрне алдау... Үзем дә зәңгәр экран-тәрәзәчектән сатлык политикларны, буш үгетчеләрне тыңлап утыруга караганда футбол-хоккейларны өстенрәк күрәм. Әдәбият уку—көч, игътибар, дикъкать сорый. Әсәр укыганда кеше акыл көченә генә түгел, физик көч тә сарыф итәргә тиеш... Ә адәмнәрнең көче,

ихтыяры китап укырга калмый, алар аны арзанлы бәрелешләргә бирәбирә сарыф итеп бетерәләр. Күптән түгел генә үзәк гәҗитләрнең берсе Толстой, Тургенев, Гончаров китапларының китапханә киштәләрендә еллар буе укылмыйча әче тузанга манчылып ятуларын әрнеп язып чыккан иде. Безнең китаплар да ята. Ятачак. Егерме ел эчендә басылып чыккан әдәби материалның нибарысы ике проценты гына алдагы елларга уза. Бу саналган, үлчәнгән хакыйкать. Без ыштансыз вә мәгънәсез татарлар гына шул аяусыз канунны санга сукмыйча, еллар өйгән бөтен черек чүпчарны—китапларын исемлектән төшереп калдырмаска маташып, тишек капчыкларыбызны иннән-ингә күчерә-күчерә киләчәккә сөйрибез. Көлке! Сафсата! Әдип, язмыш билгеләгән бер чорда, үзенә замандаш булган милләттәшләренә хуҗа була алмый, алар сирәк-мирәк аралашсалар да бер чакта да бер уйда, бер фикердә була алмыйлар. Әдип нинди бөек булса да үз чордашларын кабул итеп бетерә алмый. Ул нидер чамалый, нидер сизә, тоя, бәлки дөрес фикер йөрткән чаклары да буладыр, әмма әдипне бары тик киләчәк буын вәкилләре генә, анда да тар мохит вәкилләре, белгечләр, намусы саф кала алган әдәбиятчылар гына тулаем аңлый вә аңлата алачак. Киләчәк буын дулкыны әдипне кабул итәме, юкмы, анысы да әлегә табышмак булып кала. Шакир Мөхәммәдов, Мәхмүт Галәүләр әдәбиятыбызда үз эзләрен калдырганнар. Кабул итәме аны бүгенге татар? Ай-һай. Без бик тырышып татарга Галимҗан Ибраһимовны сеңдерергә маташтык, барып чыкмады. Менә Гаяз Исхакый кайтты дип сөенештек. Валлаһи, бөек язучы, олы әдип!» «Зиндан» дип аталган затлы китабы чыкты. Сатылмыйча ята. Нуриханның «Сызгыра торган уклар»ын алалар. «Әле Әмирханның, Вакыйф Нуруллинның томнары да сатылып бетмәгән. Замандашларын да укымый бүген татар», диде үткән пәнҗешәмбедә Фәрваз. Мина нидер ишарәләп, нидер кисәтеп «Томнарың чыкса да сатылмыйча ятыр!» дип тынычландырып, алдан әзерләп куюы булдымы?..

Кайчакта искиткеч хәлләргә юлыгасың. Гап-гади, әмма үтә тормышчан язмышларны, һәркемгә якын, аңлаешлы һәм тәэсирле сюжетка корып төшерелгән 300 серияле «Байлар да җылый икән» исемле ерак Мексика фильмын Казанның һәм авылларның яше-карты, урысы-татары егыла-егыла, җылый-җылый карый... Кытайда да аны миллиард кеше караган диләр... Әгәр Кытайда ике миллиард кеше яшәсә, ике миллиарды да карар иде. Аңласаң аңла, теләсәң ничек кабул ит. Мин әдәбиятыбыз халыкка битараф булган кебек, халык та әдәбиятына битараф дип өзгәләнәм. Ә монда... Шәһәр урамнары тына, адәмнәр Марианна—Луис-Альберто белән очрашу өчен эшләрен ташлап качалар, кибетчеләр «Санитарный час» дигән ялган такта элеп, арткы, аулак бүлмәләрдәге телевизор каршысына тезеләләр. Сүзләр юк, адәмнәрне күз яше берләштерә... Безнең шундый житәкләүче көчебез, иманнарыбызны бер итә торган әсәребез бармы? Татарны мең ел яшәтә алган гигант «Йосыф китабы»ның да бүген кыймммәте, көче, туплау хикмәте сизелми. «Идегәй»не күпме кеше укып кабул итте икән? Бүген дөнья кодрәте футбол кулында. Әлерәк кенә футбол буенча Европа беренчелегенә ярышлар булып узды. Нәни генә Дания футболчылары, крестьян кыяфәтле егетләр, мәшһүр спорт иле алманнарны таптап уздылар. Данияда ул жину сәгатьләрендә ни булганын күз алдына китерү кыен түгел! Милләтне мәгълүм бер дәрәҗәдә атаклы шәхесләр әсир итә ала.

*10 июль 1992 ел, Займище.*

Дачада. Ялгызмын. Усалланган табигать татар жиренә ыжгырып каныкты: кылган хаталарыбыз, ялгыш, гөнаһлы гамәлләребез өчен тәмам үчекте, айлар буе байтак төбәкләрдә тамчы янгыр төшмәде,

кояш «мә, сезгә!» дигәндәй кыздырды, болай да хәсрәткә уралып туган таннарны дәһшәтле мизгелләргә әйләндерде. Арыш башаклары суырылды, өскә үрләргә өметләнгән бодай кырлары пәжеп жиргә инде, күләгә эзләп бер-берсенә йомшак кулларын сузган нәфис борчак тожымнары жинелеп, яргаланган жиргә егылдылар. Бәрәнге сабакларына алка булып асылынган әмрикән коңгызлары тәлгәш-тәлгәш оешып түй итүдән туктамады... Ниһаять, янгыр жиргә түгел, адәм улларының коргаксыган күнелләренә яуды, бар тереклек газ-төтен-сөремнән арынып кин итеп бер сулап куйды. «Татар жиренә бу явыз хикмәтләрне ярсыган урыс жибәрә... Теләделәр: әрмәннәрдә жир тетрәттеләр... Теләделәр: Карабах халыкларына сугыш сулышы өрделәр. Мәскәүнең кулы бөтен дөньяны богауларга барып житә. Менә безне корылык белән жәфалыйлар, былтыр иген-тару өлгергәндә, бәрәнге алганда янгыр болытларын Татарстан күгенә бәйләп куеп жанны талаганнар иде», дип зарлана бер иш халык. Ышанмас та иден, валлаһи! Болытларына гына күтәрелеп кара: жәйге, июль болытларымы болар?! Жәһәннәмнән кубарылган албастылар, иблисләр түгелме әллә?! Кояшның мәрхәмәте беткәнен, озон катлавы юкарып жиргә зәһәр, үтергеч уклар яуганын белә идек инде. Хәзер «кислород ачлыгы» вәгъдә итәләр. Гайрәтле Мәскәү, бик теләсә, безне кислородсыз да калдырыр! Бауның башы Макашов, Жириновскийлар кулында, алар муенга салынган муенчакны тартып кысарга да күп сорамаслар.

Бүген иртәнге биштә торып чыксам, йөзеннән нур качкан Гарәф Шәрәфетдинов каршыма килә. «Афәт бу, чираттагы каргыш!» дип күккә ишарәли. Татар гына шигәя дисәк, аргы башта юл уртасында урыс Трубаевны очраттык. «Афәт бу, ей богу, табигать безгә бәла арты бәласен жибәрә!» дип, ул да сукрана. Кып-кызыл большевик, элеккеге райком секретаре, ГКЧП калкып чыгуга сүзләре тамак төбеннән генә горгылдап чыккан бәндә.

Гарәф белән Гудковлар дачасы артына, Идел ярына барып бастык. Манза-а-ра! Ахырзаман! Килбәтсез иблисләр атланган кара яллы дулкыннар шашып-ыргылып, безнең зәгыйфь аяк очларына килеп житеп, безне упкынга тарталар. Болытлар аръяктагы тәбәшәк тауларга тия-тия шуыша, агач ботакларына уралып ял итә. Баксаң, хәлдән тайган болытлар безнең кечтеки тауларга да төшеп житә ала икән. Әйтәм ич, Идел аръягындагы себерке-урманнарга болытларның иләмсезе, аклы-каралысы уралган. Һәр агач, һәр тырма-ботак кына түгел, жиргә сыпылып яткан үләннәр дә болытларга якорь булганнар. Болытлар аяк астыннан ук шуыша, үрмәли, тәгәри. Жил котсыз! Кай яктан исеп, кая барганын белеп тә булмый. Арган жил, аның агачларга кунып ял итәсе килә, агач ботаклары әз генә тынып торалар да иңнәрен кагып, болытларны өерләп куа башлыйлар. Жир шарында уй-фикер тотынып торырлык нокта калмаган кебек, жир өстендә жилләргә ял бирерлек әмәл дә калмаган. Әллә шуңа алар тыела алмыйча офык артыннан безгә туктаусыз болыт кәрваннарын ташый. Урыс иленә каһәре төшкән ходайның да кодрәте калмадымы әллә? Тьфү, тьфү, кәфер сүз сөйлим түгелме? Сөйләү түгел, акырып-бакырып артың белән киртә жимерсәң дә бүген син каһарман түгел. Киресенчә, табигать котырынганда, чынлап торып дулаганда мактанчык жир уллары бәләкәйләнеп, утырган эт биеклеге генә калалар. Күкрәкләре иске тальян күреге сыман гыжылдый, тезләре күчәре ашалган тәгәрмәч кебек кылдый-былдый килә, йөнтәс борын тишекләреннән һава түгел, зәһәр төтен сызгырып чыга. Язмыш үрмәкүчләре тирәнәйткән маңгай жыерчыкларына ачы тир кереп тула.

Тирләтә дөнья! Сикертә дөнья!

Атна буе дачадагы нәни чоланымда качып ятып (икенче каттагы аулак, жып-жылы бүлмәчегемне әйтәм!) тәүлекләрне кардай йомарлап, артка ыргыта тордым... Эш тотып булмады, иске журналларны актардым, хәтта чишелмәгән кроссвордларны чишәргә маташтым. Искеләр янына яна журналлар өстәлде: «Казан утлары», «Новый мир»ның 6 саннары

килде. Күптәннән болай рәхәт кичереп, һәр юл сызыгыннан мәгънә табып әдәби әсәр укыганым юк иде. «Новый мир»—мин утыз-утыз биш ел дәвамында өйгә алдырып укый торган журналым. Мин гомерем буе бу журналның әдәби әсәрләрен генә түгел, публицистикасын да, фәнни мәкаләләрне дә күздән кичерергә тырыша идем. Ю. Казаков, П. Нилин, Ф. Абрамов (соңгы мәкаләсендә М. Мәһдиев аны хаклы рәвештә элеп алып селкеп салды!), Ал. Солженицын, Влад. Войнович, Ал. Твардовский, Виктор Астафьев, В. Гроссман иҗатлары белән мин беренче чиратта шушы журнал аша таныштым. Хыялым шушы журналда берәр әсәр бастырырлык дәрәҗәгә җитү иде. Әхмәт Ерикәйдән бүтән берәр татар язучысы журналга менеп җитә алдымы икән? Хәтерләмим. «Новый мир» журналы һәрвакыт әдәбиятка кан өсти торды, кыен чакларда да Войновичларга, Синявскийларга көч вә куәт өстәп яшәде. Соңгы вакытларда да анда ара-тирә искиткеч кызыклы мәкаләләр басыла торды. Онытканмын, заманында А. Побожийның «Мертвая дорога» исемле әсәре миңа искиткеч көчле тәэсир ясап, Себер якларында, Салехард-Дабытнанги тирәләрендә йөрткән иде. *(«Новый мир» № 8, 1964 ел.)* Быелгы журналларның 6 санында басылган М. Конисскаяның «Злые годы» дип аталган хатирәләрен гаять зур кызыксыну белән укыдым. Конисская әдип түгел, әмма төрле яктан әзерлекле, яшьтән үк затлы һәм максатлы тәрбия алган, күпне укыган, югары дәрәҗәдәге зыялылар белән тыгыз аралашкан, зыялыларның бәрәкәтле тәрбиясен күргән ханым. Ул һич тарсынмыйча, үзе кичергәннәрне нигез итеп алып, зыялыларны һәм мокытларны янәшә куеп, төрле тарихи шартларда чагыштырып карый һәм мең төрле тормыш мисаллары яктылыгында зыялының (биредә сүз чын зыялы турында гына бара!) мокытлардан һич бәхәссез мең баскычка югары булуын үзе татыган газаплы тормыш күренешләре белән дәлилли ала. Без бит кулда җимерү әләмнәре тотып кына яшәгән түбән затлар. Рәчәйнең шигаре: «Сначала до основания разрушим... а затем!»... Октябрь җимерелүләреннән соң Ленин илдән ике миллион ярым зыялыны чит илләргә сөрә. Кайбер мәгълүматларга караганда, октябрьдән соң 4 миллион кеше илдән качты дигән сүзләр дә бар. Утызынчы, кырыгынчы елларда зыялыларны турапмы турыйлар, кулы ак булганы өчен генә дә күпме зыялыларның башы киселә! Хакимиятнең бөтен дәрәҗәләренә акылсызлар, ярты җүләрләр, кабакбашлы идиотлар килә. Күн ыштан, күн кием кигән, маузер тоткан кемсә, шыр тиле булса да, хакимияткә үрләде. Дурак дуракны ярата. Бу—аксиома. Дурак акыллыны үз түгәрәгенә якын да китерми. Акылсызлар тиз-тиз үз ишләрен табалар һәм кулга-кул тоташалар. Сатлык җаннар, хаиннар, мокытлар (без аларны бөтен дөнья пролетарийлары дип атап берләшергә чакырдык. Канлы октябрь әләме астына басканнарны илдән талап алынган алтын белән күмдек!) егерменче гасырда кешелек дөньясының унай геннарын бетереп, алардан Шариковлар, шакаллар өере тудырды. Һәм шундыйларны кызыл почмакка тәре итеп күтәрдек. Ныклап уйласаң, әнә шул мокытлар сыйныфы вәкилләрен көнгә чыгарган әсәрләр татар әдәбиятында да бардыр. Уйларга кирәк. Ләкин безнең әдәбиятыбызның үзәгендә һәрвакыт без шомарткан, таслаган һәм алга манган Мокытлар һәм Мокытихалар торды. Конисская әдәбият вәкиле түгел дип кабатлап әйтәм, әдәби укуы да булмаган, әмма Ходай аңа күпне ышанып тапшырган һәм ялгышмаган.

Без һәр әсәрдән—зурмы ул, кечкенәме—әдәбият кануннарына буйсынуны таләп итәбез, беренче чиратта ныклы сюжетлы әсәрләргә генә ышаныч белдерәбез. Бу әсәр—әдәбият законнарыннан күрәләтә качып, тормышның эчке-тышкы үз кануннарына буйсынып иҗат ителгән. Мокыт—урысмы ул, немецмы, полякмы—барыбер мокыт, ул надан, надан икән—тупас, тупас икән—явыз. Мокытның талау, үчегү, көчләү, урлашу инстинктлары гына үскән, ул ярым кыргый, ярым дивана рухы белән кол. Зыялылар исә күңел югарылыгын, рухи сафлыкны, җаннарында ныгыган мәрхәмәт-шәфкатьлелекне гадәттән тыш кыен хәлләрдә дә

җуймыйча саклыйлар, аны бикләп, яшереп тотмыйлар, үз ишләренә, үзен кабул иткән, аңлаган затларга мөмкин кадәр яхшылык, игелек күрсәтергә тырышалар. Немецларның, мокыт-фашистларның ниләр кыланганын без хәзер тулаем беләбез инде! Мин Хатыньны да барып карадым. «Мы из огненой деревни» китабы да күңелләргә кереп калган. «Иди и смотри» киносы күренешләре дә күз алдымда. Бөек белорус Василь Быковның повестьларын хәзер дә кат-кат укыйм: бигрәк тә Сотниковны яратам. Хәзер генә аңладым, ул әсәрдә дә тартыш зыялы Сотников белән мокыт Рыбак арасында бара ич! Конисская без монарчы кабул иткән, күнеккән штамплардан читкәрәк китә, ул тасвирлаган немецлар бүтәнчәрәк инде! Дәһшәтле, рәхимсез сугыш мәйданнарында немец милләте вәкилләре төрлечә булганнар. Төрле аң дәрәҗәләре белән килеп кергәннәр һәм бу төрлелек иң авыр, катлаулы чарпалышларда да сакланып калган. Безнең лагерьларда тоткыннар төрле-төрле түгел идемени?.. Мин юкка гына зыялы яһүдиләргә, урысның акыллы вәкилләре архитектор Уклейнга, казачий генерал улы Сидоринга, шагыйрь Сергей Сергеевич Козлов-Куманскийга тартылдыммы? Үземнең егерме биш еллык «юбилеем»ны билгеләгәндә өстәлем тирәсендә шул зыялы затлар һәм немец дустым Һейнц Бем утырмадымы? Немецның зыялы уллары үзләренең кешелек сыйфатларын бер чакта да югалтып бетермәгәннәр. Әйе, явыз диктатор режимы елларында алар сагайганнар, рәхим-шәфкать нурларын алар курка-курка гына күрсәтә торган булганнар. Сталин чорында Рәчәйдәге һәр өч кешенең икесе теге яки бу күләмдә МГБ-КГБ хезмәтләренә ярдәм итеп торганда кешенең эчке дөньясы имгәнмичә калмаган, әлбәттә. Хәрби киемнәргә төренгән зыялы немецлар рәссам, ике нәни бала әнкәсе Конисскаяны бүтәннәрдән бик тиз аерып күргәннәр. Гаилә, балаларга мөнәсәбәт—зыялыларның төп төсмерләреннән берсе ул. Конисская зыялы булуы белән бик күпләрдән аерылып тора һәм аның шушы югары сыйфатын, затлылыгын, немецның затлы офицерлары, солдатлары да бәяли беләләр. Җиңүчеләр, совет солдатлары да бер казанда быгырдаган тары ярмалары түгел автор өчен! Алар арасында да зыялыларны очратырга була. Ләкин күпчелек—соры мокытлар өере. Германиягә барып кергәч, ни генә кыланмый совет солдаты? Көчли, талый, урлый, җимерә. «Җиңүчегә ни кыланса шул килешә!» дигән әхлак кагыйдәсе совет солдатларын боза, алардагы хайвани инстинктларны котырта. Халкыбызга тупаслык, җаһиллек, караклык-бурлык, имансызлык каян килә дип бүген баш ватабыз. Халкыбыздагы тоташ кыргыйлык, имансызлык әнә шул җиңү тантаналарының бер шаукымы түгелмени? Дөрес, без миллионнарның каны, җаны бәрабәренә, кеше гомере белән һич исәпләшеп тормастан дөньядагы афәтләрнең берсен—фашизмны җиңеп чыктык. Ләкин бу җиңүнең икенче бер афәтне—коммунизмны ныгытуына төшенә алмыйча калдык. Җиңгән ил үз гамәлләренә дөрес бәя бирмәсә, бу җиңү халыкларда шапырыну, мактану, талап баю, бүтән милләтләргә нәфрәт хисе тәрбияләсә—моның азагын хәзер әйтү кыен түгел. Илебездәге халыкларның аң дәрәҗәсенә генә карарга кирәк. Ватан сугышында җиңү, шул җиңүнең озакка сузылган эйфориясе Рәчәйнең ялкау акыллы халыкларын һәлакәткә китерде дә инде. Чит ил белгечләре, галимнәр, философлар, әдипләр безнең ил вәкилләре белән очрашканда гел бер сорауны биреп килделәр: «Нигә сез шул кадәрле сугыш белән мавыгасыз? Сугыш беткәнгә фәлән еллар бит инде?» Әйе, Ватан сугышына багышлап төшерелгән кинолардагы сугыш эпизодларында шартлаткыч матдәләр сугышның үзеннән дә күбрәк, артыграк кулланылган икән инде ! Нигә алай?! Без сугыш хәлләренә кайта-кайта ил халыкларының күзен чынлыктан, чынбарлыктан каплап тоттык. Бүтән бер юнәлештә дә алга китә алмаган, икътисады һәлакәткә килеп терәлгән ил бары тик сугыш мактанчыклыгы, шапырынулы буш коткы белән генә яши ала иде. Әгәр инде үзгәрешләр башланып, хакимият башына Горбачев килмәсә, Рәчәй генераллары, канга манчылган маршаллары өченче бөтендөнья сугышын башлаган булалар иде. Бүгенге

ил атом сугышы хәрабәләре арасында пыскып ятачак иде. Рәчәй тарих буена бары тик сугышта җинү рухы белән генә яшәде. Урыс милләтенең дөнья фәненә керткән акыллы өлеше күпме? Ничаклы? Илнең бөтен сәрмиясе, нигездә, сугыш эшен яхшыртуга гына тотыла килде.

Конисская әсәре урыс солдатының кемлеген рәхимсез рәвештә фаш итә. Җинүчеләрне алдан торып кына түгел, арттан да карый, бәяли автор. Безнең илдәге хакимият әнә шул җинүче-мокытлар кулына калганнан бирле илебездә рәт, низам, тәртип, хокук бетте. Ватан сугышы—ике-өч буынга һаваланып яшәргә ярдәм итте, блиндажларда кача-поса партбилет өләшеп, посып яткан полковник Брежневларга күккә сикерергә, алтын таҗлар кияргә булышты. Сугыштан соңгы буын вәкилләре арасында үткәндәге җинүләргә ышыкланып, сугышка аркаланып кемнәр генә рәхәт яшәмәде дә, кемнәр дөнья байлыгын чумырып калмады?! Гомумән, бер чакта да сугышмый тормаган урыс халкына ваемсызлык, гамьсезлек, ялкаулык, эш сөймәү сыйфатлары әнә шул туктаусыз сузылып килгән хәрби җинүләрнең җимеше ул. Шуңа алар Чехословакияга бәреп керде, мадъярларны сындырды, якты дөнья күренмәсен өчен Берлинны таш дивар белән урталайга бүлде, әфганнарны басып алды. Хәзер әнә Курил утраулары хакында тартыш бара. Урыс: «Бирмибез!»—дип акыра. Нигә кирәк безгә ул утраулар? Рәчәйгә җир җитмиме? Җир өчен тартышмый Рәчәй халкы, аның болай да ярты җире тик, буш ята. Рәчәйгә «Җиңдек! Җиңәбез! Бирмибез!» дигән оран кирәк. Рәчәй халкы әнә шул буш оран белән җылынып яши. Монда «киләчәк сугышларга кадәр!» дип тә әйтергә кирәк. Шөкер, дөньяда Америка, Англия, Франция кебек илләр, аларның иманлы, динле, фидакяр лидерлары бар. Шөкер, дөньяда атом бомбалары яралды. Тыйса урысны бары тик шул гына тыячак.

Без татарлар юаш, басылган халык. «Уянабыз, уянабыз, уяндык!» дип, бер гасыр буена үз-үзебезне алдап юанабыз. Татар халкы дөнья йөзендә үз миссиясен үтәп, соңгы сулышын алып ятмыймы? Безнең канда яңарыш геннары беткән булса? Мисаллары әзме әллә? Касыйм, Кострома татарларын хәтергә төшерик. Татарстаннан читтә яшәүче татарларның хәлен анларга теләп, үз төбәгебезгә, Татарстанга игътибар итик. Татарның төп төбәгендә, яхшымы-яманмы җөмһүрият яшәгәндә татарлардан ни калды? «Учак урыннары, учак урыннары... Безгә янарыш килмәсә? Уянмасак?» дигән сорауны куярга куркабыз. Чөнки ана җавап унай булуы да ихтимал. Без, татарлар, күзгегә карарга куркабыз. Авыз кыек булгач, күзгегә үпкәлисе түгел иде дә... нишлисең. Тарихта җинүчеләр яшәгән, җинелгән илләр булган. Шведлар Рәчәйгә кергәннәр дә борылып кайтып киткәннәр. Французларның чигенүен урыс шовинистлары бүген дә көлке итеп телгә ала, киноларда мәсхәрәли. Немецлар да үтеп караган Рәчәй чикләрен, японнар да... Ә урыслар яулап алган җирләреннән бер чакта да кире борылып чыкмаганнар! Максатлары һәрчак ачык булган: «Владикавказ!» дигәннәр алар. «Владивосток!» дип ыргылганнар... Без, татарлар—җинүчеләр табаны астында яшәгән халык. Халыкның бер өлеше ничарадан-бичара урыслашкан, милләтнең аңлы өлеше урыстан мәрхәмәт көтүнең өметсезлеген белеп урыслашкан, чукынган, иманын алыштырган, чит илләргә таралган. Без татардан чыккан мәшһүр урысларны санап мактанабыз. Әгәр ул гали затлар татар булып калса... чукынмасалар, шул дәрәҗәгә ирешә алырлар идеме? Юк, әлбәттә. Бу хакта ике сүз булырга мөмкин дә түгел. Беренчедән, аларның генофондлары үзгәреш кичергән. Үзгәреш, үз чиратында, үсү таләп иткән. Икенчедән, табан астында ыңгырашып яткан татарлар үз араларыннан берәүнең дә котылып чыгуын, күтәрелүен теләмәгәннәр. Калкынырга үзләре дә ирек бирмәгәннәр. Без шуннан бирле вак, көнчел, бәләкәй булып калганбыз. Урысларны сүгеп тел ардырганчы, татарның үзенә хак бәя бирергә кирәк! Казанны урыслар басып алган, имеш! Сафсата! Казанны урысларга татар үзе яулап биргән!

Мондый уй-борчылулар миңа беренче тапкыр гына килми инде, элегрәк тә әйткәнем, язып куйган чакларым булгандыр, әмма Конисская

юлларын укыганда мин өр-янадан шушы уйларга кайттым, элгәрге иманымны ныгыттым. Элек мин белгән кешеләрне Конисская чишендереп каршыма бастырды. Әйе, бу мемуарлар—бәхетсез язмыш дулкыннарында бәхетле була алган, бәхетнен киң төшенчәсен алган хатын язмышы турында. «Страшно в этом сознаться, но после тридцати лет унижения, страха, страха, страха, я, попав под власть немцев, почувствовала себя вдруг свободной. Это звучит неправдоподобно. Ведь я тут была рабой!» Бөтен хикмәт тә шунда ки, бу язмаларны югары күтәргән сәбәп тә шунда, немец коллыгын татыган, Рәчәйнең һәлакәтен күреп торган хатын, хәзерге хәлен, халәтен кат-кат уйлагач, сәер мәгънәле нәтиҗәгә килә: немец коллыгы Рәчәйдәге коллыктан җиңелрәк икән! Йә, кайсыбызның башына бу фикернең килгәне бар? Һәм Конисскаяга бер шиксез ышанасың. Бүген, кичә, өченче көн шикләнгән булыр идек әле. Бүген, конституцион суд большевикларның ерткычлыгын күп санлы документлар, фактлар аша дөньяга белдергән көннәрдә... Юк, юк, рәчәй чушпаннары, мокытларның аны яктырды димим... Кая ул! Лигачев ишеләр, эшлексез Ивашколар һаман тыпырлдый, бәргәләнә. Әле коммунистлар йөзенә ябылган битлекнең чынлап торып алып ташланганы юк... Һәм булыр дамы?... Конисская авыз тутырып әйтеп биргән. Гаепләү сүзләрен элегрәк тә әйткәләгән, ишарәләгән әсәрләр булгалады, ләкин үз язмышыннан чыгып, шундый шомлы нәтиҗә ясаган кеше буларак, ул—беренчедер. Бу әсәр гадәти булмаган төзелеше белән дә мине үзенә тартты. Дөрес, ахырга таба, Конисская янадан большевизм оҗмахына кайтып, үзенә сыеныр почмак эзли башлагач, авторның тавышы үзгәрә, ул кирәккә-кирәкмәскә йөткерә, бугазын чистарта башлый, Рәчәй һавасыннан төенләнгән йодрыкны йотып җибәрә алмый. Кайсы почмак-тандыр ясалмалык, курку, тәлинкә тоту бүселеп чыга. Уйладым, әллә безнең ясалма, ялган тормышны бүтәнчә тасвир итеп тә булмыймы? Без шулкадәр бозылган, имгәтелгән, дөнья кануннарын аяк астына салып изгән мохиттә яшәдек ки, аны әдәбиятта бүгенчә язып та, аңлатып та булмаганмы? Инде көр, нык тавыш белән бердәм рәвештә иң кирәкле җырны башлыйбыз да, кумәкләшеп «бөтен дөнья юксыллары, берләшегез!»не күтәреп алабыз.

Рәхмәтлемен, Конисская мемуарлары күнелемә хис өстәде. Хис янара, өстәлә икән, адәм баласының гомере озая, суына башлаган күнеле дә җылына дигән сүз! Хис чыганаклары саекты, үшәнләндем, тойгылар тупасланды. Кая барыйм?

*12 июль 1992 ел, Займище, иртәнчәк-көндез-кич.*

Бүген 2 август. Дачада ашык-пошыграк, әмма кайнарланып язылган кәгазь битләрен өйдә акка күчереп утырам. Әзгә генә телевизорны тоташтырдым. Барселона хәлләрен—Лилия Нуретдинова, Рамилә Бурангулова, Мәдинә Биктаһироваларның хәлен беләсем килде! Гаҗәп, телевизорда астролог Тамара Глоба игълан итә: «Бүген әдипләр, шагыйрьләр, сәнгать әһелләре өчен «удивительный гармоничный день». Бүген эш башларга да, гаилә корырга да мөмкин икән... Күк җисемнәре, планеталар тыныч рәткә тезелгән. Шунамы, кичә, өченче көн һәм бүген мин тоташтан эш тотам. Шулай барсын кана. Йолдызлар, күкләр ярдәмгә килегез миңа! Тәнрем, шәфкатеңнән ташлама!

Григорий Канович Литвада, Вильнюста яшәүче яһүднең милли әдибе. Дубултыда очрашып, кыска-кыска гына сөйләшкәләп йөреп, шунда танышкан идек. Бераз мактанчык куык, тере саесканнарны телəп очыртучы, һавалы, безнең ише провинциаль кабартмаларга каш җимереп, өстән генә караучы бу тәкәббер кешене мин нигәдер бер күрүдә үз иттем. Яшермим, Григорий Канович үзе дә мине читкә какмады, миңа тартылды. Ике сүзенең берендә ул борчак чәчеп җибәрә иде: «Слезы и молитвы

дураков» исемле романым Англиядә басыла. Болгариядән корректурасын җибәрделәр, ФРГда чыга... фәлән илләрдә...», дигән сүзләрен көлемсерәп кабул иттем, ышанмадым. «Слезы и молитвы дураков», «И нет рабам рая» исемле романнарын язучылар кибетеннән Мәскәүдән соратып алдым һәм гаҗәпләнеп калдым: мин куык диебрәк кабул иткән Канович яһүдиләрнең бөек һәм милли язучысы икән. Бу хакта матбугатта чыгышларым булды инде. Минем коткыга ияреп, улларым да Канович китапларын укып чыктылар, нәтиҗә куанычлы булды, алар да бу яһүди әдипне кабул иттеләр, яраттылар. Шушы җәйдә, дачамда, чолан-кабинетымда мин Кановичның өченче әсәрен—«Козленок за два гроша» романын җентекләп укып чыктым һәм чын мәгънәсендә таң калдым. (Минем бу таң калуым үтә ихлас һәм чын күңелдән озакка булыр!) Мине ике нәрсә искиткеч сокландырды. Кановичның теле. Гади тел белән язмый ул, телен җанландыра, һәр җөмләсен диярлек чагыштырулар, сынландырулар, җанландырулар белән бизи, бизәкли. Романнар дәвамында ничаклы гүзәллеккә төрелгән җөмләләрне укып сөенәсең. Гап-гади тормыш хикмәтләре Канович теленә кергәч җанланалар, бизәкле тел чаралары аша күңелне җылытып йомшарталар. Бүген аннан мең мисал китереп булыр иде, чөнки Канович геройлары таш кисүче Эфраим, сучы Шмуле-Сендер, хәерче Авнер Розентальләр әсәр дәвамында зирәк пәйгамбәрләр, тапкыр философлар, тирән фикерле яһүдиләр булып күңелдәге изге уйларны, яхшы ниятләрне ныгыталар. Югарыда саналган кешеләр, барыннан да бигрәк—чәчрәп торган яһүдиләр, еврей халкының уллары. Бармы яһүд милләте? Аның вәкилләренә нинди төп сыйфатлар хас, дигәндә, әсәрдән бу сорауга тулы җавап алып була. Әсәрдә телгә алынган һәркем, баймы ул, ярлымы, хәерчеме (Канович тиккә генә таш юнучыны, сучыны һәм хәер эстәп көн күрүчене сайлап алмаган!) бер-берсен чиксез нык ярата! Яһүд булганы өчен ярата! Үзе шул милләт булганы өчен милләттәшенә тинсез мәхәббәт саклый. Әйе, әсәрдә Литвадагы «местечковый еврейлар» тормышы үзәккә куела. Әмма автор гасыр башындагы яһүдиләр тормышы материаллары аша персонажларның бер-берсенә ихлас хөрмәтен, мәхәббәтен, самими мөнәсәбәтен белдереп кенә калмый, еврейлар язмышына да, яһүдиләргә бөек мәхәббәтен дә белдерә ала. Бу өч роман дәвамында мине иң нык таң калдырганы шул булды: Канович, автор, үзе дә яһүд милләтен, аның гореф-гадәтләрен, иманын, динен, дин әһелләрен, һәр җан иясен какшамас, бетмәс мәхәббәт белән ярата. Еврейларның язмышы аны борчый, шуңа күрә авторның һәр сүзеннән, ишарә-ымыннан ут бөркелеп тора. Ул яһүдиләрнең тарихына, милләтнең гимнын тудырган бөек шәхесләргә җай чыккан саен мәдхия укый. «Яратам!» дип кычкырмый, шапырынмый, әмма еврейларның билгеле бер чорда, мәгълүм шартларда аларның бер-берсенә ничаклы ярдәмчел икәнлеген сөенә-сөенә яза. Горурлана автор үз милләте вәкилләре белән! Акыллы, хәйләкәр, эшчән, тырыш халык яһүдиләр. Ремаркның «Возлюби ближнего своего», «Ночь в Лиссабоне» романнарында михнәт чигеп йөрүче яһүдиләрнең бер-берсенә тоташкан җылы кулларын укып, күзләремә яшь килгән чаклар бар иде...

Әдәбият, асыл әдәбият, тарихка багана булып басарлык әдәбият—бары тик милли генә була ала. Ходай коллары—адәм балаларын бары тик милли мәйданда гына тулысынча аңлап вә аңлатып була. Толстой, Достоевскийлар... Канович—милли язучы. Ул үз өстенә милләтен дөнья мәйданында күрсәтү бурычын алган. Һәм искиткеч зур уңышка ирешкән. Ә бездә? Татарларда? Үз милләтен яраткан әдипләр бармы? Гомумән, татар прозасы вәкилләре татар дигән халык вәкилләрен кайсы чорда, нинди итеп тарихта беркетеп куйганнар? Әдәбиятта беркетеп куелган тарихны бозу мөмкин түгел инде. Алдагы көннәрдә яңа шәхесләр Толстойны, Достоевскийны ничаклы бозарга тырышсалар да, алар беркетеп киткән урыс—урыс булып калачак инде. Урыс халкының вәкилләре булып Карамазовлар, Мармеладовлар, Смердяковлар, Мышкиннар, Каренниннар,

Вронскийлар тезелеп торачак. Безнең татарда татарны яраткан әдипләр бармы? Татарда нинди милли сыйфатларны әсәрләрендә тапканнар алар? Татар язмышын нинди мисаллар белән ачарга тырышканнар? Мин быел җәй, үткәндәге прозачыларның иҗатына кайтып карый башладым. Тар, кара милләтчелекне кан дошманы санаган бөек психолог Фатих Әмирхан. Татарны чиксез сөйгән, үз татарын Европа кешесе итеп күрергә ашкынган остаз. Сәмигулла абзыйлардан, Фәтхулла хәзрәтләрдән көлеп, аларны чеметеп-чеметеп алса да Фатих Әмирхан татарны бөтен барлыгы белән яраткан... Мәҗит Гафури белгән татар дөньясы бөтенләй башка. «Тормыш баскычлары»ндагы шәкерт-күсәкләр... «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек»тәге бичара, мескен, уйсыз, надан, көчсез татарлар. Күр инде ул «Ярлылар яки өйдәш хатын»ны! Бер-берсенә ярдәм кулы сузарга әзер татарлар да нинди мескен, зәгыйфь... Гомумән, Уфага килгән Тукайны өенә чакырып чәй дә эчерә алмаган «Габделмәҗит мин бичара» татарда бары тик мескенлек, аңгыралык, көчсезлек кенә күргән. Үзенчә, Гафури да татарны яраткандыр, мәгәр аның язмалары татарга рух өстәмәгән, әдип һәрдаим татарның баш түбәсенә зәгыйфь йодрыгы белән төеп, көчсез иреннәре белән аны җәһәннәмгә этәргән. «Татарлар... сез бетәсез... Галимҗан Ибраһимов социалистлар, большевиклар арасында татар революционерларын эзләгән. Татар тормышын каһәрләгән, татарның бары тик кара якларын гына күргән. Революцион идеяләр татарны яктылыкка илтә дип балаларча ышанган. «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрен генә кара. Булгандыр, яшәгәндер андый татарлар да. Ләкин тарих алдында татар хатын-кызларының язмышын шул кадәр чикләнгән, кара, каһәрләнгән итеп күрсәтү белән Г. Ибраһимов та татарны артка сөйрәгән. Шәриф Камалның беренче бөек хикәяләре. Илләреннән язмыш сөргән «Акчарлаклар»... «Уяну»дагы Муса да урыс шәһәрендә иза чигә бит... Читтә, эт кулында... Социалистик реализм кысасына ирекле баштан кергәнче Шәриф Камал гүзәл бер язучыбыз булган, татар өчен янып-көйгән... Менә безнең дөньяга Гаяз Исхакыйны кайтарырга тырышабыз. Исхакыйның татарга мөнәсәбәте бөтенләй бүтән! «Тормышмыни бу?» дигән шактый төшенке әсәрендә дә татарлар чын кешеләр рәвешендә тасвирлана. «Ничто человеческое им не чуждо!»

Югарыда саналган, егерменче гасыр дәвамында татар милләтенең, татар халкының яшәү рәвешен, иманын, характерын, гүзәл вә кара якларын үз әсәрләре аша тарихка беркетеп калдырган шәхесләрнең татарга мөнәсәбәтләре төрле-төрле булган. Бусы бәхәссез. Шул мисаллардан чыгып әдипләрнең үзләренең кемлеген дә, татар халкының яшәү рәвешен дә ачарга тырышып бер нәрсә язарга кыҗрап йөрим. Вакыт җиткерә алсам, Ходай гомерне җәлләмәсә, шәт-иншалла язып та куярмын әле.

Соңгы елларда мин Ә. Еники, М. Мәһдиевләр иҗатын күтәреп, шәхес буларак аларны гел мактап киләм. Мин аларның иҗатын шулай бөек дип санаганга түгел ул. Әмирхан абыйның да, Мәһдиевнең дә уртакул әсәрләре бар, алар да безнең барыбыз кебек үк куркак, сак язучылар. Алар инде милләт дип тә язгы ташкынга күкрәкләре белән атыла торган җаннар түгел. Тәмле ашап, рәхәт кичереп, кәеф-сафада яшәгән, шулай яшәү рәвешен генә кабул иткән барчуклар. (Үзем дә алардан калышмыйм!) Ләкин бер нәрсә бар: Әмирхан Еники дә, Мөхәммәт Мәһдиев тә татарның милли әдипләре, алар татарны ярата алалар, аның җанын аңлыйлар. Менә нәрсә кыйммәт минем өчен! Шул сыйфатлары белән алар үз чордашларыннан нык аерылып торалар. Әгәр Еники белән Мәһдиевтә чорның социаль каршылыкларын аңлау, шул каршылыклар чарпалышында үз төп урыннарын билгеләү көче дә булса, алар татар тормышын дөнья мәйданына чыгарырлык әсәрләр яза алыр иде. Һичшиксез. Без, татарлар, дөнья биеклегендә уйлау сәләтеннән мәхрүм ителгән, ә әдип милләтен ташлап узып бер чакта да ерак китә алмый! Татарлык-тарлык безнең дә итәкне тота.

Канович философ. «Дети—эти не близкие. Дети—это далекие» дип

кистереп куя. Мең хаклы яһүд! Мин «дети близкие!» дип алданып, юанып киләчәгемне якты итеп күрергә тырышкан мәлдә... «Варенье—вино бедных, медовый напиток горемык», ди ул. Мин Эрих Мария Ремаркка табынган кебек үк Канович та аны үз итә шикелле. Урыны-урыны белән әсәр дәвамында Ремарк аһәңнәре янгырап әсәрне тагын да биеккәрәк менгерә. «Так пусть же бесконечно длится эта ночь! Старик Эфраим загоняет в нее своих детей, как загоняет в хлев». Вакыт турында аның үз фәлсәфи фикере, сокландыргыч дәрәҗәдә туры, усал хөкем чыгара Канович Вакыт төшенчәсенә. «Время! Что такое время,—думает Эфраим,—Паучая сеть, раскинутая над нами. Меняются пауки, мухи, а сеть висит и висит. Как только из нас высасывают кровь, в нее попадают другие, и так изо дня в день из века в век, и нет метлы, чтобы вымести из нашего дома, из нашего сердца». Ремарк аһәңнәре, Хемингуэй тавышлары. Канович аша да мин үземнең бөек пәйгамбәрләрем белән очрашам.

«Козленок за два гроша» шушы трилогиянең соңгы китабы булса кирәк. Алдагы ике китапта очраган шәхесләр ара-тирә монда да чагылып, вакыйгаларга катнашып китәләр. Һәр өч китапның яһүдиләр язмышына караган нигезле чыгармалары бар. Гыйбрәт! Яһүдне изәләр, кысалар, ул һәр тарихи чордан тагын да дус, тату, көчле, искиткеч ярдәмчел һәм хәйләкәр булып чыга. Нигә без андый түгел?! Без һаман кысыла, тарая, кечерәя барабыз. Һәм татар инде тарихта үз язмышын хәл иткән дип раслауга кем каршы чыга ала?!

Эфраимның үз балаларына булган тинсез мәхәббәте мине тетрәтте. Войничның «Кигәвен» романында Монтанелли атаның Артурга ташкын мәхәббәтен белдергән вәгазен искә төшердем. Аталарның балага мәхәббәте (әгәр ул чын булса!) чиксез кайнар, утлы бөек һәм мәңгелек була. Эфраимның балаларга белдергән эчке уйлары дәреслекләргә керерлек бөек юллар...

Канович белән без хатлар да алыштык. Мин ана да китабымны җибәрдем... Ни аяныч, минем уртакул әсәрләр, уртакул тәрҗемәчеләр аша үтеп чыгып, аның күнелендә теләктәшлек уятмадылар шикелле. Дөрес, Литвада хәлләр үзгәрде, азатлык көрәше башланды. Канович СССР Югары Советы депутаты итеп сайланды. Азатлык хәрәкәтендә яһүдиләрнең нииндидер җәмгыятен оештырып җибәргәч, аның сәяси хәле авырайган икән, дигән хәбәрләр килеп ирешге. Хат язарга кыҗрап йөрим. Израильгә китте, дигән хәбәрләр дә йөрде...

*8 август 1992 ел, Казан, иртә.*

6-7 августларда Кызыл Байракта булдык, шунда куен дәфтәренә сыздин-быздин теркәп куйган юлларымны акка күчерим әле...

«Кич. Кызыл Байрактагы өебез каршысында кирпечләргә куелган бүрәнә башы өстендә утырам. Агач куелыкларыннан курка-курка гына сузылган, текә-текә ярлы тирән чокырларда оеган кара күләгәләр кинәт куердылар—көннең көн буена татар җиренә нур олаулары койган кояш, агач очларына кунып хәл җыеп торды да, соңгы кат күзен кысты, югалды. Соңгы рәхәт яктылыкны әрсез эңгер йотып та өлгермәде, Идел аръягында елт итеп өлгер бер ут кабынды, көндезге окопларына кереп поскан, монарчы барлыклары беленмәгән ут күзләрне котырта башлады. Утлар башта өзек-өзек, аерым-аерым кабындылар да Идел агымына ияреп, тоташ чылбыр булып сузылдылар. Күз иярми нур агышына! Нур таулары Идел суына да төшеп ятты! Сихри төсләргә кереп елтырарга, җемелдәргә тотынды. Талгын җил гел-гел юнәлешен үзгәртә, юлына туры килгән үлән-чәчкәләрнең җәйге кичтә генә уяна торган исләрен өерләп китерә, эңгернең дә төсе үзгәрә, ул хәзер карасу түгел, сыек шәмәхә, зәңгәр... Мин сызлау теземне язып аякларымны сузып җибәрәм. Күз текәмдә беренче кабынган житез ут малае! Тоташ чылбырда, бәлки, мин аны

бутаганмындыр да, әмма барыбер, ул, дип уйлау рәхәт. Ул барысыннан да яктырак яна кебек!»

Кызыл Байрак! Кызыл Байрак!

Исеме гайрәтне чигерә торган, Идел ягасында сирәк очрый торган татар төбәге. Уч төбе хәтле генә авыл. Утызынчы еллар башында татарларның затлы елга ярларыннан, урманлы-сулы төбәкләрдән кайчандыр куылуын искә алып, шул тарихи явызлыкны «төзәтергә теләп», социалистик илдә милли мәсьәләне хәл иткән булып кыланып, татар гаиләләрен жыештырып, янача—советча авылларга нигез салганнар. Яна килгән татарлар бабаларының хәтерен саклап, шунда төпләнгәннәр. Әле дә урам-тыкрыкларда ак яулыкларын жилкәгә жәеп жибәргән татар апалары күренгәли, кәжә-сарыкларга татарча эндәшәләр. Шөкер, песиләр, казүрдәкләр, бүрекле ата казлар туган телләрен онытмаганнар икән. Займище белән ике ара еракмыни, илле чакрымнан артмыйдыр, кошлар дөньясында зур аерма. Монда кошлар да татарча сайрый. Әллә мина гына шулай тоеламы? Улым Мансур шушы тирәдәге дачаларнын берсенә кунакка килеп, Идел ягасындагы татар авылына гашыйк булып кайтты да: «Минем татарлар арасында яшисем килә, дача жирен алсам, шуннан гына алам!» диде. «Мондый авылны тагын каян табасын?!» Мансур кистереп куйды-куюын. Тик безгә кем аннан жир бирә? Мин совхоз директоры, райком секретарьлары янына юргалый башладым. Ел дәвамында йөреп, байтак йөз суымны түккәч, хужалык мәсьәләләрендә һәрдаим ярдәмен кызганмаган Мансур Хәсәнов булышлыгы белән без аннан зур гына кишәрлек жир алдык. Унбиш сутыйдан да артыграк ахрысы. Эшне печеп тоттык, Мансур гадәттән тыш житез булды, бабалары, кардәшләре дә булышты, ике ел дигәндә без авылча гади булса да нарат бүрәнәләрдән йорт, мунча, бетон шакмаклардан гараж житкереп куйдык та, жиребезнең читчитләрен тимер челтәр койма белән ураттык. Азнакайдан Ирек кода да ярдәмгә килде, материалларның кайберләрен ул да табышты. Мансур эшне башлап йөрде, жәйләрен шунда—елга ярында, урман-сулар арасында үткәрермен, шәһәр тузаны-газыннан, агулы сулардан котылып торырмын дип планлаштырды. Мәгәр язмаган икән! Дөнья кинәт кырыкка төрләнде, тормыш шартлары сынды, бөгелде, без көткән «якты киләчәк» томанлы, болганчык көннәр китерде, бүген ышанып уйлаган, иртәгәгә һич ярамас булды. Мансур былтыр-быел дачага эз дә басмады. Төзелеш тукталды. Гараж түбәсе бетон плиталар белән генә ябылган килеш тора, су үткәрә, сумала йөгертәсе бар. Мунча миче ялгыш чыгарылган. Эш муеннан!.. Һәммәсенә букча-букча акча кирәк! Ә ачка безнең гаиләгә саркып кына тама. «Әти, син гомерен буе жәйләрне Займищеда үткәрден, ваемын булмады. Әгәр мин синең сыман жәйләрне шәһәрдән китеп торсам, гаиләм белән ачка үләчәкмен», диде Мансур. Алай ук та булмас иде, әмма-ләкин Мансур хаклы: хәзер гомуми хәрәкәттән, төп агымнан чак кына читтәрәк калсан да—беттен дигән сүз. Менә без, бер төркем әдипләр, сугылып арбадан төшеп калдык та, хәзер кигиләре сынган тәгәрмәч булып юл тузанында аунап ятабыз. Пенсиям әдәм көлкесе, бүтәнчә бер жәһәттән акча керми... Янача эш башларга көч-куәт тә, гайрәт тә калмады. Әйе, жыелышып, күнелле итеп, бәйрәмнәр белән тормышны бизәп, Займищеда жәйләрне үткәрә идек. Урман, Идел, утраулар безнеке иде! Ай-һай, безнең балалар андый тормышны күрә алырмы, белмим. Булмастыр, ошамаган.

Шулай итеп, Кызыл Байракта үз жиребез, үз йортыбыз булды. Озак куанычкамы? Әйтүе кыен. Яна жиребезне аерата Нәкыя яратты. Һәм эшнең авырлыгы тулысынча анын жилкәсенә төште. Ниләр генә эшләмәде ул шушы ике елда! Чирәм күтәрде, жир казыды, жилкәсенә күтәреп су, тирес ташыды. Яшелчәләрне утыртты, йомшартты, утады, барса бер секунд ял итмәде. Теше-тырнагы белән жиргә ябышып ятты. Былтыр шактый уныш алган идек: помидор, борыч, бәрәнге, суган һәйбәт кенә уныш бирде. Сусызлык интектерә. Быел, шөкер, Нәкыя киявебез

Илгизәрне алып барып, электр кертteләр. Яренгә, боерган булса, сулы да булырбыз. Быел да помидор, кыяр, суган, кишер, чөгендер уңды дияргә ярый. Әгәр су да житешле булса... мондый кояшлы кишәрлектә әллә никадәр яшелчә аласы икәнбез. Агачлар да өметле калкына, Нәкыя бер машина тирес тә китерткән. Яшьләр килеп, шашлык куырып, шәрап эчеп, кәеф-сафа корып китә. Мин барып кояшта арка җылытам, төрле уйларга чумган булып, арлы-бирле йөрим. Нәкыя күтәрелеп тә карамый, жир йомшарта, утый, чиләкләп су ташый. Эшләмәгән эше юк... Менә хәзер дә ул Галияне, аның иптәш кызы Дашаны ияртеп, авылга сөткүкәй эзләп чыгып китте. Ә мин өй саклаган булып, уй йомгагын урыйурый, әле монсуланып, әле дәртләнеп-кабынып, ишеккә аркамны терәп, ялкау симертеп утырам.

Кызыл Байрак Иделнең текә ярлы уң кул ягында. Моннан ерак та түгел, моннан да текәрәк ярлар өстендә Тәтеш шәһәре ята. Истәлекле урын! Авыр истәлекләр оясы! Сугышның иң авыр бер елында, кырык дүрттә, тугызынчы классны тәмамлаган егет-малайларны бөтен Татарстаннан жыеп китереп, Тәтештә хәрби өйрәнүләр лагере оештырганнар иде. Зәй мәктәпләреннән килеп, без дә ай буена шунда марш атлап йөрдек. И-и, заманалар! Аякта чабата, өстә ямаулы пинжәк кисәге, аркада биштәрле капчык. Сугыш еллары йортыннан күпме ризык алып чыгып була? Бәрәңге кабыгы, алабута оны кушып пешерелгән кайрак ипи, икеөч баш суган булгандыр инде... Беренче мәртәбә пароходка утырып, коерыкта мичкәләр арасында аунап, бик озаклап Тәтешкә бардык. Биекбиек баскычлардан өскә менә башлагач кына ач булуыбызны, хәлсезлегебезне сиздек. Менә-менә тез буыннарыбыз калмады. Бардык, урнаштык, взводларга бүлделәр һәм юкә урманына алып киттеләр. Юкәләрдән матрас үрдек... Парталарны чыгарып ташлап, идәнгә юкә маталар җәйдек... Иртәләрен аларны урап өеп куябыз. Без солдат хезмәтеннән кайтуга алар кыза, яна. Искә чыдап булмый. Баш астына юк, өскә ябынырга бирмиләр. Ашау... чөгендер суы! Бер учма юаның бәясе егерме сум! Акчалылар шуны ашый. Җирле халык имән чикләвеге дәүлеге бәрәңгене китереп сата, иң байлар аны әз-әзләп алалар да ашыйлар. Күпләп алсаң, саклар урын юк. Ач малайларда үткенлек тә, кыюлык та җитәрлек. Урлатмасаң, талап алалар. Дүрт меңнән артык үсмер арасында кемнәр генә юк... Иң беренче булып взвод командирыбыз Закалкинның (хәтеремдә шулай сакланган, батальон командирының фамилиясе Кикодзе иде, лагерь начальнигы майор Кострач!) ботинка үкчәсе каерылып чыкты. Ике-өч көн табанны юкә белән урап-бәйләп йөрсә дә ботинка тәмам «протестка кергән» икән. Нишләргә? «Солдат хезмәтеннән», ач корсакка мылтык түтәсе терәп «право—коли!»ларга буйсынып ыргылып йөрүдән тәмам туйган мин бичара—(төннәрен бигрәк читен, күзем сукыр-букыр, күзлек юк, берни күрмим!) үзем чабата ясап бирәм!» дип командирга белдердем. Маталар үргәндә Тәтеш тирәсендәге юкә чаукалыкларын күргән идем. Шуннан китте! Бүтәннәр мылтык асып, ах-ух килеп, «Священная война»га бугаз киереп «марш-марш» атлап чыгып киттеләр... Ә мин ялгыз башым, бәләкәй балта, пәке тотып урманга юнәләм. Юкәне туныйм, кабыгын каезлыйм, киндерә ишәм. Һәммәсе әзер булгач, кайтам да эшкә тотынам. Имән ботагыннан шөшле ясадым, төрле размерда калыплар, һәммәсе әзер булды. Командир хәзер өр-яңа чабаталарын шыгырдатып марш атлый, ул арада взводның яртысы яланаякка калды. Янгырлы ел, дөпдөп басарга тиешле солдат колонналары яланаяк калгач бик мәзәк икән. Янгырның да төрлесе бар, салкыны дигәндәй, иртәләрен суык, күбәүләр төчкерә, йөткерә башлады. Чөгендер суы ныгыта алмаган эч китә! Сыйныф бүлмәләренең бер-икесен «эч белән җәфаланучыларга» бирделәр. Рәтләр күзгә күренеп кимеде. Безнең взвод исә шактый тернәкләнеп китте: көненә өч пар чабатаны тукып кына торам. Өйдә өйрәнелгән, күнегелгән норма! Чабатага чират яралды. «Миңа да миңа» дип ялыналар малайлар. Миңа әз булса да ризык тама: «сиңа!» икән, әйдә капчыгынны селке,

ипи кыерчыгы бир, бәрәнгеннән әз-мәз өлеш чыгар. Киндерә ишәргә, юкә төшерергә бер егетне бирделәр, хәзер чаукалыкка икәү барып йөрибез. Эш көйләнде. Шулай, чабатага атланып, хәрби өйрәнүләр лагереннән бик һәйбәт характеристка алып кайтып киттем. Уку башланырга күп калмаган иде инде. Тәтеш баскычлары шактый вакытларга каләр куркыныч төшләр булып гел йөдәтте. Иртән уяталар да, ярдан бәреп чыккан чишмәләргә юынырга алып төшеп китәләр. Чабатачы булсаң да иртәнге җәфалардан котылмак юк. Төшүен төшәсең, менү мең газап. Ачлык тауны, текә баскычларны яратмый шул. Өченче ел Минскида Влад. Львович Меховта кунакта ятабыз. Сүз иярә сүз чыкты, яшьтәшләр, ул да Тәтеш шулпасын чөмергән икән. Лаеш шулпасыннан бер дә ким булмаган.

Сонра, үземнең көндәлек гадәти халәтемә кайткач, уйларым белән бүгенге көннең кара дөреслегенә уралгач, уйны бүлеп шаккатып утырдым: нилектән җаныма шул тиклем рәхәт булды әле?! Балаларча гади чагыштырулар, Идел ярларын сокланып күзәтүләр, истәлекләр белән мавыгулар, наян вә гөнаһсызрак фикерләр күңелемә ничек кайтты, кем аларны тартып китерде, ни? Кайтыр сукмаклары имгәнеп бетмәгәнмени хатирәләрнең? Җаныма кем жылылык койды? Тынлыкмы? Йортыбызның юан, жылы бүрәнәләреме? Ишегалдыбыздагы йөз-мең ганжә-гөлләрнең сабыр, тыйнак гүзәллегеме? Сизелер-сизелмәс аккан куе хуш исләр жанымны өскә, күптән менә алмаган югарыга алып менеп киттеләрме? Гайрәтем тәмам чиккән дөньяның әле мине тыныч сыендырыр почмагы шушымы?..

Повторяется шопот,
Повторяем следы.
Никого еще опыт
Не спасал от беды.

«Театральная жизнь» журналларының Мансур дачага китереп ташлаган номерларын укып утырам. Мансурга багышланган хәбәрләр күзгә чалына, минем Тинчурин театрында куелган әкәмәткә дә кагылып үткәннәр. Дамир Сиражиев куйган иде! Салават театрында барган «Баласын жуйган болан эзеннән»гә дә киң генә тукталып үткәннәр. Журналда Мейерхольдка багышланган кадерле истәлекләр бар. Мансур журналлардан котылырга ниятләгән, битләрен ертып мич кабызган, тышлыкларга кайнар чәйнек куеп торган... Кызганыч! Кызыклы елларда чыккан саннар—бер заман, картайгач, үзең яшәгән заманда үз бәяңне югалткач, юаныр өчен үткәннәргә борылып карап, үткәннәр белән чикләнеп яшәгәндә бу журналларның да кирәге чыгып куяр әле. Мин Займищеда үткәндәге журналларны укып, үткән заман һавасын сулап, әллә кайчан аккан-беткән суларда коенып, бүгенгеләрдән качарга, онытылырга, күмелергә вә күренмәскә тырышмыйммыни?

Журналның 1990 ел, 23 санын актарып утырам, Василий Аксеновның «В поисках грустного беби» исемле мәкаләсендә Анатолий Антохин исеме күренеп калды да йотылып укырга тотындым. Бар иде Антохинның гөрләп-шаулап урыс драматургиясенә кергән чаклары! Алек. Арбузов шәкерте! Беренче пьесалары телгә керде, «Театр»да басылды. Без аның белән ике-өч ел рәттән Ялтада драматургларның Бөтенсоюз семинарларында катнаштык. Бергә төшкән Ялта фотоларында ул да бар. Шыксыз, төссез дип әйтерлек арык, сары егет иде. Без артык дәрәҗәдә якын идек дип расларга базмыйм, әмма ул семинарларның берсендә, Мәскәүгә кайтып китер алдыннан миңа болай диде: «Аяз, сине талант диләр. Бик күпләргә пьесаларын укып, ярдәм дә итәсең, беләм. Минем тәмамланмаган бер киносценарием бар. Укып кара әле шуны. Бәлки, бер-бер житди сүз әйтерсең?» Мин шактый кызыксынып һәм мавыгып сценарийны укып чыктым. Егет белән кыз проект институты кысасыннан чыгып баралар. Халык ташкыны аларны ияртеп, ары сугып, бире кагып метрога сөйрәп алып керә. Тагын вагонга кертеп ыргыта. Егет белән кыз кара-каршы

баскан хәлдә, хәрәкәт давылы эчендә калалар. Һәм бер-берсенең тиешле урыннарына терәлеп баралар. Егет табигый рәвештә «уяна» һәм кызны да «уята». Тагын кысан ишек, тагын халык ыргымнары, метро егет белән кызны урамга чыгарып чөя. Алар бер-берсенә тагылган хәлдә әле шактый баралар, шундый ук кысан троллейбуска кереп, кара-каршы кысылышып тагын бер-берсен «уяталар». Нәтиҗәдә, икәү генә калганда да бер-берсеннән аерыла алмыйлар, аллы-артлы барганда да бер-берсенең кайнар чакырышын сизеп, кызның фатирына кайтып керәләр. Кергән шәпкә чишенәләр, кием-салымнарын як-якка чөя-чөя караватка барып җитәләр һәм бу очрашу ашыгыч, әмма татлы... белән тәмамлана. Егет кызны, кыз егетне бик ошата, алар бер-берсе белән якын араларда очрашырга чынчыннан вәгъдәләшеп саубуллашалар. Һәм китә шуннан!.. Егет кызны, кыз егетне эзәрлекли, телефоннан очрашу хакында сүз куешалар, вакыт, урын билгелиләр. Ләкин шашкын тормыш дулкыннары аларны хәзер төрле тарафларга чөя, яшьләр авыр мәшәкатьле, аяусыз тормыш белән яшиләр, вәгъдәләр үтәлми, сүзләр кибәк урынына җилгә оча. Нәтиҗәдә, аларның беренче татлы якынлыгы егет белән кызның бердәнбер бәхетле кавышуы булып кала...

Сценарийны ошаттым. Сүзләрем дә бар иде, кинәшләр дә бирдем, уртак сүзләребез, фикерләребез булды, без бер-беребезгә дустанә хөрмәтле булып аерылыштык...

Өметле яшь урыс драматургын язучылар союзына һәм партиягә алалар. Сынау өчен туристик виза белән бүләклиләр. Юлдашларын күзәтергә боерып, Италиягә озаталар. Анатолийның Италиядә калуы заманында зур сенсация булган иде. Калды егет. Китәр алдыннан гына Татьяна Борисовна Агапова аңа кыз бүләк иткән иде! Шуларны ташлады, чит илдә император Хайле Селлассиенең күп санлы принцессаларының берсенә өйләнде, принцесса үз чиратында тагын бер принцессаны тудырды.. Татьяна Борисовнаны да чакырып алды егет, аны Аляскадагы мәшһүр бала тудыру йортына патронаж сестра итеп эшкә урнаштырды...

Вас. Аксенов Анатолийның Америка шәһәре Норвичта Гогольнен «Өйләнү» әсәре буенча куелган спектакле турында җинел юмор аша, яратып, тәэсоратларын язган. Норвичтагы фестиваль унае белән Аксенов тагын бер затлы кешенең исемен теркәгән. Норвичтагы урыс мәктәбенең почетлы директоры Николай Всеволодович Первушин дигән кеше икән. Монреаль университетының профессоры, Казан университеты шәкерте! Аксенов Казаннан, Первушин шуннан!.. Яһүд белән урыс. Нигә татарлар Рәчәй тәбесеннән ычкынып китә алмадылар да, нигә чит илләрдә яхшы ат яуламадылар?! Ичмасам бер әдип, бер язучы кысан елларда башын горур тотып чит ил кочагына ташланмады?! Нигә бездән диссидентлар чыкмады?! Эш үткәч юрган астыннан чыккан йодрыкларын селкүчеләр бар ул барын! Мәхмүт Хөсәенне дә кысканнар янәсе, фәлән фәләнеч тә диссидент булган икән! Әллә кемнәр торгынлык елларында чикләүләрдән газап чиккән имеш! Во-истину Әбрар Кәримуллин хаклы: «Ул татармы? Эшләмичә генә баюны, укымыйча гына мулла булуны көтеп ята торган халык!» дия торган иде элек. Хәзер үзгәргәндер... Рыцарь, академик булып сайлангач, исеме дан, кесәсе акча белән күмелгәч, ул да әз-мәз бүтәнчәрәк сөйли башлагандыр. Бигрәк тә татар турында бүтәнчә фикер йөртәдер...

Генрих Белль: «Писатели в странах тоталитарного режима обращаются к вере, писатели в демократических странах—к безбожию».

... Тукай урамындагы стадионны әйбер-кара базарына бирделәр. Керү хакы 5 тәнкә. Кызыксынып, бер көнне Нәкыя белән шунда киттек. Халык—судагы балык! Кым-кырыч! Мәхшәр. Ерып йөргеле түгел. Без татарны элек-электән мактап, мактанып вә шапырынып киләбез. «Без, имеш, сәүдәгә маһир халык». Татарлар чит илләрдә дә сәүдә белән алдыралар, мисалга фин татарларын китерәләр. Сүз шуңа барып җитә ки, сәүдәгәрлек безнең төп милли сыйфатыбыз, дип тә җибәрәбез! Шунын

өстенә мин соңгы вакытларда болай дип тә уйлый башладым: «Менә инициативалы, юл ярып йөрүчеләр заманы—капитализм килә. Без, йоклаган үшән татарлар, юл яручылар янәшәсендә ни хәлдә калырбыз? Һаман шул химия заводларында череп, таш базларында үпкә чире алып, урам себереп, дегет кайнатып яшәргә калырбызмы?» Базар аша кемнең кем икәнен белеп тә була!.. Базарга керсәм—сәүдә, мал Вьетнам кәтәнәләре кулында! Сатучыларның 90 проценты шулар. Таслап капчык-бүктәрләргә чалбар, куртка, юбкалар тутырганнар да базарны биләгәннәр. Рәтен белә алар! Кыз-кыркын, егет-жилән иреннәрен кыймылдатып кына үзара сүз алышалар, сакауланып кына урыс сүзләрен дә сиптерәләр. Башын сатуга гына салган адәмгә күп сүз кирәкме әллә? Сатып алучылар урыс, татар; меңлекләр, биш меңлекләр кулдан кулга гына йөри. Татар акчасы капчыгы белән вьетнамнар кулына күчә. Инде базар бетте дигән урында, тузан арасында адашкан кәжә бәрәне сыман татар һөнәрмәннәре утыра. Жиргә үз хезмәтләренен жимешен таратып ташлаганнар. Халык алар ягына әйләнеп тә карамый. Чәчрәп торган чит ил товарлары янында аларның кул жимешләре мескен, бичара, ятим булып калган. Фәкыйрьлеге кычкырып торган товар белән ярышырлык татарларны күрмәдем әлегә. Татарның тир түгеп тапкан акчасы бүген жөмһүрияттә калмый, аның икътисадын ныгытырга ярдәм итә алмый. Яшелчә-жимеш базарларында Урта Азия сәүдәгәрләре татар акчасын таласа, әйбер-кара базарына вьетнамнар баш! Мостаев барып Вьетнамнан 60 мең бәндә ияртеп кайтканнан бирле Казанның төсе үзгәрде... талый безне әнә шул кәтәнәләр, үкертеп, көпә-көндез талый. Һәм... талаячак та! Без шулар өеренә каршы торырлык житез жаннарны тудыра алмый торган алашалар көтүе ләбаса! Ай-һай, юл ярып алга чыккан адәмнәрнен кадере арткан чагында без тамак төбе белән генә сөйләшә алырбызмы берәр заман, юкмы?..

Әле Кызыл Байракта уйлап йөрим. Әйе, татар башына бәла-казалар күп килгән. Бәла-каза килмәгән, имгәтелмәгән милләт бармы соң ул? Берәүләр бәла-казалар кырыннан көчәеп, берләшеп, ныгып чыкканнар. Әйтик, немецлар. Икенче бөтендөнья сугышы азагында немец иле, немец жире исән-аман котылып чыктымы әллә? Берлиннары көлгә әйләнде, күп калалары хәрабәдәй калды. Ә хәзер алар нинди хәлдә? Үз халыкларына ожмах ясадылар да, бөтен ил ярлыларын сыендырып, туйдырып торалар. Юньсез славян калдыклары югославлар бер-берсен суеп бетергәндә 200 мең ач тәреләре Германиягә барып сыенды. Албаннар Германиягә кача, Рәчәйдән дә барып житәләр. Кем-кем, безнең малайлар да соңгы ике-өч ел эчендә немецлардан күргән шәфкать-мәрхәмәт белән хәлләнделәр. Милләтнен берләшүе иң зур сүзләрнең берсе. Татарлар—тар, таркау халык дип мең кәррә кабатладым. Татарлар—бер-берсен сөйми торган, берсенең хәсрәтен икенчесе күрми торган, ишетми торган сукыр вә саңгырау да халык.

*19 август 1992 ел, Казан, иртә.*

Әлерәк кенә Займищедан кайтып кердек. 9 нчы трамвай тулып килде, төшүчеләр ишеккә сыймыйлар. Карыйбыз: һәркемнең кулында дөя дәүмәләге ике капчык, аркаларына буйвол зурлыгы капчык асканнар. Пешкән ипи алып китәләр. Ваклап-ваклап, Татарстанны, татарны талыйлар... Ачу да килә, капчык күтәреп ишәккә әйләнгән крестьяннарны да кызганасың... Илдә иген юк диярлек, бөтен төбәкләргә ачлык яный. Ә бездә әлегә Ходага шөкер!.. Берзаман коралланып, машиналарга төялеп төрле яклардан безгә дошман баскыннары бәреп кермәсме? Бүгеннән Татарстан ипекәйгә карточка кертергә тиеш! Бүгеннән! Югыйсә, безне талап, үзебезне мәсхәрә итеп, аска салып изәчәкләр.

Муллиле авылыннан кайткандагы бер күзәтүем:

Иртәнге поезд. Каршымдагы кыз йокыдан торды да чәч тарый. Йөзе ягымлы, чибәр диярлек. Маңгае ачык. Иптәш кызы белән сузып, кыланыбрак сөйләшә. Чәче артык калын түгел, юка, тере вә эре бөртекле. Бер уйлаганда артык мәшәкать тудырмый торган чәч. Ал да күз ачып йомганчы тарап куй! Ә кыз өчен чәч тарау үзе бер театр. Уйнап рәхәтләнә кызыкай! Театрны башта үзе өчен куя. Тамашачы да була калса, ул аны дүрт-биш пәрдәгә суза. Чәч бөртекләрен саран чишмә агымы кебек бер унайга озаклап агызып тора. Ага чәч, ага, кинәт кенә бүтән якка борыла, кыз учына ятып озак кына ял итә. Кыз күзләрен көзгедән алмый, аңа шушы әле уңга, әле сулга борылган саргылт агымны күзәтеп тору рәхәт ахрысы. Тик кенә ятканда әлләни елкылдамаган учмалар хәрәкәттә күпергәндәй булалар, матурланалар. Минем аны бик кызыксынып күзәткәнне кыз сизә—белдерми. Шушы спектакль дәвамында безнең күз карашларыбыз ник бер очрашсын! Бу уен, бер кешелек шушы моноспектакль бары минем өчен генә уйналадыр дип уйламадым, мин карт, нигә минем өчен кыланып маташсын кыз, болар һәммәсе дә аның үз рәхәте, үз кәефе өчен генә! Аның муенын боргалавы, кашларының әле өскә сикереп менеп китүләре, ике ирен кысасыннан елан угыдай чәчрәп чыккан тел очының җитезлеге бу җанлы тамашаның монарчы күп тапкырлар уйналуын тагын бер тапкыр раслады. Менә чәч унга-сулга агуыннан туктады, кыз аны уңгарак каерып күтәрде дә баш түбәсен алкалап бәйләде. Шуннан соң гына күз аскарак, әүвәл муенына, аннан да түбәнгә төшеп китте. Муены арык кызның, дәртсез, көчсез муен. Түбәнгә таба да мактанырлыгы юк икән кызыкайның, имиләренең кечкенә вә ләпшердек икәнен ул күлмәк кинлеге белән яшерергә тырышкан. Күлмәге төрле тарафка җәелеп салынган, көткән урыннарда нәни таучыклар юк. Кыз тагын чәченә кайтты, бик озаклап көзгедән тырышып нидер эзләде, иң ахырда чәч учмасы очына ике җирдән ике йомшак божра кигертте...

Поездан төштек. Мин Галияне җитәкләп әкрен атлыйм, Нәкыя алданрак бара. Шулай да баягы кызларны куып җиттек һәм мин кызның ике аягы да гарип булуын, аяк табаннарын асфальтта ышкып атлавын күреп алдым. Ул җинел атларга тырыша, алга омтылып очып китәргә җыенгандай талпынып карый... Күнелем кызгану хисләре белән уалып китте. Аның бердәнбер байлыгы, матурлыгы, куанычы әнә шул чәчләре икән.

Уң кул ягымда бөкре ир утыра. Урта яшьләрдә, киң чыгынкы маңгайлы, зур күзләре эчкә батып кергән, кыска җинле буй-буй күлмәк кигән. Күрәм, беләгендәге кан тамырлары чамасыз юан, калын. Гомере буе гариплегенә рәнҗеп, язмышын каһәрләп яшәгән бу кешегә йөрәге түзсен өчен кан тамырларын шулай юан ясаганмы Хода хәзрәтләре?

*21 август 1992 ел, Казан, төштән соң.*

Соңгы көннәрдә сул күзем ныграк, уңы әзрәк авыртып гел җөдәтте. Кичә көне буе бимазалады. Күз тирәмә кул тидерә алмыйм—авырта. Сызлавы да борчудан ашмый, әллә ничек, бер дә мондый хәлне күргәнем, болай хафаланганым юк иде. Уйлыйм, Ремаркның дүрт томы кулга кергәч, романнарын ашыгып-сөенеп тагын бер кат йөгереп уздым. Вак хәрефле китаплар минем өчен түгел, әллә шул уку артыкка киттеме? Китап укыйсың, гәҗитләрне сөреп чыгасың, машинкада утырасың, житмәсә, телевизорсыз да яшәп булмый—гадәт! Тәмәкене ташладым да—котылдым, боларыннан котылмак юк. Тиешле-тиешсез чакта хәмере дә эчелде, анысы да чал чәчле бабайга файдага түгел. Кичә сәгать уннарда йокларга яттым һәм бик тиз генә уяндым да. Сәбәп нәрсәдә? Бер җирем дә авыртмый кебек, ә йокы качкан! Күз тирәләре

мәзәк кенә сызлаштырып, кычытып тора. Шуна уянганмындыр, дип юанып, әзрәк әйле-шәйле яткач, йокы тагын үзенә алган. Инде ныгытып уяндым. Сул күзем кычытып сызлый һәм ни гаҗәп, сызлавы нindидер тамырлар буйлап яңакларыма тарала, баш түбәсенә менеп китә. Күнелгә физик шом килде. Торып карадым: сәгать ике. Әйләнгәлим, боргаланам, гәүдәне куяр җайлы урын таба алмыйм. Күз чокырыннан чыккан авырту бөтен тәнгә тарала, хәлем юк. Ун-унбиш минут шулай җанып тырпылдап яттым микән, сизәм, йөрәк тәбегә эләккән коштай тырпылдый, көчсез, авырту да бар! Торып утырдым, бастым, сизәм, йөрәк каядыр агып китте, гәүдә дә йөзә! Баш әйләнә, авыз эче корыды, кул, аяк бармаклары, теге чакта 1962 нче елның 23 февралендә, Мәскәүдә кичергән хәлдәге төсле межер-межер киләләр!.. Кинәт курку килде: беттем! Кайчан исә шушы кара сүз аңга килергә тиеш бит, соңгы вакытта әҗәл белән очрашу турында кирәгеннән артык еш уйлыйм, шул сәгать җитте микән, дим! Нәкыяне уяттым: «Карчык, ахры китәргә чамалыйм, йөрәгемә мин хуҗа түгел, аны әҗәл тарткаламыйммы?» Ул курыкты, минем курку арта төште. Тел әйләнми диярлек, гәүдәм юеш мунчала кабыгыдай ишелергә тора. Нәкыя мине диванга илтеп яткырды да күршедәге врач Леняларга чабып кереп китте. Ятам—кәеф начар!.. Леня бик тиз керде. Басымны үлчәде: 180/100. Гомеремдә дә болай булганым юк иде. Тамыр тибеше: 100. «Көчле тахикардия!» ди Леня. Ятам аңгы-миңге, «Инсультмы, инфарктмы?» «Ашыгыч ярдәм чакырырга кирәк», диде Леня. Көне буе эшләмәгән телефоным соң гына телгә килгән иде, рәхмәт! Өйдәге вактөяк дарулар белән әҗәлне алдарга маташып карыйбыз. Юк, кәеф сөремле, томанлы. Җаным куркак! Ниһаять, килделәр. Врач, яшь кенә егет: тыңлады, санады. Шул ук: 180/100. Тамыр йөзне бәрә. Менә сина тимерче, чүки генә!

Соңгы вакытларда әҗәл, китү турында еш уйланам, дидем. Сәбәпсез түгел! Быел безнен яшьтәшләр кырыла. Чордашлар күпләп-күпләп үлә тора. 65 белән барам ич! Күп тә түгел... әмма кичерешләрне уйласаң!

Машинада калган кардиологны алып менделәр, озаклап тыңладылар, яздылар, саран сүзләр белән генә аңлашып алдылар: хәвеф-хәтәр юк, дигән кебегрәк нәтиҗә ясадылар һәм уң якка каратып яткырдылар да арт шәрифкә ике мул дарулы укол кададылар. Дару ампулалары әнә хәзер дә өелеп ята. «Күзне каратырга кирәк», дип саубуллаштылар, бүтән тәкъдимнәре булмады да шикелле...

Тынычландым. Нәкыя бичара таннан Кызыл Байракка чыгып чапкан, уяндым, дару тулган арт өстендәге чокыр каткан, аяк атлар-атламас, алай да күнелем тыныч. Соңгы айларда минем басымым югары булгандыр дип беләм. Еш-еш күз чокырым, бигрәк тә сулы, авырткалап куя иде. Авыр әйбер күтәрсәм дә, чамадан арттырып хәмер капсам да, иртәләрен күзем сызлаштыра иде. Басым уйнаганнан булган ич ул! Менә җүләр мин, шыр тиле!..

Иртәнге чәйдән соң Газиз Кашапов турында кичә күчергән мәкаләмне Әхәт Гаффарга илтеп бирдем. Төштән соң түзмәдем, дустым, сердәшем машинкам янына утырдым. Сул күз мәзәкләнеп тора, иртәгә окулистка бармый булмас. Көн ямьсез, офыкка кара-кучкыл сусыл болытлар салынган, бөркү. Әллә басым уйный, әллә көннең кара япанчасы күңелне болгата, утырам шунда ишелгән чүмәлә булып. Язасы сүзләр, эшлисе эшләр бихисап иде, белмим, бу күз афәте шул басымнан гынамы? Әллә мине бүтән сынаулар да көтәме? Уйласаң исең китәрлек, уйламыйча яшәргә күнекмәгәнмен.

Караңгы күк сау чакта да изә иде, тәнгә чир, җанга шик-шөбһәләр хуҗа булганда күк әйләнеп карамаслык җәһәннәмгә әйләнә, тәрәзәгә тып-тып төшкән яңгыр тамчылары да мылтык көпшәсеннән чыккан ядрә кебек. Нәкыяне көтеп утырам. Ул бичара шашып-йөгереп бакчада кайнашадыр инде. Чыланып кайтырмы, белмим.

Бала чакта ишеткән сүз: «Ярар... ярыгын түбән карар!»

*22 август 1992 ел, Казан, көпә-көндез.*

Баулыда Кәшифә апасында татарча кунак булырга ярата Вахит Юныс. Чираттагы утырмадан соң Мәскәүгә кайтышлый шәһри Казанда тукталып, өч көн дәвамында очрашып яшәдек. Бөтендөнья татарлары конгрессына килгәч, ул предпринимательләр, бизнес кешеләре белән генә аралашырга тырышып йөреп, безнең эше салам сыйракларга игътибар җитмәгән иде. Соңгы вакытларда безнең аралар ерагаебрак киткән иде бугай. Мәскәүдә яшәп, чит илләрдә эшләп, хезмәт хакын доллар белән алып күнеккән Вахит. Уллары бер авыз сүз татарча белми. Улы яһүдәгә өйләнеп, нәбәрәләре Тимур белән Антон Мәскәүнең ООН мәктәбендә укыйлар. Безнең тормыш шартлары, яшәү мөмкинлекләре нык аерылган мәлдә уртак сүзләр кимегән иде. Бу юлы Казанда нык тукталуының сәбәбе берничә булып чыкты: Вахит Язучылар берлегенә керергә омтыла—димәк, мин кирәк. Ләкин Вахит бер йомыш өчен генә акча түгеп, вакыт әрәм итеп йөри торган егет түгел. Ул һәрдаим эшлекле кеше, эшем иясе, малтабар. Ул берничә максатны берләштерә ала... Шулай булып чыкты да... Татарстан җөмһүрияте чит илләр белән бәйләнешләр урнаштырырга кулай булган дәүләт департаменты оештырып йөри. Аның мәгълүм кешеләре дә бар, алар кайдадыр үз тавышларын әлегә ишеттермичә генә эшләп тә яталар икән. Вахит шуларны эзләп тапкан. Ике улы да дипломат, үзе дә әле сукмактан сөрлеккән зат түгел, үз көчендә, әгәр җай булса әнә шул, яңа туып килгән департаментта эш күрсәтергә һәм, билгеле инде, әз-мәз акча эшләп алырга да нияте юк түгел. Эзләп тапкан, кергән, сөйләшкән, үзеннән һәм улларыннан хезмәт тәкъдим иткән һәм юл башын төйнәп куйган. Гомумән, картлыкта Татарстанга тартыласы килмиме ул егетнең? Бик мөмкин. Бирсен Ходай!

*24 август 1992 ел, Казан, иртә.*

«Парниковый эффект» диләр. Көннәр әз генә җылынды исә, шушы сүзне тәкърарлыйлар. Җир шарына уралып галәм киңлегендә йөзүче бушлыкта хәзер нинди «эффектлар» өстенлек итәдер, әйтә алмыйм, бер нәрсә мәгълүм: бүген урамга салкын җил хуҗа. Плащ-куртка кигән тәннәр дә бөкрәеп тыр-пыр йөгерәләр. Гәүдәләр җинел! Чөнки корсаклар буш. Туя ашау күпләргә насыйп түгел. Бер карасаң, акча янчыклары буазланган адәмнәргә рәхәт тормыш килде. Базар-кибетләрдә җаның ни теләсә шул бар! Эчемлекнең нинди кирәк тә, ризыкның кайсы төре генә юк?! Кызганыч, баскычның астагы араталары барыбер өскә менә алмады. Элек кем түрә булса, бүген дә шул бай. Бүген дә шундыйлар эшне эредән йөртә. Без, элгәре күкрәк көче белән уртада ныгырга тырышып яшәгән кешеләр, аскы аратадагы бичаралардан да түбәнгәрәк, тормышның караңгы упкынына мәтәлеп төштек! Бүгенге хәлдә бездән дә явыз язмышлы кеше юктыр.

Кичә Рәчәйдә ничә еллар каһәрләнгән мәшһүр «Рембо» кинофильмының 1, 2 кисәкләрен карадым. Безнең агач телләр раслаганча бер дә кан коярга өндәүче, шәфкатьсезлек, мәрхәмәтсезлекне данлаучы фильмнар түгел! Киресенчә, явызлыкка нәфрәт укый торган фикерләр сендерелә. Һич ялыкмыйча, ике серия тәмамланганчы телевизор каршысында утырдым. Икенче фильмда ахырга таба ур-ра-патриотизм мотивлары чагылып киткәләсә дә, асылда сүз яхшылык турында бара. Хәрби чиновниклар Рембоны явыз язмыш дулкынына ташлап калдырсалар да, ул, мең үлемне җиңеп, үзен һәлакәткә дучар иткән бәндәдән үч ала! Белмим, аның гамәлләрендә нинди зыян күргәннәрдер безнең коммунистөрәкләр, мин аның һәр гамәленә кушылып—теләктәшлек күрсәтеп утырдым. Рембо кебек тәвәккәллек, кыюлык, чаялык миндә булсын иде

әле бүген! Юлыма аркылы төшкән кусәкләрне урталайга сындырыр идем!.. Хәер, Рембо андый-мондый вак-төяк дошманнар белән көрәшеп дан казанмый шул, аның дошманнары да дошман! Беренче фильмдагы полицейскийны гына ал! Көчле, мәкерле, явыз җан ул. Без большевиклар тәбесендә яшәгән затлар кешеләрнең явызлыгындагы бөеклеген дә күрергә һәм күрсәтергә өйрәнмәгән шул!

*27 август 1992 ел, Казан, иртәнчәк.*

Горбачев бичәсе белән Испаниядә король гаиләсенең кунагы булып рәхәт чигеп ята икән... Бәхетле кеше! Ә илдә кырылыш, кан коюлар тукталмый. Әле бер чите кителә илнең, әле икенчесе. Гөрҗиләрне аңлы, алдынгы милләт дип йөрсәм, кулларына мылтык тоткач алар да гадәти ерткычка әйләнәләр икән. Шулай, коммунистик система тарафыннан өстен итеп тәрбияләнгән, «союзная республика» дип расланып бозылган кайбер милләтләр икенче сорт халыкларга ирек бирергә җыенмыйлар! Кыра гөрҗиләр абхазларны, кыра! Үзбәк каракалпакларны кыскан шикелле үк... Гөрҗиләр осетиннарның канын эчеп кенә туймаганнар икән, хәзер абхазларга ябырылдылар. Ничек инде урыс шовинисты Татарстанның хокуклы булуына ризалашсын! Югославия җир шарының тагын бер имгәге булды. Аларга ни җитмәгән инде? Нигә таралдылар? Ник бер-берсен кыралар? Славяннар шул, коммунистик ил дәвамчылары!.. Бүгенге көнгә халык колагына сүзе җитә торган лидерлары юк, вак-төяк өшегән кикрикле күркәләр дулкын өстендәге күбек булып калкалар да җыйнаулашып ярны җимерергә тотыналар. Җимерә алмыйлар, озак вакытлар кага-кага яр балчыгын ашыйлар.

*14 октябрь 1992 ел, Переделкино*

Идөнья! И бәхет! И куаныч! «Татарстан» поезды белән Рәсәй мәркәзенә килеп төштем. Вахит Юныс белән Ямиль Мостафин каршыладылар. Җәһәт кенә Литфондка барып беренче срогыма бушлай путевкамны алдым, тиз-тиз көйләп тә бирделәр. Элеккеге гадәтләр дә калган икән әле юмарт Литфондта! Ямиль ниндидер җыелышка кереп калды, Вахит мине Переделкинога илтә китте. Көн кояшлы, салкынча, төнлә ун-унбер градус салкын булган. Яфракларын коярга өлгермәгән авыр санлы имәннәр, яфракларының кадерен белеп, санап кына җил иркенә биреп, кышка әзерләнгән өрәңгеләр салкынның кинәтлегеннән чарасыз калып акаешып утыралар. Ә без, тирә-яктагы алтынсу хозурлыкка карап та өлгерә алмыйча, тәгәрибез дә тәгәрибез. Вахит белән сөйләшер сүзләр дә әлләни күп түгел, ул ниндидер чит ил ширкәтләренә: американнарга, итальяннарга ялланган да «бу араларда алар белән эш йөртәчәкмен, бүтәнчә вакыт та табылмас, шәт», дип искәртә. Мин көлемсерәп күтәреп алам: «Казан ярлы-ябагае Аяз белән вакыт үткәрүгә караганда, чит ил эшкуарлары белән эш йөртү кулайрак, әлбәттә. Аңлыйм!» Уйлаганымның чынын әйтәм. Вахит та яшерми: «Аяз белән очрашу рухым өчен кирәк булса, чит ил вәкилләре белән эш йөртү кесәм өчен кирәк!» Ә хәзерге каралы чуар заманда рухи азыкка караганда, кесә ягын кайгырту беренче сызыкка чыкканда... Вахит белән аралашу еш булмас шикелле. Бу фикер белән икебез дә килешәбез. Бирсен Ходай! Зарыктырган ялгызлыктан аермасын, мәүләм! Язарга җыенган үткәннәремә бер башым гына кайтып килим. Бары тик гадел хакыйкатьне ачып салам дигәндә дә күңел коесының алтмыш еллык чоңгылыннан чыгармаслык уйларым бар ләбаса! Адәм баласы соңгы чиктә, Ходай илчеләре — фәрештәләр каршысына, иң каты белгеч хөкемдарлар алдында да капчыгын төбенәчә селкеп бетерә алмый ич! Моны аңлаган фәрештәләр дә адәминен бугазына пычак салмыйлар шикелле...

И дөнья! И бәхет! И куаныч! Килеп житеп, гомеремнен купмедер давыллы вә моңсу мизгелләрен үзенә сеңдергән 114 нче бүлмәгә кереп урнашып, сөенечләремне үстерер өчен тәмле чәй эчеп, Нәкыя юл ризыгы итеп тыккан куян ботын кимереп, минем таныш тәрәзәмә текәлгән карлы жиргә, мине сагынган каен-наратларга карап, рәхәтләнеп куанып, гәүдәмә дәрт, рухыма көч, уйларыма канат өстәгәч, әз генә черем итеп алдым, аска төштем. Тактадагы исемлеккә күз йөртеп чыктым... «Спичечный состав» нык ук үзгәргән икән. Рәттән ят исемнәр, күпчелек исемнәр янына «США» дип теркәгәннәр. Мәскәү, Петербург яһүдләренә ярдәмгә «әмрикәннәр» дә килеп урнашкан икән, Переделкинога да чит илдән яу төшкән. Ни кыла алар монда, ни майтара? Элек килгәннәрдә халыкның яртыдан артыгы йә чын таныш, йә күз күнеккән танышлар була торган иде. Бу юлы... Наркирьер монда да, Илья Кашафетдин, Зәй тумасы монда икән. Тагын бер-ике таныш исем. Аннары рәт-рәт ятлар китә. Көндезге аштa Илья белән кыска гына күрештек, шыр исерек, теле сүзенә бәйләнми, кыргыйдай, телсездәй мөгери Илья. Татарның талантлары әнә шундый танымаслык, кул бирмәслек кыргыйга әйләнә инде безнең кабахәт заманда!

Әүвәле монда кавказлылар, Урта Азия тумалары мыжлап ята иде, хәзер карыйм: ник берәвесе булсын! Сугышып кан коеп яталар инде, бүтәнчә түгел, югыйсә алар һәр чак бай булдылар, айга биш меңне чыгарып салу аларга язгы ташуга йомычка ыргыту белән бер. Переделкинога китмәскә береккән Рауль Мирхәйдәр дә юк, бүтән әрсез алабайлар да юк, гомумән, язучылар бармы икән әле монда? Әллә заман кандалалары—эшмәкәрләр, алыпсатарлар, ил талаучылар кереп тулганмы? Ничек миңа ике айга урын биргәннәр алар? Былтыр Наташага бүләк итеп әз-мәз карабодай ярмасы алып килгән идем, шуның кодрәтеме?.. Шул булса кирәк. Шунысы да булса кирәк, Литфондта Наташа үзе күренмәде, мине Галина Андреевна Фашмакова ханым кабул итте, документларны шул хәстәрләде.

Ниһаять, берәүнен дә кәефен сакламыйча түшәм аклыгыннан уйлар чүпләп ятыр чаклар житте. Бисмилла!

*15 октябрь, иртәнчәк.*

Былтыр ай башында килеп, 26 нчы ноябрьдә 114 нче бүлмә белән саубуллашканмын икән. Ризван Хәмид белән бергә булдык, житәкләшеп кайтып та киттек.

*16 октябрь, 1992 ел, көпә-көндез.*

Шөкер Ходама: бүген жин сызганып эшкә тотындым. Алтынчы биткә чыккач тыелдым: сүзләрнең кадере бетә башлады... Кәгазь почкагына: «Үз-үземне ашап ятам» дип язып куйганмын. Эш кәгазьләре арасында шул почкак та ияреп килгән. Быелгы яшәү рәвешемне кыска гына бер гыйбарәдә тулысынча бәяләгәнмен.

*20 октябрь 1992 ел*

Көз кыш белән тартыша. Бүген иртә таңнан тыгыз буран уйный. Эре-эре кар бөртекләренә уралып сап-сары соңгы яфраклар оча. Юеш, дым, жил... Таңнан баш иңкеп, чуалып торды. Шөкер, тәвәккәлләп һавага чыккан идем, йөреп киттем, адымнарым жинел. Көлеп жибәрдем: сәламәтмен! Ә син, төпле күк, болытларың, яфрак бураннарың белән мине озак изә алмассың!.. Карыйм, яшь агачлар жилдә бер-берсенә якынаеп үбешәләр, ә карт агачлар юеш себерке ботаклары

белән бер-берсен кыйныйлар, чәбәклиләр. Аяусыз дөнья! Юан-юан имәннәр, калын-калын ботаклы наратлар «җирне ычкындырмыйча без тотып торабыз» дигән сыман, сукмак читләрендә тамырларын таратып, мин чалны озатып калалар.

*22 октябрь 1992 ел.*

Бүген әтинең вафаты көне. Үлгәненә 17 ел узган икән! Сөякләре таралып ятадыр, мәрхүмнең! Җаны кайларда гизә икән? Тынычмы? Безгә рәнҗемиме?.. Белгән юк. Алланың барлыгын акыл белән генә таныганнарга теге дөнья, каберстан белән чынлап торып аралашу юк. Ходайга яшьтән үк, күңелең саф чактан табынып калмасаң, яшәү шактый кыен. «Күңелнең яфрак чагында» Ходай күңелгә инәргә тиеш. Әти мулла баласы, әни—үтә дини гаиләдә туып-үскән, нигә алар Ходай тарафына бер дә борылып карамадылар икән?.. Икесе дә. Бәлки күңелләренең яшерен түрләрендә Аллага табыну да булгандыр, безгә аны-моны сиздермәделәр. Утызынчы еллардагы дингә, дини китапларга барган аяусыз һөҗүм аларны шулай сындырганмы? Белмим... Балалар алдында ул хакта сөйләшкәннәрен дә хәтерләмим. Әти мәрхүм шактый куркак кеше иде, әни исә тыңлаучан, бер чакта да ир сүзеннән чыкмый торган гадел хатын иде. Рәнҗеп ятма, әти! Быел синең кабереңә кайтып та булмады! Дөнья басты, алган акчаларны сануйсың да юлга чыгарга шүрләп торасың. Акча—явыз көч, безне җинә, бөгә, туный...

Кичә Ринат Мөхәммәдиев килеп, мине Гариф Ахуновның улы Рәшит эшли торган фирманың «штаб-квартирасына» алып китте. Рәшит хәзер тигез җирдә олы түмгәк. Рәшит хәзер нindидер, без аңламый торган фирманың Президенты. «Штаб квартираны» үзләре салганнар, үз зәвыкларына җайлап бизәгәннәр. Менә ничек яши икән миллионерлар! Бинаны алтмыш ир-егет саклый икән, һәрберсенең айлыгы 25 мең сум! Шуннан чыгып Президентның керемен чамалап була. Табынга «Метакса» дигән грек коньягы менде, биш йолдызлы, виски «Блэк энд уайт», «Столичная» аракысы. «Кока-кола», виски кушып эчә торган әллә ниләр... Төрле-төрле итләр, «салями», яшелчә-җимешләр. Саплы бәләкәй чүмечләрдә каймакта пешкән гөмбәне бик яратып икешәр чүмеч состык... Бинаның бизәлешенә таң калып өстә, бельэтажда утырдык. Рәшит бармагын гына кыймылдатып куя, аш ташучылар йөгереп кенә йөриләр. Байлык, житешлек, дөнья рәхәте бөтен яктан бәреп тора. Шунда ук сауна! Кереп юынып чык! Аша, эч—«берәү бер тиен акча түләтми». Җәннәт!

Рәшитнең «Мерседес»ы белән озатып куйдылар, беренче яртыда гына кайттым. Бер литрлы гаҗәеп матур эшләнгән «Метакса» коньягы күчтәнәч булып кайтты.

Гариф, Ринат Төркиягә очрашу-киңәшмәгә баралар икән. Зөфәр Фәтхетдинов та бара дигән сүз колагыма чалынды. Уфадан Динис Бүләков килеп җитте, аның белән ике-өч сүз алышып, берәр чәркә коньяк эчеп кенә калдык... Нәҗип: «Аяз югалды...» дип зарлана икән, вакыт табып аңа берәр хат язганда начар булмас иде...

Юк шул безләрдә берләшмәк,
Юк бергә-бергә гөрләшмәк,
Бер җан, бер тән булып, һәр неч-
кә серне бергә серләшмәк.
Үтте бездән инде дөнья.
Җан бирәбез галәл-гомья:
Дөнья! Актык сүзне тыңла:
Бәхил бул бездән, и дөнья!

Равил Бохараев чит илдә латин хәрефләре белән Идел буе татар

шагыйрьләренең дини-фәлсәфи шигырьләрен туплап чыгарган. Тукайның аянычлы «Азан» шигырен дә керткән. Дөрес күчердемме икән? Тукайны татарның бүгенге биеклегеннән торып укыдым да имәнеп киттем. Китапның исеме «Азан». Борынгы вә гасыр башындагы шагыйрьләрне гаскәр итеп тезеп, Р. Бохарай татарны кая дәшә? Ишетелерме аның тавышы? Тукайның «Туган тел»ен инглизчәгә тәрҗемә итеп бастырган.

*25 октябрь 1992 ел.*

Белгәннәр, бөек бабаларыбыз Тукай, Ф. Әмирхан, Гаяз Исхакыйлар татарның милли характерын әллә кайчан, гасыр башында ук бәяләп калдырганнар. Шунысы гаҗәп вә кызганыч, алар биргән акылны без кабул итә алмаганбыз, үзгәрмәгәнбез, үзгәрергә йөз дә тотмаганбыз. Күр инде Тукайны! Переделкино болдырына чыгып тупланган төрле илләрдән, бер-береннән ерак төбәкләрдән җыелган яһүдләрнең «бергә-бергә гөрләшүләрен», «һәр нечкә серне бергә серләшүләрен» күзәтеп, сокланып торган диярсең. Тора-бара без хәзер монда өч татар булдык, Ташкенттан Рауль Мирхәйдәров килде. Беренче күрешүдә үк Татарстанны, Казан татарларын хурларга, хакәрәтләргә , аңа яман ялалар өяргә тотынды. «Бәхетегез бар, җирегездә урыс яши. Сәнгатегез чәчәк атмый икән—урыс гаепле, тормыш алама икән—урыс гаепле, китаплар чыкмый икән—урыс гаепле. Һәр унышсызлыкны, тормышның кыек якларын урыска өясез дә тынычланасыз. Хәзер менә үзегез баш, үзегез түш—нигә татар үз язмышын үзе хәл итми? Китаплар чыгамы? Юк? Әйттем бит! Ә Үзбәкстанда китаплар чыгу икеләтә артты. Төрекмәнстан хөкүмәте гонорарларны исәпкә алмыйча, пенсияләрне санамыйча һәр язучыга гына икешәр мең сум акча биреп бара. Сез дә хәзер «самостоятельная республика!» Нәрсәгез үзгәрде?» Элек бер анекдот йөри иде. Американнар белән урыслар очрашып бәхәсләшәләр икән. Американнар безнең тормышның һәр почмагыннан гаеп табып, «Сездә хәерчелек», «Сездә КГБ», «Сездә динсезлек», дип, фәлән-фәсмәтән дип тезеп баралар, ә урыслар сүз саен: «а у вас негров бьют», дип отпор бирәләр икән. Шуның сыман, Рауль Мирхәйдәровның кайсысы дөрес, кайсысы кимсетү булган сүзләренә бер сүз белән җавап биреп тордым. «Бездә әлегә тыныч, милләтләр үзара сугышмый. Калганнарын киләчәк хәл итәр», дигән булдым.

Бүген кыш башлангандай итте. Әллә репетиция генә ясап маташамы? Сигез-ун градус салкын. Унике ел рәттән тавыклар чеби чыгарган, төсен җуйган, тетмәләнеп беткән куян бүрек башка менде. «Бакча карачкысын чишендергәнсең!» дип берәрсе якадан элдермәсә яратырсың. Бишмәт тә ташка үлчим... Хатирәләр дәфтәренең өченче ел, былтыр язып кайткан баш өлешен рәткә салып, әзерләнгән документлар белән беркетеп чыктым. Бүген алтынчы бүлеккә тотынып-тотынып карасам да тиз генә юлны табып булмады әле. Төштән соң анда борылып кармаланам—стена, монда кагылып карыйм—юл юк, ниһаять, бу якка каерылып карадым да бүлекнең башын «Ачлык» дип куйдым. Шул табышыма таянып алга китеп карармын, боерса. Кәефем ару, күз тимәсен. Кичә Искәндәр улым килеп чыкты, Италиягә барышы. Читтә очрашкангамы, улымның йөз сызыклары нык үзгәргәнне абайладым. Иртәгә, көн ямьсез булмаса, явып тормаса, Мәскәүгә барып кайтырга да кирәк. Икенче срокка да калырга булдым. Путевканы алып калыйм, дим. Йә, тагын бәясе арта башлар. Хәзерге бөкере заманны белгән юк. Әллә ниләр күрерсең.

Сул як диварым тоташ тәрәзә минем. Кичләрен, агач башларыннан карангылык коела башлагач, мин тыгыз, авыр пәрдәне ябып куям да, иртән ачып җибәрәм. Театр сәхнәсенең пәрдәсен ачкандай булам. Сәхнәдә бер башым. Тамашачыларым бер төптән чыккан өч каен, юан-юан таза ботакларын уч итеп урнаштырып үскән карт нарат. Арырак тоташ агачлыклар. Алар иртәнге яктыдан кичке карангыга кадәр 114 нче номерда

театрның карт актеры Аязның уенын карап, шаккатып торалар. Аратирә минем күнел булсын өчен жилләрдә тирбәлеп мине хуплыйлар да, гажәпләнеп тынып калалар. Көне буе күзләрен алмыйлар. Ә мин ятам, торам, утлар яндырам, күнелгә килгән фикерләрне тәрәзә төбенә әзерләп куйган ак кәгазьгә сызгалап куям. Вакыт-вакыт кадерле юлдашым, сердәшем машинкам янына утырам. Бармакларны җәлләп сабыр гына, йомшак кына басарга иде дә, юк, эшкә тотынгач һәммәсе онытыла, бармаклар сүзләрне авыр мәгъдәннән коярга теләгәндәй клавишаларны сытардай басалар, хәрәкәтләргә күз иярми... Уйлар аргамаклар сыман ярышып-ярышып чабалар. Кая баралар алар, еракмы юллары, финиш кайда, әле белмим. Сюжет сызыгы үтә томанлы гына шәйләнә. Һәммәсенә игътибар бирә башласаң, артык күпкә китмәсме?.. Белгән юк. Әнә хәзер юаш кына энгер-менгер инә, агачлар көянтә белән су күтәргән юка кыз сыман сизелер-сизелмәс кенә чайкалалар һәм бүгенге якшәмбедә карт артист ниләр кыландыра икән дип карап, хәтерләп калырга тырышалар. Тыныч йокы сезгә, дуслар!

Пәрдә төште.

*26 октябрь.*

Кичә хатыны белән Уфадан Шәриф Биккол килеп житте. Бүлмәмә керделәр, әз-мәз хәбәрләр алышып, әңгәмә корып утырдык. Шәрифнең хатыны мин язганнарны нык укып баручы, яратучы хатын икән. Гомумән, алар икәвесе дә татар матбугатын кызыксынып укып, фикер алышып һәм бәхәсләшеп яшиләр икән. Шәриф—кара ук булмаса да башкорт, Рәисә ханым чын татар хатыны. Шәрифтә элек сизелми иде, хәзер кискен генә фикерләре дә бар. Җөмләдән: «Сез бәхетле, сезне изүче берәү генә—урыслар гына. Ә безне татар да изә, урысы да кимен куймый. Мәгәр татарлар безне ныграк изә!» дип әйтеп куйды. Татар-башкорт мөнәсәбәтләре алга чыкканда мин турыдан-туры тартышка, бәхәскә кермим, аның кемгә ни файдасы бар? Үз фикеремне дә теләсә кемгә чишеп ташламыйм: аның кемгә кирәге бар? Әлбәттә, «Идел-Урал» теориясе байтак милләтләр өчен котылу чарасы, яшәү чыганагы буласы икән. Әгәр Идел-Урал төбәгендәге милләтләр үзара янәшә яшәү формасын нигезли алсалар, бу урыска йотылудан котылуның бердәнбер ышанычлы чарасы буласы икән... Булмаган, берекмәгән. Ләкин шуны кистереп әйтәсем килә: алдагы буыннарга Хода кодрәте белән акыл инеп, милли хәрәкәтләр башына зирәк, киң карашлы лидерлар туып ныгыса, «Идел-Урал» штатларына әйләнеп кайтачаклар. Башкорт өчен дә, чуваш өчен дә, бүтәннәр өчен дә бу—котылу, саклану юлы. Гарантия. Югыйсә урыс шовинизмы әкрен-әкрен барыбызны да йотачак. Урыс милләте акылга килгәнче—без бетәчәкбез!

* * *

«Аның куркак икәнлеген этләр генә белә иде. Бүтәннәрдән яшерә алганны ул этләрдән яшерә алмады».

* * *

*27 октябрь, кичкырын.*

Кичә икенче срокка путевка алып кайттым. Кәгазь кулда, тыныч кына эшлә дә эшлә. Бүген эш тукталып тора әле, үшәнләнде. Күчү бүлеге, уңайлы гына старт ала алмый. Ташлап китәргә дә ярамый, чөнки алдагы бик күп фикерләргә нигез хәзер салынырга тиеш. Тырышырга кала, чәчләрне йолкый-йолкый тырышырга!

Өфедә «Идел-Урал» дигән гәҗит чыга икән. Зур исемне алганнар Өфенең татар егетләре. «Идел-Урал» татар дөньясы өчен яна сүз түгел, мәгәр аның бөтен тулылыгы, җаваплылыгы әле хәзер безгә аңлашылып бетә микән? Әгәр без татарның, күрше милләтләрнең урыс баскынлыгыннан азат булуын теләсәк, кайчан исә бер, бүтән милләтләр белән нигезле аңлашып, һәммәбезне бер дәрәҗәгә күтәреп, рухи азатлыкка ирешсәк... Бергә йомарланмыйча без яши алмаячакбыз. Чөнки урыс бер чакта да, өскә нинди генә хакимиятләр менеп утырса да, безгә тулы ирекне бирмәячәк, урысның бәгъзе бер өлеше шовинист, империалист булып калачак. Аерым-аерым татар да, башкорт та, чуваш-мари да тулы ирекле милләтләр булып яши алмас. Без әнә шул Европа берләшмәсе мисалында үзебезнең тотаклашу мөмкинлекләренә ирешеп кенә азатлыкка чыга алачакбыз. Иң мөһиме: урыс милләте ничек яшәр?! Власть нинди урыс кулында булыр?! Әле берләшкән ирекле дәүләт төзегән очракта да бер күзебез Ходайда булса, икенчесе урыста булачак.

*31 октябрь, кич.*

Бармаклар сызлый, тырнак аслары үлгән кебек, җансыз... Һава ярышып алмаша! Кичә көне буе ботинкаларга юеш кар боткасы ашаткан идек, бүген боз суырттык. Ике көн күнелле генә эшләдем! Бирсен Ходай. Кичә Татарстанның мөстәкыйльлеге Конституциядә беркетелде, дип хәбәр иттеләр. Бүген Илья Кашафетдин «язвить» итә. «Чит ил кешесе, Татарстан гражданины», дип авызын ерып тора. Бүтәннәр дәшми, әмма нидер уйлыйлар, тапкырлыйлар, бүләләр. Җаваплары гына билгесез.

*3 ноябрь 1992 ел, кичкырын.*

Переделкинода беренче срогым бетеп тә килә. Ни тырышып эшләсәм дә әле 1950 елның декабренә барып җитә алганым юк. Зәйдән, Казаннан һаман чыгып китә алганым юк. Бүген Мәүләгә багышланган бүлеккә тотындым. Вакытсыз бу дөньядан киткән яшьлек дусларым арасында Мәүләнең үлеме иң аянычлысы. Аның мина йогынтысы зур иде, ана да минем рухи файдам тими калмагандыр. Мәүлә—тулы, бөтен шәхес, зур талант иясе иде. И-и, әгәр бүген Мәүлә Солтан, Рифгать Әминнәр исән булса... Хәер, бишектәге бала бишкә төрләнә, ә без аерылышканга кырык биш ел үткән... Шәүкәтләр, Илдарлар белән тыптын гына бер-беребездән ераклашканбыз, бәлки Мәүлә белән дә чәкәләшеп беткән булыр идек? Гөнаһлы уй әйтсәм әйтим, гомер юлында үлеп калган чордашларым хакында урнашкан фикерләремне инде беркем дә, берничек тә үзгәртә алмый, алар хакында уйлап, аларның рухына якты хатирәләремне яза-яза, аларның якты исемнәрен дога дәрәҗәсенә менгереп, мин үземнең яшәешемне аңлап һәм аңлатып бирә барам түгелме? Яшьлектә кешеләргә гел якты күз белән каралган. Гурий Тавлинның исемен дә гел ару сүз белән искә аласы килә. Яшьлек—үз күнелең караламагын чак, хәзер үз күнелең дә әллә нишләп ватылып, сынып беткән, кешеләрдән дә яктылыкны бик сирәк табасың.

Бүген иртәнге сукмакларымда мине бәләкәй кызларым көтеп торган икән, ямансулап аларны сагындым. Бергә-бергә дә, аерым-аерым да күз алдымнан үткәрдем. Монарчы алар ничектер томан эчендәрәк читтә торалар иде, бүген җанымны җылытып, күз яшьләремне эретеп хәтеремә төштеләр. Улларымны әлләни уйламыйм хәзер, «исән-сау булсыннар!» дип Ходама ялварам да, тәмам. Ә кызларны өметсез, ямьсез киләчәк көтә. Нинди заманда аларның күбәләк җаннарын күктән чакырып

китергәнбез! Аларга нинди яхшылык, акыл калдыра алам мин... Менә шул ямьсез билгесезлек изә мине.

Бүген жебетте, ботинкаларым балыкка әйләнде, рәхәтләнеп йөзделәр.

*4 ноябрь 1992 ел.*

Татарстанның мөстәкыйльлеге Конституциясендә беркетелде дигән хәбәр илгә таралды. Россия Югары Советы, көнче ир кебек, «Китмә, аерма, жаным!» дип, татарларны үгетли. Бүгеннән Америкада яңа президент. Билл Клинтон. 46 яшь. Күрер күзгә сөйкемле генә кеше. Бу ике вакыйганы янәшә куеп, икесенен дә мөһим вә бер-берсенә тыгыз бәйләнгән икәнен уйлап ятам. Әйе, әйе, Россиядәге үзгәрешләрне Горбачев түгел, Рейган-Тэтчер татулыгы башлап жибәрде, явыз Ленинны алар фаш итте, алар бәреп төшерде. Безнең барлыгыбыз, татарның бөтенлеге турыдан-туры Америкадагы хәлләргә бәйләнгән. Әгәр Клинтон урыс фашистларына, кара милләтчеләргә шәфкатьле күзе белән караса... Фашизм микробларына үрчергә мөмкинлек бирсә... татарларның мөстәкыйльлек дигән сүзе черек кәгазь кисәге булып кына калачак. Әлегә без милли мәсьәләләрнең берәвесен дә үзбаш хәл итә алмыйбыз. Клинтоннан да ярдәм өметләнәбез без, әле Ельцинга карап та чукынабыз. Европага да ялварып карыйбыз. Ничек булыр, дөнья сәясәте кая таба борылыр, Америка кебек көчле, бай ил башына яшь лидер килде. Ничек кенә килә әле! Бар халыкның мәхәббәтен казанып, дәртен кузгатып, олуг тантана-бәйрәм ясап, саксофоннар уйнап килә! Карагыз, күрегез: жаны да тәне дә ачык. Ә Рәчәйдә лидерлар караңгы баздан төтен булып кысылып чыгалар да шым гына түргә үрмәлиләр. Хәшәрәтләр инде менә, тач ач күселәр! Кемнең кем икәнен берчакта да белә алмыйсың. Монарчы кылган гамәлләре, кешелек сыйфатлары да сер, моннан соң кылачаклары да сер булып калырга тиеш. Чөнки моңарчы да явызлык кылып өскә күтәрелгән, моннан соң бары тик жинаятьләр кылып кына үз мәнфәгатен кайгыртачак...

Лашман биясе кебек хатын.

Ике башыннан да яна торган шәм мин. *(Кайгы-хәсрәтле кеше.)*

Тамак, тамак... Адәм баласының төп кайгыртуы тамак. Ир бала туа—атага жир өлеше «имана» тия. Иман белән имана бер тамырдан. Кыз бала туса, Ходайның мәрхәмәте—йортка жиде йөз фәрештә иңә. Ә малай туса—өйгә туклык, имана, жир килә. Шул бер кишәрлек жир өлешен Ходай һәдиясе жиде йөз фәрештәгә дә алыштырмаган крестьян. Ә крестьян гына татар булган да!.. Бу фикерне «Хатирәләр романына» иплән кертеп куясы иде!

*6 ноябрь 1992 ел.*

Уфадан Габдулла Байбурин килде, кемдер: «Үзе—бай, үзе—бур», дип куйды. Мин «Нәкъ Юзеевча» дип уйладым. Илдарның чирек көче әнә шундый «мәзәкләр» корып үтә.

Бригадир кыз Тәския, ирләр киеме кия.
Ирләр киеме кисә дә һаман чүгәләп...

Иртәнге чәйдән соң Шәриф Биккол белән сөйләшеп йөрдек. «Минем партиядән чыгарга уйлаганым да юк,—ди ул мактанып,—әле партиянең үз сүзен әйтеп бетерә алганы юк. Октябрь бәйрәме тирәсендә күрерсең әле менә... Чак кына исәнгерәп калган коммунистлар бүген аңга килделәр, Ельцинның кем икәнлеген күрделәр. Үз хәлләрен

төшенделәр: коммунистлар партиясен җимергән Ельциннар да алардан бер яклары белән дә аерылмыйлар икән! Һәркем үз тамагын кайгырта, үз җәннәтен төзи!» диде ул, коммунист булуы белән мактанып.

«Хатирәләр бакчасы»на тагын бер җыр. Шәп җыр, шайтан алгыры!

Кызыл ыштан, киң балак, колхоз хатыны карак.
Председатель чабып йөри, ыштан төпләрен карап.

*7 ноябрь.*

Октябрь инкыйлабының 75 еллыгы. Быел бу канлы көнне ил буйлап бәйрәм итәләр, киң күләмдә билгеләп үтәләр. Югары Советның 5 нче съездында бүгенге хөкүмәтнең язмышы хәл ителәчәк. Хөкүмәт әгъзалары хәзер нишләргә белмиләр, ары чабалар, бире чабалар, халыкка, ярлыларга эндәшәләр, һәркемнең кәефен күрергә, мафияларга ярарга тырышалар, бәлки съездда да аларны яклаучылар күпчелек булыр дип өметләнәләр. Газеталар бердәм рәвештә Григорий Явлинскийга мөрәҗәгать иттеләр. «Лит. газета» ике санында рәттән Явлинский белән интервью бирде. «Пограничная ситуация» дигән бу материалны кат-кат укып чыктым. Чыннан да, әгәр Ельцин Гайдар урынына Явлинскийны үзенә алып, илнең икътисади язмышын аңа тапшырган булса, без каярак барыр идек тә, кайда булыр идек? Күп нәрсә толпаның акыруыннан түгел, берәүнең төпле акылыннан тора шул. Минем күз алдымда кызыклы бер шәхес ялалды. Ул—Григорий Алексеевич Явлинский. Гайдарлар белән ярыша алырлык шәхес, алга карап үз юлын расларлык шәхес... Бүгенге хөкүмәтне усалланмыйча гына, төпле итеп, саннар, мисаллар ярдәмендә тәнкыйтьли, уйландыра...

Бүген икенче срогымны башлап җибәрдем. «Йәгез, бер дога»ның ике зур бүлеген тәмамлап, өченчегә күчтем, ниһаять, Казан каласын ташлап этапка чыгып киттем. Алда чак кына җинелрәк булыр төсле күренә. Казаннан, чәбәләнеп беткән мөнәсәбәтләрдән, Черек күлдән, шөкер, Ходам, котылдым. Бүген бик һәйбәт, бик җитез эшләдем. Беренче бүлек илле битләр чамасы иде, икенчесе утыз биттән артып китте. Бер интервал аша—җәмгысе сиксән биттән артык текст яздым. Байтак эш башкарылды, боерган булса, шушы дәрт белән эш барса, шактый зур тауны күчерәчәкмен.

Шәриф Бикколның хатыны Рәисә ханым—Азнакай якларыннан. Татар әдәбиятына үлеп гашыйк бу хатын Казанда чыккан китапларны да, гәҗит-журналларны да берсен калдырмыйча укып бара икән. Үземнең әсәрләрне болай яратып укыган кешене монарчы очратканым юк иде. «Яра» повестен бик күпләргә сөйләп күрсәттем, журналны Грозный каласындагы китап сөюче татар хатынына җибәреп кайтардым», ди Рәисә ханым. «Әхәт Гаффар нindирәк кеше ул, күргәнем юк», дип сорады. «Мыеклы кара егет», дидем.

Башкортта «внук»:—«ейән», «внучка»—«ейәнсәр». Матур сүзләр. Татарда бу сүзләрнең татарчасы юкмы? Һаман... тегермәне корып, «оник», «онычка» дип маймылланып йөрибезме? Бардыр ул сүз, булмый калмас, татарлар да үз нәсел җепләренең өзелмәвен теләгәннәрдер. Ләкин «әлеге дә баягы, үсә шайтан таягы» дигәндәй, милләтебезнең кадерсез вә хәтерсез икәнен тагын бер тапкыр әрнеп кычкырырга кала!

*15 ноябрь 1992 ел, кич.*

Минем куен дәфтәрләренә берзаман кем дә булса күз ташласа, анда һава торышына, ай-йолдызларга ишарәләрне бик күп очратыр. Кәгазьдә җансыз гына тырпаеп торган бу гадәти сүзләрнең кадерен үземнән башка берәү дә аңлый алмас! Әнә шул агач ботакларына кысылып чыгып килгән, әле туып кына маташкан кояшка карап, мин нинди хисләргә батмаганмын да, ай урагына озак-озак карап торып нинди

уйлар уйламаганмын! Табигать күренешләрен кыска-кыска итеп куен дәфтәренә беркеткәннән соң туган бик күп уйлар йомарланып-йомарланып әсәрләргә кереп киткән. Ай-йолдызларга карап мин үземнең тәгаен жир баласы булуымны, монда минем халкым татарлар яшәгәнен искәргәнмен, күңел шашынып тулган чаклар булган: әйне, хатын, бала-чагаларны сызланып сагынган мизгелләр килеп киткән, яңа фикерләр ныгыган, хатирәләр уянган. Картайсам да авыл баласы шул мин, табигатьнең бер ярчыгы, аның тере күзле, кайнар канлы кисәкчәсе.

«День» газетасының быелгы 43, 44 номерларын укып ятам. Үзебездәге «Суверенитет» тупас кылана, жөмһүрият башлыкларына пычрак ата, дип зарланган булабыз, болар тәмам бәйдән ычкынганнар, котырганнар. «Газета духовной оппозиции». Хакимият белән көрәшкә чакыралар, урысларның әлегә тере калган күзәнәкләрен кытыклыйлар, атап ук әйтмәсәләр дә яһүдләргә каршы чыгалар, аларга ләгънәт укыйлар. Уйга төшерә торган фикерләре дә бар, сүзләре тоташтан исәрлек дип раслап булмый. Ике санда да программа булырлык мәкаләләр бар. Юрий Власовның «Кровососы» дигән мәкаләсе ике санга сузылган. Урыс жаны өстендә утлы ураган биетә автор! Юрий Власовның кем икәнен беләм, монарчы да радио-телевидение аша ясаган гайрәтле чыгышларын ишеткән бар иде. Ике сүзнең берендә татарларны, урыслар уйлап чыгарган игоны сүгә, Россиянең бар бәхетсезлеге шулардан килә дип, тарихтан мең мисал казып чыгара торган иде. Яһүд белән көрәшкә чыгарга ниятләгәндә татар ягына карап бер баш орып та куя. «И орут до хрипоты, доказывая прелести новой жизни, обозреватели, бесталанные литераторы, коммента-торы—вся платная полуграмотная мразь, усевшаяся на спину народа. И, как правило, все безродные—не здешние, не свои, не русаки и не татары, не пермяки или мордвины, а пришлые, без корней, без любви к земле и людям».

Оппозициянең рухи юлбашчысы Александр Проханов исә татарны тагын да югарырак күтәрә, урыс белән тигез дәрәжәгә менгерә. «Вот почему, как ни тяжела была жизнь, государственниками в России были смердь и князь, приходской священник и великий писатель, великоросс и татарин. Отдавая свой живот за отечество, они знали что служат своим чадам и умершим предкам, а также высшей—для неверующего социальной, для верующего божественной—истине».

Тагын бер тапкыр татарны искә ала Проханов, Россиянең бар милләтләрен тагын бер кат урыс канаты астына тупланырга өнди!.. Соңгы сүзе дә безгә—мөстәкыйльлек таләп итеп күтәрелгән татарларга да барып кагыла. «И еще—Россия не мстительна. Россиянин отходчив. Победив, он не станет казнить. Довольно того, что вырвет из рук неприятеля меч. Мы не жаждем реванша, не намерены ставить плах. Мы устали от крови и слез». Ай-һай, шулай булыр микән? Урыс кулыннан кылыч төшкәне юк, ә кылыч белән берчакта да печән чапмыйлар, урмыйлар да. Кылыч кайсы заманда булса да кеше башын кыйган инде ул. Урыс кулындагы кылыч бигрәк тә!

*23 ноябрь 1992 ел, Переделкино.*

65 яшь тулырга да ерак калмады, бер-ике сикерсән барып та житәсен. Ил, жир, халык, милләт шушы хәлдә булганда алтмыш бишне тутырып килгән ир үзен ни чамадарак сизәргә тиеш? Хәзерге мәшәкатьләр, иртәгә килер куркынычлар, шик-шөбһәләр һәр көн саен гомернең ике көнлеген талап ала, урлый, яшәү ямен кимәтә, сөенечләрне каралта. Бүген иртәнге чәйдән соң Яр буе кибетенә сугылып чыктым. Куен кесәмдә бумажнигым. Товарларның саны арткан, ак май бар, килосы дүрт йөз сумнан артыграк. Коньяк бар, аракылар тезелеп тора, сөт, каймак, эремчек, күкәй... Ә бәяләр! Күрче, кесәмдәге бумажнигым үкереп жылый, жылый-жылый кысыла, бәләкәйләнә... Көн искиткеч матур башланган иде, иртән тып-тын, күк аяз, аяз күктән дә ефәк кисәкләре булып сирәк-сирәк кар бөртекләре төшә, сукмак коры, гәүдәм жиңел, йөрим ирәеп, аяк өскә

чөелгән, күзләр күпне күрә... Менә бер тирәдән чыккан агачлар. Яшь чагында янәшә үскәннәр, сыешканнар. Үсә-үсә аларга нур житми башлаган, һава кысанланган. Агачларның берәүләре унга каерылган, икенчеләре сулга тартылган, агач очлары бер-берсеннән ераклашканнар... Юлдашларыннан, чордашларыннан, ихтимал кардәш-ләреннән дә качар өчен байтагысы кыегайган, кәкрәйгән. Ах, таннарда кояш нурларын бүлешә алмыйча ничек-ничек талашканнардыр алар, чык суларын күбрәк эчәргә теләп кеше күзеннән читтә, түбәндә тамырлар бер-берсе белән ничек-ничек сугышканнардыр! Бер йотым су өчен бәргәләшә-бәргәләшә унга-сулга каерылганнардыр. Тормышта да шулай, менә без яшьтәш, чордаш әдипләр «үскән чакта үскән идек, тал тамырлары кебек», ә хәзер... бер-беребезгә борылып та карамыйбыз диярлек. Һәркем башын читкә бора-бора гарипләнгән, кәкрәйгән, бөгелгән... Баш очларыбыз ерагайса да тамырлар жирдә, алар бергә буталышып, аралашып беткән, кайда кемнең тамыры икәнен аерып алырлык та түгел... Тик шунысы бар—Жир һаман бер. Без шул Жиргә тамырларны нык жибәргәнбез, давылларда, явыз жилләр искәндә башларыбыз бер-беребезне тукмаса да бу Жирне ташлап китә алмыйбыз...

Язучы-әдип картлыгында тома ялгыз ул, япа-ялгыз. Аннан иптәшләре, иптәшләреннән ул качып китәләр. Былтыр 1 нче Майда монда Переделкинода Әмирхан ага Еники белән озак кына сөйләшеп йөргән идек. Әүвәлдә Әмирхан ага Әхмәт Фәйзи белән ахирәт дус булганнар да, олыгая төшкәч аралары суынган дип колагыма чалынган иде. Мәрхүм Әхмәт абый хакында сорашырга базмадым, вафат булган әдипнең исеменә тоз сибәсем килмәде, шулай да Әмирхан агадан элегрәк кемнәр белән якын дус булып яшәвен белергә теләдем. «Мин Расих һәм Фатих Хөсни белән бик дус идем», диде, көрсенеп, Әмирхан ага. «Ә нигә араларыгыз ераклашты сон?» дип кызыксындым. «Расихның әтисе Әстерханнан кайтты да авызын күтәреп: «Алла юк ул, Коръәнгә ышанып йөреп мин бик нык ялгышканмын, совет власте һәм коммунистлар партиясе минем күземне ачты», дип дингә каршы лекцияләр укып йөрде. Диндар картлар белән диспутлар уздырды... Шул чакта мин Расихка: «Ник мондый ямьсез эшләргә юл куясың?» дип сорадым. Ул һич уңайсызланмыйча «анын үз эше!» дип кистереп жавап бирде... Шул вакыйгалардан сон, табигый рәвештә, безнең аралар ерагайды, дуслык кителде... Ә Фатих... Ямьсез картайды Фатих! Кеше үзенең картлыгына әзерләнә башларга тиеш. Картлык катлаулы чор, ул аңа әзер килеш, каушамыйча барып ирешергә тиеш. Фатих биреште, тиз сынды, ямьсезләнде, үз-үзен күзәтми башлады. Өлкән кеше үз-үзен карамый башлый икән, ул кешелек сыйфатларын да жуя. Анын бүтәннәрне, шул жөмләдән, элеккеге якыннарын күрәсе дә, үзен күрсәтәсе дә килми».

Уйлап карасаң, бүген Әмирхан ага да, Фатих Хөсни дә, Расих та япа-ялгызлар ләбаса...

Әнә шундый чор, аерылышыр чаклар безнең буынны да ялмап йотты. Бер яшьтәш мине тозсыз-борычсыз чәйнәп төкереп ташларга әзер! Шәүкәт дипломат, ул гомергә акыллы булды, төс бирмәсә дә, сизәм, суынган безнең аралар! Күптәннән үзебез эзләп, жаныбыз теләп очрашкан юк. Булгалый, ялгыш-монгыш кына, платформада поезд көткәндә, йә вагонда кайтканда, кыска гына күрешеп, сөйләшкәләп алабыз. Сүзләр дә шул, шырдый-бырдый, һава хәле, базар бәяләре... Тик без мондый мокытлар түгел идек ич! Нык-нык сөйләшкән, дөнья учагында бергә янган чаклар бар иде! Марсель Сәлимжанов та мине юксынып капканы кага иде! Шәриф Хөсәенев һич көтмәгәндә килеп керер иде...

Ялгызлык—картлыкның китмәс чире икән ул.

Олыгаеп барам, сизәм. «Әшъяларның төсе» үзгәреп кенә калмады, үз төсем дә алмашына. Һәр иртәне сакал кырдырып Ходай безгә зур сабак бирә: кара, күр, уйла... Уйламый нишлисең, мангай сачләре коелып сирәгәйде, адымнар чалшайды, бер алга атласаң, ике тапкыр артка күчәсең. Минем картаюыма исем китми, шөкер, балаларыбыз житте, һәркаюсының гаиләсе, үз тормышы, үз ишеге бар дияргә була. Мин бары бер нәрсәдән: иртәрәк үлеп китеп дөнья йөзендә Нәкыяне ялгыз калдырудан куркам! Менә хәзер

генә, шушы яшькә житкәч кенә, хатын итеп бик яшь кызны алуыма үкенгән мәлләрем була... Аның да ин курыкканы, мин иртә үлеп китеп, ялгыз баш калуы...

Утыз алты ел бергә яшәдек. Төрлесе булды, әле хәзер дә баламишкинлык, жүләрлекләр калкып-калкып чыга, ике арабызны ямьсезли. Күбесенчә, боларга мин гаепле. Мин! Юньсезлек тә бар инде үземдә, дуамаллык та, ахмаклык та хаттин ашкан. Ачуланышкан чакларда Нәкыя хаклы зарлана. Нишлисен, холкымның яман якларын менә ялгыз калган мәлләрдә үзем кискен хөкем итсәм дә, тормышта сабыр акыллы, ипле, йомшак телле була алмадым... Инде үзгәреп тә булмый торгандыр. Ходай хәерлегә илтсен! Заман боздымы, заманга төкереп үзем бозылдыммы, хәзер аның әһәмияте юк та бугай. Менә кич житеп килә. Нәкыя «Татарстан» поездына утырып минем янга сәфәр чыга.Ниләр уйлый икән ул? Гомере гел ямьсезлектә үтте дип зарланамы? Бәхет-сәгадәтне татымадым дип кыйналамы? Каргыймы мине?.. Барысы да бардыр. Мөгаен, мин ана ул көткән, ул өметләнгән бәхетне бирә алмаганмындыр. Ни кызганыч, шундый хәвефле шикләрне Нәкыя белән уртак итеп булмый. Ул да дөресен сөйләп бирмәс иде. Яшьлектә ычкындырган хаталарны хәзер ямаулык белән каплап тотмыйбызмыни? Ямаулыкны сүтеп ыргытсаң, байтак ямьсезлекләр шыраеп калыр иде! «Мин сине шундый нык сагынып көттем бит, Нәкыя!» дип кычкырып әйтеп тә булмый. Әллә ничек шунда, оятмы, читенме... Гажәп икән бу картлык! Аның сагынулары да бүтәнчә, «сагындым» сүзен өлкәннәр бөтенләй яшь чактагы мәгънәсенә тәнгәл китереп әйтмиләр икән. Картлык сагынуы яшьлек калыбына сыймый, ул үзгә, аның яшертен төсмерләре күбрәк.

Кич житеп килә. Уфалы Габдулла Байбурин бүген Литфондта өченче срокка калуын тәгаенләп кайтты. Миңа да андый уй килеп киткәләде. Мәгәр мин өч срокка түзә алмам кебек. Соңгы көннәрдә кайтасы килә башлады. Нәкыянен килүе искиткеч вакытлы һәм шәп булачак.

Бүген эш тотып булмады диярлек. Кулның көчен шушы, кечкенә уйларымны кәгазьгә төшерүгә исраф иттем. Ходай кабул итсен!

«... туганнарым да зир-зәбәр килеп, юкка чыгып беткән»... «Зир-зәбәр»—нинди мәгънәле матур сүз! Аны 80 яшьлек, бүген Алманиядә яшәүче Ильяс бабай Габдулла-Казанлы кулланган...

### Болай уксыңдыр дип белмәгән идем...

*Аяз Гыйләҗевкә*

«Күрәләтә безне рәнжеткән», дип
Каргап булмый язмыш-шилманы:
Бер табында
Бик еш утырырга
Ходай безгә насыйп кылмады.
Тик, мин,
«Биргәненә шөкер,—димен.—
Бәндәләрдә төрле талым бар:
Жиләтеп тә бетәр иде бәлкем
Бик еш булса уртак табыннар...
Житмәсә дә ярты дистәгә дә,
(Тылсым алар,
серле фал алар!)
Бергә күңел ачкан бу минутлар
Асылыңны ачып салдылар.
Икеләнеп тормый тарафына
Юнәлттем мин күңел жилкәнен:
Мин бит инде
Саф алтынны жиздән
Аерырлык яшькә житкәнмен!

Шундый хакыйкать бар:
Юньле ир белән
Бер утырулары—бер гомер.
Хак сүз икән:
Йөрәк учагына
Син өстәден тере бер күмер.
Бу заманда—
Өмет өзгән мәлдә
Җанга ямь-юаныч табудан,
Еш димәем,
Булсын әле алда
Бергә утырачак табыннар!
Монарчы син
Серле китап иден,
Инде
Байтак бите укылган...
Болай уксындыр дип белмәгәйнем,
шәп кешесең икән, чукынган!

Шәриф БИККОЛ
*7 ноябрь 1992 ел. Переделкино*

*27 ноябрь 1992 ел, Переделкино, кич.*

Нәкыя килде, күнелле генә ял итәбез. Эш бераз тоткарланса да зарланмыйм, карчык белән күптәннән ял иткән юк иде... Миннән бигрәк ул ял итә, мин—куанам. Ике кулы да сынык Нәкыянең көн-төн эштән бушамавын күреп җаным нык әрни иде!..

*28 ноябрь 92 ел, көпә-көндез.*

Берсекөнгә юлга... Хуш, кадерле Переделкино! Миңа бик күп эш бәхете китереп торган бәрәкәтле, җылы почмак! Шушы каһәр суккан болганчык заманга да әз-мәз җылың калган икән. Соңгы килүемме? Белгән юк. Директор Николаев А. А.ны очратам: «Бүген каян да булса акча килеп кермәсә, иҗат йортын ябабыз», дип куркыта. Һәрбер урыс кебек, яһүдләрне сүгә. Урыска һәм татарга яшәү үтә җинел, озын-озак баш ватып тормыйлар, тоталар да берсе яһүдләрне, безләр урысларны сүгәбез дә көчебез бетеп тә куя. Шуннан арыга юк, тпру!.. Менә шулай!

1981 нче елның 9 октябрендә Әлмәттә, драма театры тирәсендә котырып үскән тигәнәкләр, себерке-себерке булып чайкалган ак вә кара әремнәр арасында, кояшлы-жилле көндә алдарак язылачы романымның исемен эзләп тапкан идем. Һәм «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» романын язам дип, гадәтемчә, бик иртәләй шапырынып та ташлаган идем. Шуннан өч-дүрт ел рәттән романны ермачлап та маташтым, очланмаган, тәмамланмаган, юл салынмаган, сукмагы төшмәгән кульязма-сәхифәләр язу өстәлем киштәсендә ничәмә-ничә еллардан бирле күзне кисеп, аңны уятырга тырышып аунап йөриләр. Шул арада житез егетләр мин тапкан (гәрчә ул өстәрәк кенә ятса да) исемне чәйнәп, теткәләп бетерделәр. Зиннур Мансуров шул исем астында поэма язды. Ниһаять, Ринат Мөхәммәдиев тә ожмахка атланып керәсе ишәгенә—Тукай бүләгенә өметенә—шул исемне такты. Китабын «Сират күпере» дип атады. Мин бу югалтулар белән тиз килештем, җинел кичердем, шапырынмаска, сүзен ычкынгач аны эш белән цементларга һәм романны язып тагын байтак коллегаларны көнләштерергә кирәк иде. Нәкыя «Шәһри Казан» гәжитләрен алып килгән. Гәҗитнең баш чаң кагучысы, рухи остазы Җәвад Тәрҗеманов жингән кыяфәттә мәкалә арты мәкалә бастырган. Һаман шул «әшния» не изә, нәгъръә ора, каһәрли һәм ялаҫынын-ялганының төп угы минем җәрәхәтле күкрәгемә төбәлгән... Ә мин нык кына язып ятам.

Инде туктыйм, ак күнелемнән шул нәләт суккан көнче-күбәләкләрнең исемнәрен мәңгегә онытам, хәтеремне сафлыйм, дип уйлап кына өлгерәм, тагын берсе караңгы почмактан чәчрәп чыга да былчырак ата. Шактый җыелганнар икән алар бу елларда!

Ярар, Ходай аларны да кичерсен. Бу дөньяда тозек кала алган адәмнәр аз, үземнең дә хаталарым булгандыр, бер төркем өлкәннәргә тел тидерергә кирәкмәгәндер дә, мөгаен... Әгәр татар тарихы әзрәккә кала алса, әйдә, безне Ходай һәм тарих хөкем кылсын.

Романның исемен үзгәрттем, тора-бара ул «Каргыш»ка әйләнде. Әле бүген төнлә уйны терелтеп азапланам: төп героем авылга, ата йортына кайтып төшә. Төн. Бер ялгызы. Өстәлдә самавыр тора. Суы да тутырылган. Ул самаврны тоташтыра. Ята, ниндидер ят тавыш ишетеп, сәерсенеп вә гаҗәпләнеп ята... Тавыш беразлан үзгәрә, тәмсез исләр чыга башлый. Ул тавышның һәм иснең чыганагын таба алмыйча баш вата. Баксаң, самавыр кайный икән, ул искәреп торып басканда суы кайнап беткән, самавыр эреп кәнкәйгән...

Әле бу искә килгәнне теркәп үтү генә! Вакыйгалар гына түгел, аерым җөмләләр, хәтта аерым сүзләр дә хәтердә тезеләләр. Яңа әсәрне шулкадәр дулкынланып, сөенеп уйлыйсың ки, сүзләр өр-яңа төсләр алып яңача яңгырыйлар, яңа куаныч китерәләр. Гади мисал: «искергән». Ха-ха, монарчы игътибар ителмәгән «искерү»—«ис- керү» икән ләбаса! Сүзнең ерак тамыры ачылса һәрчак күнелем күтәрелә. Мин үземнең миллионлаган кузәнәкләремнең берсендә шушы сүзне кулланышка кертеп җибәргән борынгы бабамның уянганын тоям. Булган ич алар, телебезне тудырганнар, әллә никадәр тормыш, яшәү күренешләренә, табигать серләренә, җир-күк микъдарларына меңнәр вә миллионнар кабатларлык затлы сүзләр калдырганнар. Шул, җимерүчеләрнең түгел, тудыручыларның үз кардәшен икәнен җан белән, кайнар кан белән сиземләү генә кешегә туп-тулы милли бәхет китерә ала! Туган тел—үтә катлаулы күренеш ул. Әбрар Кәримуллин зур мәкалә белән чыккан. Һәрбер сүзе дөп-дөрес, мәгәр маркиз-академик соңгы сүзне әлегә әйтә алмый, теле көтек. Ул чыгарган хөкемне татар телен болай да белгән, әз-мәз кадерли торган затлар гына кабул итәрлек. Ә хәзер урыслашкан, куркыныч милли нигилизм чире белән авырып, шул чирне балаларына, нәбәрәләренә дә йоктырган, телнең кодрәте сереннән ераклашкан бәндәләргә әйтергә кирәк. Хөкемен атылган пуля кебек көчле һәм үткер булсын, югыйсә урыс дөньясында рухи аңгырайган, үтә калын тиреле чучкаларга һәм мөгезборыннарга әверелгән татарга тәэсир итә алырмын дип өметләнмә. Менә, мылтыгын каян табарга да кай якка төбәп атарга, бу мәсьәлә әле чишелмәгән. Без тоташ Россиягә бәйләнгән. Кайберәүләр «без үз юлыбыз белән үзгә, үзебезчә барабыз!» дип акырсалар да... һи-и, ай-ай, менә декабрьдә гражданнар сугышы башланып, хакимият башына Прохановлар, Юрий Власовлар, Шафаревичлар килсен әле. Алар тагын империянең чиген элекке күләмдә кинәйтеп, яңа, фашистик-коммунистик кануннар урнаштырсыннар әле... Россия акыллы, зыялы, саный белә торган хуҗалык алып баруның серләрен кулында тота алырлык адәмиләр кулына күчсен дип ялварырга кирәк. Шул чакта гына без Россиядән мәгънәле, үзебез өметләнгән ишарәләрне көтә алабыз. Бүрәнә аркылы бүре куарга гадәтләнгән татар зыялыларының әле чыбыркы күргәннәре, камчы татыганнары юк. Анысы да ерак йөрми. Ай-һай кәттә казаклар яралып-туып маташа! Кичә урамда Валерий Турны очраттым. Өшәнгән, картайган...

Исән-имин шушы зур җаваплы эшемнән котылсам, рәхәтләнеп, иркенләп, ирәеп «Каргыш» романын язар идем...

Шуның белән программа-максимум тәмам. Хыялның чиге юк, язучы күнеле йөгәнсез чаптар ул, мәгәр, уйларым арды, иртәгә татар дөньясында кемнәр торып калырын һич ачыкламак юк. Чыгармы татарча җитди китаплар, әллә татар аны әнә шул театр сәхнәләрендәге бетмәс-төкәнмәс арзанлы кәмитләр белән туксынып кына яшәрме?..

*Ахыры киләсе санда*

# ШИГЪРИЯТ



## Роберт Әхмәтҗан

### ШӘҖӘРӘМ ТИРӘГЕ

### Ерак киткән саен...

Шушы көнем булды дисәм ярый
Күккә ашкан көнем,—
Ыру башым—бабам белән озак
Саубуллашкан көнем.

Төшенгәндәй уйларының гүя
Кырга сыймасына,
Арыш дулкыннары килеп егыла, егыла
Зират коймасына...

Еллар аның төз гәүдәсен инде
Бераз куйган бөгеп.
Киез эшләпәдән, ак сакаллы үзе,
Хозыр Ильяс кебек.

Мин—ирләрчә горур, аңа сыенып
Басып торуымда.
- Тап төшермә, улым, зур колаклы
Мачан ыруына.

Күп эшләде, аз яшәде,—ди ул,—
Шундый безнең нәсел,—
Шәҗәрәмнең тармаклары кими,
Ә яфраклар—яшел...

...Басып калды, күз яшьләре аша
Карап кыйбласына.
Ул сөялеп басып калды шулай
Зират коймасына...

Арыш юлы буйлап кайтып киттем,
Бабам ерагая.

Барган саен кичерәйми үзе,
Йөзе гел зурая...

Юл өстендә Шәҗәрә Тирәгем
Җилсез шаулап тора,—
Кылган гамәлемнең ниндилеген
Бабам аңлап тора.

Күңелемә килгән һәрбер сүзем
Аңлап тора Бабам...
Ерак киткән саен,
аңа үзем
Якынаям һаман.

## Гасырларда яшәр юксыну

*Әмирхан ага Еники ядкяре*

Бүген иртүк, нәзкәй генә үксеп:
«Ени...ки...и!» дип
Исте таң җиле...
Җылы яңгыр кебек салмак иде...
И, Әмирхан,
Изге җан инде!..

Китүеңмени,
Үткән чорның соңгы могиканы...
Йә, бәхил бул, әдип,
Хуш инде!..
Мең кодрәтле бөек Табигатьнең
Соңгы мөмкинлеге
Шушы инде!

Соңгы мәҗлес. Матәм җыенында
Бер догалый җаннар иң башта...
Гомереңне дәвамларбыз, Остаз,—
Һәрбер җанга
әле күп-күп еллар
Җылы килер
Синең Кояштан!

«Кояш баер алдыннан» дип язып,
Ябып куйдың «Соңгы китап»ны.
Шул китапның җаны—
хаклык сүзе
Һәр йөрәккә
Якын юл тапты.

Шытып чыгып күңел нурларыннан,
Яшь бөреләр ачар керфеген.
Мулдан иктең Иҗат кырларыңа
Игелекнең алмаз бөртеген...

Шулай укмы,
Югалттыкмы инде
Ил-илкәйнең соңгы морзасын?!
Дүрт кул булса,
дүрт шәм тотып әлә

Гасырга бер туар ир затын!
Битен ачсаң, меңгә тапкырланыр
«Соңгы китап»—
анының юк соңы.
Җәсад китә—
кала олуг Мирас...
Гасырларда яшәр Юксыну!..

* * *

Шигъри дустым, килче, карлар ерып,
Кошлары да бизде, бу кышны...
Ишекләрем кертми җан таларга
Бусагама килгән йолкышны...
Кыш шаулаган ап-ак дөньяларда
Тойсам икән язгы сулышны!

Ә син килче үтеп балачакның
Томаннарга киткән тугаен,
Күк тугайда калган яшьлек үзе
Сагынадыр безне, мөгаен.
Кайтыйк әле шунда дөнья гизеп,
Табыйк та бер юллар уңаен...

Анда ватан, анда күксел Мирәт,
Ак өермә сөйрәп җил аза.
Туң иманнәр шартлый. Туган җиргә
Тик мәхәббәт чыдар чыдаса...

Шигъри дустым, кайтыйк шунда бергә,
Тугыз баллы сагыну, җил аша.

* * *

Мәхәббәтем минем, иркә җәнлек,
гайбәт сүзләр чытырманын үтеп,
якынлашты Сөю күленә...
Күзләрендә яна иде өмет!..

Көнчеләр
таш белән ордылар,
бәгыренә савылды кан.
И куанды,
куанды соң мәләкләр,
бер ерткычны
бәреп үтергән сыман!..

И каныкты явызлар
Табигать җанына—
суктылар—
сулыгына килеп җитмәгән
җаныйга!..

## Йөрәккә сөаль

Сынауларны шактый кичтең, Йөрәк,
Син кич тагын ошбу сорауны:
Кардиограммаң тешсез тарак мисле,—
Сораумы бу?
Әллә сынаумы?

Упкыннармы,
әллә сиңа тиеп,
Дәрьяллардай еллар узганмы?..
Ярыйм, диеп, холуй көенә биеп,
Иске граммафондай
Тузганмы?

Китегез әле, минор сулкылдаулар,
Аңлыйм, Йөрәк,
Керәм хәлеңә.
Эзләмәче миңа юк сылтаулар,
Мин хуҗамы сиңа әлегә?!..

Ярсып-дулап,
Тибеп уңга-сулга,
Әллә... миннән
китеп барышмы?
Турысын әйт, шылма,
ярты юлда
Бутап куя күрмә бар эшне!..

## Салих Батталның китүе

Тормыш шау-шуыннан арып-талып,
Баш куюга йомшак ястыкка,
Гүли башлый иде
Яшьлегендә үзе очкан самолеты,
Алып китә иде төштә
Тын океанга,
Владивостокка!..

Ымсынылa... Күпме еллар инде
Ул якларга юллар ябык та...
Тын океандай чиксез хыяллары
Китапларына да сыялмады...
Сыеп бетте бер көн...
табутка...

Уйлагандыр шагыйрь, милләтен дә
Гел канатлы итү хакында...
«Батый ханга нигә хат яздың?» дип,
Кыздырдылар үзен
обкомда!..

Сугыш яңгыннарын очып үтте.
Алып китте күләгәдәй картны,
Башына җитте!—
Нәзек кенә
электропровод та!..

Шулай диеп сөйләделәр соңрак—
Юкка!—
Аның йөрәге тоташ иде
Иң югары токка:
Исән чакта
Дан-хөрмәтләр үтте читләп...
Йөрәгенең
магистраль тамыры
янды гөлтләп!—
Китте нәүмиз
Ишек төбеннән
Дөньясында
гаделлек юкка...
Дәрвиш сурәтле
олы шагыйрь,
Ятим бер кортка...

## Ак карга

Кабатлыйлар һаман—яратыпмы,
«Кара» сыйфатынмы якларга...
Кара карга, ала карга булсын,
Бармы әллә тагын ак карга?!

...Язын күрдек аны! Күрде авыл,
Яңалык дип язды хатларга.
Әйтерсең лә кошлар фәрештәсе,—
Кайтты безгә быел
Ак Карга!..

Шунсы гаҗәп: әгәр кунса килеп,
Якташлары кунган талларга,
Очып китә бар да, дәррәү кубып,
Теләмиләр «ак»ны аңларга...
...Саргайды көз, шаулап, кош гаскәре
Күтәрелде җылы якларга.
Саф артыннан, җилфер-җилфер килеп,
Ияреп очты
Быел
Ак карга...

Уйлыйм: быел язын кайтырмы ул,
Кала алыр микән сафларда?..
Теләгем зур каршыларга быел
Явыз телдән, җилдән сакларга!

Теләктәш мин аңа.
Гаепсездән
Юлыкканда кыен чакларга,
Калганым бар аның хәлләренә,—
Көлә дуслар:
«Ул,—дип—ак карга!..»

## Президент бии!

Кояш, Болак, Август—бергә килгән,
Бергә килгән—нәрсә диергә?..
Җөмһүрият бәйрәме бу.

Кояш
Үзе төшкән җиргә
биергә!..

Бии кояш, чүгә-чүгә бии,
Уйный сазның мең-мең кыллары.
Шул моңнарга таңгал генә агыла
Җөмһүриятнең имин еллары...

Дулкынлана аллы-гөлле мәйдан,
Җырлар белән шаулап, гөр килеп.
Мондый мәйдан гомергә бер килер,—
Ә мәйданда бии—
Минтимер!..

Дөньясында яшерен эшебез юк,—
Бөтен дөнья моны күрсен, дип,
Мәйдан уртасында, култыклашып,
Кояш белән бии Президент!..

Тимер капкаларны җимереп ачкан
Сугыш-ызгышлар да түгел бу.
Хөррият! дип, ярларыннан ашкан
Шатлык ярын каккан күңел бу!

Ә Президент бии,
мәйдан—чиксез,—
Үзе дәшә якты уйларга:
Республикам, керә егет чагың,—
Кыю алыш
сабантуйларда!

Күңелләрдә балкый безнең кояш,
Бер кояш ул, миргә бер кояш.
Ил вә халык һәрчак бәхетле ул
Шул кояшның берлеген тойгач!

Аяз гына булмас, без—күнеккән,—
Булыр әле,
каплар болыт та...
Тик син, халкым, гомер
Президентның
Бүгенгедәй
биюен
онытма!

Биюләрен күргән инде халкым
«Империя» дигән диюнең...
Күрсәк иде алда
Илбашының
«Без—мөстәкыйль!» диеп
биюен!

Ил түрендә якты август балкый,
Бар гавамны дәшеп
бәйрәмгә.
Дулкынлана гөлләр Сабантуе,
Мең яшьлек чал
Казан әйләнә.

# Чәчмә әсәрләр



Радик
Фәизов

## ГАДЕЛЛЕК ИЯСЕ

ХЫЯЛЫЙ ПОВЕСТЬ

*«Табигать безгә вакыйгаларның чиген белү сәләтен бирмәгән...»*
Цицерон.

### Дустым Нурул

Соңгы вакытларда безнең эшчеләр бистәсендә берсеннән-берсе сәеррәк хәлләр була башлады. Күзгә күренми торган җан иясенең бистә халкына ияләшеп, кемнәргәдер игелек, ә кемнәргәдер зыян-зәүрәтләр кылуы турында иде бу хәбәрләр.

Шунысы игътибарга лаек: ошбу хикмәтләр минем җан дустым Нурулның фаҗигале үлеменнән соң башланды. Дустымның үлеме белән әлеге сәер хәлләр арасында ниндидер бәйләнеш бар шикелле тоела иде миңа. Чөнки әлеге хәлләр, ул исән вакытта хыялланган гамәлләргә бик тә охшаганнар иде шул...

Тулы исеме аның Нурул түгел, Нурулла. Аны мин шулай үзгәрттем, әле үзебез малай чакта ук. Чыннан да, Нурул-ла-а дип сузып торганчы, Нурул дип кенә куйсаң, кыска да, ничектер, ансат һәм яңгырашы да матур.

Аның белән яшьтәшләр без, бергә уйнап үстек. Туган йортларыбыз да янәшә генә, үзебез торган зур бистәнең бер читтәге, елга яры өстендәге аулак урамында. Без балачакта җан дуслар, барча эч серләребез уртак, кайбер бүтән малайлар шикелле үзара үпкәләшеп, чәкәләшеп тә йөрмәдек. Тик менә, шулкадәр дус булсак та, тату яшәсәк тә, буй-сыннарыбыз, холкыбыз белән без бер-беребезгә һич тә охшамаган. Миңа карасаң, хәзерге көндә мин уртача гына буйлы, бик хәрәкәтчән, тәэсирләнүчән, кызык-сынучан, тынгысыз бер егетмен, сөйләшергә дә яратам. Ә Нурул исә озын буйлы, иңсәләре киң, хәрәкәтләре салмак, ашыкмыйча йөри, һәр сүзен үлчәп, мәгънәле итеп кенә сөйләшә. Мин юка йөзле, житен чәчле бер сары пышлак булсам, Нурул тулы түгәрәк йөзле, дәү күзле, кые кара кашлары кызларныкыдай сызылып киткән, чибәр һәм күркәм егет.

Безнең әти-әниләребез дә гел үзгә. Минекеләр икесе дә гыйлемле,

гомерләре буена үзебезнең бистә мәктәпләрендә мөгаллимлек иттеләр. Ә Нурулныкылар исә икесе дә гади эшчеләр, кирпеч заводында эшлиләр. Шулай булса да, әти-әниләребез дә бик тату, әйбәт күршеләр, бер-берләренең хәлен сорашып, кунакка йөрешеп, үзара ихтирам белән яшиләр.

Әй уйнап та, йөреп тә карадык инде без Нурул белән малай чакларда! Җәйгә чыктык исә иртә баштан сүз куешабыз да, кояш белән бергә торып, үзебезнең йорт яны бакчасында эшлибез. Түтәлләрдән чүп утыйбыз, кыяр-кишерләргә су сибәбез. Рәшәткә аша бер-беребезне күреп торабыз инде. Көн аз гына эсселәнү белән күлмәк-чалбарларыбызны салып ташлыйбыз да, тау астындагы елга буена йөгерәбез. Чабып килгән көйгә, бер дә тукталып тормыйча, елга өстенә сикерәбез. Берни дә, тирләгән килеш суга керергә ярамый дигән сүзләр дә куркытмый безне. Безнең арттан калмыйча йөгереп, су буена минем сеңлем Лалә дә төшеп җитә. Ул яланаяк, озын балтырлы, чәчләрен тузгытып кулын болгый, безгә кычкыра:

—Алай ерак йөзмәгез, бик тирәнгә кермәгез! Суга батып китмәгез тагын...

Аннары, күп уйлап тормыйча, үзе дә суга, ин тирән төшкә сикерә, колачын киң җәеп йөзеп китә.

Монда шунысын да әйтим, минем сеңлем Лалә булса, Нурул ул берүзе, гаиләдә бер генә бала.

Янымда дустым Нурул булганда мин берничдән дә, беркемнән дә курыкмыйм. Серне чишеп кенә әйткәндә, безнең арадагы дуслыкның нигезендә дә нәкъ менә минем ул барында курыкмавым, аны ныклы таянычым, ярдәмчем һәм саклаучым итеп тоюым ята бугай. Табигатем белән мин әлләни батырлардан түгел. Урамга чыктым исә, анда иясез йөргән дәү этләрдән, усал ата казлардан, бәйләнчек малайлардан шүрли төшәм. Ә менә Нурул булганда...

Бервакыт шулай малай чакта, матур җәй көнендә урамга чыктым. Кулымда әле кичә генә әти үземә кибеттән алып биргән бик тә матур, кызыл төстәге уенчык автомобиль. Капкадан урам уртасына чыгуым булды, ике малай каршыма килеп тә басты. Мин аларны азрак беләм дә, болар Югары урамның яман да усал, сугыш чукмарлары.

—Машинаң тәти икән. Син аны безгә дә бир! Без дә уйныйк әле,—диде битенә эре сары сипкелләр төшкәне.

—Әйем, бирмим!—дидем мин.

—Синең әти-әниең укытучылар. Алар әле сиңа машинаны тагын алып бирерләр. Монысы безгә булсын!—диде әмер төсендә икенчесе, алдагы эре, калак тешләре күренеп торганы.

—Барыбер бирмим!—дип кабатладым мин. Ә үземнең инде арка җекләрем тирләп чыкты.

—Әһә, бирмисең? Алайса, без аны синнән тартып алабыз!—диде тегеләр.

Һәм, шик тә юк, алар миннән яңа уенчыгымны талап, үземне матур гына кыйнап та китәләр иде. Шул чакта капкасын киң ачып, Нурул килеп чыкты. Теге малайлар белән минем арага кереп тә басты. Күзләрен кыса төшеп тегеләргә карады, таза бармаклы кулларын икесенең дә иненә куйды.

—Нәрсә, малайлар, әллә уенчык кирәк булдымы сезгә? Кеше малына күзегез кыздымы?—диде ул, бер дә кычкырмыйча гына. Теге малайларның шунда ук кикрик шиңде.

—Әй, юк ла, Нурул... Безгә берни дә кирәкми. Без... болай гына, уйнап кына бит,—диделәр алар, бик юашланып һәм җәтрәк китеп тә бардылар.

Тагын шунысын сизеп йөрим, мин үзем генә түгел, сеңлем Лалә дә Нурулга сыена. Ә Нурул исә үзе дә Лаләне миннән дә артык күреп якларга, сакларга әзер тора кебек. Инде без бераз үсеп мәктәпкә дә йөри башлагач, Лалә төштән соң укыды. Мин Нурулның караңгы кичләрдә

безнең читтәге аулак урамнан ялгызы кайтып килгән Лаләне каршы алырга барганына күп тапкырлар шаһит булдым.

Ә кыш көннәрендә безгә тагын да күнелле була, бергәләп чаңгычана шуабыз. Нинди генә үр башларыннан төшмәдек без чаңгы белән, нинди генә текә ярлардан күзне дә йоммыйча аска сикермәдек?! Башта, әлбәттә инде, беренче чаңгы юлын Нурул сала. Менә ул үр башына менеп баса, әйбәтләп чаңгыларын турылый, күп уйлап, куркып тормый, «Эһе-һей!» дип, бер кычкырып җибәрә дә, бөркет сыман түбәнгә оча. Каршы һава агымы аның бүрек колакларын җилфердәтә, ә түбәнгә төшеп җиткәндә йөзе алсуланып чыга, күзләре тагын да очкынланган була. Нинди генә текә үрдән төшсә дә, Нурул бервакытта да егылмый. Без исә Лалә белән ул салып биргән юлдан да курка-курка гына төшәбез. Аска төшеп җиткәч, еш кына мәтәлеп карга да чумабыз. Нурул бу хәлдән эче катып көлә.

—Их, сезне... Аякка басып түгел, киез итеккә утырып төшәсез бит сез. Җансыз курчаклар кебек. Чаңгыны аякта сизәргә кирәк аны,—дип, безне шелтәләп тә ала.

Менә шулай гел бергә уйнап, бакчаларда гел бергә эшләп үстек без. Җәтрәк үсәсе, дәү буласы килеп ишек яңакларына сөялеп, буйларны үлчәдек. Ул чакта без ясаган киртекләр әле дә булса җуелмаган.

Мәктәптә дә без гел бергә, бер сыйныфта, бер парта артына утырып укыдык. Менә монда инде дустым миннән шактый калышты. Хәзер инде мин аңа ярдәмче һәм таяныч булдым. Дәресләрдә, кыен мәсьәләләр чишкәндә математика укытучысы Госман абый гел әйтеп тора:

—Һайт, Нурулла! Синең күзләрең кылыйланып калмагае. Мин шуннан куркам.

—Ни эшләп алай дисең, абый?—ди Нурул, уңайсызланып.

—Соң, күзеңне кыеклап Сәлихҗан дәфтәренә карыйсың бит син. Аннан гына күчерәсең!—ди укытучы һәм бөтен класс көлеп җибәрә. Минем дустым исә оялудан кып-кызыл була.

Гыйлемгә, укуга табигать биргән сәләте әлләни зур булмаса да, Нурул тырышты тагын. Урта мәктәпне тәки тәмамлап чыкты.

Тик менә мәктәптән чыккач инде, безнең юллар текә җәпләкәле булып, як-якка аерылды. Мине әти-әниләрем үз варислары—мөгаллим итәргә теләделәр. Һәм мин якындагы зур шәһәргә барып, институтка кердем. Ә Нурул исә үз язмышын икенче төрле хәл итте.

—Ярый, Сәлих дустым. Мин сиңа зур уңышлар телим. Тик үзем бүтән укып тормыйм инде. Минем аңа, үзең дә беләсең, тешем дә бик үтми. Кая булса да эшкә керәм. Мин әти-әниләрем шикелле гади бер эшче булам!—диде ул миңа. Һәм, кыска курсларда укыды да, электрик булып эшли башлады. Аягына озын тимер тырнаклар тагып, багана башларына менеп йөрде. Йортларга якты кертте.

Юллар аерылды, тик мона карап безнең арадагы дуслык һич кенә дә сүрелмәде. Мин һәр атнаның җомга көнне шәһәр яны поездына утырам да үзебезнең бистәгә кайтам, шимбә һәм якшәмбе көннәрендә өйдә булам. Нурул мине һәрвакыт көтеп, капка төбендә каршы ала. Аннары безгә кереп утырабыз, мин Нурулга уку хәлләрен сөйлим, аның эшен сорашам, ә кичләрен бергәләп йөрергә чыгабыз. Бистә уртасындагы мәдәният йортына яшьләр уеннарына, дискотекаларга барабыз. Мин инде, дөресен генә әйткәндә, азрак кызларга да күз сала, сүз кушкалый башладым. Үзегез беләсез, бу уңайдан егетләр арасында төрле хәлләр була... Тагын да дөресен әйткәндә, нәкъ менә шушы унайдан мин әле дә булса дустыма сыенам.

Нурул ул хәзер озын буйлы, спортчылар шикелле сыгылмалы гәүдәле, таза беләкле егет булып житеште. Болай күрер күзгә үзе сабыр, басынкы гына шикелле. Әмма аның шул сабырлыгында, басынкылыгында нииндидер эчке ныклык, көч сизелә. Теләсә кайсы хулиганны, нахалны урынына утырта алырлык ныклык һәм көч. Барча егетләр моны бик яхшы сизәләр

һәм минем дустыма ихтирам белән карыйлар. Шул ук вакытта ул теләсә кайсы кызның күзе төшәрлек тә егет. Әмма үзе әле кызларга бик карамый. Бервакыт мин бу шактый сәер хәлнең сәбәбен белергә уйладым һәм үзем өчен кайбер нәрсәләрне ачыкладым.

—Нурул дустым, син нигә кызларга болай боздай салкын әле? Әллә куркасыңмы алардан?—дидем мин көлеп.

Мондый сораудан ул шактый уңайсызланып, югалып калды. Тик бераз уйланып торгач кына, ояла төшеп әйтеп куйды:

—Минә ни... Лалә мәктәптә укып бетерсен инде. Әлегә Лалә кичләрен урамга чыгып йөри алмый бит. Аның дәресләр әзерлисе бар...—диде ул сузып кына һәм беркатлылык белән.

Мин исә эчемнән генә елмаеп һәм тантана итеп тә куйдым. Менә, әһә, имәндә икән чикләвек! Хәер, мин моны үзем дә күптән чамалап, хуп күреп тә йөри идем инде.

Бик тә әйбәт бу! Алар бик тә пар килгәннәр. Минем сеңлем дә хәзер урта мәктәпнең соңгы сыйныфында укый. Озын, зифа буйлы, алай бик чәчрәп чыгарга яратмый торган тыйнак, сабыр холыклы, сөйкемле, эшчән бер кыз булып үсеп килә.

Шулай итеп, без Нурул дустым белән атнасына ике көн гел бергә булабыз. Йорт эшләрен карыйбыз, бергәләп мунча ягабыз, анда бергәләп чабынабыз. Һәм бик күп нәрсәләр турында, төрле темаларга сөйләшәбез. Нурул үзенең эше турында миңа шактый кызыклы нәрсәләр сөйли.

—Менә син, Сәлихҗан дустым, югары белем аласың. Күп нәрсәләр ачыла бара инде сиңа. Ә, алып карасаң, минем эшем дә бик гади генә түгел бит. Беренчедән, мин нәкъ сугыштагы сапер шикелле, гел сак һәм уяу булырга тиеш. Әгәр чыбыклар буенча килгән электроннар агымы синең тәнең аша үтеп китә икән, бу бер дә кирәкле һәм рәхәт эш түгел,—ди ул көлеп һәм горурлык белән.—Икенчедән, син шунысын да искә ал, мин кешеләрдән һәрвакыт бераз өстәрәк, югарыда торып эшлим бит. Мин биеклектә, багана башында. Ә кешеләр аста йөриләр, тегендә-монда ашыгалар, үзләренең мең төрле мәшәкатьләре белән мәш киләләр. Шунда ул кешеләр, бөтен җәмгыять, бу дөньяның үзе турында да башка төрле фикерләр килә,—ди ул фәлсәфи төстә.

Фәлсәфи димәктән...

## Дустым алга атлый

Соңгы вакытта мин Нурулда, гомумән алганда, зур үзгәрешләр, яңарышлар сизә башладым. Безнең эшчеләр бистәсендә бик данлы китап кибете һәм бик бай китапханә бар. Дустым кисәктән генә китаплар белән дусланып китте, аларны кибеттән дә сатып алды, китапханәгә дә даими йөрде. Тиз арада дөнья әдәбияты белән танышып алды, техник һәм фантастик әсәрләрне аеруча яратып укуга бирелде. Шуның белән аның уй-фикерләре, гомумән, дөньяга карашы, һәм, күрәсең, холкы да икенчеләнде. Ул, әле кайчан гына тыныч холыклы, илдәге һәм дөньядагы хәлләргә шактый битараф, гамьсез генә караган бер эшче егет, бу тормышның барышы, сәясәт хакында уйлана, төрлечә фикер йөртә башлады. Ул шактый сәер фикерләрне алга сөрде, төрле хыялларга бирелде. Үземә ул китереп биргән сораулардан мин аптырап беттем.

—Син менә, Сәлихҗан дустым, югары уку йортында белем аласың. Киләчәктә зыялы, зур культуралы, гыйлем иясе кеше булачаксың инде син. Бәс алай икән, минем сиңа кайбер сорауларым бар. Бүгенге җәмгыятьнең гади бер әгъзасы, гади эшче буларак,—ди ул һәм үзенә һич тә хас булмаганча кайнарланып, ниндидер ачыну, үпкәләү, хәтта рәнҗү хисләре белән үзенең сорауларын яудыра башлый.—Ә ник әле бу дөнья болай төзелгән? Ни эшләп ул шулкадәр шөкерле-бөкерле, ни эшләп

анда, адәм балалары арасында шушы дәрәҗәдәге тигезсезлек хөкем сөрә? Ник әле берәүләр икешәр, өчәр катлы, җылы, якты сауналары, коену бассейннары булган, җәннәт кебек сарайларда яшиләр дә, икенчеләре әллә ничә гаилә бергә тупланып, читлек кебек тар, салкын, шыксыз тартмаларда көн итеп яталар? Ниндидер бер бөҗәкләр кеби... Акча дигән бик кодрәтле нәрсә берәүләрнең янында капчыгы белән тора. Ул инде кибетләргә чыкканда акчаны кесәсенә санап та тормыйча, бөгәрләп кенә тыга. Ә менә мин, шушы галиҗәнаб җылыда, яктыда, бик уңайда яшәсен өчен көннәр буе багана башында, ачы җилләр арасында эшләп йөргән кеше, ярты ел буена үземә тиешле гадел хезмәт хакымны да ала алмыйм. Кайда монда дөреслек, хакыйкать дигән нәрсә кайда? Соң, бу дөньяга кешеләр табигать тарафыннан, инде килеп Алланың үзе тарафыннан да бертигез итеп яратылмаган микәнни? Андый баскычларга кем бүлгән, ник бүлгән адәм балаларын? Кайда монда мантыйк дигән нәрсә? Син, зыялы дустым, рәхим итеп менә шушыларны аңлатып бир миңа!—дип таләп итә ул ярсу белән. Мин аптырашта калам. Чыннан да, ни дип җавап бирәсең аңа, тормышның барышын ничек аңлатып бирәсең? Болай тота-каба гына, үзең дә бик төшенеп бетмәгән көе...

—Юк, әгәренки кодрәтемнән килсә, мин бу дөньяны үзгәртер идем. Үземчә корыр идем мин аны,—дип дәвам итә Нурул, хыялый төстә.—Бу кадәрле тигезсезлеккә чик куяр идем мин.

—Ә ничек итеп?—дип кызыксынам мин.

—Моның юлы бик гади. Мин баеп киткәннәрнең, барча түрәләрнең, капкорсакларның акчаларын шатырдатып тартып алыр идем. Ул акчаларны бер чүмәләгә өеп, тиененә кадәр санар идем дә, һәркемгә тигез итеп бүләр идем. Эшләүчеләргә, эшсезләргә, йорт-җирсез сукбайларга, ярлыларга, түрәләргә, эшмәкәрләргә—җәмгыятьнең һәр әгъзасына тип-тигез итеп. Менә бу дөрес юл булыр иде!

—Моның дөрес юл булуына зур шик тотучылар бар әле. Әйтик, менә без,—дим мин.

—Ничек алай?!—ди ул, яңадан кабынып.

—Шулай! Чөнки нәкъ менә син әйткән табигать тарафыннан, бу дөньяга адәм балалары, дөрестән дә, тигез итеп яратылмаган. Ошбу дөньяның кеме юк, минем әти әйтмешли. Берәүләрнең сәләте, табигый мөмкинлекләре бик гадәти генә. Һәм болар үзләре дә гади кешеләр, гади эшчеләр, гади зыялылар. Урта бер катлам, әйтик, менә синең белән мин. Һәм болар әлләни зур байлыкларга, биек урыннарга өмет тә баглый алмыйлар. Ә менә икенчеләр исә бөтенләй бүтән калып басмасы. Алар инде сәләтле, булдыклы, хәйлә кору, алдан күрә, исәпли белү кебек сыйфатларга ия. Менә мондыйлар инде тормышта да, җәмгыятьтә дә керемле, югары урыннарны билəп алалар, зур дәрәҗәләргә ирешәләр. Тормышта һәм җәмгыятьтә тоткан урыннарына тәңгәл рәвештә, аларның табышы да мул була. Димәк ки, алар үзләре билəгән байлыкларга да хаклы рәвештә ия. Алардан байлыкларын, акчаларын тартып алу, аны бүтәннәргә бүлеп бирү, бу—гайре табигый гамәл, бик тә сәер бер эш булыр иде. Чын җинаятькә тиң гамәл. Алар бит бу байлыкларны берәүдән дә тартып алмаган, алар бу акчаларга хаклы рәвештә хуҗа, Нурул дустым!—дим мин.

Ә Нурулның йөзе кызарынып китә, күзләрендә ачулы очкыннар кабына.

—Син дә сөйлисең сүз! Дөрес әйтмисең син, Сәлихҗан!—ди ул ярсып. Гаделлек түгел бу. Алар кулында нәкъ менә талап, хәтта урлап җыелган байлыклар, бик беләсең килсә! Кайчандыр бөтен илнеке, бөтен халыкныкы булган байлыкларны үзләштерделәр алар. Турыдан-туры булмаса, төрле әйләнгеч юллар белән. Әнә шул син әйткәнчә, хәйлә кору юлы белән.

—Нәкъ менә килеп тә чыктык бит инде! Димәк ки, кеше сәләткә ия икән, ул бүтәннәрдән әйбәт яшәргә дә хаклы булып чыга. Тормышның,

җәмгыятьнең законнары да шундый аның, дустым,—дим мин.

—Барыбер дөрес түгел бу!—дип каршы төшә Нурул.—Димәк ки, андый законнарга нигезләнгән җәмгыять үзе үк гадел түгел. Димәк ки, ул җәмгыятьнең үзен үзгәртеп корырга кирәк.

—Ә ничек итеп?

—Шундый җәмгыять корырга кирәк ки, анда барча байлыклар тигез бүленсен. Сәләтлеләргә дә һәм бернинди сәләтсезләргә дә тигез итеп. Һәм моны каттый законнар белән ныгытырга кирәк. Адәм баласының бу дөньяга нинди итеп яратылуына ул үзе гаепле түгел бит. Бер генә тамчы да! Ни өчен ул аннан иза чигәргә тиеш? Димәк ки, тигез хокук, тигез тәэмин ителеш булсын. Яна җәмгыять әнә шундый булсын!

—Һә, яна җәмгыять, имеш!—дим мин көлеп һәм бу юлы инде үзем дә ачынып.—Бернинди яналык түгел бу. Моңа охшашлы җәмгыятьне әле күптән түгел генә төзеп карадылар бит инде. Аз да түгел, күп тә түгел, ә житмеш биш ел буена яшәде бу җәмгыять. Шуннан нәрсәләр килеп чыкты, җә? Аларын үзең дә беләсең бит инде. Бик яхшы беләсең...

Тик Нурул һаман да бирешми, үз фикерендә кала.

—Димәк ки, безнең әти-бабаларыбыз ул җәмгыятьне гадел итеп төземәгәннәр. Бөтен якларын да уйлап, исәплән бетерә алмаган алар. Шуңа күрә зур ялгышлыклар җибәрелүгә юл куйганнар. Янабаштан төзеп карага кирәк ул җәмгыятьне. Барысын да уйлап, һәр якны искә алып. Бу дөньяда бер генә зур гамәлнең дә беренче талпынуда гына чынлап тормышка ашканы юк әле, барысы да ялгышлыклар, эзләнүләр, төзәтүләр белән бирелә,—ди ул, уйчанланып һәм катгый нәтиҗә ясап куя.—һәрхәлдә, хәзерге көндә җәмгыятьтә урнашкан бу кадәр тәртипсезлеккә, тигезсезлеккә, законсызлыкка, вәхшәткә чик куелырга тиеш!

Менә монысы белән мин дә тулысынча килешәм.

Без, яшьләр уеннарыннан кайтканда капка төбендәге эскәмиягә утырабыз да, төннәр буе диярлек шулай бәхәсләшәбез. Аерылышабыз, тагын күрешәбез һәм... тагын сәясәткә кереп китәбез. Безнең бу бәхәсләрнең иге-чиге күренми, анык кына бер нәтиҗәгә, ачык фикергә дә килеп булмый. Ни эшләргә?! Менә шушы конкрет сорауга һич кенә дә җавап табып булмый. Кайчак Нурул барысына да кул селти дә, төрле уйларга, бөтенләй дә төпсез хыялларга бирелә:

—Их, менә мин чиксез бер кодрәткә ия булсам икән ул...—дип куя.

Без шундый уйлар белән йөргәндә генә...

## Дустымның үлеме

Ул шимбә көнне, каладан кайтканда поездга кереп утыру белән нигәдер күнел тынычлыгым югалды, эчем поша башлады. Юл буе беркем белән сөйләшәсем килмичә, үземне кая куярга белмичә кайттым. Инде бистәнең шау-шулы үзәген үтеп, үзебезнең аулак урамга килеп керүгә, күнелем тынычсызлануы тагын да көчәйде. Кичке энгер-менгер дә кисәк кенә төшеп, урам каранrыланып киткәндәй булды. Үзем дә аптырыйм, ни хәл инде бу? Аяк астындагы көзге пычракны ерып, үзебезнең йортларга якынлашам, ә күнелдәге шом арта гына бара. Нуруллар йортының капка төбе, анда мине дустым көтеп торырга тиеш. Күрәм, капка төбендә кемдер бар, әмма бу озын буйлы Нурул түгел. Якынрак килгәч, танып алдым, бу дустымның әтисе Нотфулла агай, инде сиксәненә якынлашкан, гәүдәсе бөкрәйгән карт иде. Ул мине күрүгә каршыма атлады, калтыранган кулларын миңа таба сузды.

—Һай, Сәлихҗан энем... Бездә кара кайгы бит әле! Безнең улыбыз, берданбер Нуруллабыз һәлак булды. Моннан ары сине дустың капка төпләрендә каршыламас инде. Ул бу якты дөньяларда юк инде,—диде карт, тирән хәсрәт белән күз яшенә буылып.

Башыма күсәк белән китереп ордылармыни! Тәмам тетрәнеп, катып калдым. Бу коточкыч хәбәрне күңелем белән дә, йөрәгем белән дә һич кенә дә кабул итә алмадым. Тукта әле, ничек инде ул алай? Әле үткән атна башында гына мине шушы урында озатып калган егет ничек инде... дөньяда юк?! Төрле уй-хыяллар белән тулган, тап-таза күкрәп торган ярь-яшь егет. Һич кенә дә ышана алмадым.

—Ни сөйлисең син, Нотфулла абый? Чынмы бу?—дидем.

Карт җавап бирә алмады. Бары тик үксеп кенә куйды.

—Ни эшләп һәлак булды? Кайчан булды бу хәл? Җирләдегезме инде?—дип өзгәләндем мин.

Бу сорауларга картның җавабы тагын да коточкыч булды:

—Утта янып үлде Нурулла дустың. Берние дә калмады, гәүдәсе дә, кием дә. Ичмасам кәфенлек кидереп күмәрлек җәсәде дә калмады баламның...—диде карт, чиксез хәсрәт белән. Һәм, бераз тынычлана төшкәч, миңа бу фаҗиганең ничек булганын сөйләп бирде.

Нурул бистәнең йортлар идарәсендә эшли иде. Шул идарәдә иртә баштан янгын чыккан. Кемнендер саксызлыгы белән гаражда торган бензин ташый торган мичкәле машинага ут капкан. Мичкәсендә туп-тулы бензин булган машинага. Аны җәтрәк гараждан алып чыгарга, җайлы урында сүндерергә, һичьюгы янәшәдәге тирән чокырга төшереп җибәрергә кирәк була. Әмма янып торган машина янына тар гаражга барып керергә беркемнең дә йөрәге җитми. Җыелган кешеләр янгынчыларны көтеп, бер-берсен куәтләп тик тора. Шунда каяндыр Нурул килеп чыга, хәлне белеп алуга, тукталып та тормастан, гараж капкасына йөгерә. Аның машина кабинасына кереп утырганын да күреп калалар.

Шул ук мизгелдә бөтен тирә-якны иләмсез көчле шартлау тетрәткән. Гараж эчен күзләрне йомдырырлык ап-ак ут ялкыны тутырган, түбә каерылып күккә очкан, ялкын өскә, әллә кайларга кадәр күтәрелгән. Аны бик озак сүндерә алмаганнар, ут ике сәгать буена котырган. Күп тырышлыклар куеп, ниһаять, янгынны сүндерәләр, гараж эченә үтеп керәләр һәм «аһ!» итәләр. Мондагы хәлне күреп кешеләр тәмам тетрәнеп калалар. Гараж эчендә чын мәхшәр булган, әле яңа гына алып кайтылган машинадан кәкрәеп, каралып беткән тимер-томыр өеме генә торып калган. Ә менә предприятиенең мактанычы булган, бөтен иптәшләре, җитәкчеләре дә шундый яраткан электрик егет Нурулладан берни дә калмаган. Аның гәүдәсе, сөякләре, кигән киемнәре—барысы да янып төтенгә әйләнгән, каядыр һавага очкан. Әлбәттә инде, милиция дә килеп җиткән. Барысы да бергәләп гаражның барча почмакларын актарганнар, һәр карыш җирен тикшереп чыкканнар. Күпме эзләп тә гаип булган егетнең бер генә нәрсәсен дә, ичмаса кесәсендә йөртә торган тимер кисәкләрен, төймәсен генә булса да тапмаганнар. Бар халык шунда утырып елаган. Гаражның Нурулла җан биргән дип чамалаган урынын иптәшләре нәни чардуган белән әйләндереп алганнар.

Шулай итеп минем җан дустым, яшьтәшем, сабакташым, күршем Нурулла бу якты дөньядан бөтенләй юкка чыкты. Гаип булды ул, тирән упкынга төшеп киткәндәй булды. Яннарына барып йөрергә ичмасам кабере дә калмады.

Аның инде икесе дә бик олыгайган әти-әниләре өсләренә көтмәгәндә ишелеп төшкән бу тиклем авыр хәсрәтне күтәрә алмадылар. Тиз арада тәмам рәтләре китте, хәлсезләнделәр, зиһеннәре чуалды, урын өстенә егылдылар. Һәм озак вакыт үтмәстән, берсе артыннан икенчесе гүр иясе дә булдылар. Нурулның бүтән туганнары, якын кардәшләре юк иде. Ул, онытылмас якты бер хатирә булып, минем һәм сеңлем Лаләнең күңелендә генә яшәп калды.

Ярсу йөрәге, бөтен барлыгы белән гаделлеккә омтылган, бөтен уй-фикерләре, ният-хыяллары белән халыкка хезмәт итәргә әзер торган, үземне яклаучы һәм таянычым да булган дустымны мин бик озакка кадәр, еллар буена юксындым. Аның белән бергә уйнап-үскән балачагым-

ны, бергә егет булып йөргәннәремне, кызып-кызып бәхәсләшүләребезне, барча сөйләшкән сүзләребезне, ул әйткән кискен дә, бераз сәер дә фикерләрне берәм-берәм хәтерләп сагындым. Каладан кайтып үзебезнен урамга килеп кердем исә, мине газаплы уйлар, үкенечләр биләп алды. Кайткан саен капка төбендә мине дустым Нурул көтеп торадыр, ул елмаеп каршыма килеп чыгар кебек тоелды. Кайчак хәтта аның озын буйлы, нык инсәле гәүдәсен ап-ачык күргәндәй булам, имәнеп китәм. Аның инде дөньяда юклыгына һич кенә дә ышанасым килми.

Бик сизенеп йөрим, безнен күршебез Нурулланы, түгәрәк йөзле, куе кара кашлы күркәм егетне минем сеңлем Лалә дә бер дә оныта алмый. Без Лалә белән бергә килсәк, еш кына, үзебез дә сизмәстән, Нурул турында сөйләшеп китәбез. Лалә мәктәптән кайтканда Нурулның аны ничек каршы алуларын, су коенганда да сиздермичә генә гел үзен саклап йөрүләрен, чаңгы шуганда да күзәтчелек иткәнен сөйли һәм... авыр итеп көрсенеп куя. Алай гына да түгел, кайчак мина сиздермәскә тырышып кына елап та алгалый. Үзе белгән догаларын укый, каршы йортта торган диндар карчыкка садакалар бирә.

Әмма бит тормыш дигәнен ул бернигә дә карамыйча алга бара, һәркемнен үз мәшәкатьләре, борчулары килеп туа. Ул арала безнен йортка да зур кайгылар килеп керде. Башта инде бик картайган әтиебезне, аннан озак та тормый әниебезне дә җирләдек. Өйдә сеңлем Лалә белән икебез генә торып калдык.

Еллар үтте, мин инде институтны тәмамладым. Каядыр еракка китеп йөрмәдем, үзебезнең бистәдәге педагогия колледжына укытучы булып кайттым. Кем әйткәндәй, баш-аягым белән эшкә чумдым. Сеңлем Лалә, теге чакта Нурул кебек үк, урта мәктәпне тәмамлагач, инде бүтән укып йөрмәде. Бистәдәге тегү-чигү фабрикасына эшкә барып керде. Соңгы елларда Лалә бик нык үзгәрде. Кайчандыр сөякчән, озын балтырлы бер кызчык, хәзер калку буйлы, шактый тулы һәм төз гәүдәле, чибәр генә кыз булып үсеп житте. Үзе эшчән, әле фабрикадан кайткач та барысына да өлгерә, бөтен хуҗалыкны ялт иттереп алып бара. Үзе бик сабыр холыклы, бик тыйнак, хәтта артыгын да тыйнак бугай әле. Кичләрен дә бик чыгып йөрми, егетләр белән танышлыгы да сизелми. Хәер, әле мондый гамәлләргә вакыты бар, егермесен тутырып кына килә.

Үзем—колледжда математик, эшемне яратам, иптәш—хезмәттәшләрем, укучыларым да мине хөрмәт итәләр кебек. Эш күп, көннәрем шул колледжда үтә. Таныш кызларым күп булса да, чынлап торып күзем төшкәне юк әле. Өйләнмәгән егет килеш йөри бирәм, бу арада гына гаилә корырга да исәбем юк.

Тормыш менә шулай барганда гына...

### Тагын Нурул!

Кышкы кичләрнен берсе. Мин үзебезнең өйдә иртәгә буласы дәресләргә әзерләнеп, планнар төзеп утырам. Бүген шимбә, мин өйдә ялгызым гына. Сеңлем Лалә соңгы вакытларда ял көне житте исә, авылдагы туганнарыбызга кунакка барырга галәтләнеп китте. Анда аңа, авыл кызлары һәм егетләре белән күңелле, күрәсең.

Мин укыйсымны укып, язасымны язып бетердем дә, өйдәге барча утларны сүндереп куйдым, тәрәзә пәрдәсен ачып, урамга карадым. Анда матур кышкы кич, салмак кына, кыеклап кына гаҗәеп эре кар бөртекләре төшә. Менә шулай үзем ялгыз калган кичләрдә өйдәге барча утларны сүндереп, тәрәзәдән тышка карап утыруны яратам мин. Өйдә куе караңгы, ә тышта кар яктысы. Барча нәрсәләр, каршыдагы якты тәрәзәле йортлар, якындагы яңа салынган мәчет, аның биек, очына ярымай куелган манарасы, урамнан сирәк-мирәк үтеп йөргән кешеләр дә ап-ачык булып, шул ук вакытта ничектер кызыклы, серле булып күренәләр. Дөньяда

тынлык, рәхәтлек, хозурлык! Көллияттә үткән шау-шулы, мең мәшәкатьле көннән соң монда иркенләп ял итәсең.

Бүген дә байтак шулай хозурланып, күңелемә тынычлык җыйнап утырдым. Инде өйдәге утларны алындырырга, телевизорны кабызып җибәрергә дә җыенган идем. Шунда һич көтелмәгән хәл булды. Ишек ягыннан, куе караңгылыктан пышылдаган кеше тавышы ишетелде:

—Сәлихҗан!

Мин дерт итеп сискәндем. Бу ни хәл бу тагын, ниткән тавыш бу?! Мин бит өйдә берьялгызым... Мин, бернинди җеннәргә, шайтаннарга ышанмаган атеист булсам да, яман да куркып, аптырап калдым. Әллә юкса күңелемдә, колагымда гына яңгырап ишетелдеме бу тавыш? Алай дисәң, мин аны аерым-ачык ишеттем, хәтта ул тавыш ничектер таныш та булып тоелды. Бу ни хәл инде бу? Мин бүлмәдән, өйдән үк чыгып таярга җыендым. Әмма шунда теге тавыш тагын кабатланды:

—Сәлих дустым, зинһар дип әйтәм, курыкма. Мин бу!

—Кем син? Нишләп йөрисең монда?—дидем мин, барча батырлыгымны туплап.

—Мин бу. Синең дустың Нурулла,—диде тавыш, ап-ачык итеп.

Тагын коелып төштем. Ничек инде ул алай—Нурулла? Әллә кайчан һәлак булган, тимерләрне эретерлек ут кибәне эчендә калып төтенгә әйләнгән, бу дөньядан гаип булган Нурулла?! Шунда минем барча куркуларым каядыр юкка чыкты, үртәлүгә, ачуга әйләнделәр алар. Тукта әле, тикмәгә түгел бу... Тәгаен генә кайсыдыр шаяра. Әллә кайчан вафат булган дустымның тавышы белән эндәшеп өркетмәкче, көлкегә калдырмакчы була. Ну, хәзер беләбез аның кем икәнен... Шунда ук ялт иттереп түшәмдәге зур люстраны кабыздым. Ишек яннарын карадым, почмак якка, йокы бүлмәсенә дә кереп чыктым. Бернинди адәм заты, шаяртучымазар юк. Тынычлана төшеп, җиңел сулап куйдым. Куркырлык берни дә юк икән. Бер саташу, утырган җирдән йокымсырап төшләнү генә булды, ахырысы, бу. Соңгы вакытта көллияттә эшләр дә бик тыгыз, нервлар да киеренке булган иде шул. Инде тәмам тынычландым дигәндә генә теге тавыш янадан ишетелде:

—Син, Сәлих дус, онытма. Синең дустың Нурулла үзе булам мин,—дип кабатлады ул.

Мин, тәмам гаҗиз калып, як-ягыма карандым. Яп-якты бүлмә, якында гына тере кеше тавышы да бар, әмма бүлмәдә, ишек катында да беркем юк, беркем дә күренми.

—Сон, әгәр чыннан да Нурул икәнсең, ник әллә кайларга яшеренеп сөйләшәсең аны? Качышлы уйнаган бала-чага шикелле. Ник күземә күренмисең дә, ник каршыма килеп басмыйсың? Ышанмыйм мин сиңа!—дидем мин, тәмам җенем чыгып.

—Син гафу ит, дустым. Мин хәзер сиңа күренә алмыйм шул. Бик теләсәм дә. Мин хәзер күзгә күренми торган кешегә әйләндем,—диде ул. Бу тавыш куанычлы да, ничектер монсу да булып ишетелде. Һәм, шайтан алгыры, бу чыннан да минем дустым Нурул, һәрхәлдә, бу аның тавышы иде. Бу сузынкы, салмак аһәңне мин меңнәр арасыннан танып алыр идем. Янә дә чиксез аптырап, әмма бераз тынычлана да төшеп, диванга килеп утырдым.

—Син... Тукта әле, Нурул дустым. Син инде күптән һәлак булдың бит. Ничек инде хәзер—син исән? Ничек инде син... минем күзгә күренмәс кеше? Гафу ит, тик мин моңа ышана алмыйм. Башым да җитми, акылыма да сыймый бу минем!

Авыр көрсенгән тавыш ишетелде:

—Ничек исән калуларымны, болар барысы да ничек булганын соңыннан сөйләп аңлатырмын. Ә хәзергә... минем бу дөньяда чыннан да бар икәнемә ышан син. Күзгә күренмәс зат икәнемә ышан. Болары—ин кирәге бит. Һәм мин сиңа аларны раслап та бирим. Мин кулыма алган, миңа орынып, кагылып торган барча әйберләр дә шунда ук күренмәс

була. Менә мин хәзер өстәлдәге бер китапны кулыма алам. Син шуны карап тор!

Мин бик тә дулкынланып, аннан да битәр кызыксынып, бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәлгә текәлдем. Анда минем дәреслекләрем таралып ята. Менә берзаман, чыннан да, бернинди тавыш-тынсыз, хәрәкәтсез генә бу китапларның берсе юкка чыкты, аннан икенчесе... Шунда яткан кызыл карандаш та гаип булды. Мин исә тамам хайран булып, авызымны ачтым да калдым.

—Менә күрдеңме инде, күрдеңме?!—диде күзгә күренмәс Нурул. Шайтан алгыры, бу чыннан да шул—минем дустым иде. Тавышы, сүзләрне сузып әйтүләре, нәкъ үзе! Һәм ул үзе дә каядыр шушында, янәшәдә генә. Мин хәзер моны тоям, хис итәм. Бик сәер, гаҗәеп, кызыклы да бер хәл иде бу!

—Күрүен күрдем дә, тик һаман да ышанып җитә алмыйм әле. Дустым Нурул, син исән! Син, күзгә күренеп тормасаң да, бу дөньяда бар. Моннан да зур шатлыкның булуы мөмкинме? Янıма кил, бер күкрәгемә кысыйм үзеңне, гәүдәләреңне, җисемеңне тоемлыйм. Аннары, бәлки, бу могҗизага ышана да алырмын,—дидем мин һәм идән уртасына басып, кулларымны як-якка җәеп җибәрдем. Әмма ләкин беркем дә минем янга килмәде, кочагым буш калды.

—Син мине тагын гафу ит, Сәлих дустым. Сиңа кулымны биреп күрешүдән, кочаклап алудан, сиңа килеп орынудан да сакланып торам әле мин. Синең сәламәтлегеңә нинди дә булса зыян салудан шикләнәм. Әнә диванга барып утыр, тынычлан. Болай гына сөйләшеп утырыйк әле. Борчылма, мин гел шушында, синең янында гына булам,—диде Нурул.

—Алай да... искитмәле бит бу! Башларың эшләмәс, миләрең кирегә әйләнер бу хәлгә. Ничекләр итеп кеңә исән кала алдың син? Кибән чаклы ут эчләрендә калып төтенгә әйләнгәннән соң... Ничек итеп күзгә күренмәс булдың?—дип, тезеп киттем мин сорауларымны.

—Барысын да тәртибе белән сөйләп, аңлатып бирәм. Син инде бүлдермичә генә тыңлап тор,—диде Нурул һәм ашыкмый гына сөйләп китте. Нәкъ гадәти бер хәлне бәян иткәндәй генә.—Ул чагында мин тәвәккәл иттем, ут капкан машина янына, гаражга йөгереп кердем, кабинага да менеп утырдым. Аны чигереп урамга чыгарсаң гаражны да, андагы барча машиналарны да янгыннан саклап калырга була иде әле. Бу бик хәтәр булса да мин тырыштым инде, үзем эшләгән оешма бит... Әмма мин машинаның моторын кабызып җибәрүгә коточкыч шартлау булды, күрәсең. Мин ниндидер бер иләмсез куәтнең үземне югарыга, коточкыч кайнарлык эченә чөеп җибәргәнен генә сизеп калдым. Аннары инде минем өчен ни дә булса тоемлау, тирә-яктагы тормыш, дөнья үзе дә бетте,—диде Нурул, авыр көрсенеп һәм дәвам итте.—Әмма, дустым Сәлих, без дөньяның төзелешен, Галәмне, аның законнарын бик тә аз, чыпчык борыны чаклы гына беләбез икән. Бактың исә, дөнья дигән нәрсә ул бер генә түгел икән әле. Без, кешеләр, ягъни акыл ияләре, Галәмдә ялгыз түгел икәнбез. Галимнәр бар икәнен сизенеп, чамалап, исбатларга тырышып йөргән янәшә дөньялар дөрестән дә бар икән. Җитмәсә, анда акыл ияләре, нәкъ безнең кебек кешеләр дә яши икән. Һәм алар янәшәдә генә, менә шушында, без яшәгән пространствога керешеп үк яталар икән. Тик без аларны берничек тә сизмибез, ишетмибез, белмибез дә...

—Һе, алай диген, ә!—дидем мин, бу ишеткәннәремнән тәмам таң калып.—Ә син, дустым, боларның барысын да кайдан белдең әле? Шушы кадәр лекция сөйләрлек итеп.

—Машинаның бензин цистернасы шартлаган мәлдә, ут кибәне уртасында бик югары температура хасил булган. Минем гәүдәм янып көлгә калмаган, ә турыдан-туры парга гына әйләнгән. Ягъни аерым атомнарга таркалган,—диде тавыш гади генә итеп.—Шул ук югары температура, янәшә яшәп яткан ике дөнья арасында, бик тар гына булса

да, ярык хасил иткән. Бу ярык нәкъ минем атомнарым турысында ясалган, атомнар шуннан безнең дөньядан янәшә дөньяга күчкәннәр. Бәхеткә каршы, барысы да, өере белән. Ә ул дөньяның акыл ияләре бу хәлдән хәбәрдар булып, аны күзәтеп торганнар. Аларда фән һәм техника без бөтенләй дә күз алдына китерә алмастай дәрәҗәдә. Аларның приборлары минем атомнарымны барчасын да, берсен дә калдырмыйча җыйнап алганнар. Һәм алар мине, нәкъ үзем шикелле итеп, янадан ясап та куйдылар. Менә асылда нинди ансат һәм гади генә бит ул!—диде Нурул, күнелле итеп.

—Ә бу күзгә күренмәвең ничек килеп чыкты? Аның кеше ышанмаслык могҗизасы да нәкъ менә күзгә күренмәү бит әле, дустым,—дидем мин.

—Бәс алар ясаган икән, мин инде бу дөнья кешеләре күзенә күренмәс булам. Һәм алар үзләре дә безнең күзгә күренмиләр. Янәшә дөньялар шулай корылган алар,—диде тавыш.

—Әгәренки... үзең теләсәң, син кеше күзенә күренә торган була аласыңмы? Әйтик, менә мина?—дип, сорашуны дәвам иттем мин.

—Менә бу кадәресен мин төгәл генә белмим дә әле, дустым. Мөгаен, әгәр үзем телим икән, алар мине күренә торган итәаладыр. Аларда бит кодрәт чиксез... Мин ул дөньяга чыкканда бу хакта алардан сорармын әле,—диде Нурул, гамьсез генә.

—Хикмәт! Син бу дөньядан тегесенә кереп-чыгып та йөри аласыңмыни әле? Күршегә кереп чыккан шикелле...—дидем мин, тагын таң калып.

—Теләгән вакытымда. Аның өчен миндә махсус җайланма, прибор бар. Югалмас өчен мин аны муеныма бөти төсле итеп тагып йөрим. Әгәр телим икән, черт! Төймәсенә генә басып куям. Күз ачып йомган арада абзаң алар янында, ягъни янәшә дөньяда була!—диде тавыш, шактый ук һавалану белән.

—Алай булгач... нигә дип еллар буена юк булып тордың син?! Ник инде әллә кайчан минем яныма килмәдең? Бер дә дусларча түгел инде бу.

—Сон, дустым, үзең уйлап кара. Кеше кадәр кешене атомнардан берәмтекләп җыеп куярга. Моңа аларның да күп вакытлары киткән. Мине еллар буе җыйганнар.

—Болай... үзләре нинди(е)рәк соң алар? Нинди инсаннар? Төскыяфәтләре, гәүдә төзелешләре нинди? Ул дөнья үзе нинди, андагы табигать, авыл-шәһәрләр ни рәвешле? Барысын да сөйләп бир!—дидем мин, бик кызыксынып.

—Барыбыз да бер үк Җир шарында яшәп ятабыз. Шулай булгач, табигать законнары да уртак,—дип сөйләп китте Нурул.—Андагы җан ияләре дә килеш-килбәтләре белән бездән әлләни аерылмыйлар. Шул ук ике кул, ике аяк, күрү-ишетү әгъзалары. Гәүдәнең зурлыгын һәм буйсын рәвеше дигән нәрсәләрне дә Җирнең тарту көче билгели икән. Тик менә алар барысы да пигмейлар кебек, буйга бездән шактый кыскалар. Уртача буйлары метр ярымнан артмый. Ә менә бәдәннәре калын, нык, башлары бераз озынча, колаклары зур. Дөресен әйтим, күрер күзгә әлләни сөйкемле түгелләр. Хәтта, үзләре дә мине бик сөйкемле тапмадылар бугай, шулайрак сизендем,—диде Нурул көлеп.—Ә инде андагы техниканы, машиналарны, приборларны сөйләп тә, аңлатып та бетерерлек түгел. Алары инде безнең гакыл дәрәҗәсеннән күпкә өстен. Тормыш-яшәешләрен дә безнеке белән берничек тә чагыштырып булмый...—диде Нурул һәм никтер сабырсызлана төшеп дәвам итте.—Мин сина боларның барчасын да тагын сөйләрмен әле. Ә хәзергә... мин үземнең хыялыма ирештем бит, дустым! Шундый могҗизалар аша үтеп булса да. Мин—кешеләр күзенә күренмәс зат! Без синең белән чиксез кодрәткә ия бит хәзер. Менә шуны уйлыйк без хәзер. Ниләр эшлибез? Минем бу кодрәтемнән, мөмкинлекләремнән ничек файдаланабыз? Беренче нәүбәттә менә

шуларны хәл итик без!—диде Нурул. Ул боларны иләндә әрле-бирле йөренеп сөйләде, күрәсең. Тавышы аннан-моннан ишетелеп торды.

—Соң, ниләр генә эшләрбез икән без синең белән?—дидем мин, бик аптырап кына. Чыннан да, бик кыен, четерекле сораулар китереп куйды әле бу. Хәл итәргә бик авыр мәсьәләләрне. Мин ни дип әйтергә дә белмичә аптырап калдым.

—Әйдә, эшне тотабыз да моннан башлыйбыз!—диде Нурул, күтәренкелек белән.—Мин сине иртәгә үк машиналы итәм. Иртәгә үк сиңа үзең теләгән машинаны сатып алырлык акча бирәм. Юкса—нәрсә инде бу? Минем дустым артын сузып көллияткә җәяүләп йөри. Шушы ерак урамнан бирле. Менә бүтәннәр кебек машинада гына сызгырып узарсың моннан ары. Иртәгә үк машиналы итәм мин сине!

Мин чын-чынлап куркуга төштем.

—Зинһар эшли күрмә моны! Син бит, дустым, минем кем икәнлегемне бик яхшы беләсең. Әти-әниләрем кемнәр булганын, нинди гаиләдә тәрбия алып үскәнемне. Мин бу дөньяда хәләл көчем белән эшләп тапканга гына яшәргә күнеккән. Катгый рәвештә! Бу—минем тайпылмас кыйблам,—дидем мин.

—Син... шундый идеяле зат инде. Мин моны уйлаган идем,—диде ул, кәефе бик тә кырылып. Шактый вакыт сүзсез торды. Аннары ниндидер бер эчке дулкынлану, өметләнү белән үзенең, күрәсең, иң соңгы чиратка куйган, әмма иң мөһим соравын бирде.—Ә Лалә кайда соң әле безнең? Ул ник өйдә түгел? Ул бәлки кияүгә дә чыгып киткәндер инде...

—Юк, дустым, безнең Лалә бернинди дә кияүгә чыкмады ул. Алай гына да түгел, егетләр белән йөргәне дә күренми әле. Кичә генә ял көне дип, үзебезнең авылдагы туганнарга кунакка китте. Шунысын да әйтим, озын буйлы, кара кашлы күрше егетен онытa алмый йөри бугай ул, әле һаман да...—дидем мин көлеп.

Бу хәбәр дустыма бик көчле тәэсир итте, күрәсең. Күкрәгеннән шатлыклы авазлар атылып чыкты:

—Менә Лаләне... замана байларына тиңләп куям мин. Юк, алардан да өстен итәм мин аны. Зиннәтле сарайлар салдырам, бассейннар казытам, гөбакчалар эшләтәм дә, шунда гына яшәтәм мин аны. Бистәбезнең королевасы итәм!—дип кычкырып җибәрде ул.

—Тукта, алай бик ашыкма әле син, дустым. Хәлләр ничек килеп чыга бит әле?.. Лаләнең син вәгъдә иткән байлыкларга төренүе, югары урыннарга менеп утыруы бик икеле. Үзенең холкы, дөньяга карашы белән ул да бит абыйсыннан әлләни ерак китмәгән. Лаләгә килгәндә... без синең белән сабыр итик әле,—дидем мин. «Нәрсә килеп чыга бит әле? Ул сине, күзгә күренмәс бер затны, ничек кабул итә бит әле?»—дип тә өстәмәкче идем, әмма тыелып калдым. Кодрәт иясе дустымның кәефен кырасым килмәде. Тик ул үзе дә нидер сизенеп алды, күрәсең.

—Әйе, монда ашыгу ярамас шул. Барысын да әйбәтләп уйларга кирәк,—диде ул, уйчан гына.

—Әлбәттә шулай. Башта без иң беренчел мәсьәләләрне хәл итик. Әйтик, синең ары таба ничек көн итәсеңне, тормыш хәлләрен. Киләчәккә планнарны аннан соң корырбыз. Син... кайда әле?—дидем мин, тирә-ягыма карап.

—Менә монда, өстәл янында басып торам,—диде Нурул.

—Алайса, янәшәмә килеп диванга утыр. Бергәләп киңәшик,—дидем мин.

Без бер дә ашыкмыйча гына, барысын да җентекләп уйлаштык. Нурулның кайда яшәп көн итәсе шактый ансат хәл ителде. Аның әти-әнисеннән бушап калган йорты әле шактый әйбәт, нык. Ана газ кертелгән, электр уты бар. Өстәвенә ул йортның әлегә анык кына хуҗасы да юк. Әти-әниләре тарафыннан ул йорт Нурул исеменә яздырылган. Ә Нурул үзе, гәүдәсе-ние дә табылмагач, безнең сәер һәм буталчык законнар буенча, әле һаман да вафат булганга исәпләнми, ә хәбәрсез югалган

булып санала. Йортның законлы хуҗасы булып кала бирә... Бәс шулай икән, Нурул шул йортта торырга булды. Әлбәттә, ул теләгән вакытында безгә дә кереп йөри ала. Минем янга килгәндә теләсә кайсы урында шыпырт кына итеп: «Мин бу!»—дип кисәтеп куя... Бу—беренчел мәсьәләләр.

—Менә... Лалә белән дә бик сөйләшеп, аралашып йөрисем килә инде минем. Моны ничек эшләргә икән?..—дип куйды Нурул, бик уңайсызланып кына.

Мин уйга калдым. Шайтан алгыры, чыннан да... Сеңлем Лалә белән ни эшләргә? Бу могҗизаны, бу гайре табигый хәлне аңа ничек аңлатып бирергә? Дөрес, ул үзе Нурулны әле һаман оныта алмый йөри кебек. Әмма бит... мәсьәлә архи четрекле! Күзгә күренмәс, җисемсез егетне кыз бала ничек кабул итәр? Бик яман куркып, өркеп калса, ни эшләрсең... Аның мондый заттан бөтенләй йөз чөерүе дә ихтимал бит әле. Һәм мин боларның барысын да, бик сак кына булып, хәтерен калдырмаска тырышып, Нурулга сөйләп бирдем. Аның авыр көрсенеп куйганы ишетелде.

—Әйе... болар барысы да шулай шул. Ни хәл итмәк кирәк...—диде ул, күңелсез тавыш белән.

—Алай да син бик борчылма әле, дустым. Тик бераз вакытлар сабыр гына итик,—дидем мин, мөмкин кадәр йомшак итеп.—Тота-каба китереп әйтсәң, Лалә куркып, югалып калыр ул. Моның өчен аны башта бик әйбәтләп әзерләргә кирәк булыр. Монысын мин үз өстемә алам. Аңа җай белән барысын да сөйләп бирермен, аңлатырмын.

Шунда Нурул миңа якын ук килеп, нindидер хәрәкәтләр ясап алды, күрәсең. Битемә җиңел генә җилләр бәрелеп торды.

—Җәл, дустым, синең игелекле кулыңны кыса алмыйм. Рәхмәт сиңа!—диде ул, хис белән.

Йә, әлегә алда торган мәсьәләләр хәл ителде кебек. Бүгенге әңгәмәгә нокта куярга да була. Шулай да минем күңелемне кызыксынулы кайбер сораулар кытыклый иде.

—Ары таба ничек яшәмәк буласың инде син, дустым? Нилэр уйлыйсың, ниләр кырмак буласың?—дип сорап куйдым.

—Киләчәккә минем планнар зурдан!—диде Нурул, ниндидер тантана һәм горурлык белән.—Минем уйлап куйган эшләрем бар... Үземне сиңа сиздергәнче мин бу дөньяда байтак яшәдем инде, Сәлих дустым. Ил буйлап йөрдем, төрле урыннарда булдым. Күзәттем, дөнья хәлләрен, тормыш агышын өйрәндем. Шул исәптән үзебезнең бистәдә дә. Шушы үзебезнең зур булмаган бистәдә генә дә минем өчен кайбер эшләр бар әле...

—Нинди эшләр инде ул, әгәр дә сер булмаса?—дип, кызыксынуымны дәвам иттем мин. Аның теге вакыттагы дөньяны тигезләү, хәтта берәүләрнең байлыгын тартып алып, икенчеләргә өләшү кебек балаларча беркатлы хыялларын әле дә хәтерли идем.

—Кайбер кыекларны турайтасы, почмакларны кисеп куясы бар...—диде ул, серле итеп.—Сиңа ваклыкларына кереп сөйләп тормыйм. Килер вакыт, үзең күрерсең, ишетерсең!—диде ул, бу хакта артык җәелеп сөйләшәсе килмәгәнне белдереп. Бик ихтимал, үз планнарына минем каршы төшәсемне дә чамалагандыр.

—Анысы синең эш... Тик, замана Дон-Кихоты булып килеп чыкма тагын. Җил тегермәннәренә каршы көрәш ачып җибәрмә,—дидем мин.

—Ә нигә әле Дон-Кихот? Хыялый Дон-Кихот янәшәсендә гаделлек сагына баскан Робин Гуд та бар. Аны бөтен дөнья халкы белә!—диде ул, горурлык белән.

Икебез дә тынып калдык. Бераз шулай торгач, мин сорап куйдым:

—Син мондамы соң әле, Нурул?

—Менә синнән ерак та түгел өстәл янында мин. Уйланып утырам,—диде ул.

—Бәлки бүген бездә генә кунып китәрсең. Күрәсең, мин өйдә ялгызым гына. Хәзер чәй куеп җибәрәм, әгәр телисең икән, мәен дә табарбыз,—дидем мин.

—Рәхмәт, дустым, өйгә кайтам. Миңа да ялгызым гына калырга кирәк әле. Барысын да бик әйбәтләп уйларга кирәк. Бәлки якын көннәрдә генә синең янга да сугыла алмам. Бу хакта белеп торуың хәерле,—диде ул, дусларча җылы итеп.

Бераздан безнең өй ишеге акрын гына ачылды һәм ябылды.

Нурул чыгып киткәч, тагын утларны сүндердем дә, бик озак диванда утырдым, чәй дә куеп тормадым. Бу вакыйгадан, бу хәлләрдән тәмам дулкынланган, әсәрләнгән идем. Менә кара инде син! Нинди генә могҗизалар юк бу дөньяда... Әле урынга яткач та, тиз генә йоклап китә алмадым. Баягынак, үз планнарын ачып салмаганы өчен Нурулга шактый гына хәтерем дә калган иде. Уйланып ята торгач, менә кул селтәдем. Үзе теләгәнен эшли бирсен, әйдә. Бәлки, чынлап та, соңгы вакытларда бу дөньяны шыплап тутырган шушы кадәрле гаделсезлекләргә, оятсызлыкларга аз гына булса да чик куя алыр. Кайчак үзен дә әллә нинди уйлап куясың бит... Аннан килеп, аның гамәлләренә баш булырга, юнәлеш бирергә минем ни хакым бар?

Шунда күңелемнән түрендә хәтәр бер уй баш калкытып алды. Менә көллияттә укытып йөрим, өч ай хезмәт хакы алмаган килеш... Бистәнең аргы башындагы көллияткә көн саен җәяү йөрим. Шул ук вакытта минем белән мәктәптә бер класста укыган, көчкә сөйрәлеп барган кайберәүләр дөньяның артына тибеп яшәп яталар. Тукта әле, дустым Нурул миңа да ярдәм күрсәтә ала бит. Үзем күпме теләсәм, шул кадәр! Әмма шунда ук бөтен барлыгым белән мондый уй-фикерләргә каршы килдем, аларны җәтрәк авызлыклап алдым. Кирәкми! Алла үзе сакласын.

Әйе, миңа берни дә кирәкми. Ә менә минем дустым Нурул... теләсә ни эшләсен. Хәзерге көндә ул Җир шарындагы кешеләрнең иң кодрәтлесе. Әйтерең генә бармы, күзгә күренмәс кеше! Аның нинди мөмкинлекләргә ия булганын башында гакылы булган һәркем чамалый алыр.

Мин шундый фикердә торганда...

## Нурул эшкә башлады

Бу вакыйгадан соң бер атна-ун көн, бер айга якын вакыт үтеп китте. Мин күңелем белән гел сагаеп, халык арасындагы сүзләргә колак салып йөрдем. Ни дә булса көтеп инде. Әмма ләкин бернинди ул-бу хәбәр, яңалыклар ишетелмәде. Борчыла ук башладым: нигә үзен берничек тә сиздерми Нурул? Әллә бер-бер хәл булдымы үзенә, әллә теге яңашә дөньясына китеп бардымы? Шулай уйлана-уйлана бер кичтә үзебезнең аулак урамнан өйгә кайтып киләм. Кинәт яңашәдә генә таныш тавыш ишетелде:

—Мин бу!

—Әһә, син! Нинди яңалыкларың бар? Сөйләп җибәр җәтрәк!—дидем мин, бик шатланып.

—Эшләр шәп бара минем, дустым. Гөрләп бара!—диде ул, канәгать тавыш белән һәм, күрәсең, кулларын угалап алды.

—Нинди эшләр бара? Нәрсәләр майтарасың син анда? Әйдә, сөйләп җибәр!

—Менә шушы араларда белерсең. Ишетерсең хәлләрне...—диде ул, кыска һәм серле итеп. Аның болай тел яшереп маташуыннан минем җен ачуларым чыкты.

—Нәрсә ишетермен? Ниләр эшли алдың?—дип кычкырып ук җибәрдем. Хәтта кулларына сумкалар күтәреп алдан барган ике хатын-

кыз юлларыннан тукталып, миңа борылып карадылар. Урамда ялгызым гына кычкырынып йөргәнемә аптырап, ахры, бераз тукталып тордылар. Аннары гына, башларын чайкап, китеп бардылар.

—Менә хәлләр ишетелгәч, барысын да белерсең. Ә хәзергә гафу ит, дустым. Минем вакытым юк. Эшләрем бик күп минем. Санау, бүлү гамәлләре...—диде ераклаша барган тавыш.

—Ниләр кыланып йөрисең син анда? Әйт инде шуларны миңа, имансыз!—дидем мин, тәмам гаҗиз калып. Әмма инде тавыш бүтән ишетелмәде. Аның иясе, күрәсең, артта калды яисә каядыр китеп үк барды. Тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка дигәндәй, мин буш урамга булса да йодрыгымны күрсәттем.

Шуннан соң инде озак көтәргә дә туры килмәде. Китте хәлләр, китте хәлләр! Бистәдә берсеннән-берсе сәер, кеше ышанмаслык хәбәрләр, сүзләр йөри башлады. Бистә хатыннары аларны исләре китеп, куанычларын кая куярга белмичә сөйләделәр.

—Ишеттегезме әле, җанашларым, картларга пенсия түли башлаганнар. Ике айлык акчаларын берьюлы китергәннәр дә биргәннәр.

—Булмас ла!

—Булган. Җитмәсә, бернинди талон белән дә түгел ди. Һәммәсе акчалата икән.

—Менә. Аллаһы Тәгалә бар ул. Әгәренки бирәм дисә, үзе китереп бирә ул.

—Күктән яуган бәхет инде бу!

Шунда ук көлкеле дә, кызганычлы да вакыйгалар да булды.

—Шәйдулла абзыйларга ялгышып өч айлык пенсияләрен берьюлы китереп биргәннәр. Бу тиклем акчаны күргәч, Шәйдулла абзый һушыннан язган, чак кына теге дөньяга китмичә калган. Карчыгы Маһинур апай догаларын укып, дарулар биреп кенә коткарган үзен.

—Иван дәдәй шатлыгыннан галәмәт күп итеп, әрҗәсе белән аракы сатып алган. Хәзер инде өендә идән буйлап мүкәләп йөри икән. Айный алмый ди.

—Кайсы Иван дәдәй ул?

—Әнә теге клубта кочегар булып эшләгән, пенсиягә дә бик картаеп чыккан Иван дәдәй инде. Идәндә мүкәләп китә дә эт булып өрә икән. Карчыгы Настя түтәй ни эшләргә дә белми ди. Бик елый ди.

—Кулларына шул тиклем акча килеп кергәч, Нәфикъ бабай белән Мәрфуга әби үзара бик яман ачуланышып киткәннәр. Ут ягып кычкырышканнар инде. Берсе бу акчаларны саклык банкына салып куйыйк ди икән. Икенчесе моңа каршы төшеп, юк, өстебезгә ябынырга яңа юрган алыйк диган. Картаеп беткәч аерым ашый, аерым йоклый башлаганнар. Һич кенә дә килешеп китә алмыйлар икән. Адәм көлкесе инде бу...

Бистәдә әнә шундый хәбәрләр йөрде.

Әмма күп вакытлар да үтмәде, бу пенсия мәсьәләсе, аның шатлыклары һәм кайгылары халык арасында икенче юнәлеш алды. Аптырашка әйләнде, акрынлап төрле шомланулар тудырды.

—Бу пенсияләрне, җанашларым, кешеләр кулына гадәтенчә хат ташучылар китереп бирмәгән ич. Әллә кемнәр, серле бәндәләр китереп биргән аны.

—Бер әкәмәт булган ул. Почта әрҗәләренә салып, өстәл өсләренә куеп киткәннәр. Хуҗалар үзләре өйдә юк чагында... Аларны китереп тапшыручыны беркем дә күрмәгән, ишетмәгән дә. Кәгазьгә кул куеп та алмаган. Шуңа күрә хәзер күбәүләр пошаманга төшкән, бик куркалар ди.

—Һе. Законный түгел инде ул алайса.

—И, хәзер законный эш бармы соң ул?

—Кемнәр эше булыр бу, менә шунысын әйтегез сез? Әллә бу дөньяда, чынлап та, җен-пәриләр бар микән?

—И хәзер... булса да булыр. Дөнья дигәнебез үз урыннарыннан купты инде ул.

—Әллә инде мафия эше микән бу? Шулар бер-бер хәйлә корып йөри микән? Азагында халыкка нинди дә булса җәфаларын китереп салырга. Акчаларны икеләтә итеп кире таләп итәргә?..

—Әйе, әйе, тагаен генә мафия эше бу. Шулар бер-бер хәйлә корып, тозак куеп йөриләр!

Шуннан инде төрле эзләнүләр һәм тикшеренүләр китте, бик күңелсез хәлләр ачыкланды. Иң гаҗәбе, бу пенсия дип өләшенгән акчаларның берниндә пенсия фондыннан алынмаганы беленде. Милиция тикшерүчеләре ачыклаганча, алар бистәдә соңгы вакытта бик баеп киткән, сәүдә эшендә арадашчылык иткән һәм бүтән яшерен эшләр белән шөгыльләнгән бер бәндәнең шәхси акчалары булып чыкты. Ул аларны ниндидер максатларда җыйнаган, шушы вакыйгалар алдыннан гына саклык банкыннан алган. Һич кичекми әйләнешкә җибәрү өчен. Кайсыдыр явызы шушы хәлне белеп торган, тегеләр эштә чагында ишек төбендәге кимендә аю чаклы этне, заманның гаять нык, хәйләле йозакларын үтеп өйгә кергән, нәни сейфны барча хәзинәсеннән бушаткан. Хәзер теге зарар күрүче бәндә һәм милиция үзе дә бик нык аптырашта калганнар. Шушы кадәр яхшы сакланган йортка ничек итеп үтеп кермәк кирәк? Кемнең зиһене, тапкырлыгы һәм батырлыгы җиткән моңа? Каза күрүче, болай алганда үзе әйбәт кенә, бистәдә хөрмәтле генә кеше, зур кайгыларга төшкән.

Бу җәһәттән халык арасында тагын төрле фикерләр килеп туды:

—Алай... Бик тә уңайсыз килеп чыкты бит әле бу. Бәс, кеше акчалары булгач, безләргә ни эшләргә кала инде?

—Ходай Тәгалә каршысында гөнаһ булмасмы бу?

—Ә ни эшләп алай гөнаһ ук булсын икән әле? Соң бит, ни бит... Асылда кеше хакына кереп җыелган акчалар бит алар. Менә синең белән минем хакка да кереп.

—Анысы да бик ихтимал. Әмма болай... күрәләтә торып барыбер яхшы түгел.

—Ни сөйлисең! Алар барысы да кеше талап баеп яталар.

Ахырда бистә хакимияте һәм милиция бу эшне үз кулына алды. Һәм болай боерды. Сез анда ниләр генә сөйләнсәгез дә, нинди генә юл белән тупланган булса да, болар конкрет бер кешенең шәхси акчалары. Димәк ки, алар пенсия дип, кайсыдыр шамакае тарафыннан законсыз таратылган. Бәс, законсыз икән, ул таратылган акчаларны, рәхим итеп, кире кайтарып бирергә туры киләчәк. Һич кичекми һәм чәчми-түкми! Ә законлы пенсия исә... тагын бер айдан биреләчәк.

Хәзер инде кайда ул күңелсез хәлләр генә... Хәзер инде кычкырышталаш, елау-сыктау, чын мәхшәр башланды. Бик күбәүләр үзләренә күктән яуган бу сумманың байтак өлешен инде тотып та бетергән, базаркибетләрдән он, ярма, май, ит ише азык-төлекне күпләп алган булып чыкты. Кайберәүләр үзе яраткан газитә-журналларга язылган, бурычын түләгән, туган көннәрен иркенләп бәйрәм иткән. Кыскасы, мул килгән сәмәнне җәлләмичә тоткан. Әлбәттә инде, әлеге сумманы кайтарып бирү мөмкинлеге һич тә юк. Карт-карчыклар кайдан алсын инде аны... Милиция үзенекен таләп итә, карт-карчыклар үзенекен кычкыра. Тулы ералаш бара!

Акчаны кире кайтарып бирүдән кискен рәвештә баш тартучылар да булды.

—Бернинди тәртипсезлек, закон бозу юк монда. Закон-тәртипләрне әнә хөкүмәт үзе боза. Әнә безгә айлар буе пенсия түләми. Әгәренки шәхси кеше акчасы булган икән, аны хөкүмәт әнә үзе түләсен!—диделәр алар.—Без, гомер буена намус белән эшләп, картлык көнебездә шушындый мәсхәрәләргә дучар булдык. Инде бер миһербанлы бәндә безне акчалы иткән икән, аны кулдан ычкындыру юк!—диделәр.

Законсыз таратылган пенсия акчаларын кире китереп бирүчеләр дә аны күз яшьләре, ямьсез сүзләр белән тапшырдылар.

Мин инде, әлбәттә, килеп туган бу кәмитнең кем эше икәнен яхшы белә идем. Һәм, теләсә ни әйтегез, дустым Нурулның авыр тормышта яшәгән халыкка ярдәм итү йөзеннән башкарылган бу беренче гамәлен хуплаган да идем. Чәнчелеп китсен, булмады, барып чыкмады! Ботаклы-ботаклы кәкре таяк булды бу. Дөресе, ихлас күңелдән яхшылык эшлим дип йөрүе әнә нинди ямьсез кәмиткә әйләнде. Бистә халкына бернинди куаныч түгел, ә өстәмә борчу, кайгы-хәсрәт кенә китерде. Бу шәхсән минем өчен дә бик тә күңелсез бер вакыйга булды. Нурулдан мин ниндидер зур, мәгънәле, кызыклы эшләр көтеп, шуларга өметләнеп йөри идем.

Озак көттермичә ул үзе дә минем янга килеп керде. Эштән кайткач гадәтемчә караңгы өйдә, диванда ял итеп утыра идем. Янәшәмдә таныш тавыш ишетелде:

—Син бистәдәге соңгы хәлләрне беләсеңдер инде, Сәлих дустым. Каш ясыйм дип күз чыгару булмадымы соң бу минем тарафтан?..—диде Нурул аптырашлы итеп һәм авыр сулап куйды. Үзен күрмәсәм дә, мин аның бик күңелсез кыяфәттә, иңбашларын салындырып утырганын чамалап алдым.

—Ниткән белмәгән ул, дустым. Гарык булганчы беләм. Пүчтәк бер эшкә әйләнде синең бу гамәлең!—дидем мин, эчемдәгесен яшереп тормыйча.

—Аңламадылар мине. Белмәделәр мине...—диде Нурул һәм ачыну белән дәвам итте.—Дөньяның кайсыдыр акылбае әйткән бит әле. Халык ул—сарык ул дигән. Бу сүзләрдә, никадәр сәер булмасын, хаклык та бар, күрәсең. Минем игелек теләгән гамәлемне бистә халкы менә кая китереп чыгарды... Соң, дустым, үзең уйлап кара. Кулына ике айлык пенсияң берьюлы килеп кергән икән, нигә инде бу хакта шулкадәр шапылдап йөрергә? Йомырка салган тавык кебек кыткылдап. Нигә шул байлыкны шыпырт кына янчыгына салып куймаска? Нигә ул кадәр аптырап, гаугалар күтәреп йөрергә? Җитмәсә, кайберәүләре шул сумманы үз куллары белән кире кайтарып та бирде бит әле. Юк, дустым, бер дә бердәм түгел икән безнең халык. Бик тә таркау икән.

—Әле генә белдеңме шуны?—дидем мин.

—Бердәм дә түгел, яхшылыкның да кадерен белми икән. Пычагым да! Дөресе, бу дөньяда үзенә яхшылык эшләүче, ярдәм кулы сузучы булыр дип башына да китерми икән. Менә нәрсәсе кызганыч аның. Менә нәрсәсе хәтәр аның!—диде Нурул үртәлеп.—Мин бит халык өчен дип никадәрле көч түктем, төн йокыларымны җәлләмичә эшләдем. Нинди зур сумманы кулыма төшердем. Тәэминат бүлегенә үтеп кердем, бистәдәге пенсионерлар исемлеген үземә күчереп алдым. Шул исемлек буенча һәркемгә тиешле акчаны бүлеп утырдым. Көннәр-төннәр буена исәп-хисап белән мәтавыкландым. Аннары һәркайсының ихатасына кереп, тиешле сумманы өләшеп йөрдем. Мин нинди зур күләмдә хезмәт түктем? Ә менә шушы игелекле затка рәхмәт сүзе әйткән бер бәндә табылмады?—диде дустым, җан ачысы белән.—Шундый затның булу ихтималын уйлаучы да булмады ичмасам. Җен-парилэр эшедер, имеш, фәлән дә төгән... Һә! Үзенә яхшылык теләүче булуына ышанмый икән безнең халык. Менә шушы хәл бөтен эшне бозды. Минем планнарымны җимереп ташлады...—диде ул һәм тынып калды.

—Үпкәләмә, дустым, син үзең бик әйбәт егет. Әмма артык садә күңелле, беркатлы син. Бу дөньяны, кешеләрне, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлап та бетермисең. Бөтен бәла шунда,—дидем мин.

Без шактый вакыт сүзсез утырдык.

—Соң, ни эшләргә инде миңа? Ары таба ниләр майтарып карарга?—диде Нурул, аптыраулы итеп.

Ә бит, шайтан алгыры... чынлап та, ни эшләргә?! Минем өчен дә

бик авыр сорау иде бу. Сүз дә юк, минем дустым бу дөньяда беркемгә дә тәтемәгән кодрәткә, мөмкинлекләргә ия. Ул беркемгә дә сиздермичә теләсә кайда йөри ала, ул бик яшерен урыннарга үтеп керә ала. Бу инде үзе генә дә нинди зур кодрәт, нинди могҗиза! Тик менә шушы кодрәтне жыен вак-төяккә, кемнедер баету, акча өләшеп йөрү кебек беркатлы гамәлләргә сарыф итмисе иде. Нindидер югары максатларга, бөтен халыкка, хәтта илгә файда китерерлек эшләргә юнәлтәсе иде аны. Ләкин нинди максатларга, нинди эшләргә? Уйланып утыра торгач, башыма бик бәхетле бер уй килде.

—Менә нәрсә, Нурул, болай инкогнито йөреп, мөгаен, әлләни эш кыра алмассыңдыр. Болай итеп бу дөньяда тигезлек тә, дөреслек тә урнаштырып булмый. Монысы көн кебек ачык. Иң яхшысы, менә ни эшлә син. Бар да рәсми властьларга җәвит ит. Үзенне аларга белдер, үзенне аларга тәкъдим ит. Менә алар белән берлектә, алар карамагында бинйһая зур эшләр башкара алырсың син. Без бөтенләй белмәгән, уебызга да китерә алмаган эшләрне!—дидем мин.

—Ни сөйлисең, дивана! Әйтә дә күрмә, сөйли дә күрмә...—диде Нурул, куркынган тавыш белән.—Әгәренки рәсми властьларга үземне белдерсәм, үземне алар карамагына тапшырсам, беләсеңме нинди хәлдә калачакмын мин. Хәзер тотып алалар да, кул-аякларыма богау салалар минем. Богау салалар да эчке органнарга китереп тә тапшыралар. Ә аннан соң китә инде! Анда инде мин, дустым, чын кол хәлендә калам. Алар мине үзләренең төрле максатларында куллана башлыйлар. Төрле явыз, кабахәт, минем намусыма бөтенләй дә каршы килә торган максатларда. Әйтик, чит илләрдә шпионлык итәргә, яшерен документларын, хәрби серләрне, тагын әллә нәрсәләрне урлап кайтырга. Хәтта үзләренә каршы килгән бәндәләрне үтереп йөрүдә дә кулланачаклар. Әгәр каршы киләм икән, ул чакта үзем дә исән калмаячакмын. Икенче кат үләсем килми минем... Әйтә дә күрмә бу сүзләреңне, дустым. Үзем исән чакта рәсми властьлар кулына бирелә́мме соң?!

Шайтан алгыры, дөрестән дә! Аның бу сүзләрендә зур хакыйкать ята бит. Мондый мөмкинлекләрең була торып, хакимият кулына төшеп кара син. Бигрәк тә хәзерге заман хакимияте, хәзерге түрәләре кулына... Һәм мин дустым фикере белән тулысынча килештем. Әмма башымда аның киләчәктәге гамәлләренә карата ачык кына бер фикер, ана бирерлек киңәш-табышларым юк иде. Аннары, үз эшем, үз мәшәкатьләрем дә муеннан, көннәрем көллияттә үтә.

—Алайса, син үз җаеңны үзең кара инде, үзеңчә хәл ит, дустым. Тик болай берәүләрдән байлык талап, икенчеләренә өләшеп кенә йөрмә. Болай итеп бернинди дөреслек урнаштыра алмассың. Дөреслек дигән нәрсә бу дөньяда, гомумән, юк ул,—дидем мин.

Әмма бу унайдан Нурулның үз юлы туры иде.

—Дөреслек ул булырга тиеш, кечкенә генә масштабларда булса да. Әйтик, менә безнең бистә масштабында. Ә гаделсезлекләр нинди зур, алар көннән-көн үсә, киңрәк җәелә хәзер. Бөтен чик-чамаларны үтеп китә. Мин шушы үзебезнең бистәдә генә дә гомерләрен намуслы хезмәт белән үткәргән күпме кешеләрне беләм. Ихлас күңелдән эшләп һәм тыйнак яшәп тә бернинди байлык туплый алмаган, үзләренә лаеклы шартларда яши алмаган фидакарьләрне. Шул ук вакытта бернинди эш кырмыйча баеп киткән, зур йортлар салган, кыйммәтле чит ил машиналарына гына утырып йөргән бәндәләрне дә беләм. Хәйлә, намуссызлык, нахаллык белән баеган төрле түрәләрне. Халык өстеннән яши алар, миндә барысы да исәптә алар!—диде ул һәм нindидер янау, тантана белән дәвам итте.—Мин үзем куйган юлдан алай гына читкә тайпылмыйм әле. Дөреслекне эзләп карыйм. Үзем белгәнчә генә булса да!

—Ай-һай, дустым. Тагын кәмит куймасаң ярый инде син. Тагын көлкегә калмасаң...—дидем мин.

—Юк инде, Сәлих дустым. Бу юлы без икенче төрлерәк эш

итәчәкбез. Ә ахыр чиктә кәмит чыга икән... чыга бирсен. Бу тормышта һәр гамәл, нигездә, кәмиткә корылган... Мин үз сукмагымнан тайпылмаячакмын!—диде ул, ышаныч белән.

Һәркайсыбыз үз фикерендә калып аерылыштык.

Шуннан соң тагын байтак вакытлар үтеп китте. Нурул миңа үзен сиздермәде. Мин тагын борчуга төштем. Тагын нинди хикмәтләр чыгарырга йөри икән инде бу? Ул арада бистәдә яңа хәбәрләр таралды:

—Безнең бистәдә бик бай бер кеше бар икән. Чамасыз да бай.

—Акчаны кая куярга да белми, ди. Бер дә жәлләми дә, ди.

—Балалар бакчалары чутына бик зур суммалар күчергән. Хәйрия исәбеннән. Кара әле син ул хәлне!

—Алай гынамы әле! Теге гарип балалар санаторие бар ич әле. Тау астындагы. Шуңа күп итеп акчасын да күчергән, автобус та алып биргән, ди. Бик зур автобус. «Балалар рәхәтләнеп калага барсыннар, циркларга, театрлар карасыннар, табигатькә чыксыннар»,—ди икән.

—Мөдирләр дә, тәрбиячеләр дә бик тә куанганнар, ди. Ул балаларга бирелгән бүләкләрнең дә исәбе-чуты юк икән.

—Тик менә... ул игелекләр иясенең кем икәнен дә, исемен дә белмиләр икән. Ул үзе беркемгә дә күренмәгән, сөйләшмәгән дә, барча эшләрне язу биреп кенә хәл итә, ди. Мин шулай сер булып калырга тиеш дип язып биргән.

—Бигрәкләр дә тыйнак зат икән, бахыр. Хозыр-Ильястыр ул.

—Әйдә, күренмәсә күренмәс, сөйләшмәсә сөйләшмәс. Аннан гына ни зыян. Биргәннең битенә бакма. Изгелекләрен генә эшләсен. Алла үзенә миддәт-куәт бирсен.

Халык әнә шулай сөйләште.

Һәм бу хәбәрләр буш сүз генә булып та калмады, бу изгелекләр дөрестән дә эшләнде. Балалар бакчаларына бик күп тәмле ризыклар, яңа уенчыклар сатып алдылар. Юкса, совет заманыннан калганнары барысы да искереп, ватылып беткәннәр иде инде. Тау астындагы санаторийның сәламәт булмаган балаларын барчасын да өсләреннән сәләмәләрен салдырып алып, өр-яңадан, матур итеп киендереп куйдылар. Бичара балаларга бөтенләй икенче төс керде. Бөтен бистә халкы бик куанды бу хәлгә. Урамнарда, кибет-базарларда хатын-кызлар һәм ирләр дә әлеге миһербанлы затка карата рәхмәт сүзләре сөйләделәр. Мәчеткә йөрүчеләр аның исәнлегенә дога кылдылар. Мәчетнең имам-хатибы үзе дә аңа багышлап вәгазьләр сөйләде.

Әмма дә ләкин... Шушы гомуми куаныч, шатлык дулкыннары янәшәсендә бистәдә ниндидер бик яшеренке, шомлы җилләр дә исте. Соңгы елларда бик баеган, иркенәеп киткән, икешәр катлы йортларда яшәгән уртакул түрәләр, алардан югарыраклар, кайбер эшмәкәрләр арасында ди бик көенеп, сөмсерләре коелып, куркуы, аптыравы йөзенә чыгып йөрүчеләр күренә башлады. Бик яшерергә тырышсалар да, шул да беленде: бу катлам да, милиция дә астыртын гына кемнедер эзләделәр. Бик тырышып карадылар, тик таба алмадылар.

Яңа ел якынлашкан көннәрнең берсендә эштән кайтып киләм. Үзебезнең урамга килеп керүгә янәшәмдә Нурулның тавышы ишетелде.

—Менә күрденме инде абыеңны, дустым. Кайбер син яраткан гамәлләрне дә тормышка ашырдым бит әле. Балаларга Яңа ел бүләгенен ниндиен ясадым!—диде ул.

—Күрдем һәм тулы теләктәшлек белдерәм. Молодец!—дидем мин. Аның бу гамәлләрен, дөрестән дә, чын күңелемнән хуплый идем.—Әмма ләкин, дустым, чаманы белеп кенә эш итә күр. Әлегә шушылар да бик җитеп торыр.

—Ә юк әле, җитмәс! Минем планнар тагын бар әле, дустым...—диде Нурул.

—Ниткән планнар ул тагын?

Тик минем бу соравыма җавап ишетелмәде.

Үзенең шау-шуы, күп мәшәкатьләре белән Яна ел бәйрәме дә үтеп китте. Ул арада бистәдә тагын ниндидер яшерен хәрәкәтләр, астыртын үзгәрешләр үзен сиздерде. Гомерләре буена, совет чорында да, аннан соң да аз хезмәт хакы алып эшләгән, бик уртача, тыйнак кына тормыш итәргә күнегеп беткән хезмәткәрләр тиктомалдан кибетләргә, бистә уртасындагы базарга еш чыгып йөри башладылар. Чит илләрдә эшләнгән кыйммәтле телевизорлар, суыткычлар, кайсылары хәтта затлы йомшак мебельләр сатып алдылар. Бу хәл халыкта тагын аптырау тудырды, бик тә кызыксыну, астыртын күпсенү, көнләшү хисләре уятты. Йөзләренә эчке бер куану, канәгатьләнү, тук чырай чыккан әлеге хезмәткәрләрдән кыюрак хатыннар кактырып-суктырып булса да сорашып та карадылар. Мондый мөмкинлекләрнең кисәк кенә кайдан килеп төшкәнен. Тик берсеннән генә дә төпле җавап ала алмадылар. Кибетчеләр инде нинди хәйләкәрләр, үткер халык. Мебель кибете сатучысы Мәдинә үзләренә йомшак мебель алырга дип уч тутырып акча күтәреп килгән Хөснулла абзый белән Хәдичә апайдан читләтеп кенә түгел, туп-туры итеп сораган:

—Хөснулла абзый, сез әле күптән түгел генә гади бер караватны карап йөрдегез. Гафу итегез, ул чагында аны алырга да сәмәнегез җитми иде кебек. Ә менә бүген нинди кыйммәтле йомшак мебель алырга килгәнсез... Ул арада гына нинди байлыклар ишелеп килде соң сезгә? Тагын гафу, үзем гаҗәпләнгәнгә күрә генә әйтүем инде. Үз итеп кенә соравым.

Хөснулла абзый, юаш кына кеше, ык-мык килә башлаган икән, аның өчен карчыгы Хәдичә апай чатнатып җавап биргән:

—Ай, Аллам, нәрсәсе гаҗәп булсын икән әле аның? Күптәннән җыйнаган акчаларыбыз бу. Гомергә бер затлы әйбер алырбыз дип җыйган идек,—дигән.

Гомерләре буена техник хезмәткәр булып эшләгән Харис абзый белән Мәһинур апа, өйләрендә эшләп утырган телевизорлары булуга карамастан, чит ил телевизоры алдылар.

—Теге искесен кухнәгә куябыз. Монысы түр башында була!—дип, мактанып та җибәргән алар.

Төрле йорт җиһазлары, хәтта мотоцикллар алып улларына, оныкларына бүләк итеп бирүчеләр дә булды. Кыскасы, бистә халкының аз тәэмин ителгән катламы әйбәт яши башлады. Түбән иелгән башлары югары күтәрелде, сүрән көнелләр ачылып китте.

Тик менә... мондый матур хәрәкәт, ни кызганыч, озакка бармады. Ничек кинәт башланып киткән булса, шулай кисәк тукталып та калды. Әле генә шатлык-куанычлары, бу дөньядан канәгать торулары йөзләренә чыккан адәмнәр тагын элеккечә борыннарын салындырып, нуры сүнгән карашлары белән йөри башладылар. Мин моңа гаҗәпләндем дә, пошындым да. Чөнки бу бәрәкәтле эшләрне кем алып барганын бик яхшы белдем һәм дустымның бу гамәлен дә хуп күрдем. Ниләр генә булды икән инде аңа тагын?

Бу сорауга җавап озак көттермәде.

Өйдә гадәтемчә ялгыз утырганда янә Нурул тавышы:

—Мин булам әле бу!—диде ул, кыска һәм ничектер ачулы, үпкәле дә итеп.

—Әһә, син икән, әйбәт бу... Күптән сорамакчы булып йөрим: ник әле син, дустым, алай ярты юлда тукталып калдың? Хөснулла абзыйларны, Сания апайларны әнә ничек куандырган идең бит. Һәм бик дөрес тә эшләгән идең. Тик мондый ярдәмгә мохтаҗлар бистәдә тагын җитәрлек бит әле. Ник алар синең исемлектән төшеп калды, ә? Игелекнең ахырынача булуы мәслихәт ләбаса,—дидем мин.

—Менә... фәләнем аларга!—диде Нурул ачулы һәм тупас итеп.

Менә сиңа мә! Һич көтелмәгән бу хәлдән мин озын итеп сызгырып җибәрдем.

—Бу ни сөйләвең әле? Ник алай сүгенәсең? Нинди яман чебен

тешләде сине?—дидем мин, бик гаҗәпләнеп.

—Их, Сәлих дустым, без кешеләрне белмибез икән шул,—диде ул, тирәнтен ачыну белән. Пычагым да белмибез. Безнен кеше дигәнебез начар гына түгел, чын мәгънәсендә чучка икән. Адәм балалары тискәре һәм комсызлар икән. Чикләрне белми торган комсызлар. Аларны, беләсенме...

—Шулай укмы?—дип бүлдем мин, аны бу авыр каргануларыннан туктатасым килеп.

—Шулай ук! Мин монa тәмам инандым инде, дустым. Менә кара инде син бу хәлне,—диде ул һәм, күрәсең, кулларын як-якка җәеп җибәрде.—Мин бер дә иренмичә аз керемле, авыр тормышлы кешеләрнең исемлеген төзедем. Үземчә төгәл һәм гадел итеп. Аларнын һәркайсына үзләре өчен чагыштырмача бик зур суммада ярдәм иттем. Җаннары теләгән әйберләрен сатып алуны шарт итеп. Шуны беләсеңме, дустым, аларның җаннары тагын ниләрне теләде?!—диде ул, каһкаһә белән һәм, бераз тынып торды да, бик үртәлеп дәвам итте.—Аларнын ул бик тәҗрибәле, зирәк һәм тыйнак җаннары янадан-яңа әйберләр теләде. Зиннәтле, кыйммәтле әйберләр! Аларга акчалар тагын, тагын, бик күп кирәк булды... Аптыраш, билләһи! Адәм баласы дигәнебез чик-чаманы, тыйнаклык, оят дигән нәрсәләрне белми икән ул. Бөтенләй дә. Аның нәфесенә, комсызлыгына бернинди чикләр юк икән... Мин, үземнен күзгә күренмәс бер зат икәнемне белдермәс өчен, алар белән язулар алмашу аша гына сөйләшү тәртибе керттем. Һәм дә ки, аларның кайберләре миңа менә нинди язулар язып бирде. Син, дустым, аларны укып кара да, шуннан үзеңә нәтиҗә ясарсың,—диде Нурул һәм диванда берничә кәгазь пәйда булды. Мин ул дәфтәр битләрен кулыма алдым, аларга язылганнарны укыдым. Аларнын кайберләрен сезнең хөкемгә дә тапшырам:

*«Безгә билгесез мәрхәмәт иясе, изге җан! Син безгә зур игелекләр күрсәттең, безне яңа телевизорлы, суыткычлы иттең. Мең, мең рәхмәтләр укыйбыз сиңа моның өчен. Юк, миллион рәхмәтләр. Тик... безнең тагын бер татлы хыялыбыз бар. Бәлки үзең дә беләсеңдер, төпчек улыбызның, иң кадерле балабызның җиңел машинасы юк. Ул бахырның шушы көнгә кадәр өйләнә алмыйча йөрүенә дә шул сәбәп. Кызлар белән таныша башлауга: «Ә синең машинаң бармы соң?»—дип сорыйлар. «Юк»,—дигәч, күңелләре суына, ди. Бөтен яшьтәшләрем үз машиналарында элдертә, минеке генә юк, мин бик хурланам бу хәлгә, ди. Гаепне бездән күрә, безне тирги. Шул күз алмабызны машиналы итүдә безгә ярдәмеңне салсаң иде. Иномарка машинасы булса, бигрәк тә әйбәт».*

Менә икенче бер хат:

*«Дустыбыз, яклаучыбыз! Безгә күрсәткән изгелекләрең өчен синең исәнлегеңә догалар кылабыз. Көн дә саен. Әмма... менә тора торган йортыбыз гына үзебезгә бер дә ошамый. Заманына күрә кысан да, ямьсез дә. Үзең дә күрәсең булыр, бер алачык инде... Әнә безнең күршеләр ниндәен йорт торгызып куйдылар? Үзе иркен, үзе матур, үзе мансардлы... Соң бит, дустыбыз һәм яклаучыбыз, без ул күршеләрдән бер дә ким булырга тиешле түгел. Хәтта рухи дөньябыз белән алардан югары торабыз, алардан зыялырак та әле. Без алардан ким булмаска лаеклы! Безне киләчәктә дә бәрәкәтле ярдәмеңнән ташламассың, әнә шундый йортлы итәрсең дип ышанып калабыз. Синең исәнлегеңә догалар укып...»*

Хатларны укуны дәвам итәбез:

*«Хөрмәтле яшертен дустыбыз! Синең мәрхәмәтең белән без киләсе җәйгә сәфәр чыгарга, чит илләргә, Төркигә барып кайтырга план кордык әле. Бу—безнең күптәнге хыялыбыз иде. Әмма дә ләкин, оят булса да әйтик, син биргән акчалар юлга гына җитәр дип исәпләп чыгардык. Бәс, анда тиклем баргач, бер дә бүләк-санакларсыз да кайтып булмас бит инде, хөрмәтле дустыбыз. Бер дә килешмәс инде ул, шулай бит? Бәс, алай икән, сез дә ярты юлда тукталып калмасагыз иде инде. Безгә тагын шул кадәр күләмдә ярдәм булса, җитеп торыр. Әлегә җитеп торыр дибез».*

Таң калып укыдым мин бу язмаларны. Кешеләрнең эчке дөньясын

яшермичә ачып салган, алар психологиясенең карангы почмакларын яктыртып күрсәткән бу документларны. Ярый, болары белән әле килешеп тә булыр иде. Алар кешеләрнең табигый ихтыяжларыннан алай ук биеккә үрелмәгән дә әле. Тик алар арасында бөтенләй дә оятсызлары, чиктән ашкан тупаслары да килеп чыкты. Аларын инде нәфрәтләнмичә укуы да мөмкин түгел:

*«Әй, син, кайсыдыр ки, сихер иясе!» Җен-пәриләр затыннанмы син, әллә тылсым иясе адәми заттанмы—монысы безләргә караңгы. Әмма андый мөмкинлекләргә ия булгансың икән, теләсә никадәр акча таба аласың икән, син инде кешеләргә тугрылыклы хезмәт итәргә бурычлы. Әйтик, менә миңа! Һәм син миңа акчаны тиз арада тагын китереп куй! Моның кадәр ике өлеш итеп. Юк, өч өлеш кирәк!»*

*«Исәнме, инкогнито калырга исәп тоткан шамакай! Безгә син анда күпме генә акча салып киткәнсең. Нәрсә генә инде ул синең өчен... Шундаен тылсымнарга ия икәнсең, син инде колачлы да була бел. Безгә акчаны чемоданы белән китер. Әйе, чемоданы белән. Юкса, һаман да болай инкогнито кала алмассың. Без сине эзләп табарбыз. Шул чагында ни эшләтергә белербез... Кара аны!»*

Бу язуларны укыгач, мин сызгырып җибәрдем. Кешеләрне, аларның психологиясен азмы-күпме беләм дип йөрсәм дә, бу кадәресен үк мин дә көтмәгән, башыма да китермәгән идем.

—Әйе, бар икән бу дөньяда әкәмәтләр. Бар икән адәми затлар!—дип куйдым.

—Алай гынамы әле, дустым, алай гынамы?..—диде Нурул.—Минем үзләренә ихлас күңелдән яхшылыклар эшләп йөргән клиентларым болар белән генә дә чикләнеп калмадылар әле. Алар минем өстән хакимияткә, милициягә шикаятьләр язуга кадәр барып җиттеләр.

—Булмас ла!—дидем мин, ышанасым килмичә.

—Мин милиция идарәсенә үтеп кердем. Ул шикаятьләрне үз күзләрем белән күрдем. Мин дус дип йөргән бәндәләр бистәдә ниндидер бер бик сәер, хәтта ки гакылга сау булмаган ахмак җан иясенең пәйда булуын хәбәр итәләр. «Бик хәтәр һәм куркынычлы бәндә,—дип язалар.—Ул йә ниндидер серле, хикмәтле яңа аппарат уйлап тапкан, йәисә моңарчы күренмәгән гипноз сәләтенә ия булган экстрасенс. Бу адәмнең безнең илне тәмам таркатып ташларга җибәрелгән чит ил шпионы булуы да бик ихтимал. Ул зат төрле вак-төяк ярдәмнәр өләшкән булып кешеләрнең ихтирамын яуларга исәп тота, аларны үз ягына аударырга тели. Аннары аларның барысына да баш булып алырга да үз файдасына эшләтергә. Мөгаен генә, бер-бер эш кылмак була... Ул мәлгуньне ничек кенә булса да эзләп табарга кирәк. Чын йөзен ачарга, фаш итәргә, зарарсызландырырга кирәк аны. Йөрмәсен монда дөнья болгатып!... Фаш итәргә һәм тиешле җәзасын бирергә...»—Менә нинди тәкъдимнәр белән чыга минем клиентларым. Мин үзләренә ихлас күңелдән ярдәм итәргә, аз гына хәерчелектән йолып алырга теләгән адәм актыклары. Менә шуннан соң үзең уйлап кара инде син, дускаем,—диде Нурул һәм тынып калды.

Монда инде мин дә ни дә булса әйтә алмадым. Үзем укыган язулардан, дустым сөйләгәннәрдән тәмам тетрәнеп, югалып калган идем. Тышта кышкы кич, өйдә инде караңгы. Утларны да кабызмадык, шулай караңгыда һәм тынычлыкта, уйлар эчендә тик утырдык. Шактый вакытлар берни сөйләшмичә. Чынлап та, монда ни әйтәсең инде?

—Ярый, мин киттем. Тиздән Лалә дә кайтып керер,—диде Нурул, күңелсез генә.

—Тукта әле,—дидем мин һәм ана үземне күптән кызыксындырган бер соравымны бирдем.—Син, дустым, миңа бер нәрсәне әйтеп бир әле. Әгәренки сер булмаса. Менә син балалар бакчаларына, аерым кешеләргә күпме ярдәмнәр күрсәттең. Ул тикле акчаларны кайдан алдың син? Бөтен халык, бөтен ил акчасызлыктан интеккән бер заманда кайдан килә ул тикле суммалар сиңа? Мөмкин булса, син миңа шуны аңлатып бир әле.

Нурул, аз гына тын торгач, сөйләп китте:

—Мин төрле урыннарга үтеп кердем, бик күп күзәтүләр, эзләнүләр алып бардым. Дәүләт банкларында, бүтән төр финанс органнарында булдым. Төрле эшмәкәрләр, эре сәүдәгәрләр арасында да йөрендем. Аларның акча янчыкларына, сейфларына күз салдым... Акча юк дигән сүз, Сәлих дустым, гомумән алганда, дөрес түгел ул. Илгә әйләнешкә чыккан акча беркая да китми, юкка чыкмый, шул килеш әйләнеп йөри бирә. Шулай булгач, акча бар ул. Тик менә ул хәзинә кешеләр арасында тигез бүленми генә. Һич тә тигез бүленми! Әйтик, шул әйләнеп йөрешендә берәүләр кулына бик күп килеп керә, кайчак сейфлар төбенә килеп төшә, аерым шәхесләр исәбенә саклык банкларына салына. Шунда байтак вакытларга тоткарланып та кала. Менә шушы хәл инде хезмәт хакының, пенсияләрнең вакытында түләнмәвенә китерә. Кайчак зур суммалар төрле максатлар өчен тупланып та тоткарлана. Асылда кешеләргә кирәкле, файдалы максатлар өчен...—диде Нурул һәм горурлык белән дәвам итте.—Мин банклардагы, финанс органнарындагы акчаларга бер вакытта да кагылмыйм. Чөнки алар шул ук халык акчалары, ил байлыгы. Эшмәкәрләрне, сәүдәгәрләрне рәнҗетүдән дә бөтенләйгә тукталдым. Чөнки күрдем һәм аңладым, алар да акчаны хәләл көчләрен куеп, эшләп таба. Җитмәсә, кулларында иректе акчалары да сирәк була. Ирекле зур суммалар хакында әйтәсе дә юк. Мин үзебезнең бистәдәге кемнән дә булса акча алуны да күптән ташладым инде. Минем үзем яраткан, конфискация ясау гөнаһ булмас дип санаган статьяларым бар. Андый максатларда инде мин зур шәһәрләрдә булам, башкалаларга ук барып җитәм...—диде дустым серле итеп һәм бераз тынып торды.—Ә зур шәһәрләрдә исә без уйламаган хикмәтле хәлләр бар. Төрле биек урыннарга, түрә кәнәфиләренә үрмәләп менәргә омтылучылар, шуның өчен җан атып торучылар күп анда. Ә моның өчен өстәгеләрнең кулын җылытырга, ягъни ришвәт бирергә кирәк. Бик зур суммаларда, монда вакланып торуны кичермиләр. Беләсең килсә, хәзерге заманда илдә һәр биек, төшемле урын сатып алына... Әгәр дә мин шушы максатларда сейф төбенә тупланган суммага конфискация ясап, аны мохтаҗларга таратам икән, бу гөнаһ булмый бит, дустым? Гөнаһ түгел бит, шулаймы?—дип кайтарып сорады Нурул.

—Ул кадәр гөнаһ ук түгелдер инде,—дидем мин, шиктый икеләнеп кенә.

—Менә шулай ул, дустым. Син мине нинди дә булса хезмәт кешеләрен талаучыга, аларга ясак салучы бер явызга санап йөрмә тагын. Мин бары тик хәрам акчаларны гына алам. Хәрам юл белән тупланган һәм хәрам максатларда кулланылачак акчаларны. Асылда мин халыктан талап алынган байлыкны халыкка кире кайтарып кына бирәм!—диде Нурул, горурлык белән.

—Һәм шушы үзең изге дип санаган гамәлләрең әнә кайларга алып чыга? Үзеңне үк шамакайга, ахмакка да чыгарып куялар икән бит әле. Алай гына да түгел икән. Үзенә үк яныйлар, эзләп табарга, кулына богау салырга тәкъдим ясап, милициягә үк хәбәр бирәләр икән!—дидем мин, көлеп.

—Менә шулай икән шул ул, дускаем. Аңламый, аңламый икән адәм балалары яхшылыкны... Һич аңлаешсыз икән алар. Мин үзем дә бик аптырадым инде бу хәлләргә. Ни әйтергә дә белгән юк,—диде Нурул, уфтанып.

—Ары таба ни эшләрсең икән инде син? Бәлки моның ише гамәлләреңне бөтенләй ташларсың. Берсе дә юньлегә килеп чыкмый бит. Үзеңә күңелсезлек кенә алып килә,—дидем мин.

—Ары таба ни эшләсене белгән юк әле, Сәлих дустым. Менә бергәләп уйлашыйк әле шуны. Минем монда килүем дә шуна иде,—диде Нурул.

Әмма ни дә булса уйлаша, киләчәккә планнар кора алмыйча калдык. Безнең капка келәсе челтерәп куйды һәм кемнендер шәүләсе тәрәзәне карангылатып үтте.

—Лалә кайта!—диде Нурул куркынып һәм шул ук вакытта бик дулкынланган, шатланган да тавыш белән.

—Зинһар, үзенне ана сиздерә күрмә! Тота-каба бик яман куркытырсын гына...—дидем мин.

—Әлбәттә! Син нәрсә, ул кадәр мине тинтәк дип белденме әллә?—диде Нурул һәм тынып калды.

Мин жәтрәк утларны кабызып жибәрдем. Салкында бит алмалары алсуланган, тагын да чибәрләнеп киткән Лалә кайтып керде һәм... минем йөземә серле елмаю чыкты. Ул елмаюны тыярга, Лаләгә күрсәтмәскә бик тырышам. Әмма һич булдыра алмыйм. Шунысы көлке, менә хәзерге мәлдә минем сенлемне ул үзе белмәгән, башына да китермәгән тагын бер кеше күзәтеп тора һәм ничек кенә күзәтә бит әле!

—Нәрсә ул кадәр авызынны ерасын әле?—диде Лалә.

—Сон, көлкеле хәлдән көлмичә ничек түзим?—дидем мин һәм шул ук мәлдә Нурул нык итеп кабыргама китереп тә төртте. Мин утырган урынымда сикереп куйдым. Лалә бик сәерсенеп мина карап торды да өсләрен чишенә башлады.

—Кызыклы гадәт синен. Гел генә дә карангы өйдә утларны кабызмый утырасын. Болай булса, күзенә әллә ниләр күренә башлар әле. Хыялыйга әйләнерсен,—дип шелтәләде мине Лалә һәм үз бүлмәсенә кереп китте.

Шунда ук безнен өй ишеге акрын гына ачылды да ябылды.

Мин Нурулны тиз арада минем янга тагын килеп керер, барысынбарысын да сөйләшербез, уртага салып кинәшербез дип көттем. Әмма ул хәбәр бирмәде. Тик тагын бер айдан гына үзен сиздерде.

—Ну, дустым, яшәп тә карадым әле мин сонгы вакытларда! Пәтшалар, президентларнын үзе кебек яшәп алдым,—диде ул, мактанасы килеп.—Беләсенме, бардым бер зур шәһәргә. Ин кыйммәтле, әллә ничә йолдызлы кунакханәнен бер буш бүлмәсенә кереп урнаштым. Бик сирәкләрнен генә кесәсе рөхсәт итә торган бүлмәгә. Йөрим, малай, каз кияве кеби киерелеп. Тамакны да беренче класслы ресторанда гына туйдырам. Һәм дә ки, бераз шулай яшәп алырга да исәп бар әле. Иркенләп бер ял итәргә. Төрле музейларны, күргәзмәләрне тамаша кылырга, театрконцертларга йөрергә. Замана байлары кебек яшәргә... Менә шулай, дустым, абыен корсакны киереп, тук кикереп шәһәр урамнарында тик йөри. Ә нәрсә, мина кем комачаулык итә ала?!—диде ул.

—Бик әйбәт инде бу, бик хуп. Дөнья белән туйганчы таныш инде әйдә... Әмма алай ук тик йөрисен микән әле син анда? Монысына мин шик тотам, дустым,—дидем мин.

—Тик йөрү дип, берочтан анда-монда, төрле яшерен урыннарга күз дә салгалыйм инде. Гөнаһлы урыннарга...—диде ул серле итеп.—Менә мин тукланып яткан ресторанны гына алыйк. Беренче карашка барысы да бик әйбәт анда, хезмәт күрсәтүчеләр ягымлы, мөлаем. Ризыкларны да ин югары дәрәҗәдә, бик тәмле итеп әзерлиләр, кергән кешене хөрмәтләп кунак итәләр. Әмма шушы яктылыкнын бер карангы, яшерен ягы бар. Монда керүчеләрдән чәйлекне, төрле өстәмә түләүләрне дә бик мул алалар. Бөтенләй оятсыз төстә, бер дә чамасыз каералар! Исәпләп карасан исен китәрлек. Хәер, анын монда керүчеләре дә симез янчыклы бәндәләр. Мондый урында төгәл исәп-хисап ясатып торуны үзенә түбәнчелек саный торганнар. Һәм син, дустым, шушы салым көнозын хезмәт түккән официантлар кесәсенә керә дип уйлыйсынмы? Тот капчыгынны. Бу салымнын зур өлеше, беләсенме кая китә? Бер кеше—ресторан директоры кесәсенә керә. Дөресе, анын сейфында туплана. Гаять тә комсыз, нахал, мәкерле бер кеше сейфына. Һәм калын стеналы бу тимер тартмага мин күз дә салгалап йөрим. Анда сәмән дигәнен... әйтеп ышанмассын, чемоданга гына да сыярлык түгел. Ә бу сәмән хужасынын мәкерле планнары бар. Халыкка каршы килә торган планнары. Ул шәһәрнен ин унайлы урынындагы бер торак йотны сатып алырга жыена. Анда яшәгән, гомер үткәргән кешеләрне төрле урыннарга тарата,

йортны сүтеп ташлый, аның урынына заманча ресторан салдыра. Үзенә шәхси ресторан ачарга... Менә нинди исәптә тора ул, карсак буйлы, зур башлы адәм кисәге. Йә, ничек, тәртипме бу, дустым,—дип сорады Нурул, киная белән. Монда шунысын да әйтим, ул, кайчандыр аз һәм тыйнак сүзле егет, соңгы вакытларда бик уйдырып, каһкаһә белән сөйләшергә күнегеп китте.—Бер дә тәртип түгел бит инде бу. Ә мин кемнәрдер бозган ул тәртипне яңадан урнаштырып куярга йөрим әле...

—Кирәкмәс, дустым! Тагын бер-бер кәмит кенә китереп чыгарырсың. Син аңла шуны, безнең илдә хәзер капитализм урнаша, башлангыч капитал туплана. Ә ул башлангыч капитал һәркайда һәм һәрвакыт диярлек җинаятьчел юл белән тупланган. Монысын фәнни коммунизмга нигез салучылар төгәл әйтеп калдырган. Шулай булгач, ул хәрәкәтне син генә туктата алмассың,—дидем мин.

—Кирәгер! Бу кадәрле хәсислеккә, комсызлыкка, намуссызлыкка ничек итеп түзеп тормак кирәк? Бер-бер нәрсә уйламыйча булмас...—диде ул.

—Тукта әле!—дидем мин, кыза башлап.—Алай ашыкма. Син, дустым, соңгы вакытларда үз терсәгеңне бөгәргә генә остарып киттең әле. Бергәләп сөйләшик, киңәшик. Мине тыңлап тор!—дидем һәм... тыңлап торучының юк икәнен сизеп алдым. Тик ераклаша барган көлү тавышы гына ишетелде.

Шуннан соң атна-ун көн үттеме икән, миңа үзем эшләгән көллият йомышы белән калага барырга туры килде. Поездан төшеп вокзал алдына чыктым, анда соңгы вакытта үзгәртеп корылган мәйданның иркенлегенә, матурлыгына сокланып, беразга тукталып калдым. Шунда, гаҗәеп ямьле бу мәйданда гаҗәеп ямьсез шау-шу купты. Үзегез беләсез, хәзерге заманда мондый җәмәгатьчелек урыннарында төрле хәерчеләр, айнымас әлкәшләр, кыйбласын һәм кешелек дәрәҗәсен, йорт-җирен дә югалткан бәндәләр—бомжлар һәрвакыт җитәрлек була... Як-ягына матур чәчәкләр үскән юл буйлап шундый йолкыш бер ир-ат килә иде, исерек кыяфәтле, шапшак киемле ике хатын-кыз кисәк кенә икәүләп шул ир-атка ташландылар. Бөтен йөзен сакал-мыек баскан, чәчләре тузгыган бу сәләмә бәндәне тиз арада җиргә егып та салдылар. Бер оятсызы аның күкрәгенә менеп утырды, икенчесе ашыга-ашыга кесәләрен актара башлады. Һәм шунда бу хәлгә шаһит булып торган барча халык «аһ!» итте. Теге хатын бомжның кесәсеннән.... акча тартып чыгарды. Төргәге белән! Хатын бу акчаларны ашыга-ашыга куенына яшермәкче булды. Әмма төргәк таралды. Искән җилдә як-якка акчалар очып китте.

Шунда инде чын мәгънәсендә мәхшәр башланды. Әллә кайдан гына көтүләре белән берсеннән-берсе сәләмә, таушалган кыяфәтле адәмнәр йөгерешеп килеп җиттеләр. Һич кичекми теге акчаларга ташландылар. Күкрәгендә утырган хатынны гайрәт белән читкә тибәреп, таланучы да сикереп торды, үкереп гомуми өергә килеп керде. Хәерчеләр, исерекләр бер-берсеннән акча таладылар, акыра-бакыра сүгенделәр. Бик рәхимсез итеп сугыша, җиргә егылганнарны таптый, изә башладылар. Кып-кызыл сугыш купты.

Ул арада, яман ачы итеп милиция сыбызгысы чырылдады, өсте ябулы машина килеп туктады. Аннан өсләренә чуар киемнәр кигән, берсеннән-берсе таза егетләр сикерешеп төштеләр. Һич кичекми, үләмәле сугышучыларны аера, кулларындагы саллы резин таяклары белән рәхимсез төстә кыйный башладылар. Суккалап-типкәләп машинага төяделәр. Ә тегеләре исә җан-фарман тартышты, акырды-бакырды, иңәлеп елады. Карап торырга галәмәт тә ямьсез, кызганыч, хәтта җирәнгеч бер күренеш иде бу. Җыелган халык бу көрәшне йөзен чытып, зур ризасызлык белән тамаша кылып торды.

—Ай, Аллам, бу ниткән хәл инде бу? Ник юл куялар мондый мәхшәргә? Замана ахырлары җитү шушыдыр, күрәсең. Кыямәт көне үзедер бу,—дип сукранды сумкалы бер әби.

—Соң, әле бу бичаралар үзара тату гына көн итәләр иде ич. Һәркайсы

үз почмагын, үз киштәсен белде. Ни бүлешә алмадылар икән тагын? Нигә дип бу тиклем үләмә киләләр икән?—дип гажәпләнде бер бабай.

—Милиция үзе дә боларны бу тикле үк рәнҗетми иде әле. Нәрсәләр генә булды икән?—диештеләр.

—Кайсыдыр бер ахмагы дөньяда булмастай хәлне эшләгән. Шушы хәсрәт адәмнәр кесәсенә акчалар салып йөргән. Әйтерең генә бармы, кайберләрен зур суммалы иткән... Хәзер, билгеле инде, болар шуны бүлешә. Аны бүлешеп, соңгы тиененә кадәр эчеп бетермичә сугышу-талашудан котыла алмый инде алар. Бу хәлләр тагын да дәвам итәчәк әле,—диде вокзал хезмәткәре киемендәге бер апай.

Кайберәүләр аның бу хәбәренә ышанмады.

—Булмас. Бу әтрәк-әләмгә кем акча бирсен дә нинди акчаларын бирсен? Әкият бу...—диде алар.

—Булган шул менә. Берсе сөйләп торды, мин үзем ишеттем,—диде теге апай.

—Нинди тинтәк биргән аларга акча, ни уйлап биргән? Ай Аллам, бар икән бу дөньяда байлыгын кая куярга белмәгән кешеләр...

—Башына тай типкән адәмнәр бар икән,—диеште шундагы кешеләр.

—Бер дә тай типмәгән алар башына. Юри китереп тудыралар мондый хәлләрне. Халыктан көлү, аны бутау максатларында. Ярлылыктан, эшсез-лектән интеккән халыкның игътибарын шушындый кыргый күренешләргә, җыен вак-төяккә юнәлтү максатларында. Безнең халык тәмам кыргыйлыкка төшсен, түрәләр алдына катгый таләпләр куя алмасын өчен!—диде зыялы кыяфәтле, чал чәчле бер абзый.

—Каһәр төшсен бу хәсрәт демократларга! Бөтен илне таркатып, дөньяны буяп, пычратып бетерделәр инде...—дип карганды кемдер.

Ахырда вокзал алды мәйданындагы шау-шу тынды. Халык та таралды.

Мин үз юлым белән киттем. Күңелемдә авыр, ямьсез уйлар әйләнде. Бу мәхшәрнең, кыргый күренешнең сәбәпчесе кем икәнне чамалый идем инде. «Их, Нурул, Нурул, беркайчан да, беркемгә дә бирелмәгән бәхет, кодрәт иясе!.. Тагын ни кыланып ташладың бит. Тәмам кыйбласын җуйган, хәмердән башканы белмәгән сәрхүшләр кулына төргәге белән акча тапшыр инде. Моның өчен, белмим, кем булырга кирәктер»,—дип, уйларымны дәвам иттем мин, шәһәр урамы буйлап атлаганда һәм шунда кинәт күңелемне ниндидер икеләнүле, кызганулы уй көйдереп үтте. «Тукта, ә менә Нурул асылда ул кадәр үк бәхет иясе микән әле ул? Әгәренки аның урынында булсаң, син үзең ниләр кыла алыр идең? Ул бит киң күңелле егет, асылда яхшы ният белән эш иткән. Адәм балаларының шушы кадәр әхлаксыз, дуңгыз булуларына ул гаепле түгел ләбаса! Һәм шунда мин үземә тагын бер ачыш ясадым. Нурул хәлендә калу кеше өчен, гомумән алганда, бәхет микән әле ул? Шайтан алгыры, чынлап та. Менә тиктомалдан үзең кебек кешеләр, дусларын-туганнарын, хәтта сөйгән кызың күзенә дә күренми торган бер затка әйләнеп калып кара әле син. Беркем белән дә аралаша алмыйча инкогнито яшәгән затка әйләнеп кара. Шул чагында ничек җырларсың, ниләр башкарырсың икән. Әйтергә дә, тәнкыйтьләргә генә ансат ул». Мин менә шундый уйлар эчендә атладым.

Нурул үзе минем янга тагын өйдә ялгызым утырганда килде.

—Йә, ни хәлләр бар тагын анда, сезнең яшерен һәм гадел дөньяда? Син үзең теләгән дөреслекне, тәртипне урнаштыра алдыңмы? Һәм дә ки әйбәт булдымы шул тәртип? Сөйләп җибәр барысын!—дидем мин, берни дә белмәгәнгә сабышып.

—Бу юлы да бик барып чыкмады шул әле минем эшләр, Сәлих дустым. Синең каршыңда берни белән дә мактана алмыйм. Урыс әйтмешли, һаман да не везет әле мина,—дип башлады Нурул, сүрән генә.—Башта барысы да җай барды. Теге ресторан хуҗасын, капкорсакны, хәрам белән җыйган хәзинәсеннән ансат кына азат иттем. Ул кадәрле байлыкны кая куярга белмичә тинтерәмәсен тагын, дип. Шуннан инде

уйга калдым, бу сәмәнне кая куярга? Кемгә һәм нинди максатларда таратырга? Үзең беләсең, мин үзем, шәхсән, үз кирәгемә бер тиен дә акча тота алмыйм. Бер савыт шырпы да сатып ала алмыйм мин. Күз алдыңа китер, күзгә күренмәс кеше товар сорап кибетчегә акча сузса, ни булыр... Менә өстемдәге киемнәрем тузса да, синең аша гына эш йөртеп киенергә туры киләчәк әле... Ярый, монысы сүз арасында... Күп уйлана торгач, мин мондый карарга килдем: шушы хәзинәдән мәркәзебез вокзалы тирәсендә кангырып йөргән йорт-жирсез хәерчеләргә, кыйбласызларга өлеш чыгарырга! Беләсенме, бу минем күптәнге хыялым иде. Ник дигәндә, дустым, бик тә кызганам мин ул халыкны!—диде Нурул, хис белән.— Бик тә жәллим мин аларны. Менә син үзең уйлап кара. Бу бичараларның һәркайсы, исәпкә ал, һәркайсы, әле күптәнме бу тормышта үз урынын тоткан кеше булган бит. Бәлки намуслы, ә бәлки гаиләле, йорт-жирле, һәм, бик ихтимал, хәтта хөрмәткә ия бер кеше. Хәзерге мондый хайвани хәленә аны көтелмәгән зур бәхетсезлек, ниндидер хәтәр очраклык төшергән. Хәзерге тормышның авырлыгы, яраткан эшен югалту, киләчәккә бернинди өмет күренмәү төшергән. Бу адәмнәр андый хәлгә төшүләренә бер үзләре генә гаепле түгел... Һич кенә дә алай түгел. Конкрет ижтимагый сәбәпләр, гаделсезлекләр гаепле монда... Һәм менә мин, үз мөмкинлекләремнән чыгып, бер тәжрибә ясап карарга булдым. Шушы жәмгыятьтән читкә тибәрелгән фәкыйрьләрнең берничәсен, үзем бер жаен табып, акчалы иттем. Үзләре егылып төшкән түбәнлектән күтәрелү, жәмгыятьтә тагын лаеклы урыннарын яулап алу өчен житәрлек сәмән бирдем мин аларга. Әйбәтләп киенергә, туенырга, хәтта, кирәк икән, квартира-йорт сатып алырга да житәрлек итеп. Өйтәвенә һәркайсына менә шушыларны шарт итеп куйдым... Әмма шуннан мин көткән нәтижәләр булмады. Күңелсезрәк хәлләр килеп чыкты.

—И, дустым, күңелсез хәлләр дип торма инде син аларны. Мәхшәр килеп чыкты диген. Шәһәрнең вокзал алды мәйданында бомжлар белән син күрсәтеп алган кәмиткә мин үзем шаһит булдым!—дидем мин.

—Ничек шаһит булдың?—дип кычкырып жибәрде Нурул һәм, мөгаен, утырган урынында сикереп куйды.

—Ул көнне эшем төшеп калага барган идем. Вокзал алды мәйданындагы мәхшәрне башыннан-ахырынача тамаша кылып тордым. Дөресен әйтим, синең өчен шактый оялдым. Менә шулай ул, дустым. Андагы халык арасында син үзең дә булгансыңдыр бәлки. Син инде анда, шаять, үз адресыңа әйтелгән кайбер шәрехләрне дә ишеткәнсеңдер. Халык һич кенә дә хупламады инде анда синең бу гамәленне.

Икебез дә тынып калдык. Өйдә авыр тынлык урнашты.

—Нәрсә була соң инде бу, дустым?—диде Нурул бераздан, бик ачынып һәм аптырау белән.—Мин үземчә тырыштым, нинди зур ярдәм күрсәттем. Асылда колларына нинди зур мөмкинлекләр китереп тоттырдым. Шул бәндәләрнең берсендә генә дә кешелек хисләре, кешелек горурлыгы калмады микәнни? Хет араларыннан берсендә генә булса да?..—диде ул, өзгәләнеп.—Минем изге ниятләремне ичмаса берсе дә аңламады. Колларына акча килеп керү белән тәмам шашындылар, нәжескә ябырылган чебеннәр кебек хәмер ларекларына ташландылар. Дөньяларын онытып, дуңгыз булганчы эчә башладылар. Бөтен гамәлләре шул булды. Күрәсең, бүтән бер максатлары да юктыр аларның.

—Һәм булмас та. Ул халык нинди дә булса максатлардан баш тарткан инде, аны белми дә. Тик менә син генә көлкеле хәлгә каласың,— дидем мин.

—Соң ни эшләргә кушасың инде миңа?

—Анда-монда тыгылмыйча гына яшәп кара. Гали генә итеп. Өеңдә утыр, әнә телевизор кара, газета-журналлар укы. Бер хобби тап шунда үзенә, әнә балыкка йөре һич югында. Соң, инде синдәге мөмкинлекләр!— дидем мин, дустымның күңелен күтәрәсем килеп.—Әгәренки өйдә тыныч кына утырасың килми икән, син бит теләсә кая чыгып китә аласың. Ил

буйлап көньякларга, төньякларга, телисең икән, бөтен дөнья буйлап сәяхәткә чыга аласың бит син, дустым!—дидем мин, тәмам рухланып.—Дөньяның жылы дингезләрендә коена, чит илләрнең безнең төшләргә дә кермәгән курортларында ял итеп, әвәләнып ята аласың. Дөньяда адәм баласы өчен шушыннан да зур бәхет бармы?.. Гиз дөньяны, рәхәт чик! Ә монда нәрсә әле? Жыен юк-бар гамәлләргә керештең бит син...

—Ничек инде ул алай... юк-бар гамәлләргә керештем?—дип бүлде мине Нурул һәм мин дустымның тавышында чын-чынлап үпкәләү ишеттем.—Житмәсә, син һаман саең кабатлыйсың бу сүзләреңне. Үзеңне бик акыллыга, бүтәннәрне ахмакка санап... Фикерләреңне гел түгәрәкләп, тоныклап маташкан буласың. Син алай тел төбеңне яшереп маташма. Туп-турысын әйт тә бир!

Шунда инде мин дә күңелемдәгеләрне әйтеп салдым:

—Синең менә бу кыланышларың... Һе, дөньяда гаделлек, тигезлек урнаштыра имеш. Каян килгән пәйгамбәр. Кешеләрне аптыратып, нәфесләрен котыртып, үзара канга батканчы сугыштырып... Пүчтәк эшләр болар, дустым. Алай гына да түгел, барысы да зарарлы гамәлләр. Асылда шул ук син яклаган халыкка зыян сала торган гамәлләр...

—Беләсеңме, Сәлихжан дустым, кем син?—дип сорады Нурул, уйдырып кына. Пешеп житмәгән интеллигент кисәге. Синең ишеләр бит инде әнә һәрвакыт хакимият тегерменәнә су коялар. Ул хакимият нинди булуга да карамастан. Шулай булмас иде, чөнки хакимият сезләрнең тамагын туйдыра... Менә хәзер дә сез шул жыен капкорсаклар, халык жилкәсендә утыручылар тегерменәнә су коясыз!—диде Нурул ярсып.—Һе, дөнья гиз, рәхәт чик, имеш... Бөтен халык хәерчелектә, бөлгенлектә яшәгәндә. Телевизор кара, кул кушырып өйдә утыр, имеш. Шушы мөмкинлекләргә ия була торып, мин дә шундый хыянәтчел юлга басарга тиешме?

Дустымнан ишеткән бу каты сүзләрдән, өстәмә ташланган гаептән минем дә ачуым чыкты:

—Алай бик гадел, бик туры булсаң, мәйлең падишаһ, дустым... Әнә үзең теләгәнеңне эшлә, теләсә ни кылан шунда!

Мона жавап булмады. Шунда ук безнең өй ишеге ачылды да ябылды. Бу юлы бик киң булып ачылды һәм каты итеп ябылды. Шул рәвешчә, без дустым Нурул белән ачуланыштык. Гомергә беренче тапкыр һәм нык итеп ачуланыштык!

Нурулның чыгып китүе булды, мине бик күңелсез, үкенечле уйлар биләп тә алды. Аһ, ялгыш булды бугай бу, пешмәгән авыздан урынсыз сүзләр әйтеп ташладым лабаса. Ашыкмыйча, акыл белән генә эш итә белмәдем. Дөрес, аерым кешеләргә андый ярдәмнәр күрсәтеп, кыйбласын жуйган сәрхүшләргә акча өләшеп кенә бу тормышта тәртип, тигезлек дигән изге нәрсәләрне урнаштырып булмый. Буш хыяллар, заяга башкарылган гамәлләр генә булып кала алар. Дөньяны үзгәртү өчен бөтен жәмгыятьнең тоткан юлын үзгәртү таләп ителә шул. Ә бу аерым бер кешенең, хәтта күзгә күренмәс кешенең дә кодрәтеннән килә торган эш түгел. Моның өчен бөтен халыкны күтәрергә кирәк.

Менә шуларны дустыма аңлатып-төшендереп бирә алмадым.

## Нурул... үзенчә яши

Безнең өй ишеген каты ябып чыгып киткәннән соң, дустым минем янга килеп йөрүеннән тәмам тукталып калды. Үпкәләве дә каты булгандыр инде. Белмәссең, ул кая да булса китеп тә баргандыр. Әгәр дә бистәдә генә яшәп ятса, моны аның серен белгән мин бер дә сизмичә калмас идем. Ә кем белә, бәлки ул ерак сәяхәткә үк чыгып киткәндер. Ә бәлки үзе әйткән тылсымлы төймәсенә баскандыр да, теге

дөньяга ук ычкынгандыр. Мондагы хәл-әхвәлләрдән тәмам туеп.

Ул арада салкын кышлар үтте, ямьле язлар житте. Минем көллияттә эшем гаять күбәйде, имтиханнарга әзерлек, тегесе-монысы дигәндәй. Дөресен генә әйткәндә күнелем экраннарыннан, дөнья мәшәкатьләре белән, соңгы вакытларда Нурул дустым шәүләсе еш кына югалып та тора башлады. Ни хәл итәсең, тормыш дигәнебез шулай корылган инде ул.

Тик менә көннәр тәмам жылынып жәйләр житкәч, бистә халкы арасында нindидер шомлы, серле хәбәрләр йөри башлады. Иң әүвәле безнең аулак урам чатында урнашкан, кайчандыр Нурулның әти-әниләре яшәгән, хәзер буш торган, керер юлларын биек чүп үләннәре баскан йортта сәер хәл күзәтеләр. Мәдәният йорты кассасында билетлар сатып утыручы Маһирә апай жәйге кичләрнең берсендә бик соң гына өенә кайтып килә икән. Мәрхүм Нотфулла абзыйларның менә ничә еллар инде кеше яшәмәгән йорты тәрәзәсендә тоник кына ут яктысы күреп алган. Калын пәрдәләр белән томалап куелган тәрәзәләрдә, зәгыйфь кенә булса да ут яктысы шәйләнә икән. Житмәсә, бик тоник кына булып музыка тавышы да ишетелә, ди. Менә нинди гажәп хәлләр! Маһирә апай сагаеп калган, тәрәзәгә елышып, бик колак салып, тыңлап, күзне үткерләтеп күзәтеп тә торган. Әмма йорт эчендә нинди дә булса адәми затның шәүләсен абайлый алмаган.

—Алай да кем дә булса яшәп ята инде ул йортта. Яшерен генә. Ул ут шәүләсе, ул музыка кайдан килер иде... Тәгаен генә берәү яшәп ята анда!—дип сөйләгән Маһирә апай базардагы хатыннарга. Ә тегеләре исә төрлечә фараз кылганнар:

—Менә син... хәзерге заман хәлләрен! Иясез торган йортны да тынычлыкта калдырмыйлар. Әллә юкса чегәннәр кереп ияләште микән? Чегән халкы бик әрсезләнде соңгы вакытларда. Ишегенне ачтың исә, теләсә кемнең йортына киләләр дә керәләр. Керәләр дә төрлечә алдаларга, күз буарга тотыналар. Аз гына аңгыраеп торсаң, талап та чыгалар...

—Чегәннәр булмас, алар шау-шулы халык... Туктагыз әле, берәрсенең ялган аракы заводы ачып жибәрүе дә бик ихтимал анда. Аулак урын, тик иркенләп акча коеп ят.

—Анысы да бик булыр. Шул ялган аракыны чөмереп кенә дә ничә кеше теге дөньяга ычкынды бит инде бистәдә.

—Төрле әфьюн тартучылар жыйналмасын анда тагын.

—Милициягә хәбәр салырга кирәк бу хакта. Барсыннар, тикшерсеннәр.

Иң шомлы һәм, әйтергә мөмкин, хакыйкатькә дә якын сүзне, үзе дә тау астындагы ялгыз йортта ялгызы яшәп ятучы, әллә нинди серле, күнел түрләренә үтеп керә торган үткер карашлы, багучы хатын Сара әйтте:

—Берниткән милициягә барып йөрмәгез, тынычлык бозып. Нотфулла абзыйларның теге мәрхүм малае, үлеп тә күмелмичә калган Нурулланың өрәге кайтып кергән ул йортка. Теге чакта гаражда янып көлгә әйләнгән, жирләргә гәүдәсе дә калмаган бичара егетнең өрәге. Бер дә бүтән түгел бу! Сак булыгыз, ул йортка бик якын килеп йөрмәгез...—дип кисәткән багучы хатын.

Баштарак бу хәбәрләргә ышанмадылар. Тик, әлеге йорт тирәсендә шикле хәлләр дәвам итте. Эчтә ут янганны шәйләүчеләр, музыка уйнаганны, телевизор сөйләгәнне һәм бүтән тавышларны ишетүчеләр дә байтак булды. Бер малай хәтта бу йортның өйалды ишеге ачылып ябылганны да күреп калган. Әмма, күпме тырышса да, эчкә кереп киткән яисә тышка чыккан нинди дә булса кешене генә күрә алмаган. Ишекнең тиктомалдан үзеннән-үзе ачылып ябылуы баланы тәмам куркуга төшергән. Кемдер шаярткан, баланы куркытмакчы булган, дип, әти-әниләре эзләнеп тә йөрделәр... Менә шушындый галәмәтләр. Тик, бистә кешеләре арасыннан беркемнең дә бу галәмәтләрнең сәбәбен белергә, хужасыз торган йорт ишеген ачып керергә, анда эзләнүләр үткәрергә йөрәге

житмәде. Алай гына да түгел, күбәүләр бу йорт яныннан шүрләп, аны ерактан әйләнеп үтә башладылар. Татар кешесе булса, белгән догасын укыды, урыс булса, чукынды.

Имеш-мимешләр торган саен ишәйде, халык арасында тынычсызлану сизелде. Ахырында эш җәмәгать тәртибен саклаучы милициягә барып терәлде. Ә тегесе исә каушап, өркеп тә калмады, эшне бик озакка да сузмады. Җайге тын кичләрнең берсендә, елгыр һәм батыр егетләр искәрмәстән әлеге йортка бәреп керделәр. Шунда чыннан да бик сәер, серле күренешләргә тап булдылар. Егетләр гайрәт белән, бер тибүдә тышкы ишекне ачып, йортка килеп керәләр. Һәм... якты йөзем, ниләр күрәләр! Өй чиста итеп җыештырылган, идәнгә паласлар җәелгән. Беркайда да буш йортта була торган чүп-чар, әйберләргә кунган тузан юк. Алай гынамы, ярты тавышы белән булса да телевизор эшләп утыра, газ плитәсендә чәйнек кайный! Өстәлдә савыт-саба, төрле ризыкларга кадәр бар. Ә шул ук вакытта өйдә бер адәм заты, беркем дә юк. Бу хәлдән бик аптыраган һәм үртәлгән егетләр бик тырышып эзлиләр, кулларындагы фонарьларын яктыртып карават асларын, караңгы бүлмәләрне карыйлар, идән астына төшеп менәләр. Өй яннарын, сарайларга кадәр тикшереп чыгалар. Тик беркемне дә таба алмыйлар.

—Тәки тотып булмады... Качып өлгерделәр, аналарын фәлән-төгән иткере...—ди егетләрнең башлыгы, бик хәтере калып. Ачуына, гарьлегенә түзә алмыйча, күрәсең, кулындагы резина күсәге белән түрдә эшләп утырган япон телевизорын бәреп вата, аяк астына туры килгән әйберләрне тибеп очыра.

—Качып китмәссез менә, албастылар...—дип сөйләнә ул.

Әмма хәлнең тагын дә серлесе, чын мәгънәсендә шомлысы һәм берничек тә аңлатып булмаслыгы алда көтеп торган икән әле. Инде милиция өйдә эш беткәнгә санап, өйалды ишегеннән чыгып барганда, япон телевизорын бәреп ваткан егетнең артына кемдер тибеп җибәрә! Шундый җилле тибә ки, теге әзмәвер өйалды баскычыннан мәтәлеп төшә...

Мондый хәлдән соң инде, агай-энем, табигый ки, үз эшләрендә шактый куркынычлы хәлләр белән очрашкан егетләрнең дә эче сыеклый. Турысын гына әйткәндә, тәмам котлары ботларына йөгерә. Шайтан алгыры, нинди сихер, нинди зәхмәт бу? Алар җәтрәк үзләрен көтеп торган машиналарына тәяләләр дә, таю ягын карыйлар. Исән-имин чакта... Шуннан соң инде бу йорт янына милиция дә килеп йөрмәде. Әгәренки кемнәрдер яшеренеп ята икән, ята бирсеннәр шунда. Өйдән чыксалар, тотып алырбыз әле, дип хәл иттеләр, күрәсең.

Бистәдә бары тик бер кеше—мин генә бу галәмәтләрдән курыкмадым, тик эчем катып көлдем генә. Аларның сәбәпләрен дә, ул күрше йортта кем яшәп ятканын да бик яхшы беләм бит инде. Тик бер нәрсә бик гаҗәпләндерде дә, борчыды да. Бу Нурул дустым янәшәдә генә яшәп тора, ә менә ник минем яныма килеп чыкмый, үзен сиздерми икән? Бик вакыт иде бит инде, югыйсә. Теге чакта шулкадәрле үпкәләде микәнни? Алай үпкә саклый торган егет тә түгел иде үзе...

Безнең бистә уртасында өсте ябулы азык-төлек базары бар. Ул базар тарафыннан да төрле җилләр исте. Анда да бик хикмәтле хәлләр күзәтелгән булып чыкты.

—Дус кызыма дип кенә зур бер кәбестәне сайлап куйдым. Каядыр үзем читкә борылган арада гына шул кәбестәм юкка чыкты. Кайсыдыр рәхмәт төшкересе алды да китте. Рәхмәт төшкере дип шуна әйтәм, ул аны урлап-нитеп алмаган. Тиешле акчасын үлчәү тәлинкәсенә салып калдырган. Хәтта ки артыгы белән салган әле, сдачасын да сорап тормады. Ә мин аның үзен губчим дә күрми, искәрми калдым. Карагыз әле бу хәлне!—дип сөйләгән кәбестә сатучы Мәймүнә.

—И, Мәймүнә җанашым, синең ул кәбестән нәрсә әле... Син бит аны алып киткәннәрен күрми калгансың. Ә мин менә, йа, Аллам, үзем

күреп тордым. Кеше аз, йокымсырап утырам, әмма керфекләрем аша гына әйберләремне дә күзәтәм. Шунда ни булды диегез... Шунда, минем күз алдында, өстәлдә торган симәнке мае шешәсе үзеннән-үзе урыннан кузгалды. Аннары үзеннән-үз һавага күтәрелде, аннары инде бөтенләй дә күземнән югалды, гаип булды. Шул чагында, мин шаклар катып торганда, май бәясе акча әкрен генә алдыма килеп төште. Әгәр күрәсең булса, чын әкият инде, чын әкият менә! Ул куркуларым, ул белгән догаларымны укуларым...—дип сөйләде үсемлек майлары сатып торган яшь кенә бер кыз бала.

Бүтән сатучылар арасында да бик сәер хәлләрне күзәтүчеләр булган. Мин үзем дә ит алырга дип базарга барган идем. Шунда ит сатучы Хәсән абый сөйләп торды:

—Әкәмәтләр күрсәтә әле бу безнең базар. Әллә урнашкан урыны женне-тылсымлы инде. Монда кайчандыр ком базы бар иде, анда юлда катып үлгән хәерчеләрне күмгәннәр дигән сүзләр йөрде,—диде бу хәмер белән дус кеше. Беркөн ит сатып утырам шулай. Көн уңышлы түгел, алучылары да сирәк-мирәк. Бүкәнгә утырган жиремнән йокымсырап киткәнмен. Шунда, йокы арасыннан күрәм, чабып табакка салынган ит кисәкләрем урыныннан кузгала башлагандай булды. Башта күземә генә күренәме соң бу болай дип торам. Юк, чынлап хәрәкәт итә ит кисәкләрем. Әйтерсең, аларны күзгә күренмәс кемдер сайлый, үзенә кирәген карый. Менә чын әгәр!—дип сөйләде Хәсән абый кызык итеп.—Мин инде шүрли үк калдым, ит чаба торган үткер балтама үрелдем. Шунда гына итләрем жанланудан туктадылар. Белмим нинди хәл булды бу. Бәлкем күземә генә күренгәндер... Шуңа әйтәм: кичтән яхшы гына салынган да иде,—диде Хәсән абый.

Бер хатын өстәл өстендәге тоз пакетларының һавада очып йөргәнен, икенчесе кипкән өрекләрнең сикерешкәнен күргән. Бик курыкканнар, бу хакта бүтәннәргә пышылдап кына сөйләгәннәр.

Менә шуныңише әкәмәтләр китте. Болай да эшсезлектән, акчасызлык һәм кыйммәтчелектән интеккән халыкның күңеле тәмам кузгалды, кайберәүләр куркуга ук төште. Бистәдә киеренке хәл килеп туды. Ахырда рәсми властьлар да бу хәлгә битараф торып кала алмадылар. Мондагы болай да ишле милициягә ярдәм йөзеннән шәһәрдән тагын да резин таяклы егетләр жибәрделәр, күрәсең. Аларның саны бистәдә кисәк артты. Кибетләрдә, базарда, урамнарда төркем-төркем йөрделәр, этләр ияртеп йөргәннәре дә күренде. Кемнедер яшертен эзләделәр, кешеләргә шикле-сынаулы карашлары ап-ачык сизелде.

Мин инде Нурул дустым өчен тәмам пошаманга төштем. Нәрсә булды бу егеткә, нигә бу кадәрле саксыз кылана башлады? Үзенең халык арасында никадәрле шикләнүләр, курку-өркү, шау-шу китереп тудырганын үзе үк күреп, ишетеп торадыр бит инде, югыйсә. Минем янга килеп чыгуны да кирәк санамый, тәмам әллә кем булды. Мин үзем аны берничек тә эзләп таба алмыйм. Бер табышмак булды бу, билләһи!

Ул арада бистәдә бернинди кысаларга да сыймаган, чын мәгънәсендә сихерле вакыйга булганлыгы турында хәбәрләр таралды. Аны бик астыртын гына, төрле кеше төрлечә, бик күп имеш-мимешләр белән, буталчык итеп сөйләделәр. Бөтен имеш-мимешләрне жыйнап, азрак тәртипкә салсак, түбәндәгеләр ачыклана.

Жәйге караңгы төннәрнең берсендә, инде юллардагы машиналар хәрәкәте тәмам тукталгач, бистә читендәге тимер юлны үтеп чыгу урынын күзәтү хезмәте сержанты үзенең будкасыннан чыга. Очраклы рәвештә генә, инде бераз тынычлап, черем итеп утырган жиреннән уянып, пес итәргә генә. Шунда шәһәр ягыннан бистәгә таба килгән жиңел машинаны абайлап ала бу. Машина, ничектер сиздермичә үтеп китәргә теләгәндәй, акрын гына, моторын ярым эшләтеп кенә килә. Инде бераз якынлашкач, сержант машинада рульне тотып утырган шоферның да булмавын шәйли. Бик зур, куәтле, чит илдә ясалган бу жиңел машина, әйтерсең, үзеннән-

үзе килә. Бик аптыраган сержант кулындагы чуар таягы белән юл читенә чыгып туктарга ишарә ясый. Ә иясез машина исә, бу әмергә, кем әйткәндәй, нуль игътибар. Ничек жай килсә, шулай үтеп тә китә.

Бу хәлдән бик үртәлгән һәм яхшы гына курыккан да сержант йөгереп будкага керә, телефон аша бистә башындагы постта торучыларга хәбәр сала. Тегеләре тиз генә үзара киңәшеп алалар һәм бердәм карарга киләләр: тәгаен генә урланган машина бу. Һәм дә ки аның шоферы бер-бер хәйләгә бара, ул станциядәге пост турысыннан үзен күрсәтмичә, йә утыргычка ята төшеп, йә бүтән хәйләсен табып үтеп киткән. Сержантны юри куркытырга, бутарга теләгән. Алай кешесез генә йөри ала торган машиналарның сатылуга чыкканы юк әле. Ул машинада бик тапкыр, бик явыз бер жинаятьче утыра булыр. Егетләр шулай хәл итәләр.

Тагын ашыгыч киңәшмә үткәрелә. Бу аерым очрак, һич тә гадәти түгел. Һәм жинаятьчене корал белән каршы алырга әзерләнәләр.

Менә куәтле моторын выжылдатып кына тауга күтәрелеп килгән машина да күренә. Егетләр кыска көпшәле автоматларын әзер тотып, юлга аркылы басалар. Шунда, инде килеп житә генә дигәндә, теге машина кисәк кенә борылып асфальт юлдан төшә һәм читкә каерып, чокыр-чакырлы юлга кереп китә, моторын гөрләтеп тизлекне дә арттыра. Мондый мәкерле хәйләне көтмәгән егетләр бердәм сүгенеп жибәрәләр, тиз генә үзләренең машиналарына төяләләр дә, тегене куа китәләр. Шунда алар жинаятьченең безнең бистә кешесе икәненә тәмам ышаналар, чөнки теге барча урам-тыкрыкларны әйбәт белә. Әмма алай да бистә читендәге начар юллы тар урамнарда авыр чит ил машинасы әлләни алдыра алмый, безнең егетләр жинел һәм чыдамлы машинада аны куып житә язалар. Тик, инде бистәне үтеп аргы баштагы әсирлектә вафат булган немесләр зираты турысына житкәч, качып барган машина олы юлга чыгып баса һәм тизлекне дә кискен арттыра.

Шунда, бәлки безнең тыныч бистә тарихында беренче тапкыр булурактыр, ату тавышлары яңгырый. Егетләрнең берсе кулындагы автоматыннан теге машинаның көпчәкләренә төбәп атып жибәрә һәм... тидерә дә. Машина тормозларын чыелдатып юл читенә чыга, ава язып тукталып кала. Аның ишеге чартлап ачылып китә. Тик егетләр, барчасы да кулларындагы фонарьларын яктыртып шул якка юнәлтсәләр дә, машинадан кемнең дә булса чыкканын, жиргә төшкәнен күрмиләр. Эчтә утыра мәлгунь, корал тотып утырмагае... Курка-курка гына якын киләләр һәм күрәләр: кыйммәтле, өр-яңа, әмма гап-гади тимер машина. Салонында да, утыргычта да адәм заты күренми. Бернинди сихере, эчендәге рулен борып бара торган жайланмасы да юк. Берни дә юк! Барысы да аптырап калалар. Менә сиңа табышмак тек табышмак!

Инде төн үткән була, яктырып та килә. Шунда егетләрдән берәү машина янындагы чирәмдә кан тамчылары күреп ала. Кан тамчылары!.. Бу инде хәлне кискен үзгәртә. Димәк ки, бернинди могжиза да, сихер дә булмаган монда. Барысы да шалкан кеби гап-гади. Димәк ки, ниндидер бер тапкыр һәм жинаятьчел кеше, зур хәйлә иясе, яисә гаять көчле гипнозга ия адәми зат утырган монда. Әнә бит, ул сихри зат түгел, машинага килеп тигән ядрәләрдән яраланган. Тик менә ничек бер дә сиздерми машинадан төшкән дә, шул арада кая качып китәргә өлгергән... Тагын бер киңәшеп алгач, егетләр карар итәләр. «Шәлиш! Әлләни ерак китә алмас ул болай булгач. Эзләп табарга аны һәм тотып алырга! Зур коштыр бу, бистәне болгатып ятучы да шушыдыр әле...» Һәм егетләр кан таплары эзе буйлап китәләр. Ул исә аларны туп-туры немес зиратына алып килә һәм... шунда югала да. Тәмам ачулары кабарган егетләр иренмиләр, бөтен зиратны бетереп тентү ясыйлар. Теге билгесез адәмгә төрле авазлар салып, бирелергә тәкъдим ясап та карыйлар. Әмма ләкин беркем дә күренми, тәкъдимнәргә жавап бирүче дә булмый. Егетләрдән берсе мондый тәкъдим кертә:

—Әйдәгез, сафка тезеләбез дә автоматлардан ут ачабыз. Бөтен

зиратын айкап чыгабыз. Шул вакытта беркая да китә алмый ул. Ике кулын берьюлы күтәрә дә килеп чыга.

—Син нәрсә сөйлисең, акылыңнан ук яздыңмы әллә?—ди аларның башлыгы теге егеткә һәм бистәнең зиратка терәлеп үк диярлек торган йортларына күрсәтә.—Әнә анда кешеләр яши...

Бәхеткә каршы, дөресе, Нурул дустымның бәхетенә каршы, әлеге кинәшне беркем дә якламый. Милиция егетләре зират эчендә тагын байтак эзләнеп йөриләр, бер утырып тәмәке тарталар да, кайтып китәләр. Табылмый тек табылмый, ни эшләтәсең аны.

Менә шундый вакыйга булганлыгын сөйләделәр. Эзли торгач, теге сихерле машинаның иясе дә табылды. Ул шәһәрдәге бер зур түрәнең үз улына, туган көненә бүләк итеп бирелгән машина булып чыкты.

Бу вакыйгалардан соң, рәсми властьлар да, халык та уртак бер фикергә килделәр. Эш һич кенә дә уен-муен түгел, эш җитди. Безнең моңарчы, гомумән алганда, тыныч кына яшәп яткан бистәдә зур бәла, афәт йөри! Бистәдә нindидер бик көчле, бөтен халыкны берьюлы, массовый төстә гипнозлый ала торган, үз ихтыярына буйсындырырга исәпләгән экстрасенс хәрәкәт итә. Яисә ул бөтенләй яңа, әле беркемдә дә булмаган тылсым иясе. Мөгаен генә, ул шундый осталыкка барып җиткән, хәтта инде кешеләр күзенә күренмичә йөри ала. Бөтенләй дә күренмичә һәм сиздермичә. Моңарчы тупланган хисапсыз күп фактлар раслый моны... Иң хәтәре шул: бу инкогнито зат үзенең куәтен явыз максатларда да куллана. Әнә бит ул ни эшләде? Хакимият, рәсми властьлар белән халык арасында никадәрле аңлашылмаучылыклар, каршылыклар китереп тудырды. Ул хәтта кайбер түрәләрне, эшкуарларны турыдан-туры талауга кадәр барып җитте. Конкрет һәм зур күләмнәрдә зыян күрүчеләр бар. Тагын да хәтәре шул: ул үзе дә берни дә эшләмичә яшәргә, бүтәннәрне дә шуна өмсендерергә мөмкин. Бу бит инде нәрсә китереп чыгарыр... Шайтан белсен, ул тагын нәрсәләр уйлап табар, ниләр кылана башлар?!

Билгесез, күренмәс бу зат безнең бистәгә чит планетадан килеп төшкән акыл иясе яисә робот түгелме икән әле, дигән фикерләр дә әйтелде. Әмма бу фараз зур яклау тапмады. Болай бит, әгәренки чит планета вәкиле, оча торган тәлинкәдән төшеп калган бер зат булса, ул бу рәвешле хикмәтләр кылып йөрмәс иде. Җир кешеләренә күренмичә, кача-кача уйнап, аларны өркетеп, үртәп, төрле ярдәмнәр оештырган булып маташмас иде. Болар барысы да нигә хаҗәт аңа? Җир кешеләренең мәшәкатьле тормышына кысылу—адәм көлкесенә калу... Һәм әлеге фаразны бердәм төстә кире кактылар.

Табышмак бу затның үзен фаш итү, ул корырга ихтимал булган төрле тискәре гамәлләрне кисәтү чаралары да күрелде. Иң беренчесе итеп, Нотфулла агайларның иясез торган һәм, мөгаен генә, нәкъ менә шушы сихер иясе беренче әкәмәтләрен күрсәтеп алган йорт янына кораллы милиция сагы куелды. Кибетләрдә, базарларда сату итүчеләргә ныклы наказ бирелде: әгәренки нинди дә булса шикле гамәлләр сизеп алалар икән, һич кичекми милициягә хәбәр салырга. Бөтен оешмаларга, дәүләт һәм аеруча финанс учреждениеләренә саклыкны көчәйтергә. Болар өстенә халык арасында кайбер бик мөһим саналган урыннарга яшеренке рәвештә генә төнлә дә күрә торган хикмәтле приборлар куелган икән дигән дә имеш-мимешләр йөрде. Теге серле зат шул приборларда күренеп китмәс микән һәм кулга да килеп эләкмәс микән дигән максатларда.

Менә шушындый хәвефле хәлләр китте, өстәмә мәшәкатьләр килеп туды бистәдә.

Мин үзем инде Нурул дустымның теге вакыттагы дорфалыгын күптән гафу иттем, аның өчен борчуларга төштем. Тәки сак кына эш итә алмады, үзен халыкка сиздерде, эш рәсми властьларга кадәр барып җитте. Менә хәзер, мондый хәлләрдән соң, кайларда төн кунар, тамагын кайда туйдырыр, гомумән, ничек яшәр икән инде ул? Аның өчен бистәдә

көн итеп яту мөмкинлекләре дә бетеп килә кебек. Әллә кайларга, зур шәһәрләргә генә китеп бармаса инде. Анда да, кая гына барса да, ана гел күченеп, урын алмаштырып торырга туры киләчәк. Чөнки, күзгә күренми торган зат булсаң да, бу дөньяда үзеңне кешеләргә бер дә сиздерми яшәү мөмкин эш түгел ләбаса. Үзең күренмәсәң, гамәлләрең күренә... Аннан килеп, теге шоферсыз машина вакыйгасы. Иманым камил ки, Нурул дустым эше булды инде бу. Ул чагында яраланган да бит әле ул... Ә ни өчен минем янга килеп чыкмый икән? Әллә ярасы бик авыр булып, бер аулак урында җәфа чигеп, сызланып ята микән? Үземә урын тапмадым, күңелемне әнә шундый бимазалы уйлар телгәләде.

Җәйнең матур бер көнендә кармакларымны алдым да, тау астындагы елга буена төштем. Шунда бераз тынычлык табармын, авыр уйларымнан да котылып торырмын дип. Тик киресе килеп чыкты... Таллыклар арасына кереп утырдым. Менә кин, салмак агымлы елга. Әнә, кайчандыр, гамьсез бала чакта без Нурул дустым белән су коенып йөргән тугай. Әле Нурул күзгә күренә торган, гади, башкалар кебек үк бер кеше чагында... Их, бәхетле вакытлар булган икән шул ул!

—Нигә болай уфтанып утырасың әле?—диде янәшәмдә генә таныш тавыш.

—Нурул? Синме бу, синме бу?—дип кычкырып җибәрдем мин, чиксез шатланып.—Сине тотып тукмакларга кирәк иде дә, булмый бит менә. Бу мөмкин эш түгел... Сөйләп җибәр барысын да җәтрәк! Син теге чакта яраландыңмы? Ул яра бик авыр түгелме, сәламәтләндеңме инде?

—Тән ярасы—пүчтәк ул, дустым. Ул яра төзәлде дә инде,—диде Нурул, фәлсәфи төстә.

—Ничек көн итәсең? Тамагыңны ничек туйдырасың? Кайларда төн кунасың син, яшәүләре бик авыр түгелме?—дип, сораулар яудырдым мин.

—Боларына борчылма син! Боларның берсе дә минем өчен берниндн проблема түгел. Тамагымны мин теләсә кайсы ресторан яисә ашханәдә, бик ансат туйдыра алам. Теге чакта үземне базарда сиздерүем бер шаяртып алу гына булды ул. Тылсымга ия була торып та кайчак шаяртып аласы да килә бит. Кешеләрдән бер көлеп аласы,—диде Нурул.—Ә төн куну дигәндә, шул ук замана байларының өчәр катлы йортларында буш торган бүлмәләрнең исәбе-чуты юк. Болары да минем өчен берни тормый,—диде ул һәм авыр итеп көрсенеп куйды. Аңарда ниндидер ризасызлык, күңел төшенкелеге сизелә иде.

—Эш тагын нәрсәдә соң?—дидем мин.

—Менә, Сәлих дус, син үзеңне минем урынга куеп кара әле,—дип башлады Нурул, сызлану белән.—Әйтик, иртәгә иртә баштан ук син бу дөньядан юкка чык, кеше күзенә күренмәс бул. Ниләр эшләр идең, кая барыр идең син ул тәкъдирдә? Уйлап кара әле шуны яхшылап... Хәзер инде син көллиятеңә барып укыта алмыйсың. Иң әүвәле сине директор үзе дә, укытучы иптәшләрең дә берничек тә кабул итә алмаячак. Нинди генә аңлатуларга кереп маташсаң да. Һавада яңгыраган тавышны гына кем инде кеше, шәхес итеп, житмәсә, укытучы итеп танысын. Аның йөзен, килеш-килбәтен, гомумән, җисемен күрмәгәч. Аннан килеп студентлар да, аларга нинди аңлатмалар ясамасыннар, мондый зат биргән дәресне тыңламас... Менә, дустым, шулай. Син инде тирә-юньдәгеләр үзеңне кабул итми, аңламый, араларына алмый торган бер мәхлукка әйләндең дә калдың. Асылда җәмгыятьтән читкә басып, күзәтүче сыйфатында гына торган бер затка. Син, биниһая зур кодрәткә ия була торып, бик гади, әмма һәр адәм баласы өчен бик кирәкле, табигый һәм беренчел мөмкинлекләрдән колак кагасың. Шул ук вакытта барча хокукларыңнан, вазифаларыңнан да. Ниндидер бер тирән бушлыкта каласың. Бик тә авыр бер халәт бу, коточкыч авыр халәт... Менә мин шушындый хәлдә хәзер. Уналты мең халкы булган бистәдә япа-ялгызым! Моның ни икәнен үзем генә беләм...—диде Нурул.

—Әйе...—дип суздым мин дә. Дустымның хәлен дөрестән дә, чамалый идем инде.—Соң, синең күп хыялларың бар иде бит. Хәтерлисеңме, күзгә күренмәс була алу хакында күптән хыял йөрттең син. Шуннан файдаланып башкарасы гамәлләрең дә җитәрлек иде.

—Аһ, дустым, туйдым барысыннан да, тәмам туйдым! Асылда тормышка ашмаган ул хыял-гамәлләрдән гарык булдым. Ялгызлыктан, кешеләргә бер кәлимә сүз әйтеп сөйләшә, аралаша алмаудан туйдым. Гел сакланып, сагаеп кына йөрү ай-һай, кыен икән. Минем кешеләр арасында яшисем, алар кебек буласым, сөйләшәсем, кычкырыша-талашасым, уйныйсым-көләсем, елыйсым килә. Гап-гади бер кеше булып каласым... Ә болай... бу дөньяда яшәүдән дә туеп барам бугай инде,—диде ул, өметсез итеп.

—Теге дөньяга, икенче яссылыктагы дөньяга күчеп карамыйсыңмы соң?—дидем мин, сак кына.

—Анда да күчеп карадым инде. Бер тапкыр гына түгел, өч тапкыр. Аларда тормыш бездәгедән чагыштырмаслык әйбәт. Андагы мөмкинлекләрне, унайлыкларны син күз алдыңа да китерә алмыйсың. Әмма дә ләкин, дустым, син тагын бер уйлап кара әле. Ул дөнья—алар өчен бит. Ә без, менә синең белән мин, менә шушы дөнья кешеләре. Шушы шартларда, шушы мохиттә яшәү өчен яратылган. Авырлыкларда, җитмәүчелектә, хәтта инде хәерчелектә булса да... Юк! Яши алмыйм, торып кала алмыйм мин ул дөньяда. Гәрчә анда җәннәт булса да, гәрчә алар үзләре мине бу хакта бик үгетләсәләр дә. Бер генә көн дә яшисем килми шунда. Бер көн эчендә дә шушы керле дөньяны үлеп сагына башлыйм!—диде Нурул.

Шунда минем башка бәхетле уй килде:

—Ә, тукта әле, дустым! Алар сиңа вәгъдә иткәннәр бит. Синнән күзгә күренә торган кеше ясарга вәгъдә иткәннәр. Шуны сорап кара алардан.

Нурул сүзсез калды. Шактый шулай утыргач, авырлык белән әйтте:

—Их, дустым... мин сорадым инде. Үтенеп тә, ялынып та карадым. Булмый икән шул! Миннән инде кабат бу дөньяда күренә торган кеше ясап булмый икән. Бөтенләй дә. Минем теге чакта ялкын эчендә калып атомнарга таркалуым үзем өчен фаҗига булган! Инде кабат төзәтеп булмаслык коточкыч бәхетсезлек булган,—диде Нурул, тирән хәсрәт белән.

Икебез дә тынып калдык. Өстә каядыр җил исә, таллар шаулый, елга өстендә вак дулкыннар уйный. Якты кояш безгә нурын сибә. Әмма дөнья безнең өчен барыбер күңелсез иде.

—Ниләр генә эшләп карарсың икән инде?—дидем мин бераздан.

—Менә белмим инде ни эшләргә дә. Ничек яшәргә дә белмим,—диде ул һәм кинәт өмет белән, сулышы кысылып, әйтеп куйды.—Алай да бер уем бар әле минем! Соңгы өметем бар. Әгәр дә син ачуланмасаң, син ярдәмгә килсәң...

—Нинди уй ул? Мин сиңа ярдәмгә килергә һәрвакыт әзер!—дидем мин шатланып.

—Менә Ләлә... Әгәр дә Ләлә риза булса, мин шушы дөньяда гына яшәп калыр идем. Әгәр дә Ләлә мине әле һаман да яратса, авыр язмышымны уракташырга батырлыгы җитсә... Ләлә миңа кияүгә чыкса!—диде ул.

Монда инде мин үзем дә ныклы уйга калдым. Чыннан да, ай-һай, кыен мәсьәлә бу... Минем сеңлем Ләлә болай үзе кыю гына кыз. Әмма алай да...

—Ләлә белән сөйләшеп карармын соң...—дидем, аптырап кына.

—Аның шунысы да бар бит әле, дустым. Әгәр Ләлә үз язмышын минем язмыш белән бәйләргә хәл итсә, без инде бу бистәдә яшәп кала алмыйбыз. Бу шартларда яши алмыйбыз...—диде Нурул.—Безгә кайсыдыр бер аулак, тыныч урынны сайлап алырга туры киләчәк. Әйтик, каядыр таулар арасында яисә урманда яшәргә. Ул чагында Ләлә үзенең тегүче эшен калдырыр, урман каравылчысы яисә умартачы булыр. Әгәр дә

моны ошатмый икән, болай барып чыкмый икән, без зур шәһәрләргә китәрбез. Үзен беләсен, матди як минем өчен зур мәсьәлә түгел... Их, әгәр дә Лалә минем язмышымны уртаклашса!—диде ул һәм кайнарлык белән дәвам итте.—Мин Лаләне яратам. Бу дөньяда мин бары тик аны гына яратам. Син ана шулай диген. Ә минем җилбәзәк егет түгел икәнемне син, дустым, үзен беләсен,—диде ул, өмет белән.

—Мин... үз ягымнан эшне җайларга тырышып карармын,—дидем.

—Сәлих дустым, зинһар, тырышып кара әле. Син дә ашыкма, мин дә сабырлык белән көтәрмен. Лаләгә барысын да җай белән генә, әйбәтләп аңлат. Бу эшкә тота-каба тотынып өркетә, күнелен кайтара күрмә. Җай белән генә эш итә белсән, Лалә куркып та калмас әле ул. Мәктәптә урта белем алган, кыю кыз бит ул. Мин беләм...—диде Нурул һәм хыялый тонга күчеп дәвам итте.—Их, әгәр дә Лалә риза булса. Ул ризалыгын бирсә! Һәм без кешеләрдә шик тудырмый торган бер аулак урында яшәсәк. Минем янымда үзем сөйгән кешем булса, көн дә сөйләшер, серләремне утраклашыр кешем. Мона тиң бәхет минем өчен бу дөньяда булыр идеме?! Мин үзем дә Лаләне бәхетле итәчәкмен. Җаны ни тели—шундый байлыкларга тиендерәчәкмен, теләсә кая алып барачакмын. Теләсә Гавай, Канар утрауларына, зөбәрҗәт дингезләргә... Мин бәхетсез кеше түгел, кодрәт иясе дә бит әле!—диде ул, горурлык белән.

Без елга яры буендагы таллар ышыгында, аулак бер урында Нурул белән кечкә кадәр бергә утырдык. Туйганчы сөйләштек, бистәдә ул китереп чыгарган хәлләрне искә алып көлештек.

—Кая, бер кармагыңны мина да бир әле. Бер рәхәтләнеп балык тотыйм әле. Үземнен бала чакларымны, гади генә бер кеше чакларымны искә төшереп,—диде Нурул һәм тиз арада минем янәшәдәге озын кармак сабы үзеннән үзе һавага күтәрелә башлады. Җитмәсә, әледән-әле берсеннән-берсе җайлы алабугаларны чабакларны тартып чыгарды. Ни әйтсән дә Нурул шул ул. Балык тотарга да миннән оста иде бит ул...

### Лалә үзенчә хәл итә

Мин байтак вакытлар уйланып, тәвәккәлли алмыйча йөрдем. Ничек кенә аңлатып бирергә соң сенлем Лаләгә бу хәлне? Дөньяда монарчы беркайчан да, беркайда да булмаган хәл бит бу. Сенлем кайчандыр үзе яратып йөргән егетне, ә хәзер күзгә күренмәс бер затны ничек кабул итәр? Җисемсез, гайре табигый бер затны... Сүзне ничек һәм нидән башлап җибәрергә? Күп баш вата, фаразлар итә торгач, мин Лаләгә барысын да гади генә итеп, турыдан-туры сөйләп бирергә булдым.

Беркөн кич Лалә эштән кайтып керде һәм мин ана карап ирексездән сокланып куйдым. Минем сенлем хәзер алсу йөзле, гел елмаеп торган сөйкемле, чибәр бер кыз булып җитте. Акылы-фигыле дә әйбәт, сабыр, зәвык белән матур итеп киенә дә белә. Нурул белән гаҗәп тә пар килерләр иде дә бит, эх!..

—Лалә, син бу дөньядагы төрле серле, могҗизалы хәлләргә ышанасыңмы?—дип башладым мин.

—Ниткән могҗизалар да серләр ул тагын?—диде Лалә, кухнәдә чәй куеп йөргән җиреннән илтифатсыз гына.

—Менә, әйтик, әле күптән түгел генә телевизордан бер фильм күрсәттеләр. Фантастик фильм. Анда болай: бер яшь кенә галим, үзе тикшеренүләр үткәрә торган лабораториянен электр системасында кыска ялганыш булу нәтиҗәсендә, зур бәхетсезлеккә очрый. Кешеләр күзенә күренмәс булып кала ул. Әгәр чынлыкта да шундый хәл була калса, син мона ышаныр идеңме?

—Ай, Аллам, кем генә ышансын инде андый әкиятләргә. Фантастика бит ул,—диде Лалә көлеп.

—Ул егет күзгә күренмәс зат булып кала. Шунын аркасында бик авыр, кызганычлы хәлләргә дә тарып бетә. Аннан кешеләр куркалар, аны дошман күрәләр хәтта. Анын белән ахыр чиктә шул илнең разведка идарәсе дә кызыксына башлый. Аны тотып алырга, үзләренә хезмәт иттерергә уйлыйлар...

Ләлә минем сүзне дәвам итте:

—Һәм дә ки бу егет белән анын яраткан кызы икесе бергәләп кешеләрдән качып китәләр,—дип дәвам итте Ләлә, мине бүлеп.—Алар ул кыз белән өйләнешәләр дә әле. Бергәләп тауларда чаңгы да шуып йөриләр. Мин бу фильмны карадым, Сәлихҗан абый. Күнелле фильм, әмма фантастика. Ни генә әйтсәң дә, шул ук әкият инде ул. Дөньяда бит андый хәлнең булуы мөмкин түгел...

—Менә нәкъ шундый хәлнең булуы да мөмкин икән шул әле, сенлем,—дидем мин.

Ләлә кулын гына селтәде.

—Сөйләп утырма әле юкны!

—Соңгы вакытларда бистәдә булган хикмәтле хәлләрне беләсең бит син. Серле бер кешенең үзе күренмичә генә пенсионерларга акчалар өләшеп йөрүен... Базардагы адәм ышанмаслык хәлләр... Шоферсыз машинанын юл буйлап килүе... Син бу хәлләрне ишеткәнсеңдер бит инде.

—Ишетүен ишеттем дә...—диде ул, сузып кына.

—Менә ишетсәң, белеп тор! Болар барысы да дөрестән дә күзгә күренми торган бер кешенең эше. Мин беләм аны. Мин ул кешенең кем икәнен дә беләм!—дидем мин.

—Кем була соң инде ул, андый сихер иясе? Йә, әйтеп кара шуны,—диде Ләлә көлеп.

—Нурулла ул! Безнен күрше Нурул. Кайчандыр син яратып йөргән егет!—дип ярып салдым мин.

Ләләнең кулындагы табагы шалтырап идәнгә төшеп китте. Ул бар эшен ташлап кухнядән йөгереп чыкты, каршыма килеп басты. Куркыну, аптырау, әчке газап белән тулы күзләрен миңа текәде.

—Ни сөйлисең син, Сәлихҗан абый? Ниткән Нурулла булсын ди ул... Ник теләсең минем бәгырьләремне... Нурулла ул күптән вафат бит инде. Ул җанашым гараж эчендә, ут ялкыннарында калып һәлак булды ич. Нурулла юк ич инде ул бу дөньяларда... Син, абый, әллә нинди сүзләр сөйләп утырма әле, зинһар! Кеше куркытып, күнелләрне кузгатып...—диде Ләлә, өзгәләнү белән.

—Тынычлан әле, сенлем. Нурул вафат булмаган ул чакта,—дидем мин, йомшак итеп.—Әйе, вафат булмаган. Әмма дә ләкин бик зур бәхетсезлеккә тарыган. Ул кеше күзенә күренми торган булып калган. Менә синең белән минем күзгә дә күренми торган булып. Нәкъ әнә теге кинодагы кебек инде,—дидем мин.

Ләлә беразга катып калды, йөзе дә ап-ак булды. Аннары тәмам хәлсезләнеп минем янга, диванга килеп утырды.

—Ай, Аллам, Нурулла!—диде ул, авыр сулап һәм йөзен куллары белән каплады. Анын бармаклары арасыннан күз яшьләре саркып чыкты.—Аһ, Нурулла! Бу нәрсә була инде бу? Ничекләр генә итеп ышаныйм инде мин бу хәлгә? Чынмы бу, абый, әллә уйнап сөйлисеңме соң син?—диде ул һәм тагын елап җибәрде.

—Чын хәл бу, сенлем. Менә бераз тынычлан да, тыңлап тор әле,—дидем мин һәм җайлап кына ана барысын да сөйләп бирдем. Ул таң калып тыңлады һәм, күрәсең, ахырда минем сүзләремә берникадәр ышана да башлады бугай. Мин сөйләп бетергәч:

—Ай, Нурулла... Бичаракаем, мескенкәем. Нинди бәлаләргә килеп тарыган икән. Адәм ышанмаслык бәхетсезлеккә тарыган,—дип куйды.

—Менә шулай, сенлем. Нурул исән һәм ул безнең бистәдә яшәп ята... Мин анын белән күптәннән элемтәдә инде, күптәннән сөйләшеп йөрибез. Нурул сине һич кенә дә онытмаган, ул әле дә сине ярата, бары

сине ярата. Алай гына да түгел, ул синен белән бергә булуны тели!— дидем мин.

Лалә тагын киндер кебек агарынды, еш-еш сулый башлады.

—Тагын ниләр сөйләп утырасың, абый? Ничек инде ул... бергә булуны тели?.. Күземә дә күренмәгән бер егет белән мин ничек итеп бергә була алам? Син, ахры, саташып сөйлисеңдер бу сүзләреңне, абый,— диде ул.

—Бер дә саташмыйм, сеңлем. Нурулның синең белән бергә буласы килә, бергә яшисе килә,—дидем мин.—Әнә теге фильмдагы кебек. Без Лалә белән бистәдән еракка китеп, аулак бер урында яшәсәк иде, ди. Лалә урман каравылчысы яисә умартачы булса иде, ди. Мин аны бик тә житешле, унайлы тормышта яшәтер идем, теләсә кая, чит илләргә, диңгез буйларына алып йөрер идем, ди. Дөньяның иң матур җирләренә, ди. Йә, сеңлем, син үзең ни әйтәсең?—дидем мин, өметләнеп һәм... бик куркып.

Лалә күзләрен чытырдатып йомды да, бик озак уйланып утырды. Аннары күңелсез генә, әмма тәвәккәл итеп әйтеп куйды:

—Юк, Сәлихҗан абый, булмый бу миннән. Син Нуруллага әйт, ул, җанашым, зинһар, үпкәли күрмәсен,—диде ул, катгый итеп.—Мин әллә кайдагы урман араларына да, зур шәһәрләргә дә китә алмыйм. Мин шушы бистә кызы... Үземә күренмәгән сихри зат белән дә яши алмаячакмын. Аннары, ни бит әле...—диде ул, тартынып кына.—Аннары, күпме еллар үтте бит инде. Минем Нурул каршысында кәррә дә гаебем юктыр. Минем инде яратышып йөргән, вәгъдәләр бирешкән егетем бар. Теге, үзем кунакка барып йөргән авылда...—диде.

Шул ук мәлдә без Лалә сеңлем белән икебез дә сискәнеп, дерт итеп куйдык. Кинәттән безнең өй ишеге үзеннән-үзе киң итеп ачылды һәм акрын гына, монсу гына итеп ябылды.

### Соңгы сүз

Шуннан бирле Нурул дустым бөтенләй дә юкка чыкты. Үзен хәтта мина да сиздермәс булды. Бистәдә дә бернинди хикмәти хәлләр кабатланмады. Кешеләр ул хәлләр турында төрлесен сөйләделәр-сөйләделәр дә акрынлап оныттылар. Дөнья мәшәкатьләре барысын да оныттыра бит ул.

Тормыш алга бара, акрынлап еллар үтә тора. Лалә шул үзе кунакка барып йөргән авыл егетенә кияүгә чыкты. Мине ялгыз калдырып шунда китеп тә барды. Хәзер инде ирен карый, балалар үстерә. Үзенчә тулы тормыш белән яшәп ята. Ул кунакка килгәндә без икәү генә калып серләшәбез, Нурулны сагынып искә алабыз. Мин үзем әле һаман да өйләнмәгән, ялгыз башым—җан тынычым, дигәндәй...

Нурул дустым югалды, әмма мин аны онытмыйм. Еш кына аны уйлыйм. Кайларда гына йөри икән инде ул бахыр? Бик җылы, рәхәт, бай илләрдә, диңгез буйларында яши микән? Бәхетлеме икән ул, туган ягын сагынып, бик моңланып гомер итми микән? Ни эшләп аз гына вакытка булса да минем яныма килеп чыкмый икән? Җан дусты янына... Әллә инде теге янәшә дөньясына китеп, шунда ияләнде, гомергә шунда торып калды микән. Күңелем дә никтер шулай сизенә. Менә шуларны уйлыйм да дустымны сагынам.

Бер дә бәхетләре булмады бит аның, дип уйлыйм мин. Менә дөнья алай икән ул. Табигать-анабыз һәр адәм баласына мөмкинлекләрне, талант һәм сәләтләрне дә бик житәрлек итеп, үзенә тиешлесен бирә икән. Өстәмә мөмкинлекләр, тылсым, сихер кебек нәрсәләрнең бер дә, бер дә кирәге юк икән. Ни пычагыма да! Аларга ия булу бернинди бәхет бирми, ә бәхетсезлекләргә генә китерә икән. Нинди тиргәнтен, үкенечле, һич кайтарып ала алмаслык бәхетсезлекләргә, дип уйлыйм...

Һәм дә ки бу уйларым дөрес булса кирәк.

*Арча, 1999 ел.*

# ШИГЪРИЯТ



## Рөстәм Мингалим

### КОТЛАУЛАР-БАГЫШЛАУЛАР

*Мин кайвакытта язучы гомерен очрашу, танышу, дуслашу, котлашу, югалтышу һәм сагыну кебек хис дулкыннарында тирбәлгән каек хәлендә күрәм. Үземнең мондый хәлем-хәләтем шактый еллар дәвамында «Котлаулар-багышлаулар» папкасына, әлегә дөньяга чыкмаган китабымдагы шигырьләргә керә барган. Аларны бүген укыганда, гомернең йә бик матур, йә бик тә моңсу вакытларын: теләкләребез белән тормышыбыз арасында нинди упкыннар булуын өр-яңа баштан, кабат йөрәктән кичерәм. Әнә шул шигырьләрнең кайберләрен абруйлы «Казан утлары» укучылары игътибарына бирергә булдым. Шигырьләр язылган еллары тәртибендә бирелә.*

#### Илдар Юзеевка

*(Бераз шаярып)*

**... Безнең урын,**
**бу нәкъ безнең җир дип,**
**җиң сызганган идек.**
**Хуҗаларча йөреп,**
**ут өереп,**
**эшләп алган идек.**
**Яшәр өчен урын**
**сайлаганда**
**ялгыштыкмы әллә?!**
**Турайт әле билең,**
**әйт кызык сүз,**
**хәлләрне күр, әнә!**
**Без тормаслык гүзәл**
**бу урынга**
**яшьлек кора оя.**
**Кая китик?**
**Монда, әй, валлаһи,**
**картаерга оят.**

*1977*

## Равил Фәйзуллинга

Миңа кердең Мәскәүдә,
сөйләшәсең, ипле син.
Нидер язып кайт, дисең,
нидер табып кайт, дисең.
Бәлки, нидер табылыр—
утлар якты үзәктә...
Беләсеңме, син миңа
тапмасам да сүз әйтмә.
Күпләр килгән табарга,
әле һаман киләләр.
Этә-төртә Мәскәүгә—
югалырга керәләр.
Югалырга яшьлектә,
югалалар картлыкта.
Елмаешып, исереп—
югалалар шатлыктан.
Төсләре дә үзгәрә—
соры юлда сорылар.
Тавышлары—хәрабә,
башы бар да соңы бар.
Һич күренми эзләре—
шундый якты үзәктә?!
Беләсеңме, син миңа
тапмасам да сүз әйтмә.
Мин үземне югалтмам,
хәтта нидер язармын.
Күрешербез исән-сау
уртасында Казанның.
Алда безнең җәйләр бар,
күп кышларда әле без—
ике кара ир булып,
ак юлларда йөрербез.
... Һәм иҗаты тукталган
егетләрнең өенә,
йә кызлар бүлмәсенә
илһам булып керербез.

*1977*

## Хәсән Сарьянга

*(Вафатыннан соң)*

Өзелеп яратсак та дусларны,
берәм-берәм җирдән китәрбез...
Яратсак та җәйләр, кышларны,
бала-чага, хатын-кызларны...
Берәм-берәм шулай китәрбез.
... Бизмәсәк тә кырдан, үләннән,
көйрәп яткан бөрлегәннәрдән...
Тәм тапсак та төрле телләрдән,
туймасак та торган өйләрдән,
барысын да ташлап китәрбез.
Калдыралмас безне бирегә
калдырырга теләгәннәр дә.
Төгәллисе мөһим эшләр дә
калдыралмас безне бирегә.
Калдыралмас безне Кояш та,
йолдызлар да, Идел буе да...
Калуыбыз кирәк булса да—
калдыралмас безне бу дөнья.
Шулай булгач,
шулай итәрбез—
курыкмыйча гына, тын гына,
күптән киткән дуслар янына,
берәм-берәм шулай... китәрбез.

*1978*

## Каләмдәшем Рәдиф Гаташны озаграк күрми торганда туган уй

Ул шулай көлә белә,
яктырып килә белә:
көмеш таңкә сипкәндәй,
тавышын сибеп көлә.

Җыя алсаң, көлүен—
учка җыеп торырлык,
кесәңә тутырырлык,
куенга тутырырлык.
Тәнең шуны сизәрлек
рәхәтләнеп беравык.
Аның гына көлүе—
шундый тере матурлык.

Аның гына көлүе—
шундый рәхәт түгелү.
Тик отарлык түгел ул,
онтырлык та түгел ул.

*1983*

## Йөреп чыгыйк әле Казанны

*(Роберт Әхмәтҗановка)*

Сине күрми торсам, әллә ничек,
танып булмый көнне, Кабанны.
Йөреп чыгыйк әле, бер күрешкәч,
чигеп чыгыйк әле Казанны.
...Үзебездән әйбәт дуслар монда
очрап, хәлне сорап үтәрлек...
Күрмәмешкә салышып үтсәләр дә
үпкәләмик артык, күтәрик...
Исемебез чиста, кием пөхтә,
акча да бар кесә төбендә.—
Без бит риза шуңа, данга менеп,
күккә ашкан даһи түгелләр.
Дәрәҗә бар—әйбәт уңыш бирер
сары бодай кыры биеклек.
...Ял итәргә дисәк, диван нигә?
Безгә таш та, җир дә бик ипле.
Берәүләрне ун кыз сөйсә—нәрсә?
Безне сөйгән, әйдә, бер булсын.
Киеме ни безгә, кием аша
җиткерсеннәр йөрәк җылысы.
Чәчәк сузмый гына тыңласыннар,
әй, укырбыз шигырь туктап бер.
Һәм, кем белә, Казандагы гөлләр—
бәлки, бар да безнең өчендер?!

*1985*

## Лена Шагыйрьҗанга

Түшәгең дә шигырь синең,
шигырьләр юрганың да.
«Мөлдерәмә күңел»ең дә,
шигырең юллары да...

Яшьләрне, яшьтәшләреңне
көнләштереп яз гына.
Гомерлеккә кердең, Лена,
син шигърият язына!

Кычкырып сине сөйлибез,
кайчакта—яшерен генә.
Котлыйбыз иҗатың белән...
Һәм булган яшең белән!

*1995*

## Илһам Шакировка

Бергәлеккә—бердәмлеккә
чакыру чаңы булдың,—
син күзе булдың татарның,
сызлаган җаны булдың.
Алтмышка җитеп сызлавың
авыр бит, авыр ла ул:
йөздә үтмәс, меңдә бетмәс,
мәңгегә калырмы ул?
«Туган тел»ле халкың калса—
чынга ашар өметең.
Котлыйбыз сине, туганкай,
чын күңелдән үз итеп!

*1995*

## Хисам Камаловка

«Чияле тау»дан шактый ук
еракка киткәнсең бит.
Без сизмәгән-көтмәгәндә
җитмешкә җиткәнсең бит.
Узган гомер, калган хәтер,
төзәлмәс яралары...
Безнең яшәү—зур тукталыш,
бәйрәмнәр—алга бару.
Котлы булсын бу бәйрәмең,
шатлыгы уртак булсын!
Җитмештән соң да җайдак бул,
иҗатың юртак булсын!

*1996*

## Гәрәй Рәхимгә

Тормыш тоташ бәйрәм түгел,
булгалый бәйрәмнәре.
Ник булмасын бәйрәмнәре,
булганда Гәрәйләре?
Ул Гөргөри, Григориймы,—
анысы—Алла эше:
әдәбият дөньясына—
безгә кирәк бу кеше.
Мәхәббәттә, дуслыкта да,
иҗатта да алдыра...
Моннан да зур бәйрәмнәрең
булсын, Гәрәй, алдарак!

*1996*

## Клара Булатовага

Юлга чыктың «Гел кояшка карап»,
гел кояшка карап яшәдең.
Күзләреңдә шуңа гел нур булды,
нур киптерде—килсә яшьләрең.
Елмаюың нурдан гына торды,
беләсеңдер үзең калганын...
...Бәйрәм котлы булсын!

Гомере озын булсын
синең кебек якты баланың!

*1996*

## Олуг бәйрәм

—Баян улы Галиевкә
Илле тулган,—ди халык.
Олуг бәйрәм тарафыннан
бу бит бераз нахаллык!
Әкренрәк, ашыкмыйча,
соңрак килсә ни булган?!
Соңламый, Марсель, бәйрәмнәр!
Котлыйбыз сине, туган!
Яшә күреп бәйрәмнәрнең
олысыннан-олысын:
«Алтын тотка»ң,
«Апрель кызы»ң,
җырларың юлдаш булсын!!!

*1996*



# Эльмира Шәрифуллина

## Су бирегез!

1

Әллә инде Рәсәй кечерәйгән,
Әллә биегәйгән Шырдан тавы?
Колакларда изге дастан кебек
Кое[1] чишмәсенең сулкылдавы.

Кайтавазлар сеңгән тирәнлекнең
Саф суына серләр манчылган күк.
Чирткән Каюм кое ниргәсенә—
Хакыйкатькә юллар ачылган күк.

Әкиятләр хәтта әйтмәгәнне
Әйткән галим туар баласына.
Кое төпләреннән күтәрелеп
Чыгып баскан белем даласына.

Җитмеш һөнәр җиде юл чатында—
Әле уңга, әле сулга илтер.
Каюм бабабызның салган эзе
Мәгърифәткә,
Фәкать нурга илтер.

...Кайда юнәлсәк тә сынатмабыз,
Махы бирү—безнең шөгыль түгел.
Туган җирен соеп сихәтләнсен
Һәм хушлану алсын һәрбер күңел!

2

Алдап булмый икән Табигатьне,
Үзенекен итә Җир-Җиһан.
Без генә ул
Ялган белән бизәп,

[1]К. Насыйриның үз куллары белән казыган, бүген дә исән, авылдашларына саф суын биреп торучы кое күз алдында тотыла.

Кызыл сүздән көттек
Җыр-илһам.

Ә Табигать гадел!
Юк кодасы,
Кодагые,
Килен-кияве.
Даһиларны үзе сайлап ала,
Һәм бәяли, биреп тиярен:
Гыйбрәт алсын,
Нәтиҗәсен кылсын,
Шифалы су белән туенсын,
Диеп, гүя ике гасыр буе
Яшәтә ул Каюм коесын.

Яшәтә ул җыры үлмәсен, дип,
Җире иңмәсен, дип, татарның.
Исбатлый күк Каюмнары белән
Биеклеген илнең, Ватанның!

Урау юллар,
Гасырга тиң еллар
Кайтавазлар булып эндәшә.
Инә белән казылса уй-җырың—
Каюм коесына тиңләшә.

...Су бирегез,
Кирәк бер йотым су,
Кайчагында җитә бер тамчы.
И Табигать,
Каюм коесыннан
Шул бер тамчы
Саф су булсамчы!

## Өеңдә көтсә

Көтсә өеңдә ягымлы күзләр,
Каршы йөгерсә кадерле сүзләр—
Елмаер кояш кара төнеңдә,
Җылы тоелыр салкын көне дә.

Көтсә өеңдә ихлас ярату,
Мөмкиндер анда кайгың тарату.
Авыр уйларың качар, онтылыр,
Шундый бер көнең—мең алтын торыр.

Көтсә өеңдә тәрбия, тәрәк,
«Син», диеп типсә анда һәр йөрәк.
Бәрәкәт иңәр бердәм нигезгә,
Тәгәрәр дөньяң төздә, тигездә.

Көтсә өеңдә кадер вә хөрмәт,
Сиңа дип пешкән ләззәтле нигъмәт.—
Үрнәк алып бу тату тормыштан,
Тәрбия күрер бала тумыштан!

## Бәхетле бул!

*Мәңге дә бәхил түгел,*
*Бәхетсез булсаң әгәр!*

Хәсән Туфан

Төшләремә минем керәсең дә:
Бәхетле бул, бәгърем, диясең.
Ак мендәрне кочкан чәчләремне
Бөртегенә кадәр сөясең.

Ак мендәрне кара чәчем кочкан—
Бу фалны соң ничек юрыйсың?
Синең һаман үз туксаның туксан,
Бәхетлеме, диеп сорыйсың.

Чәчләремне сыйпап сөясең дә
Баш очыма төйнәп өясең.
«Баш түбәмә кайгы өймә, бәгърем,
Тарат, зинһар!»—
Килә диясем.

Бәхетле бул, бәгърем, диясең дә
Бармак янап үзең көләсең.
Әйтәсең күк: син бәхетсез булсаң—
Бәхил түгел, үзең беләсең...

...Син яраткан кара чәчкәйләрем
Бөртегенә кадәр агарган.
Ак башымда кара кайгым шул син,
Төшкә кергән саен яңарган...

## Өлгергән миләш

Әче дә генә миләш—тәлгәш-тәлгәш,
Суык тешләп кайчан балланыр?
Очраша да юллар аерыла,
Киләчәктә бәлкем ялганыр?

Әй, уңган соң миләш—тәлгәш-тәлгәш,
Миләш уңу—диләр суыкка.
Уйларыма бәреп керәсең гел,
Чыгаралмыйм хәтта куып та.

Тәм йөгергән миләш—тәлгәш-тәлгәш,
Кышка кала көзен җыймасаң.
Үкенечтә үтә икән гомер,
Хисең белдерергә кыймасаң.

Әче генә миләш—тәлгәш-тәлгәш,
Кырау төшәр, ә ул балланыр.
Очраша да юллар аерыла,
Киләчәктә бәлкем ялганыр...

*1998*

## Аяк астындагы болыт

Баш очыннан җилләр акты,
Кичләрдә таңым атты...
Күк гөмбәзен төргән болыт
Ак юрган булып ятты.

Ак юрган булып ятты да
Кыш булып җирне төрде.
Җәйләрдә чуп-чуар дөнья
Актан ак төскә керде.

Ак юрган булып ятты ул,
Кара болыт иде бит...
...Аяк асларымда калдың—
Бәхетемне күреп кит.

*1999*

## Җете төсләр тиз уңа

Син тез чүктең алларыма, сүзең бер үк:
—Тәкъдимемне кире какма, какма берүк.

Җаваpладым:—Синең буе улым үсә...
Сүзләреңнән җетелеге юлны кисә...

## Булмаган да кебек

Сары күзле, соры йөзле,
Җилбәзәк сөюләрең,
«Яратам», дигән ялганны
Миемә «төюләрең».

Вәгъдә сүзләрең төялеп
Чаптылар... яманатта:
Танымадым тавышыңны
«Ярың» хурлаган чакта.

Җир уптымы,
Җил йоттымы?
Булмаган кебек бер дә
Сөюнең энҗе-мәрҗәне
Күмелде кара гүргә.

Җиргә сеңгән мәхәббәткә
Кинәнгәндер җир корты...
...Тик кыйссадамы сөюнең
«Йосыф-Зөләйха сорты»?!

*2000*

# Чәчмә әсәрләр



## Нурулла Гариф

### УЛ ҮЛДЕ...

ЯШӘҮ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Кеше үзенең үләсен алдан тоемлый, диләр. Төне буе саташып, иртәдән үк сәер уйлар белән уянган Навилнең күнe дә әллә ничек кенә узып китте. Аңлата алмаслык, гомергә татып карамаган сәер хисләр иде алар. Бу арада дөньясының кызыгы бетеп, яшәүнең тәме калмады. Дөрестән дә, бу яшәүнең ни яме бар соң, ахыры билгеле булгач? Менә үләргә иде дә, сине әйләндереп алган дөньясына читтән генә бер күз салырга иде. Сүз дә юк, дөньясында барысы да үз урынында калыр, кояш та көндәгечә вакытында чыгып, вакытында батар аңысы. Ул алары турында уйламады. Навилне кызыксындырганы-уйландырганы кабергә кергәнче үк яшәүнең мәгънәсен табып, дөньяда эшләгән яхшылыклары белән гөнаһларын бер үлчәүгә салып карыйсы килүдә иде. Аннан соң туганнары, дуслары, бергә эшләгән хезмәттәшләре дә бар бит әле. Алар ни сөйләнерләр икән.

Шул уйлар белән ишек бусагасын атлап керде ул. Баш миенең кайсыдыр почмагындагы күзәнәк, бу ишектән үз аягы белән чыкмау мөмкинчелеге булуын искәртеп, бүтән уйлар өерендә миллионнарча иптәшләреннән уздырып, шул турыда хәбәр бирергә тырыша иде. Өйдәге тормыш аны үзгәрешсез каршы алды. Хатыны да, көндәгечә вакытына тугрылыклы булып, савыт-саба шалтыратып, ашарга әзерләп йөри. Иренең башкалар кебек эштән соң әрле-бирле сугылып йөрмәвен белсә дә, вакытында ашарга пешереп куймас. Әйтерсең лә бары ун-унбиш минут кына булса да алданрак тотынса, дөньясының чите кителер.

Чишенде. Киемнәрен пөхтәләп элеп куйды. Бүлмә буенча йөренеп, үз әйберләрен хәстәрләп чыкты. Аннары көндәгечә телевизорны кабызып җибәрде. Ә анда бердәнбер калдырмыйча карап барырга тырышкан яңалыклар программасы бара. Хәер, телевизорны караганчы ук ни сөйлиселәре билгеле инде: анда—атыш, монда—үтереш. Радиосын, видеосын җибәрсәң дә шул—кеше үтерү. Моннан өйдә дә котылу чарасы юк. Тегендә мылтык ата, монда бомба шартлый. Бар дөньясы шуның белән генә яши кебек. Әйтерсең лә анда бәхет-шатлыкка, матурлык-сөюгә урын җитми. Авыл җирендә генә рәхәт ул. Телевизор карыйсы да,

радио тынлыйсы да юк. Гәҗит тә килми. Шуңа да озак яши алар. Һәрчак эш белән мәшгуль булып, үләргә вакытлары тими. Хәер, соңгы вакытта аракы белән булышып, алар да бер җаен тапты сыман.

Навил телевизорның тавышын көчәйтте. Дөрес, ач тамакка бик үләсе килми иде. Ни эшлисең, үлемнең дә үз унайсызлыгы булырга тиештер лә. Аның балалары турында уйланырга гына вакыты калмады. Хәер, алар турында исән чакта уйларга кирәк иде. Кеше үзенең кайчан үләсен белми бит. Ярый әле ул үзенең үлеменә аңлап бара...

Ул әзер! Навил иркенләп кәнәфигә сеңде... Менә ул гомеренең соңгы минутлары якынлашуын тоя. Аякларда кан йөреше туктады. Кулның авырлыгы юкка чыкты. Тән оеп, сулыш кысыла башлады... О, юк! Кирәкми, ул үлемнең болай ук авыр буласын белмәгән иде!.. Кирәкми!.. Кирәкми!!! Ләкин соң иде инде, күрәсең, эчке яктан бернигә дә буйсынмаган нидер, күкрәкне вата-җимереп, теше-тырнагы белән тырмашып, дөньяга чыгарга омтылды...

Үлемнең соңгы минутлары авыр, бик авыр икән. Кеше аның авырлыгын алдан белсә, гомере буе шуны уйлап, шуннан куркып кына яшәр дә һәм үзенең үлгәнен дә тоймыйча мәңгелеккә күчәр иде. Шуңа күрә үлемнең көтмәгәндә килүе аның кайчан һәм ничек буласын белмәгәнгә генә уйландырмый икән. Үлем ачысы авыр, әмма бу авырлык бетмәс кебек тоелган мизгелдә генә булып, Ходай аны җиңеләйтә, күрәсең. Навил дә акылдан шаштырырлык тойгылардан бер-ике тапкыр тартылып куйды да хәрәкәтсез калды. Шул арада ук, бу авырлыкны җиңеләйтеп, тәннең тышкы ягыннан томан кебек бер җиңеллек сеңә барды. Ул бөтен тәнгә таралды, акылны томан каплады. Ул үлде, дөньясы аның өчен бетте инде. Тирә-юньдә бер хәрәкәт тә, үзгәреш тә тоелмады. Телевизорда һаман каты тавыш белән диктор сәясәт, байлык турында гәп сата иде. Ни җитми бу адәм баласына... Тормышны тарих күзлегеннән карасаң, ул болай да гел сугышлардан гына тора бит. Алар, күп очракта, адәм баласына җир җитмәүдән башланып китә. Җирдән туып, тукланыр өчен гомер буе шунда казынучы кешелек дөньясы, кайчандыр кабат шунда әйләнеп кайтачагын онытып, сугышып яшәгән һәм яши бирә... Хәер, аңа боларның берсе дә—гайбәте дә, сәясәте дә кирәкми инде хәзер. Ул бу дөньяда юк инде. Бары тик тәне генә кәнәфигә сеңгән килеш вакыт узышында кала бирә.

Ул үлде. Дөньясы үзендәге барлык мәшәкатьләрен төяп артта калды. Дөнья бетми, кала икән ул. Һәр кешенең—үз дөньясы. Аны ул үзенчә күрә, таный һәм кабул итә икән. Кешенең үлеме белән шул дөньясы да бетә. Һәркемнең—үз ахырзаманы. Кичә генә бөтен дөньясын куып чапкан борчылулары да юкка булган икән. Кичәге көнен бүген күрсә, ул күпкә башкачарак яшәр иде. Бу дөньяда бәхетле тормыш белән яшәүчеләр суфилар гына, күрәсең...

Тоныклана барган телевизор тавышын юкка чыгарып аш бүлмәсе ягыннан хатынының чәрелдәгән тавышы соңгы тапкыр ишетелде. Ит тарткычны әйләндерергә кирәк икән. Ит тарткыч. Дөньясы да шул ит тарткыч түгелме соң? Шул ит кисәгеннән акыл аерылгач, аның катып калган тәне өстәлдәге сыер итеннән нәрсәсе белән аерыла соң? Хатыны бер-ике тапкыр кычкырып, аңардан телевизорның тавышын киметүне сорап сөйләнде дә туктап калды. Итне барыбер үзенә чыгарырга туры киләчәген белә лә ул. Беренче тапкыры гына түгел—иренә әйтеп ни файда. Ярый залга кереп кычкырмады әле, күрмәгәннәрен күрәсе иде. Хәер, кызыгы да, үлеп карауның бар сәбәбе дә шунда иде бит. Юккабарга ачуы килгән саен, дөмекмисең дә шунда, дип кабатларга яраткан хатыны бу яңалыкны ничек кабул итәр икән? Аның иреннән дә яхшы ир бу дөньяда булмаячак. Кадеремне белмәгәненә үкенерсең әле!

...Аның җаны, тәненең бар авырлыгын югалтып, кирәкле җиренә яшен тизлегендә очты. Ул инде башка үлчәүләр буйсынуында булып, үткән дөньясыннан бөтенләе белән аерылып өлгермәсә дә, яна дөньясының

үткәнендә дә, киләчәгендә дә була ала иде.

Беренче булып, туган йорты, әти-әнисе искә төште. Шул ук мизгелдә ул инде туган авылында булып, балачактан күнеленә сеңгән нигез йортының капкасына ябышты. Капка төбендә бик кызу гына бер-берсен әтешә-тартешә дүрт-биш карт гәпләшә иде. Каршы яктан капканы урамдагы әлеге шау-шуга борчылган әтисе үзенә тартты. Нәбиулла карт, аның әтисе, авыл халкы арасында яшәүчеләрдән иң олы яшьтәгеләрнен берсе иде. Ата-ана өчен иң авыры—бала хәсрәте. Улың үлгән, дигән авыр сүзне акылы тиз кабул итсә дә, мәгънәсе аңына барып житә алмыйча, ялгыш ишетмәдемме, өнемме-төшемме бу, дигәндәй, кабат-кабат сорады. Биш-ун минутлар элек кенә, мин әйт, син әйт, дип сатулашкан картлар арасындагы бу авыр хәбәрне ирештерергә батырчылык иткән чордашын тагын да авыр хәлгә куеп, кабатларга мәжбүр итте. Бу сүзне житкерүче Хәлил бабай да аңлый иде, гомер буе дус, тату яшәгәннән соң да, кабат булачак очрашуларда авылдашы Нәби карт карашының бер читендә үзенә карата курку, әлегәчә булмаган күңелгә ятышсыз тойгы сизәчәк иде ул.

Безнең халыкка үлемгә алдан әзерләнеп кую хас. Үлемнең барыбер киләсен белгән карт-карчыклар үз мәшәкатьләрен башкаларга өймичә күтәргә тырыша. Әзерләнеп тә таманга килә, үзеннән соң да эшләре өч көнгә калып, искә алулары белән ел буена сузылачак әле ул. Нәбиулла бабайның да ләхеткә дип әзерләп куйган такталары ничә тапкыр череп, күпме тапкыр башкалар тарафыннан алып торылды инде. Бу юлы да үзенә дип әзерләп куйган иде, әле яшәргә дә яшәргә тиешле кече улына кирәге чыгар дип кем уйлаган бит...

Үлем-житемнәрне үз гомерендә күп күрде Нәбеш-Нәби карт. Сугышта да кырылды халык, тыныч чак булуга карамастан, ачлыктан да күп үлде. Үлем-житемгә дә иялашелә икән.

Югалтуларның төрлесе булды. Ата-ананы бигрәк тә яшь чакта югалту—зур кайгы. Абый-энекәшләрне, якын дусларны югалту да, күңелдә жәрәхәт калдырып, күңелне озак елларга телгәли икән. Әмма үзенә чират көткәндә үзеннән соң нәселенне дәвам итәргә тиешле баланны югалту авыр, бигрәк тә авыр икән. Чыдый инде адәм башлары. Ташлар да түзмәс иде, башкайлар түзә икән.

Менә кабат күтмәгәндә кайгы инде. Күрсәтте инде дөньясы Нәбеш картка, күрсәтте. Алдын да күрсәтте, артын да. Үпкәләрлеген калдырмады.

Хәбәрнең авырлыгы Нәбиулла картка төште. Инде хәзер гомер иткән карчыгына бу кайгылы хәбәрне ничек ирештерәсе?

—Карчык, барасы жиребезгә кечкенәбез бездән алдан китә торган икән. Бетеренмә инде, тиздән үзебезгә дә шунда юл тотасы. Барган жиребездә бер юанычыбыз булыр,—дип жайлап кына сүз башлады.

Хәлимә әбинең кулындагы савыт-сабасы идәнгә төшеп челпәрәмә килде...

—И, Раббым, картлык көнебездә нинди гөнаһларыбыз өчен жибәрден бу кайгыны...

—Язмышлар күкләрдә языла, карчык, безләргә буйсынмый шул... Сабырсызланма әле...

Кайгылы хәбәр авылда сәгате-минутында таралды.

Төрлечә сөйләделәр.

Берәүләрнең Навилнең үзен, икенчеләре бала-чагасын, кайсысы хатынын жәлләде. Бик яхшы, тату яшәгән булган бит алар. Шул матур тормышка риза булып, Ходайга шөкерана кылып, яшисе дә яшисе икән. Үзе турында шул чаклы яхшы фикерләр ишеткәч, нигә үлгәненә дә үкенгән иде Навил. Хатынына карата да юкка гына начар уйда булган ул. Аның Тәслимәсе кебек яхшы хатынны дөньясының барлык читен кырыштырып, көндез чыра яндырып эзләсәң дә табырлык түгел икән бит. Ах! Нинди үкенечле бу үлем...

Үлгән кеше турында начар яктан сөйләргә ярамаганлыгын белсәләр

дә, сүгүчеләре дә күп иде. Үзенә дә, хатынына да эләкте. Шул бер хатынына да баш була алмаган бит ул. Кеше тик торганнан гына кәнәфигә утырган килеш үлми инде. «Чүпрәк башлылыгы» башына житкән дә инде аның. Хатыны елап калыр, дип уйлагандыр инде. Киләчәктә Тәслимәсе артыннан анардан күпкә әйбәтрәкләрнең көтүе белән чабып йөриселәре алда икән. Ярый үлеп котылган әле...

Навил турында сөйләнгән гайбәтләр мәрхүмне күмеп кайтканнан соң да атна-ун көн буена житте. Аның үлеменә бәйле яна дәлилләр көннән-көн өстәлә торды. Берәүләре, исерек булган икән, дисәләр, икенчеләре, хатыны әллә нәрсә дигән эчемлек эчерткән икән, дип исемнәренә чаклы белеп сөйләделәр. Эшендә дә нәчәлникләре белән арасы төгән булган икән. Бурычы булган, һәм, киресенчә, кассада үз исеменә язылган әллә ничаклы акчасы барлыгын үз күзе белән күргәндәй сөйләүчеләр дә табылды. Имеш-мимешләрнең очы-кырые күренмәде. Алар барысы да Нәбиулла бабай белән Хәлимә әбигә көнендә ирешеп, күңелләренә таш тавыдай өелә торды...

Үзе турында, үзе белмәгәннәре, башкайларына да кереп карамаган уй-фикерләре, кеше ышанмаслыклары да күп ишетелде. Имеш, алар, икесе дә, алны-ялны белмичә эшләгәннәр дә эшләгәннәр. Үз гомерләрендә дуслыкны да, туган-тумачаның хәлен белешүнең дә нәрсә икәнлеген белмәгәннәр. Кунак жыймаганнар, туйганчы ашамаганнар. Навил гомере буе дөнья куган, байлык жыйган. Шунлыктан хатын ягына ишәрәләүчеләрнең:

—Инде менә бары да этләргә калды,—диючеләре дә булды.

Булды инде, булды... Гомер ишетмәгән гайбәт-сүз калмады.

Һәркемнең күңеленә кереп, барын үлчәп, үзенә карата булган һәр карашны тойса да, берсенә дә үпкәләмәде, рәнжемәде Навил. Чөнки дөньясында үзе дә хаталардан, кешеләр турында ямьсез уйлардан азат түгел иде. Фикерләрнең юньсезлеге дә, комсызлыгы да кылган гамәлләрендә дә чагылыш табалар иде. Сыналырга килгән дөньясында сынмаучылары бик сирәк. Саклану чарасыннан чыгып, алары да ачы язмыш жилләрендә кырыкка бөгелергә мәжбүр. Дөнья шул бу.

Күмәргә кайтучыларның берәүләрен кайгы чакырса, икенчеләре сүзе булмасынга ашыкты. Кызыксынып, хәер-акчага өметләнеп килүчеләре дә бар иде. Һәркем үзенекен уйлады. Үлемгә чират юк. Әмма ул килмичә калмый. Аларның язмыш-күрмешләре барысы да алда әле. Навилнең үлеме кешечә, үз өендә. Хушлашмыйча чыгып китеп, кире кайтмаучылар да күпме әле бу дөньяда. Үлемнәрнең төрлесе була. Табын корып көтеп торганда кеше кулында кайтучылары. Гаепле-гаепсезләре, акылга сыймаслыклары, күңел ышанмаслыклары. Жан өшеткечләре... хәтта сөенечлеләре—котылды, яисә, котылдым, дип әйтерлекләре. Үлеме белән үлемсезлеккә күчүчеләре. Тыныч кына бәхилләшеп, елмаеп китүчеләре. Күзенең агы белән карап, газиз балаларына да бәхиллеген бирмәүчеләре...

Исәнлектә калучылары үлемне төрлечә кабул итә. Дөньяның фанилыгына ышанмыйча, якын кешесенең каберенә көн саен килеп, сәгатьләр буе тере кеше белән сөйләшкәндәй елап утыручылары, казып алып кабат бер генә, соңгы тапкыр карап калырга теләүчеләре... Аракысын, ризыгын калдыручылары, шунда ук үзенә кул салучылары...

Була инде була, дөнья булгач, төрлечә була...

Кешенең үлеменнән соң барысы да кала. Кырыгы кырык якта төйнәлеп чишелмәс бәхәсләр дә, күренмәс жепләр белән бәйләнгән хис-тойгылар да, берьюлы чишелеш табып, хәл ителеп, челпәрәмә килә. Эшләнеп бетмәгән эшләре, төзегән сарайлары, гомер буе хәләлме, хәрәм көч беләнме жыелган, тупланган машина-маллары, миллионнары кала. Гаеп-гайбәтләре, үпкәләре, үзеннән соңгыларга бары тик тимер-томырга әверелеп, орден-дәрәжәләре кала. Сөйгәннәре, сөеләчәкләре... Әйтәсе килгән яисә ишетмәгән күңелне юатырлык сүзләре кала. Начарлыгы да

кала, яхшылыклары да кала. Болар үзеннән сон яшәүчеләр һәм яшәячәкләр күнелендә гасырлардан гасырларга күчеп кала.

Кала инде, кала, барысы да кала...

Үлем нихәтле аяныч һәм куркыныч булса да, Ходай тарафыннан кирәк табылган гамәлдер. Гомерләр узган саен тән дә, дөньясына караш-фикерләр дә картая. Барлык матурлык тоныклана. Яшь чакта гына үзен кебек яшь, матур, күнелен кебек иркен икән лә бу дөнья. Гомер агышы узган саен анын төсләре уна, озынлыгы кыскарып, үтәр юлын авырлаша икән. Яши-яши кырысланган күнел катылыгыннан үлем генә коткара. Үлем—олы йокы ул. Кеше мәнгелеккә килсә, ризасызлыгы күбрәк булыр иде. Тик анын вакытсыз, сәбәпсез килүен генә ничек анларга да ничек анлатырга икән...

Эштән венок китерделәр. Урыс динендәгечә булды инде, әмма башка әмәле табылмады. Бирелгән акчанын бер өлеше автобуста килгәндә ук үзара чөкердәшкән «урыс малайлары»на тотылган иде. Үлгән кешегә акча кирәкми ана. Хатынына бирсән—ничек тотыла әле. Туй түгел лә, киләчәккә якты хыял-өметләр корасы юк. Балаларын исә хөкүмәт үз ярдәменнән ташламас.

Каберне чәчәкләргә күмделәр. Шунда ук бастырып куйган ташта бәйрәмнәрнен берсендәге шатлыклы минутларын искәрткән фотосурәттә Навил үз урынын алды.

Әйтерсен, анын үлеме бер бәйрәм иде. Дөрес, дус-ишләре арасында бер-икесенен күнелен борчыган башка уй да бар иде. Ничек алдан башына килмәгәндер—Навилнен күп булмаса да, аларга бирәсе бурычы калган иде. Менә хәзер җаен китереп хатыныннан шул бурычны ничек сорап аласы?

Күмүдә катнашып, шәһәргә кайтып баручылар, автобусны бер матур гына аулак урынга туктатып, Навилне искә алырга утырдылар. Артык борчылганнары, ин якын күргәннәре искә алунын чама-хисен дә югалтты. Күп тә үтмәде, үзләренен кайда, ни өчен җыелганнарын да онытып, Навилнен «сонгы туен» «Эх! алмагачларын»нан башлап... «Горько!» белән дәвам иттерде. Аклану сәбәбе бер—вакыт та, үлем дә безнен белән санлашмый. Үзе теләп ашыкканнар китә торсын, яшәп калыйк!

Кеше кайгысы кичкә чаклы, диләр. Ялган бу! Зират капкасыннан чыккач ук онытыла икән ул.

Төпчекләрен—картлык көннәрендәге ин олы өметләрен җирләп кайткач, карт белән карчыкнын икесенен ике якта, берсеннән-берсе яшеренеп елаулары, аларнын исенә дә кереп карамады.

Якын туганнары, күнелләре бер эшкә ятмаса да, һәрберсе үз кайгысын үзе белән йөртеп, ни беләндер мәшгуль булды. Күнелләрендә бер генә тынгылык булмаса да, алар бер-берсенә карамаска, ни генә сөйләшсәләр дә, сүз очынын Навилгә барып тоташасын тоемлап, күнел җәрәхәтләренә кагылмаска тырыштылар. Өчесе, җидесе узса, кырыгына чаклы әкренләп булса да, кайгылар артка чигенә барып, тормыш үз агымына кайтыр. Инде Ходай хәсрәтнен башкаларыннан сакласын!

Ишегалды көне буена Навилнен якын туганнарынын кайгысын уртаклашучы күрше-күләннәрдән, авылдашлардан бушамады. Ничек кенә борчылмады да нинди генә юату сүзләре ирештермәде алар. Дөрес, кешене ярып карап булмый. Шулай да алар арасында ин риясызы, бу олы кайгыларнын барын да ихластан үзенә алырга теләп, адым саен сыкранып шыгырдаучы, майланмаган җил капкасы гына иде.

Күмү мәшәкатьләреннән котылып, уйланып кайту юлында Навилнен олы абыйсы Касыймнын хатыны, иртәдән бирле күнеленнән чыкмыйча йөргән соравын индерде:

—Бу Тәслимә Навилнен машинасын кая куяр, ни эшләтер икән?..

Авыр уйларыннан бүленгән Касыйм дәшмәде. Вакытсыз сорау биргән хатынына ачуы килмәде. Хәер, бу сорауга җавап эзләү Навилнен җиделәрен

уздырганчы ук үзенең дә күңелен кытыклый башлаячак иде...

Барын да күрде Навил, барына да түзде. Инде хатынының халәтен белергә теләп Казанга очты. Өйгә керер юлында, кем тарафыннандыр кыерсытылып, күз яшьләренә төренгән беренче сыйныфта укучы улы басып тора иде. Ах! Бу бала, хәзер өйгә кергәч үк, тышкы дөньясының барлык юньсезлеген, кимсетелүен онытып, көндәгечә:

—Әти, әни, мин кайттым!—дип кулларын җәячәк тә әтисенең кочагына ташланачак...

Ата-ана бурычы—гасырлардан килгән гореф-гадәтләрне киләчәккә тапшыручы инсафлы бала тәрбияләү. Бала бурычы—ата-анасына кайгы-хәсрәтләр китермичә генә, аларны гомер азагында кешечә соңгы юлга озату. Тормышның язылмаган олы бер мәгънә-кануны бу. Кешелек бурычы, Навилнең әлегәчә аңламаган, үтәлмәгән, улына ярдәм кылып, оныкларын тупырдатып сөяргә тиеш бурычы. Тәнсез жанның сыкрануы тәмуг утларында көйдерде...

Ах, ялгышты, барыбер киләчәк үлемнең чиратын үз теләге белән бозып, дөрес эшләмәде ул. Бала, әтисен бу халәттә күрсә, ни эшләр дә, аның ярдәм-киңәшләреннән башка киләчәгендә ниләр кичерер инде?!

Дөньяда үтәлмәгән бурычы калганлыгын белү, әлегәчә үз үлеменең хәсрәтен җиңә алган Навилне куркытып җибәрде. Бу тетрәнү шул чаклы зур иде ки, аның тәнсез җаны өшеп китеп, кабат ак парга әйләнде. Аннары сузылып кына суына да башламаган тәнгә сеңә башлады. Әле генә булып узган үлем ачысы онытылып, тәнгә кабат җан керде. Акыл кайтты. Бая гына күкрәкләрне тырнап чыккан тойгы, кабат эчкә кереп, кинәт кенә йөрәкне кысты. Ә анысы, миңа нәрсә, ни кушсагыз, шуны үтим, дигәндәй, дөпелдәтеп тибә дә башлады. Бу тибү, азрак ял итү мөмкинлеге бирелүгә рәхмәт әйткәндәй, кирәгеннән артык тырышу иде. Кул-аяклар җылынып, тән үзлегенә кайтты. Җан, тәннән оялып, Навилне сикертеп торгызды. Шул чакта, дөньясын беренче тапкыр күргәндәй булып, аның күз алдында искитәрлек манзара туды. Элекке халәт онытылып, кабат күңелдә яшәү теләге уянды. Ул да түгел, ишек ачылып китеп, анда:

—Мин кайттым!—дип оран салган улы—яшәргә өмет биргән бердәнбер үтәлмәгән бурыч-өмете күренде.

Навил өчен дөньясының иң зур шатлыгы, әти-әнисен, хатынын, улын, якын туганнарын хәсрәт-кайгыларга төшермичә яши бирүдә табылды.

Бу дөньяның кояшлы көннәре генә түгел, зәмһәрир суыгы да, тәнне өшеткән җилләре дә, күңелләрне төшергән гайбәтләре дә, ызгыш-талашлары да яшәргә туган кеше өчен Ходай тарафыннан иңдерелгән иң зур бүләкләрнең берсе икән ләбаса...



*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

## ҖИТМЕШ ЕЛДАН СОҢ ОЧРАШУ

*Күренекле татар совет язучысы, әдәбият галиме, фольклорчы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Гомәр Толымбайның туувна быел—2000 елның 14 апрелендә 100 ел тулды.*

*Егерменче-утызынчы еллар татар әдәбияты үсешендә тирән эз калдырган бу әдибебез үзе иҗат иткән унбиш ел вакыт эчендә, ягъни 1922 елдан 1937 елга чаклы, утыз ике китабын бастырып чыгарган. Шул чорның көн кадагына суккан тәнкыйди-публицистик мәкаләләре, очерклары, фәнни хезмәтләре, яңа социаль җәмгыятьнең яңа әсәрләре буларак тәкъдим ителгән этюд һәм хикәя-повестьлары белән замандашлары күңеленә көчле тәэсир ясаган. Әдәбият галиме Г. Нигъмәти 1927 елда («Безнең юл» журналы, 6-7 саннар), аны «татар революция әдәбияты күгендә» булган биш йолдызның (К. Нәҗми, Һ. Такташ, Х. Туфан, Г. Толымбай, Г.Кутуй) берсе итеп күрсәтә.*

*Әмма, белүебезчә, бу үзенчәлекле тарихи чор әдәби ачышлар белән генә түгел, һәртөрле социаль тетрәнү, эзләнү, табу-югалту, хаталану, фаҗигаләр белән дә тулы.*

*Үз заманының сикәлтәле юлы, мираж булып балкып торган мавыктыргыч социаль кыйбласы, табигый ки, иң талантлы әдипләребезнең дә иҗат куәтен шактый зәгыйфьләндергән, әсәрләрнең кыйммәтен еш кына үз заманы кысалары белән чикләп куйган. Тик, ни хикмәт, чын мәгънәсендә талантлы язылган әсәрләр, төрле дәвернең кырыс сынауларын да исән-имин үтеп, яңа буын укучысына да тулы кыйммәтендә барып ирешә ала икән...*

*Бүген Гомәр Толымбайның егерменче-утызынчы еллардан «адашып» калган һәм бернинди заман җилләре дә искертә алмаган классик хикәяләре белән очрашу безгә әнә шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Социаль-сәяси тоткын булып, җитмеш ел буена гарәп шрифтында һәм яңалифтә «консервланып» торганнан соң, ниһаять, алар мәдәни кулланышыбызга, рухи тормышыбызга—лаеклы үз урыннарына әйләнеп кайта.*

*Гаҗәпләнүемнең иң зурысы, шулай да, ул әсәрләрнең заманча кабул ителүендә түгел... Мине бүгенге көндә әдәби мирасыбызны өйрәнүнең соң дәрәҗәдә түбән торуы, үз милли байлыгыбызга мөнәсәбәтебезнең мокытлык дәрәҗәсенә төшкәнлеге хәйран итте. Моның сәбәпләре хакындагы сөйләшүне киләчәккә калдырып, биредә укучыларыбызга әдипнең 1926 елда язылган «Фамилия ясаучылар» исемле кечкенә бер хикәясен тәкъдим итәбез.*

Равил РАХМАНИ

## Гомәр Толымбай

## ФАМИЛИЯ ЯСАУЧЫЛАР

хикәя

1

Җыелыш башланырга тора. Ячәйкә сикритәре Атаманов члиннәрне барлау өстендә:

—Ибрай Имәнов килгәнме?

—Фатих Зиновьев монда!

—Кәрим Мормин?..
—Мирза Калпаков?
—Сафи Суганов.
—.............

Әхмәтнең әле комсомоллар җыелышына чынлабрак беренче килеше. Ул, бу хәлне күргәч, аптырап калды.

—Комсомолга кергәч, шундый бер әйбер исемен тагалар микәнни?.. Әллә үзең белеп бирәр исем табарга кирәк микән? Әнә, Кәримне дә авылда «Чатан Гариф малае» дип йөриләр. Ә монда аны «Кәрим Мормин» диләр икән... Мирза да шулай. Мирзаның атасын «Бияләй Вәлиулла» дип йөриләр. Мирзага да шуңа күрә «Бияләй малае» дип әйтәләр. Ә монда аны «Мирза Калпаков» диләр икән... Әллә, авыл кешеләре белмәсен, дип инде. Ничек куштылар икән? Әтигә «Шакмак Латый» диләр. Миңа «Шакмак» дип кенә кушмасалар ярый инде...

Ячәйкә сикритәре, члиннәрне барлый-барлый, Әхмәткә дә килеп җитте.

—Әхмәтме, Әхмәтовмы... Шундый кеше бармы?

Әхмәт оялып кына:

—Монда,—диде дә... «Шунын өчен комсомолдан чыгармасалар инде...»— дип куркуга төште. Шуннан ул җыелыш беткәнче гел шул турыда гына уйлап утырды: «Миңа ничек әйтерләр икән?.. Линин, димәсләр. Әле ячәйкәнең башлыгы Фарук та үзен, Атаманов, дип кенә йөртә. Зиновьев, дип Фатихка кушканнар инде. Сталин, дип кушсалар?.. Матур исем, алырга ярый. Троцкий, дисәләр ни булыр?..»

Озак вакыт үтмәде:

—Җыелышны ябык дип белгертәм. Бүгенге җыелышта Гатаулла абзый белән минем сүгешүемне тикшерүдән башка нәрсә юк. Гатаулла абзыйны «контр» дип йөртәбез моннан соң, шулай бит?!—диде иптәш Атаманов.

—Шулай, шулай,—дип барысы да аңа кушылды.

Шуннан комсомоллар тарала башладылар. Әнә Әхмәтләрнең күршесе Мирза да чыгып бара. Мирза Әхмәттән өч яшь зур.

Әхмәтнең әнкәсе:

—Мирзаның теле ачылган иде. Мин ул чакта, Әхмәткә йөкле калып, тәрәзә лайлалары гына ялап йөри идем,—ди.

Шул өч яшь зур булу дөрес булырга кирәк. Шуңа күрә дә бит Әхмәт аны «Мирза абый» дип йөртә дә. Аннары соң Мирза бер елдан бирле бугай инде комсомолда да тора.

Әхмәт, серне чишәргә уйлап, аның артыннан киткән иде, менә бәхет, Мирза үзе:

—Әхмәт, бергә кайтабызмы? Әйдә, яна комсомол бит әле син,—дип Әхмәтне җитәкләде. Ул гына түгел, кайтуга берничә адым атлагач, Мирза:— Нәрсә, синең фамилияң юкмыни?.. Аны миңа әйтәләр, үзеңә менә дигәнен табып биргән булыр идем. Әллә, Әхмит Әхмитов, дип җибәрик?—дип теге мәсьәләне дә кабызды.

Әхмәтне ата-анасы һәрвакыт «улым» дип кенә йөртәләр. Сәвит мәктәбе, әллә авыл кечкенәгә, нишләптер ачылмады. Мулла мәктәбендә Әхмәтне «Шакмак Латый малае» дип кенә йөрттеләр. Урамда инде бөтенләй «Шакмак» кына диләр... Шулай итеп, Әхмәт комсомолга кергәнче фамилиянең ни икәнен дә, аның кирәклеген дә белми иде. Шуңа күрә дә ул Мирзаның: «Фамилияң юкмыни?»—дигән соравына да бер нәрсә дә әйтә алмады, бары дәшмичә калмас өчен:

—Ник алай, Мирза абый, сине «Калпаков» дип йөртәләр? Чатан Гариф малаен «Кәрим Мормин» дип йөртәсез. Миңа да шундый берәр нәрсә кушасызмы инде?..—дип сорауга каршы сорау гына куйды.

Мирза аңа зур итеп сөйләп бирде:

—Кешенең аты була. Сине, Әхмәт, диләр. Мине, Мирза, диләр. Аннары кешенең фамилиясе дә була. Линин, дибез бит. Аның аты Владимир булган икән. Ә фамилиясе—Линин. Волстан килеп йөри торган иде, зур мыеклы кешене беләсенме? Күргәнең бардыр. Әнә аның да фамилиясе, Чукмаров, ә үзе—Нурул атлы. Аңладыңмы? Әнә шул фамилия дигәненне табуы авыр инде. Ә комсомол булгач, тапмыйча ярамый. Тапкан чагында аның матурын,

авызны зур ачып әйтә торганын, халыкнын исен китәрә торганын табарга кирәк. Фамилияне әйтү белән үк халык, әй, бу зур кеше икән, дип белсен. Әле без үзебез дә моны яна белдек. Волстан сәвит эше белән килеп йөргүче шул Чукмаров сикритарны өйрәткән: син, дигән, үзең комсомоллар башлыгы. Үзенне, Миннулла, дип кенә йөртәләр. Сина бер яхшы, кеше куркыта торган фамилия табарга кирәк, дигән. Менә мин сина, дигән, бер фамилия табып бирәм, син моннан сон үзенне тот та, Атаманов, дип йөр, дигән. Шуннан сон инде ул «иптәш Атаманов» булып китте. Аннары барыбыз да фамилияле булып беттек. Минем фамилиям шәп бит? Калпаков... Калпаков! Калпаков?..

Әхмәт төшенде.

—Ул алай комисарлар кебек була инде,—диде.

—Вәт. Бөтенләй өстенә үк бастын. Баш бар икән үзендә,—диде Мирза.

—Сон, алай булгач, мина ничек кушабыз?

—Менә синнән шуны сорар идем мин. Бик усалын кушарга кирәк инде анын. Штубы әтиен белән әниен дә куркып торырлык булсын!

—Алай булгач, ничек дип кушыйк сон, Мирза абый?

—Әхмәт, әй, давай сина, Гармунов, дип кенә кушыйк.

—Гармуннан безнең әти белән әни бер дә курыкмый, Мирза абый... Еланов, дип кушсак, нишләр?

—Вәт, вәт молодис! Башын бар икән. Комсомолга зерә генә кермәгәнсен икән. Еланов! Еланов... Еланов?.. Еланов!!! Яхшы чыга икән. Ярый, бетте. Ячәйкәгә әйтермен. Ячәйкә жыелышы каршы килмәс. Үзенне моннан сон шулай йөртербез.

## 2

Ячәйкә жыелышы каршы килмәде—«Еланов»ны раслады. Иптәш Атаманов, олы башын кече итеп, үзе:

—Ярый, юньле фамилия тапкан. Безгә елан кебек кеше кирәк иде. Әйдә, шулай булсын,—дип әйтте.

Шуннан сон инде Еланов та Еланов...

Әхмәтнен тәмам кәефе килде. Нигә кәефе килмәсен—иптәшләрен, Калпаков, Мормин, Арсланов, дип чакыралар икән, Әхмәткә дә, Еланов, дип эндәшәләр. Әле бит Әхмәт яшь. Үсә төшкәч, комисар булыр да китәр. Аннары инде ана:

—Товарищ Еланов,—дип кенә йөрерләр.

Әле күптән түгел генә ячәйкәгә конткомолдан бер кеше килгән иде, ана шулай:

—Менә бу—товарищ Еланов инде...—дип күрсәттеләр.—Әле ул яна гына комсомолга керде, маладис ул,—диделәр.

Әхмәтнен фамилиясе шулай рәтләнеп китте. Өендә дә инде:

—Елан булдын... елан булмасан, син атан сүзенә карышып йөрмәс иден. Сина шул белеп «елан» дип кушканнар,—дип тирги башладылар.

Ул әле шул... фамилиянен рәтләнүе генә дә житми икән. Беркөнне ячәйкә жыелышында: «Фамилиясен кем оста яза да кем оста яза?»—дип тавыш купты. Спорлашу күтәрелде. Барысы да оста язарга тырыша башлады. Барысы да, ячәйкәдән яртышар табак кәгазь алып, фамилия төшерергә керештеләр. Берсеннән-берсе уздыра: кайсы бөтенләй бутап куя; кайберсе, әллә нинди мөгезләр, койрыклар чыгарып, әлләни кыландыра; кайберсе, мин комисарлар кебек кул куям, ди.

Барысы да хәл кадәренчә маташтырды. Ә Елановнын фамилиясе һичбер килешле, килбәтле чыкмый да чыкмый. Ул «Еланов»ны елан кебек тә чорнап куйды; койрыклар да язып карады. Төрлечә маташтырды... барыбер барып чыкмады. Иптәшләре дә, күргәч:

—Бер дә рәтен юк икән...—генә диләр, житмәсә, көлделәр дә әле.

Нишләргә?

Әхмәт, өенә кайткач, бик озак маташты. Атасынын докуминтларын алып, шундагыча кыландырып бөтерде. Әнисенен бер тәнкәлек кәгазь акчасын алып, шундагы язулар кебек тә язарга тырышты. Юк, барыбер чыкмады. Шуннан ул ачуны фамилиядән алырга булды!

—Әллә фамилияне базардан сатып алыргамы?.. Нигә юньле язылa торган фамилия уйлап тапмаска? Аны бит чәчеп үстерәсе юк. Тотарга да берне уйлап табарга! Җитмәсә, үзең комсомол булып тор!

Шуннан ул яна фамилия эзләргә кереште:

«Арсланов?»—бу бездә бар инде. «Мылтыгов?»—бу килешмәс. «Шайтанов?»—комсомолга шайтан булырга ярамый булыр... «Кусалов?»—мин үзем андый усал кеше түгел... Тагын ниндирәкләрне табарга була? «Тегермәнов?»—юк. Тегермән кебек күп лыгырдыйсың, диләр. «Комсомолов?»—тукта, тагын бер әйтеп карыйм әле: Комсомолов! Тагын бер кычкырыбрак әйтим әле:—Комсомолов!!! Менә бәхет, бу шәп чыга. Тукта, язуга килә микән?.. Чорнап-чорнап язсаң, Атамановныкы кебек үк килеп чыга икән! Булды. Ячәйкәгә барам да әйтәм, әйдә, жыелышка куйсыннар. Моннан соң мин үземне, Комсомолов, дип йөртәм тек йөртәм!

### 3

Ячәйкә жыелышы фамилияне алмаштырырга бер дә каршы килми. Килергә урыны да юк. Ячәйкәнең бөтен члиннәре берничә кат фамилия алмаштырдылар инде. Мәсәлән, Әхмәтләрнең күршесе Мирза, Әхмәт комсомолга кергәндә, Калпаков иде, ә шул елны көз «Усаков»ка әйләнде. Ә үзен «Усак—таш корсак» дип үрти торгач, ул «Усаков»ны ике айдан ук ташлады. Кышын «Урманов» дигән фамилиягә күчте. Шуңа күрә Әхмәткә бер дә куркыныч юк әле. «Комсомолов» ошамый икән, берәр айдан тагын яңа фамилия эзләргә була.

Эш торган саен зурайды. Үзеңә фамилия табу, аны алмаштыруга атаңа фамилия табу кирәклеге килеп ялганды. Мирза атасына «Батыров» дигән фамилия тапса, Әхмәт атасына фамилия таба алмыйча жәдәп чыкты: «Сакалов» дисәң, сакалы кечкенә, кәҗәнеке кебек кенә. «Сабанов» дисәң, үзебезнең сабаныбыз юк. «Сука»дан фамилия ясап булмый. Ә, «урак» дигән сүз бар икән... «Ураков» дисәң ничек булыр? Шәп була, бетте. Әтине моннан соң «Ураков» дип йөртәм.

Әхмәтнең иптәшләре дә моңа каршы килмәделәр. Әле иптәш Атаманов үзе моның өчен Әхмәткә:

—Шәп иткәнсең,—диде.

Шулай итеп, Әхмәт атасын, Ураков, дип йөртә башлады.

Өйгә кайткач та, ул әнисеннән атасын:

—Иптәш Ураков өйдәме?—дип кенә сорый башлады.

Бер Әхмәт кенә түгел, башкалар да шулай иттеләр. Шул уңай белән бер күңелсез хәл дә чыгып алды. Комсомол Иманов атасына «Бурзаев» дип кушкан булган. Кайткан да атасына:

—Нихәл, Бурзаев иптәш?—дигән.

Атасы Имәневне тоткан да:

—Мин нинди «Бурзай?» Әле син бик зур кеше булдыңмы... Мин синең атаң бит!—дип пешергән дә пешергән...

Шуннан ячәйкә жыелып:

—Имәневнең атасы контр!—дип әйтсә дә, аның белән генә Имәневнең аркасы авыртуы туктамады—малай бер ай чамасы авырып йөрде.

Безнең Әхмәт, билгеле, моңардан сабак алды. Аталарына яхшырак фамилия кушарга, кушкач та үзләренә әйтмәскә чамаладылар.

Эш аталарына фамилия кушу белән генә чикләнмәде.

«Нигә бөтен авыл кешеләренә фамилия кушмаска?!» дигән мәсьәлә ячәйкә алдына килеп басты. Шуңа күрә иптәш Атаманов, моны ячәйкә жыелышына куеп, үзе:

—Егетләр, болай үзебез генә яхшы фамилияле булып торырга ярамый. Бу тигезсезлек була. Крәстияннәрне мыскыллау була. Шуңа күрә авылдагы барлык кешегә яхшы фамилия кушарга кирәк,—диде.

Шуннан жыелыш бик ачык итеп карар да чыгарды: «Урманов белән Комсомоловка—Урта урам; Кәрим Мормин белән Зиновьевка—Олы урам; Имәневкә—Югары тыкрык. Шул кешеләр бер атна эчендә үз урамнарындагы

кешеләргә фамилияләр кушып бетерергә тиешләр!»

Фамилия дә фамилия... муеннан фамилия... бөтен авылда фамилия. Иптәш Атаманов үзе:

- Ячәйкә тырышып эшләгәч, шулай була ул!—ди.

Анысы шулай, бөтен авыл яхшы фамилияле булды. Ә комсомолларга тагын нишләргә? Эш бетте бит. Тагын нишләргә дә юк. Әхмәтнең эше рәхәт иде, ул һәрвакыт фамилия турында гына уйлап йөри иде. Ә хәзер алар эшләнеп бетте. Хәзер нишләргә инде? Бусына инде иптәш Атаманов үзе дә:

—Әле без яшь, үскәч, комисар булырбыз,—диюдән башка җавап таба алмый, читтән килеп өйрәтүче юк...

Ә иптәш Атаманов үзе чибәр генә итеп самогон кәкkәләргә дә кереште. Әхмәткә нигә иптәш Атаманов кебек кылынмаска? Ул да, аның байтак иптәшләре дә иптәш Атаманов эзеннән киттеләр...

—Кем янына барасың?

—Иптәш Самогонов янына!

—Кая киттең?

—Самогонов янына!

—Кем белән йөрдең?

—Самогонов белән...

Ул вакыт «урыс әчесе» таралып житмәгән иде әле.

1926

ИСКӘРМӘ

Гомәр Толымбайның (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов, 1900—1938) иҗатын хәзерге күпчелек укучылар әлегәчә тирәнтен белмиләр. Моның сәбәбе—реабилитацияләнүеннән соң да аның әсәрләренең сирәк басылуында. Кырык ел дәвамында тулылыкка, хәтта сайланмалыкка да дәгъва итмәүче ике китабы чыкты, һичшиксез талантлы бу әдип турында тәнкыйть мәкаләләрендә искә алынгалады һәм истәлекләрдә язылгалады. Ә Г. Толымбай иҗаты җентекле өйрәнелергә тиеш икән. Моны мин язучының Равил Рахмани әзерләгән китаптагы (әлегә кулъязма хәлендә, тиздән басылып чыгачак) берничә әсәрен укыгач аңладым.

Г. Толымбайның эшчәнлегенә халык бәхете өчен тынгы белмичә бирелеп хезмәт итү хас, аның иҗаты күп кырлы—язучы, галим, журналист, институтта укытучы ул. Боларга өстәп, җәмәгать эшләре...

Менә аның өлгерлегенә журналистлык хезмәтеннән бер мисал. Мин, шушы искәрмәне язучы Мәгъсум Хуҗин ягъни, хәзерге «Ватаным Татарстан» газетасының егерменче еллар төпләмәләре белән танышканда, Гомәр Толымбай материалларын еш ук очраттым. Һәм миңа кирәклеләре дә булды. 1928 елда безнең Байлар Сабасында авыл хәбәрчесе Закир Йосыповны үтерүчеләргә хөкем турында, авыл һәм волость хәлләре турында күләмле дүрт мәкалә язган ул. Аларда авторның ныклы карашы аерымачык аңлашыла. Ә инде әдипнең шул елларда (1925—1930) иҗат ителгән, якын арада укучыларга барып җитәчәк хикәяләрен укыгач, аның үз чорын дөрес аңлавына ышанасың. Һәм:

—Шул заман сәясәтенең коточкыч упкынга илтәчәген тирән акыллары белән төшенгәннәр һәм иҗади әсәрләрен һәлакәткә бару юлына киртә итеп салганнар безнең әдипләр!—дигән фикергә киләсең.

Әйе, халык язмышы—ил язмышы—турында уйлана белгәннәр безнең акыл ияләребез. Алар арасында Гомәр Толымбай да бар. Моны аның «Мөртәт Гыйбай», «Саматов», «Фамилия ясаучылар», «Әтәчләр сугышы», «Нигә кыр үрдәге булмаганнар...» һәм «Кара такта алдында» кебек хикәяләре үк раслый.

—Кешеләр! Аң булыгыз—корыкуыклар, бушбугазлар, наданнар, әчкечеләр, ата-анасына җәбер салучылар тормыш мәйданына чыга! Юл бирмикче афәт чукмарларына!

Һәм бу хәлләр Гомәр Толымбай хикәяләрендә коры вәгазь булып яңгырамый, ә төзек-саллы тел белән тасвирлана.

*Әсәрне журналда бастыруга*
**Равил РАХМАНИ** *һәм* **Мәгъсум ХУҖИН** *әзерләде*

# ПУБЛИЦИСТИКА



**Туфан Миңнуллин**

## «БЕТТЕ КӨЧ, СЫНДЫ КЫЛЫЧ...»

СССР ХАЛЫК ДЕПУТАТЫ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

ТЕЛЕВИЗОРДАН Ельцин турында фильм күрсәттеләр. Анда 1989 елда СССР халык депутатларын сайлауны һәм сайланганнарның съездын бик еш телгә алдылар. Әйе, аерым тукталып сөйләнерлек, тарихта калырлык съезд иде шул ул. Россия империясенең, соңрак исемен генә үзгәртеп, СССР дип аталган империянең җимерелә башлавын раслаган съезд иде. Ә мин депутат буларак шул съездда катнашкан, бик күп вакыйгаларны үз күзем белән күргән, күп сүзләрне үзем ишеткән кеше. Һәм мин анда кеше саны гына тутырып утыручы да түгел идем. Булдыра алганча, дөньяны үзгәртергә маташучы да идем. Дөньяны үзгәртүгә күпме өлеш керткәнмен, белмим, әмма үзем бик нык үзгәрдем ул чорда. Ул үзгәрү, әлбәттә, җиңел генә булмады. Хәтта мәңге төзәтә алмаслык фаҗига белән тәмамлануы да мөмкин дәрәҗәгә җиткән чаклар булды.

Ләкин ни өчендер шушы иң киеренке чор минем көндәлек дәфтәремә теркәлеп куелмаган. Анда-санда өзек-төтекниләрдер язылган, әмма тоташ уйлану, нindидер нәтиҗә ясау юк. Фильмны караганнан соң уйланып йөрдем дә, истә калганнарны, истә калмаганнарын архивымнан эзләп табып, үткәннәргә кайтып килергә кирәк таптым. Чөнки, кабатлап әйтәм, ул көннәр минем тормышымда кискен борылыш чоры булды.

Мин үзем теләп коммунистлар партиясенә кергән кеше, чын коммунист булырга теләп, ул партиягә турылыклы хезмәт иткән кеше, шул партиянең таралганын күргән һәм таралуына үземнең өлешемне дә керткән кеше. Алдануымны күреп, авыруга сабышкан кеше, ул чирдән өле дә булса арынып җиткәнем юк. Чөнки бүген дә коммунистик идеянең кешелек дөньясы өчен кирәклеген зарур нәрсә дип саныйм. Бөтен кешеләр дә җир йөзендә тигез булырга тиеш дигән тәгълимат начармыни? Эшләмәгән—ашамый, дигән өндәмәдә ни начарлык бар? Менә шул бөек идеянең тапталуын күрдем бит мин. Һәм аны коммунистлар үзләре таптадылар. Дөресрәге, партия башында

утыручылар эшләде ул эшне, без дәшмичә карап тордык. Хуплап кул күтәрдек, кул чаптык. Президиум өстәлләре артында утыручылар әйткән һәр сүз дөрестер дип уйладык.

Мин шунда утыручыларның алдашуын, хәтта мескенлеген күреп тетрәндем, зиһенем чуалды. Миңа алар сәхнәдә геройларны уйнап, тормышта шактый ук мескен булган артистларны хәтерләтә башладылар. Бүген дә мин андый коммунистларга ышанмыйм. Ышана алмыйм. Үз-үземне җиңә алмыйм. Шуңадыр ахры, беркөнне үзеннән-үзе күңелдә бер такмак туды.

Белә алмыйм, әйтә алмыйм—
Ялгышаммы, хакмы мин:
Коммунистлары булмаган
Коммунизм яклы мин.

Кабатлап әйтәм, чын коммунист идем. Мондый такмак чыгаручыны чын күңелдән гаепләргә тиешле коммунист идем.

Әлбәттә инде, фанатик түгел идем. Коммунистлар партиясе җитәкләгән илдәниләр эшләнгәнен күреп, азмы-күпме бәяли белүче кеше идем. Хрущевның егерме елдан коммунизм төзергә алынуыннан кычкырып көлүчеләр арасында мин дә бар идем, аның турында анекдотларны курыкмыйча сөйли идем. Берсе әле дә хәтеремдә: ике агай сөйләшә икән. Беренчесе: «Американы куып тотып узып китәбез», дип мактана икән. Икенчесе: «Куып тотуын тотабыз, ләкин узып китмибез», ди икән. «Нигә?», дип сорагач, «Ыштансыз килеш алдан йөгерү уңайсыз», дигән.

Әйе, Американы куып тотып узып китәбез дип шапырынуга илдә беркем дә ышанмагандыр.

Хрущев урынына Брежнев килде. Аңардан да көлдек. Чөнки Кремль картлар йортына әйләнде. Безнең районда акылга таман Хәерниса апа түшенә, орден дип, төрле калай кисәкләре тагып йөри иде. Брежнев та шуның сыман, түшенә йолдыз такты да йолдыз такты. Авызын ачып сүз әйтә алмас хәлгә җиткәч тә эшләттеләр мескенне. Аның «систематически» дигән сүзне, кәгазьгә карап, абына-сөртенә «сисиматически» дип укуын күреп көлдек. Кычкырып көлдек.

Андроповтан бераз шикләнеп, койрыкларны кысыбрак йөрдек. Сталин заманы кабатланмасмы диеп, шомга калдык. Ул турыда курка-курка сөйләшә идек. Аның тәртипсез илдә тәртип урнаштыра башлавына әлләни сөенмәдем мин. Бу илдә тәртип урнаштыруның гаепсезләрне җыеп ату белән тәмамланачагын аңлый башлаган идем.

Андроповны алыштырган Черненконың «мәетен» телевизор каршына утыртып, берничә сүз әйттергәннәрен күреп мин хурлыгымнан еладым.

Ләкин мин барыбер партиягә ышана идем әле. Кемдер берәү килер дә коммунистик идеологиянең чын асылын аңлап эш итәр дип өметләндем. Партия чистарыныр, арыныр, аны җитәкләргә акыллы, белемле, намуслы, кешелекле иптәшләр алыныр дип көтә идем.

Һәм Горбачев кыяфәтендә без көткән кеше килде. Без сөендек. Куандык. Илдә демократия җилләре исә башлагач, иркен сулыш алдык. Тотындык үзгәртергә һәм үзгәрергә. Ләкин ничек үзгәртергә дә, ничек үзгәрергә дә белми идек. Буталыш башланды. Бу кыйблаcызлыктан партия алып чыгар дип ышандым мин.

Менә нәкъ шушы вакытта СССР халык депутаты булып сайландым. Сайлауларга өзерлек демократик рухта барды сыман. Һәрхәлдә, без күнеккән сайлаулар түгел иде. Альтернатив кандидат дигән сүз модага керде. Анда да китте ыгы-зыгы. Элегрәк депутат булырга өмет итмәгәннәр дә депутатлыкка дәгъва кыла башлады. Депутат булырга күнеккәннәр каушап калды. Кешеләрчә ярышуның ни икәнен белмәгән җәмгыятьтә сайланырга теләүчеләр бер-берсе өстенә пычрак сибәргә тотынды. (Ул бүген тагын да әшәкерәк формада дәвам итә).

Депутатлар эшләгән урыннарында сайланачак дигәч, безнең Язучылар союзы да гөжләп алды. Депутат булырга теләүчеләр шактый табылды.

Нык кына тәпәләшеп тә куйдык. СССР Язучылар союзына кандидатларыбызның исемлеген җибәрдек. Анда минем фамилия дә бар иде. Әмма, киленгә дә катыкмы, дигәндәй, татар язучыларын депутатлыктан сыздылар.

Мине милли территориаль округтан сайладылар. Кандидат берүзем генә идем. Соңыннан альтернативаның нигә юклыгы аңлашылды. Ул чактагы КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы Усмановның боерыгы шундый булган икән. «Туфан Миңнуллин сайланырга тиеш», дигән ул. Беренче секретарьның боерыгы ул чакта әле хөкем карары белән бер иде.

«Туфан Миңнуллин сайланырга тиеш»нең тарихы бар.

Гомәр Усманов ни өчендер мине ярата иде. Югыйсә, мин ул яратырлык әлләни дә эшләмәдем. Аны мактап очерклар язмадым, күккә чөеп чыгышлар ясамадым, очрашканда ялагайланмадым. Үз бәямне белә идем, ул бәяне төшермәскә тырыштым. Усманов шаярып сөйләшкәндә дә, аңа ошарга тырышып, кеткелдәп көлмәдем. Әлбәттә инде, тәкәббер булып та уйнамадым. Нормаль җитәкчеләр белән нормаль җитәкләнүчеләр арасында мөнәсәбәт ничек булырга тиеш булса, безнең мөнәсәбәтләр дә шундый булды. Хәтта мине якын иткәнен, миңа аеруча игътибар белән караганын сизеп, читтәрәк йөри идем әле. Начальствога бик якын килергә ярамаганлыкны белә идем.

Обкомның идеология секретаре Рәис Беляев аркасында Усманов миңа салкыная төште. Ләкин эзәрлекләмәде. Югыйсә, сәбәпләр бар иде. Рәис Беляевне эшеннән алып, аңа партия шелтәсе биргәндә, Усмановка каршы барып, өлкә комитеты членнарыннан мин Беляевне яклап чыгыш ясадым, шелтә бирүгә каршы берүзем кул күтәрдем.

Эзәрлекләмәсә дә, Гомәр Исмәгыйлевич ризасызлыгын күрсәтте. КПССның чираттан тыш конференциясенә делегат итеп минем кандидатура күрсәтелсә дә, Усманов сыздырттырды. Һәм үзе сыздырттырганын яшермичә, хәйләкәр елмаеп, кешеләр алдында миннән: «Ну, как дела?»—дип сорады. Аны-моны уйлап тормастан: «В уважаемой республике своих писателей за борт не бросают»,—дидем. Гомәр Исмәгыйлевич кызарынды, ачуы йөзенә чыкты, ләкин дәшмәде. Соңыннан, депутат булып сайланып берәр ел үткәч: «Знаешь, я сделал тебя депутатом. Помнишь, тогда ты меня так больно кольнул. Я сначала хотел тебя приучить. Потом передумал. Отомстил тебе, когда начались выборы. Я настоял, чтоб тебя сделали депутатом»,—диде.

Менә шулай җиңел генә депутат булдым да куйдым.

Депутатлар төялеп Мәскәүгә киттек. СССР халык депутатларының беренче съездына. Барганчы ук безнең депутатлар үзләренең дөньяга карашы белән икегә бүленгән иде. Бәлки өчкәдер. Беренчеләре—коммунистик системаның турылыклы вәкилләре. Илдә демократия дигән сүз еш кулланылса да, алар демократиянең безнең илдә хәерлегә алып чыгуына ышанмаучы, коммунистик системаны какшамаслык дип инанганнар һәм шуңа җаны-тәне белән хезмәт итүчеләр. Икенче төркем—коммунистик системаның какшый башлаганын сизеп, аны тагын да какшатырга теләүче реформаторлар. Алар да демократиянең ни икәнен бөтен тирәнлеге белән аңлап җиткермиләр. Аларга башта җимерергә кирәк. Җимергәч, ничек нәрсә төзергә икәнен белмиләр. Нәкъ менә 1917 елдагы большевиклар инде. Алар да бит «башта җимерәбез» диделәр, җимерек урынына нинди бина төзисен белмәделәр һәм илне кризиска китереп терәделәр. Хәзер әнә үзләрен җимерәләр.

Өченчеләре—теге якка да, бу якка да кушылмаучылар. Мин шул өченчеләр төркемендә идем. Без яшәгән системаның шул килеш дәвам итә алмаячагын аңлау дәрәҗәсенә җиткән коммунист идем. Ләкин аны бер кизәнүдә бәреп аудару ягында да түгел идем. Һәртөрле волюнтаризмны реформа дип кабул иткән илдә гомер кичереп, Рәсәй империясендә реформа була алмыйдыр дип, язмышыбызга буйсынып яшәргә күнегә башлаган кеше идем. Үзгәртеп кору кирәк, әмма кабаланырга да ярамыйдыр дигән фикердә идем.

Партия өлкә комитетының бер конференциясендә чыгыш ясап,

«демократия» диген сүз белән шаярмаска иде диген фикер дә әйткән идем. Минем бозау турындагы хикәятемне Мәскәүдән вәкил булып конференциядә катнашкан Вольский диген иптәш тә ошаткан иде. Мондый иде ул хикәят.

Язның бер матур көнендә кыш буе ябылып торган бозауны муенчагыннан ычкындырып ирекка чыгарып җибәргәннәр. Бозау, муенчактан котылуына куанып, ишегалдыннан урамга атылып чыккан. Коерыгын чөнчеп урам буйлап чапкан. Каз-үрдәкләр, әтәч-тавыклар куркышып читкә очканнар, тузан купкан. Ирекле бозау чапкан да чапкан һәм нәтиҗәдә яныл үлгән.

Шуны сөйләгәннән соң, без дә шул бозау хәлендә кала күрмик, диген идем.

Кыскасы, мин үзгәртү ягында, ләкин кискен борылыш ясарга ашыкмаска кирәк, диген фикердәге кеше идем. Партияне бетерү диген нәрсә минем уемда да юк иде. Аны алыштырырлык көчнең безнең җәмгыятьтә булуына ышанмый идем. Дөресрәге, мин бу турыда уйламый идем әле. Мине борчыган төп проблема—Татарстанның, союздаш республикалар дәрәҗәсендә булып та, автономия кысаларында гына тыпырчынуы, татар милләтенең хокуксызлыгы иде. Шуңа күрә съездда миңа Татарстаннан сайланган депутатлар исеменнән чыгыш ясау эше йөкләтелгәч, чыгышымның үзәге итеп республикабызның статусын күтәрүне алдым.

Съездда сөйләячәк сүзләрне Татарстан депутатлары белән җыелышып укып чыгып, аларның да фикерләрен искә алдым. Әлбәттә, ул чыгыш бүгенге күзлектән караганда бик йомшак, ә ул чакта шактый ук кыю иде шикелле.

Съездның беренчесе үк минем уйларымны бутап ташлады. Гомердә ишетмәгән, ишетергә дә мөмкин булмаган, хәтта тыңларга да куркыныч тоелган сүзләр яңгырады трибунадан. «Әйтелергә тиеш түгел» сүзләргә кул чаптылар. Мин караңгы авылдан зур шәһәр урамына килеп кереп каушап калган малай шикелле, һәрбер сүзне колак торгызып тыңладым. Бара-тора кыю чыгышлар миңа ошый башлады. Алар бит минем күңел



*Татарстаннан сайланган СССР Халык депутатлары—Югары Совет әгъзалары. 1990 ел.*

төпкелендә яшеренеп яткан уйларыма тәңгәл киләләр иде. Без яшәгән система гадел түгел дигән яшерен уйларымны кычкырып әйтәләр иде трибунадан. Һәм мин андый чыгышлардан соң рәхәтләнеп кул чаптым. Минем бу кыланышым үзебезнекеләр арасыннан кайберәүләргә ошап җитмәде. Академик Андрей Сахаровның ялкынлы сүзләреннән соң җилкенеп кул чапкан идем, артымда утыручы бер иптәш: «Миннуллин, не перестарайся»,—дип, кисәтү ясады. Ләкин мин андый гына кисәтүләрдән курыкмый башлаган идем инде. Дөньяда демократия дә булырга мөмкин икән дип сөенергә әзер кеше идем. Шул сәбәпледер, күрәсең, безнең депутатларыбызның реформа яклылары мине үз иттеләр. Миңа номенклатура депутаты итеп, шикләнеп карамадылар. Дөресен әйтергә кирәк, җитәкче депутатлар да мине чакырып алып «төзәтмәделәр». Чөнки мин уйнамый идем, ихлас идем. Минем үзгәрә баруым конъюнктурага карап үзгәрү түгел, дөньяның мин теләгән якка үзгәрүенә реакция иде.

Ләкин мин барыбер әле үткәннәр йогынтысыннан арынып җитмәгән коммунист идем. Политбюроның ялгышуы мөмкин дип санасам да, андагы кешеләргә, зур шәхесләргә караган кебек курку катыш хөрмәт белән карый идем.

Чираттагы съездларның берсендә Гдлян дигән тикшерүченең политбюро члены Лигачевка каршы әйткәннәрен, караклыкта гаепләүләрен тыңлаганда «Ни белән бетәр икән бу?» дип, шикләнебрәк тыңладым. Шундый зур кешегә яла яккан өчен Гдлянны алып китәрләр сыман тоелган иде. Карыйм, Гдлян рәхәтләнеп урынына барып утырды. Сүзне Лигачев алды. Ык-мык килде дә бу, рәтле сүз әйтә алмады. Шулай да: «Яла яккан өчен судка бирәм»,—дигән сүз әйтте. Ләкин судка бирергә ашыкмады. Гаҗәеп хәл—Гдлян әйтә: «Миндә Лигачевның җинаятьче икәнлеген исбатлаучы документлар бар»,—ди, ләкин ул документларны күрсәтми, Лигачев: «Судка бирәм»,—ди, әмма бирми. Инеш буендагы хатыннар кебек талашалар болар. Бу кызганыч уенны карап-тыңлап торгач, миңа куркыныч булып китте. «Нинди илдә, кемнәр арасында яшим соң мин? Һәм шушы вак кешеләр безне җитәкләп йөрткәннәрме?»—дип көләргә тотындым. Туктый алмыйча көләм. Көлүем истерикага күчте. Янәшәмдәге депутатлар миңа шикләнеп карый башладылар. Хәлемне Гомәр Исмәгыйлевич аңлады бугай: «Бар, кайтып ял ит»,—диде.

Шушы көн минем тормышымда иң кискен үзгәрү көне булгандыр. Мин беркемгә дә ышанмый идем инде. Ул көннәр минем сәламәтлегемә дә тәэсир итте. Кан басымы туктаусыз уйнарга тотынды. Врачлар карап, сораштырып, тынычландыра торган әллә нинди дарулар бирә. Ләкин ул дарулар мине тынычландыру урынына изә генә иде. Ахыр чиктә мине Зорина фамилияле докторга күрсәттеләр. Ул минем «авырулар тарихы»ннан нинди дарулар эчүемне укып чыкты да:

—И вы пьете всю эту дрянь?—диде.—Немедленно выбросьте все,—дип тә өстәде. Аннары икенче бер докторны чакырып алып:

–Займитесь, пожалуйста с ним,—диде.

Докторның монысы психотерапевт булып чыкты. Миңа бик нык ярдәм иткәнгә мин аның фамилиясен дә яхшы хәтерлим—Ромашевский.

Мин инде Ромашевскийның ничек дәвалаганын язып тормыйм, шунысы факт—сәламәтлегем тотрыкланды. Чирләвемне язмаган булыр идем дә, үзгәрешләрнең ничек итеп психикама хәтле тәэсир итүен әйтү өчен генә кирәк. Минем белән бергә бик күпләрдә мондый тетрәнүләр булгандыр дип беләм. Юкка гынамыни татар язучылары арасында болганулар булып алды, бер чиктән икенче чиккә ташланып, бер-беребездән гаеп эзләргә тотындык. Такташ, Туфаннардан кер эзләүчеләр, Җәлилгә ташланучылар табылды. Кайберәүләр үзләрен диссидент итеп күрсәтү өчен: «Бу системага каршы көрәштек!»—дип күкрәк какты. Заманында теге яки бу сәбәп белән партиядә тормаучылар, коммунист каләмдәшләрен хурлап, мәсхәрәләп йөрде. Әйткәнемчә, болар барысы да, тоталитар режим кысаларында яшәп арыганнан соң, демократия җилләреннән чир эләктерүнең нәтиҗәләре иде.

Бара-тора съездларда бәхәсләр кызганнан-кыза барды. Гомердә күрелмәгән хәл—кайбер союздаш республикалардан сайланган депутатлар, теге яки бу мәсьәлә белән килешмәгәндә, протест йөзеннән залны дөррәү ташлап чыгып китә торган булдылар. Аннан моңа да ияләштек. Мин инде мондый гына «вак-төяк»ләргә игътибар да итми башладым. Без еллар буе мәктәпләрдә «союз нерушимый» дип җырлаган гимнның ялган икәне дә ачыкланды. Балтыйк буе республикалары: «Без СССРга кушылмадык, без Россия тарафыннан оккупацияләнгән генә»,—дип, минем күземне ачтылар. Әлегрәк Латвия, Литвада булганда, Рәсәйдән килгән кешеләрне анда яратмауларын белә идем, әмма бу хәтле үк булыр дип кемнең башына килгән?!

Мине иң гаҗәпләндергәне Балтыйк буе республикаларының «кәҗәләнүе» түгел, Украинаның ирек даулавы булды. Россия-Украина мөнәсәбәтләре дуслыкка гына түгел, туганлыкка корылган дип йөрсәк, алай булып чыкмады. Украина депутатларының «Москаль» дип, Рәсәйгә мыскыллап карауларын күреп шаккаттым. Кыскасы, СССР дигән илнең бернинди дә союз түгеллеген аңладым мин. Ә моны аңлавы бик авыр иде. Идеалларның тәмам җимерелүе иде. Тоташ ялганда яшәвебезне төшенеп ачыну иде.

«СССРны таркаттылар»,—диләр. Аны таркатмадылар, матбугатта язганым бар. Бау белән тышаулап куелган союзда бердәмлек була алмый. Халыклар сортларга бүленсә, дуслык була алмый.

Менә ни өчен мин СССР Конституциясеннән 6 нчы статьяны алырга дигән тәкъдимне яклап тавыш бирдем. «Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Совет җәмгыятенең житәкләүче һәм юнәлеш бирүче көче, аның сәяси системасының, дәүләтә һәм иҗтимагый оешмаларының төп үзәге булып тора...»

Мин бу сүзләрнең инде көче беткәнлегенә, кешеләрне кайчандыр тигезлек даулап күрәшкә күтәргән партиянең тормозга әйләнә баруына төшендем.

Бу статья буенча исемле тавыш бирдек, аларның нәтиҗәләре матбугатта басылып чыкты. Шул уңайдан мине хыянәттә гаепләүчеләр дә булды. Конвертына Баулы дигән язулы пичәт сугылган хат аеруча усал иде. «Әгәр дә син, Туфан Миңнуллин, әллә нинди пычрак Гайерларга ияреп, партияне бетерергә йөрисең икән, телеңне тиз тыярбыз. Сиңа тугыз грамм кургашын житә»,—дип кисәтелгән иде.

Ходайның биргәненә шөкер, кисәтү сүз генә булып калды. Ләкин мин тавыш биргәнемә үкенмәдем һәм үкенмим. Ул турыда язмамның башында әйттем инде. Тагын әйтәм—мин хыянәт итмәдем, мине һәм минем белән бергә бик күпләрне алдадылар. Партиянең гомерен лидер булырга тиешле функционерлар кыскартты. Бүген дә ул дәвам итә. Бүген дә аның башында гап-гади функционер утыра. Ул партиянең дәрәҗәсен саклый алырлык шәхес түгел.

Әгәр дә халык депутатлары съездларына бәя бирергә кирәк булса, аны инде илледән узган хатынның унсигез яшьлек кыз кыяфәтенә керергә тырышуы белән чагыштырыр идем. Без мең ярым кеше җыелып, тоталитар режим дип аталган «карчык»ны бизәп, иннек-кершән сөртеп яшәртергә азапландык. Ничек итеп яшәртү мәсьәләсендә ызгыштык, талаштык. Реформа, яңарыш дип сөйләдек, искечә эшләдек, искечә уйладык.

Мәсәлән, СССР Министрлар Советы нинди булырга тиеш, дигән мәсьәләне тикшерү өчен комиссия төзелде. Комиссиядә мин дә бар идем.

Комиссиянең председателе карар проекты белән безне таныштырды. Анда СССР Министрлар Советы членнары булып бөтен союздаш республикаларның вәкилләре кертелгән иде. Автономиядән берәү дә юк. Моңа комиссия членнарыннан калмык язучысы Давыт Кугелтинов белән икәү каршы чыктык. Министрлар Советы составында автономияле республика вәкилләре дә булырга тиеш, дидек. Шулвакыт комиссиянең председателе:

—Әгәр дә анда автономияле республикаларны кертсәк, Министрлар Советы үзе үк идарә итә алмаслык бер органга әйләнәчәк,—диде.

Шунда мин:

—Идарә итә алырлык булмагач, шул хәтле җирне яулап алмаска иде,—дип ычкындырдым.

Бүтәннәргә ничек тәэсир иткәндер, шагыйрь Евгений Евтушенкога ул сүзләр бик ошады, ул хәтта кул чапты. Нәтиҗәдә Министрлар Советы составына Татарстан, Башкортстан, Якутия вәкилләрен кертергә булдылар.

Съездларда миңа нык тәэсир иткәне академик Сахаровның чыгышлары иде. Дөресен әйтергә кирәк, баштарак мин аны шикләнебрәк тыңладым. Чөнки минем колагыма ят сүзләр сөйли сыман иде. «Советлар Союзының патриоты түгелдер бу»,—диебрәк уйлый идем. Патриот булган кеше үз илен хурлап сөйләмәскә тиеш дигән фикердә идем. Шул ук вакытта: «Патриот булмаган кеше Советлар Союзына атом бомбасы ясап бирер иде микән?»—дип тә уйлап куйгалыйм. Президиум өстәле артында утыручыларның һәм залның шактый өлеше Сахаровның сүзен әдәпсез рәвештә бүлә башлагач һәм бер надан депутатның академикны мыскыл итеп сөйләвен тыңлагач, Сахаров ягына күчтем. Дөресен сөйли академик, бу илдә чын кешенең кадере чынлап та юк, дигән төпле фикергә килдем. Һәм әле дә шул фикердә, кеше кадере булмаган җирдә демократиянең дә булуы мөмкин түгел.

Съезд истәлекләреннән тагын бер вакыйганы искә алып китмичә булмастыр. Ул бөтен кеше дә белгән Жириновский белән бәйләнгән.

Мин инде шундый әкәмәт кеше барлыгын ишеткән идем, әмма үзен күргәнем юк иде.

Беркөнне арып-талып съезд утырышы барган залдан фойега чыксам, халык җыелган. Кычкырып нидер сөйләүче берәүне уратып алганнар. Шунда фотокорреспондентлар, тележурналистлар, радиожурналистлар мәш килә. Теге кешене фотога, телевидениегә төшерәләр. Авызы янына микрофоннарын сузганнар. «Ни бар икән?»—дип шунда бардым. Әлеге кешенең ни сөйләгәнен тыңлый башладым. Шаккаттыргыч сүзләр сөйли.

—Залда сафсата сөйлиләр. Горбачев ул тел бистәсе,—ди,—Мин лыгырдарга ирек бирмәячәкмен. Мин власть башына килүгә үк лыгырдыкларны куып чыгарачакмын,—ди.

Янындагы кешеләр төрле сораулар яудырып, моны кыздырып торалар.

—Сезнең күзлектән караганда, залда сезнең белән эшләрлек кешеләр бармы?—диделәр.

—Юк,—ди бу,—барысы да эшлексезләр, бөтенесе дә әрәмтамак,—ди.

Аны мыскыл итүчеләр дә бар.

—Сез бит нормаль кеше түгел, сез—шизофреник,—ди берәү. Жириновский шунда ук җавап бирә:

—Мин үземнең шизофреник икәнемне яшергәнем дә юк, сез менә үзегезнең дурак икәнлегегезне яшереп йөрисез,—ди.

Җыелган төркем рәхәтләнеп көлә. Арадан берсе:

—Сезнең еврей булуыгыз дөресме?—ди.

—Ә сез миннән кан алып анализга бирегез,—ди. Тагын көләләр. Рәхәтләнә генә Жириновский. Җыелган журналистларны, залдан качып чыккан депутатларны авызына каратып тора. Мин дә аны сокланып тыңлыйм. Чөнки ничәмә дистә ел берүк сүзне тыңлау ялыктырган, бу оста итеп сөйләшә, бәхәсләшә. Минем өчен яңалык.

—Милләтләр проблемасын ничек хәл итәргә җыенасыз?—дип сорыйлар аңардан.

—Андый проблема юк,—ди оратор.

—Бар,—ди берәү,—Украина, мәсьәлән, мөстәкыйль булырга тели.

—Нәрсә лыгырдыйсыз, нинди мөстәкыйльлек? Булыгыз мөстәкыйль. Без Донбассны сезгә бирмәячәкбез, сез Полтавский галушкагыз белән

кәкрәеп катачаксыз,—ди.—Әрмәннәр дә дәүләт дип сөйләшеп маташалар. Россиядән башка кая бара ала алар? Безнең гаскәрләр Әрмәнстаннан китсә, әзербайҗаннар әрмәннәрне бер атна эчендә суеп чыгачаклар,—ди.—Ә бу казаклар нишли ала? Андый республика була алмый. Алар рус җирендә яшиләр. Аларның беркайчан да дәүләте булмаган,—ди.

Шунда кемдер:

—Татарларның бит дәүләте булган,—дип куя.

—Булса ни. Булган чакта сакларга кирәк иде, хәзер тыпырчынудан ни мәгънә?—ди. (Бу сүз урыс телендә әйбәтрәк ишетелгәнгә мин Жириновский сүзләрен үзе әйткәнчә дә язып куям: «В свое время надо было защищаться, сейчас нечего рыпаться». Әлеге сүзләр йөрәгемә килеп кадалганга мин аны һич оныта алмыйм.)

Ул чакта үзенең башкалыгы белән Жириновский миңа ошады. Әмма ләкин бер нәрсәне аңлый алмадым. Кремльгә, утырышлар барган съездлар сараена керү өчен депутатларны инә күзеннән чыгарып тикшерәләр. Һәр капка, һәр ишек саен очлы күзле сакчылар. Жириновский депутат та түгел, чурт та түгел. Теләсә кайда теләсә ни сөйләп йөри. Бөтен җитәкчеләрне мыскыл итә. Ә үзе рәхәтләнеп Кремльгә дә, Съездлар сараена да кереп йөри. Анда да теләсә ни кычкыра. Әмма аңа сүз әйтүче дә, туктатучы да юк. Әкәмәт дөнья, әкәмәт кешеләр.

СССР халык депутатларының съезды даими эшләү өчен Югары Совет сайлады. Мин дә ул Советның әгъзасы булдым. Андагы хәлләрне дә теркәп куярга кирәктер.

Югары Советта Татарстаннан миннән тыш даими эшләүчеләр тагын биш кеше иде. Алар арасыннан күбрәк элек Буа районында колхоз председателе булып эшләгән Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов белән аралаша идем. Белемле, инициативалы, төпле кеше. Әлбәттә, ул, практик җитәкче буларак, күбрәк республика экономикасына бәйле мәсьәләләр белән шөгыльләнде. Мин исә, милләтнең рухи дөньясы белән бәйләнгән кеше булганга, сәясәткә кереп чумдым. Үзем ишеләр белән якынаеп алып, СССР дигән илдә автономия кысаларында көн күрүче халыкларны икенче сортлылыктан чыгару өчен азапландык. Абхазиядән Владислав Ардзинба, Якутиядән Владимир Ларионов, Калмыкның олы шагыйре Давыт Кәгелтинов бер төркем булып оештык. Арада иң активы Ардзинба иде. (Соңыннан Абхазия республикасының Президенты итеп сайланды). Үзебезнең тирәгә бүтән республика депутатларын да тупларга теләдек. Ләкин кызганычка каршы, андый республикалардан милләт язмышын ныклап кайгырткан депутатлар күп түгел иде. Без әзерләнгән теге яки бу документка кул куйдыру өчен дә кайберләрен шактый үгетләргә туры килә иде. Ә без автономияле республика мәнфәгатьләрен якларга тиешле белдерүләр, мөрәҗәгатьләр белән Югары Совет утырышларында чыгышлар ясый идек. Миндә ул мөрәҗәгать, белдерүләрнең кайбер копияләре сакланган. Шуларның бер-икесен тәрҗемә итеп һәм әзрәк кыскартып әлеге язмага да кертергә кирәктер.

**«Автономияле республикалардан, автономияле өлкәләрдән һәм округлардан СССР халык депутатлары төркеменең, СССР Югары Советы әгъзаларының СССР Югары Советы әгъзаларына МӨРӘҖӘГАТЕ**

*... Безнең илдә милләтара мөнәсәбәтләр катлаулана баруның төп сәбәбе—чынлыкта СССР халыкларының тигез хокуклы булмавында. Ленинның федерация идеясен («яңа Союзга, яңа Федерациягә бергәләшеп һәм тигез хокуклар белән керәбез») элекке рәвештә тормышка ашырасы урынга, бер төрле булмаган берәмлекләрнең күп баскычлы структурасы төзелде. Шулай итеп, автономияләр союздаш республикаларга гына түгел, хәтта крайларга, өлкәләргә буйсындырылды.*

*Нәтиҗәдә халыкларны рангларга бүлү өчен нигез барлыкка килде.*

*Халыкларның бу тигезсезлеге СССР һәм республикалар конституцияләрендә беркетелде.*

*Тигез хокуклылар Союзының субъектлары булмаганга күрә, автономияләр административ-команда системасының бөтен авырлыгын татыды һәм чынлыкта гадәти административ берәмлекләргә әверелде. Алар үзенчәлекле социаль-икътисадый ихтыяҗларын хәл итүдә, ана телләрен, милли мәдәниятләрен үстерүдә, табигатьне, тарихи ядкярләрне саклауда реаль хокуклардан—һәр халыкның үзенә генә хас сыйфатларын билгеләүче барлык нәрсәләрдән мәхрүм ителде. Автономияләре булган аерым бер союздаш республикаларның конституцияләрендә шушы республикаларның федератив корылышы чагылдырылмау кайбер очракларда бу тискәре процессларны көчәйтеп җибәрде.*

*Хакыйкый тигез хокуклылык урнаштыруга, СССР халыкларының үзара татулыгына, милли дошманлыкны бетерүгә юнәлдерелгән яңа милли сәясәт түбәндәге чараларны күз алдында тотарга тиеш:*

*1. Федератив союздаш дәүләттә барлык автономияләр барлык милли-дәүләти төзелмәләр рәтендә «бергәләшеп һәм тигез хокуклы» булсын өчен, шушы автономияләрнең сәяси һәм хокукый статусын яңадан карарга.*

*2. Милли-территориаль округлар буенча СССР халык депутатларын сайлаганда һәм Милләтләр Советы составында союздаш һәм автономияле республикаларның, автономияле өлкәләрнең һәм округларның вәкилләре тигез санда булуны тәэмин итәргә. Халык санындагы аерма территориаль округлар буенча сайлауларда чагылмаска тиеш».*

**СССР Югары Советы Рәисе**
**ип. М. С. Горбачевка**

## Автономияле берәмлекләрдән СССР халык депутатлары МӨРӘҖӘГАТЕ

*СССР Югары Советының II сессиясе көн тәртибенә СССРның милли-дәүләти корылышы нигезләренә кагылышлы закон проектлары буенча фикер алышу кертелгән.*

*Бу закон проектлары билгеле бер концепция кысаларында эзерләнергә һәм каралырга тиешлеге мәгълүм. «Хәзерге шартларда партиянең милли сәясәте» дигән КПСС платформасы булган бу концепцияне караудан һәм анализлаудан СССР Югары Советының үз ихтыяры белән читләшүе сәер һәм мантыйксыз тоела.*

*Бу документның мөһимлеген һәм хөрмәткә лаек булуын танып, түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк. СССР халыкларының тигез хокуклылыгы турында Платформа игълан ителгәннәргә каршы килеп, СССРның милли-дәүләти корылышының гамәлдәге структурасының какшамаслыгы хакындагы тезисны алга сөрү аеруча бәхәсле күренә безгә. Федерациябез гамәлдәге дүрт баскычлы иерархиядән (союздаш һәм автономияле республикалар, автономияле өлкәләр һәм округлар) гыйбарәт, шушы сәяси тигезсезлекнең дәвам итүе милли җирлектә конфликтлар килеп чыгуның даими чыганагы булачагына без ышанабыз.*

*СССРның киләчәк дәүләти корылышы турында үз фикерен автономияле берәмлекләрдән булган СССР депутатлары СССР Югары Советының беренче сессиясендә СССР Югары Советының барлык әгъзаларына мөрәҗәгатендә аерымачык итеп, әзеп әйтте («Бюллетень», N 45, 42 һәм аннан соңгы битләр). Кызганычка каршы, безнең тавышны ишетүче һәм игътибарга алучы булмады.*

*СССР Югары Советы Милләтләр Советының милли сәясәт һәм милләтара багланышлар комиссиясе әгъзалары тәкъдимнәр пакеты әзерләгән булсалар да, бик үтенеп сорасалар да, КПСС ҮК Пленумында катнашырга рөхсәт ала алмадылар.*

*КПСС ҮК адресына автономияле республикалардан, илебез җәмгыятьчелегенең төрле катламнары вәкилләреннән килгән тәкъдимнәр турындагы статистик белешмәләр җыелмасы да бастырып чыгарылмады. Шуңа күрә кабул ителгән карарларның күпчелек халык фикерен чагылдыруына бернинди ышаныч юк.*

*Милли мөнәсәбәтләр кебек катлаулы һәм нәзберек мәсьәләдә хакыйкатькә монополиячел хокук булмаска тиеш, альтернатив тәкъдимнәр дә булырга мөмкин һәм алар кирәк тә.*

*КПСС платформасының СССРның милли-дәүләти корылышына кагылышлы бүлекләре нигездә СССР Югары Советының II сессиясендә һәм СССР халык депутатларының II съездында карау өчен беренчел закон проектларын һәм концепция әзерләү максатларында, Милләтләр Советының махсус утырышында КПСС платформасының шушы бүлекләрен СССР Югары Советының II сессиясе көн тәртибенә кертүне таләп итәбез.*

*СССР халык депутатлары*
*(Барысы 18 имза)»*

Бу мөрәҗәгатьләрнең барысы да диярлек йә Ардзинба, йә минем кул белән языла иде дә, аннан соң бергәләп редакцияли идек.

Яки менә мондый белдерү.

**«Башкортстан, Татарстан, Якутия-Саха республикаларыннан сайланган СССР халык депутатларының БЕЛДЕРҮЕ**

*СССР Президенты һәм Союздаш республикалар җитәкчеләренең ил экономикасын стабилизацияләүгә юнәлтелгән Белдерүе белән танышкач, түбәндәге белдерүне ясарга кирәк дип таптык:*

*СССР Президенты һәм Союздаш республикалар җитәкчеләре, милләтләрнең мөстәкыйльлеге һәм үзбилгеләнү хокукын танып, үз республикаларының суверенлыгын конституцион юл белән игълан иттеләр.*

*Шул Белдерү нигезендә союздаш булмаган республикалар да суверен дәүләтләрнең сәяси һәм экономик союзын төзүдә тигез хокуклы республикалар булып катнашырга тиеш дип саныйбыз».*

Бу белдерүгә өч республикадан 34 депутат кул куйган. Шулар арасында Башкортостанның бүгенге Президенты Мортаза Рәхимовның да имзасы бар.

Шунысын да әйтергә кирәк, безнең белдерүләр, мөрәҗәгатьләргә өстәгеләр җитди итеп карамады. Хәтта Союздаш республикалардан сайланган депутатлар да безнең җан ачысы белән әйтелгән сүзләребезгә: «Нәрсә маташкан булалар инде бу мескеннәр?»—диебрәк карый иде. Үзләренең беренче сорт депутатлар икәнлеген күрсәтергә тырышалар иде. Шулай корылган системаның беренче сорт коллары иде алар. Әмма без барыбер үз хакыбызны даулауны дәвам иттек. Әгәр дә башка автономияле республика депутатлары да, безнең кебек актив булып, сүзләрен трибунадан кычкырып әйтсәләр, бәлки ишеткән дә булырлар иде, тик алар дәшмәде. Күпләре сүз әйтүдән курка иде, кайберәүләре «әйтеп ни мәгънә?» дип кул селти, кайсылары үз язмышларына риза иде. Мәсәлән, мин Югары Совет утырышларында Төньяк Осетия депутатлары Агузарова һәм Базырова дигән ханымнар белән янәшә утырып, аларның милли проблемаларны аңламауларына һәм аңларга да теләмәгәннәрен күреп аптырый идем. Миңа калса, алардан автономия исемен алып, гап-гади өлкә итеп калдырсалар да, аларның исләре китмәс иде. Мари һәм удмурт депутатлары да үзләрен инде беткән халыкка санап, өметсезлеккә бирелгән иде. Хәер, аннан сайланган депутатлар арасында шул республика исемен йөрткән милләттән депутатлар юк иде диярлек. Мондый битарафлык безгә сүзебезне сүз итәргә комачаулый иде, әлбәттә. Кайвакытларда: «Кирәк

микән көрәшеп азапланырга, нервыларны талкырга?»—дип уйлап куйган чаклар да була иде. Әмма барыбер бирешәсе килми. Үз сүзебезне әйтергә трибунага ыргыла идек. Безгә сүз бирмиләр. Трибунада күбрәк Союздаш республика депутатлары. Үземә сүз бирелүдән файдаланып, бер утырышта: «Әлбәттә, Президиум өстәле артында утыручылар без автономияләрне ишетергә теләмиләр. Безне күрергә теләмәү күңелсез нәтиҗәләргә китерүе дә ихтимал бит»,—дигән идем. Һәм шулай булып чыкты да. СССРның таркалуы нәкъ менә милли сәясәтнең гариплегеннән килеп чыкты. Бөтен милләтләрне берләштереп, гадел принципларга корылган идея юк иде. Союздашлар безне кешегә санамады, без алардан көнләштек, дошман ук күрмәсәк тә, үзебезне аларның фикердәшләре дип санамадык.

Теге яки бу дәүләт органнарына вәкилләр тәкъдим иткәндә, Союздаш республика депутатлары безне турыдан-туры мыскыл итүгә барып җитәләр иде. Ул мисалларның берсен мин язган идем инде, менә икенчесе: СССР Югары Судына Татарстаннан да судья тәкъдим иткәч, мине милли чикләнгәнлектә гаепләделәр, судьяларның кайсы милләттән булуларына карап түгел, аларның профессиональ әзерлекләрен күздә тотарга кирәк диделәр. Шул сүзләргә каршы ясаган чыгышымның тексты саклана. Шунда мин болай дигәнмен: «Хөрмәтле депутатлар! Без дәүләт, хөкүмәт органнарына үзебезнең милләт кешеләрен тәкъдим иткәндә, кайбер депутатлар безнең тәкъдимнәргә көлебрәк карыйлар. Янәсе, без, тәкъдим ителгән белгечләрнең профессиональ якларына игътибар итмичә, милли кадр булулары турында күбрәк кайгыртабыз. Мондый караш безне түбәнсетә, безгә андый мөнәсәбәтне без мыскыл итү дип кабул итәбез. Профессиональ әзерлеге булмаган милли наданнар дәүләт белән идарә итәргә тиеш дип әйтергә, без әллә ахмаклармы? Без тәкъдим иткән кадрлар профессиональ әзерлекләре һәм эшлекле булулары белән берәүдән дә ким түгелләр. Мин, мәсәлән, СССР Югары Суды составына үз халкымның вәкилен тәкъдим иткәндә югары класслы юристны күз алдымда тоттым. Югары Судка ветеринарлыкка укыган кешене тәкъдим итәргә, мин, сез уйлаганча ук, тиле түгел. Әйдәгез, киләчәктә бер-беребезне хөрмәт итеп сөйләшергә өйрәник.»

Халыкларны сортларга бүлеп, аларны бер-берсенә каршы кую СССРның милли сәясәте булганын мин һәркөнне күреп, ишетеп тордым. Нинди генә закон проекты каралса да, анда халык мәнфәгате түгел, Үзәкнең, ягъни мәсәлән, Мәскәүнең генә мәнфәгате ягыннан чыгып фикер йөртелә иде. Ара-тирә Союздаш республикаларга ниндидер «өлеш» чыкса да, автономияләр бөтенләй онытыла иде. Шул елларда дәфтәремә теркәп куйган уйларымның берсе белән тагын уртаклашам.

«Йә тегеләй, йә болай» дип атала ул.

«Бу көннәрдә Верховный Советта чәчү өсте. Халыкларның, илнең, җәмгыятьнең язмышын хәл итә торган законнар кабул итәбез. Шулар арасында иң үзәктә торганы—Милек турында закон. Закон проектының икенче вариантын карыйбыз инде, әмма очы-кырые күренми. Талкыга салып талкыйлар, килегә салып төяләр депутатлар проектны. Төп сүз законның нигезен, җәмгыятьнең киләчәген тәшкил иткән ике мәсьәлә тирәсендә бара. Беренчесе—хосусый милек, икенчесе—илдәге җир-су, урман һәм табигый байлыкларга кем хуҗа булырга тиеш?

Беренче мәсьәлә буенча берәүләр: «Хосусый милек булмаска тиеш, чөнки аны законда танысак, капитализмны реставрацияләү була» диләр. Икенчеләр «Хосусый милекне тыю безнең илне шушы хәлгә китереп җиткерде» диләр. Мин бу мәсьәләдә күп нәрсәне аңлап та бетермим. Чөнки «нәрсә ул хосусый милек?» дигән сорауларга безнең экономика фәнендә төгәл җавап юк шикелле. Политэкономия буенча имтиханнар тапшырдым, әмма надан килеш калдым. Бәлки мин надан түгелмендер—фән үзе ялгандыр, кешелек законнарына нигезләнеп язылмагандыр. Безнең илдә «минеке» дигән нәрсәне бетерергә тырыштылар, «безнеке» дигән нәрсә керттеләр. «Безнеке»—ул беркемнеке дә түгел дигән нәрсә. Шуңа күрә илдә хуҗасызлык хөкем сөрәдер.

Ләкин хосусый милеккә кайтып, ил белән мал бүлә башласак, ул ни белән бетәр? Бигрәк тә юк малны бүлешү. Кайбер гаиләләр мал бүлгәндә талашып-сугышып-үтерешеп бетәләр. Бүгенге көндә, илдә тотрыксызлык чакта андый нәрсә белән шаярырга ярамыйдыр. «Уртак малны эт җыймас» дигән дөрес мәкаль булса да, «халык милке, җәмгать милке» дигән төшенчәләр дә безнең психологиягә сеңгән. Урталыкны табарга иде. Галимнәр баш ватарга тиеш. Үзгәртеп кору турында җитди сүз сөйлибез икән, җәмгыятьнең—социалистик җәмгыятьнең дә үзгәргән моделе булырга тиеш. Кешегә яшәргә җайлы җәмгыять моделе.

Икенче мәсьәлә буенча минем фикерем ачык, тәгәл. Җир-су, урман һәм табигый байлыкларга шул җирдә яшәүче, шул суны эчүче, шул урманны караучы кешеләр хуҗа булырга тиеш. Ә проектта хуҗа итеп Союздаш республикалар гына күрсәтелгән. Бу зур ялгыш. Халыклар арасында низагны китереп чыгарган ялгышның иң зурысы. Ничек инде ул? Эстония, Казакъстан үз җиренә хуҗа. Татарстан, Якутия хуҗа түгел.

Мин сессиядә чыгыш ясап, автономияләрнең фикеренә бер проектта да колак салынмый дип, съездагы чыгышымның фикерен дәвам иттем. Минем сүзне яклап, автономияләрдән бүтән депутатлар чыгыш ясарга тотындылар. Ниһаять, безнең сүзгә игътибар итәргә уйлыйлар шикелле, белмим, кулга тагын нинди проект тоттырырлар. Һәрхәлдә, әгәр дә безне җирдән-судан мәхрүм итәргә җыеналар икән, автономияләрнең проектны кабул итмәскә көчләре җитәчәк, дип өметләнәм.



*Туфан Миңнуллин СССР Халык депутатлары, казах язучылары Сакен Жунусов һәм Олжас Сөләйманов белән. 1990 ел.*

Кызык нәрсә, күпләр чын күңелдән ялгышып, җир-су мәсьәләсенә матди яктан гына килеп карый. Ә минем өчен һәм минем кебекләр өчен җир ул рух мәсьәләсе дә. Җире булмаган кеше үзен кеше итеп хис итә аламы? Җирдән мәхрүм халык халык була аламы? Һәм ничек инде ул минем бабаларым, әтием-әнием күмелгән җир икенче берәүнеке булырга тиеш? Ул чакта мин кем?

Хакыбызны даулар көннәр килеп җитте. Мондый чакта читтән күзәтеп тору—җинаять. Һәм шуңа күрә мин бүгенге халәтемне, ниятемне

бу дәфтәргә теркәп калдырырга кирәк, дип санадым. Укыганнар белсеннәр, халык ышанычын аклау дигән сүзнең чын, асыл мәгънәсе дә югалмаган әле. 18 октябрь, 1989"

Бүген инде ул чактагы депутатның көндәлек тормышы, мәшәкатьләре турында язып торуның кирәге юктыр. Шулай да җанга тигән бер нәрсәне искә алмый булмас.

Кешедән туйдым мин анда. Кешеләрне күрәсем килми башлады. «Мәскәү» кунакханәсендә торабыз. Иртән көтү белән ашханәдә ашау. Аннан көтү белән—утырышка. Көтү белән әбәт ашау. Тагын утырыш. Кич белән чәй эчкәндә дә ялгыз калып булмый диярлек. Йә берәрсе номерга чәй эчәргә керә, йә үземне чакырып алалар. Кайвакытта бикләнеп утыра идем.

«Акчасы күп кеше акчаның кадерен белми», диләр. Кеше күбәйсә дә, кадере бетәдер. Шуңа күрә шәһәр җирендә кешеләр трамвай, троллейбус, автобусларда туктаусыз ызгышалардыр.

Беркөнне кешедән туеп, утырыштан качып киттем дә, номерга кереп бикләндем. Берәүгә дә ишек ачмаска сүз бирдем. Шул чак телефон чылтырады. Гөнаһ шомлыгына, алдым трубканы. Мәскәү шәһәрендәге таныш татарлар кунакка чакыра. Ычкынып кителде, әллә ниләр әйтеп бетердем. «Оставьте меня в покое!»—дип урысча да кычкырдым шикелле. Бу кыланышым өчен бүген дә оялып йөрим. Ярый әле танышым әдәпле кеше булып чыкты. Бер очрaганда «Сиңа шалтыраткан идем, ниндидер исереккә туры килдем»,—диде. Ул «исерек»нең үзем икәнен әйтмәдем.

Нервылар һәркөн киеренке. Күп укырга, күп белергә, чыгышларга әзерләнергә кирәк. Әзерләнәсең—сүз бирмиләр. Аптырагач янымдагы осетин кызлары белән шаярмакчы булам. Алар кирәгеннән артык җитдиләр. Мөхәррәм белән, Марс белән сөйләшкәләп алабыз. Ул да туйдыра.

Кайвакытта кызыклар да булып куйгалый үзе. Берсендә, мәсәлән, Литва депутаты СССР составыннан чыгу турында сүз сөйли. Ә безнең яндагы бер депутат (Мари республикасыннан, урыс агай-эне): «Не отпустим!»—дип кычкыра. Мин этләшергә тотындым»: «Как вы их любите»,—дидем. «Я? Их? Я их ненавижу»,—ди бу. «Нет,—мин әйтәм,— любите? Не хотите отпускать. Вот я их не люблю, пусть уходят»,— дигән идем, депутатым алданганын аңлап, сүгенеп куйды.

Татарстан суверенлык турында декларация кабул иткәч тә исте калырлык көннәр булды. Без—Татарстаннан сайланган Югары Совет әгъзалары, каршыбызда торган «ТАССР» дигән язудагы «А» хәрефен сызып ташладык. Күршеләребез безгә көлебрәк, әмма көнләшеп карады. Ләкин шатлыгыбыз озакка бармады. Залдагы тәртипне күзәтүчеләр безгә кисәтү ясады һәм икенче көнгә каршыбызда тагын «ТАССР» тора иде. Без тагын «А»ны сыздык. Бу юлы күршеләребез безнең өчен бераз курыктылар шикелле, әмма кисәтү ясаучы булмады. Икенче көнне безне «ТССР» дигән табличка каршы алды. Без кул чаптык. Ни әйтсәң дә, демократия дигән нәрсә күренә башлаган чак иде шул.

Декларация белән бәйле янә бер гыйбрәтле хәл булды. Без «Татарстанның Суверенитет турындагы Декларациясен хуплыйбыз» дигән язу яздык та, СССР халык депутатларыннан кул куйдырып, Югары Совет председателе А. Лукьяновка бирергә булдык. Балтыйк буе республикаларыннан, Украинадан, Молдовиядән, автономияле республикаларның берничәсеннән кул куючылар күп булды. Тик менә Урта Азия республикалары депутатлары, Кавказ республикалары ни өчендер баш тарттылар. Минем өчен бу гаҗәп тоелды, сәбәбен аңлый алмадым. Нәтиҗәдә, минем аларга хөрмәтем кимеде. Хуплау кәгазен Лукьяновка бирдем. Нишләткәндер— белмим.

Депутат булып йөргәндә эшләнгән эшләремнең берсе—Җәлил белән бергә йөрешеп, бергә үлем җәзасына хөкем ителгән егетләрне орден белән бүләкләтүгә ирешү булды. Ул турыда Язучылар союзы

Мәскәүгә берничә тапкыр мөрәҗәгать итеп караса да, файдасы булмаган иде. Монда мин нык-лап йөри башладым. Казанда Рафаэль Мостафин белән элемтәгә кереп, документлар әзерләдек. Мин аларны күтәреп, Югары Советның бүләкләү бүлегенә кердем. «Барысына да Советлар Союзы Герое бирергә кирәк»,—дигәч, сөйләшмәдеәр дә. Орден мәсьәләсен карарбыз, диделәр. Карап, Ватан сугышы Ордены белән бүләкләү турында Указ чыкты. Әлбәттә, бик күпләргә тоташтан бирелә торган бу орден җәлилчеләрнең батырлыгына тиң түгел иде. Ләкин, нишләтәсең, Мәскәү-Мәскәү инде ул.

Депутатлык турында язганда безне куып тарату турында да язарга кирәктер инде. Әлбәттә, безне, 1917 елдагы учредительное собраниене тараткан шикелле, «Долой временные, постоянные пришли» дип кумадылар. Беренче булып, безне санга сукмый башладылар. Ни әйтсәк тә, тыңлаучы, ишетүче юк. Догага туймаган әрвахлар кебек йөредек-йөредек тә, кайсыбыз кая таралыштык. Аннан бөтен кешегә дә мәгълүм—ГКЧП. Безне рәсми рәвештә сызып ташладылар. Законнарсыз яшәгән ил законсыз рәвештә таралды да куйды. СССР дигән илне яклап йөрүче берд әнбер кеше—чечен хатыны Умалатова гына үзен законлы депутатка санап йөрде. Әкәмәт ил. Безгә үлем хөкеме чыгарган РСФСР Югары Советын да куып тараттылар. Тукай әйтмешли:

> Бетте көч, сынды кылыч—шул булды эш,
> Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьлый алмадым.

Машинкадан алгач, язганнарымны укып чыктым да, нәрсәдер әйтелеп бетелмәгән кебек тоелды. Өстән-өстән генә «тырмалап» чыккан сыман. Шундый да буталчык вакытка бәя биреп, үзеңнең шул чорда болганып йөрүеңне аңлату өчен зуррак нәрсә язарга кирәктер. Хәер, анысы инде бүтәннәр эше. Болганып йөрүче мин генә булмадым лабаса. Әле һаман да буталабыз. Алда ни көтәчәген беребез дә белми. Үзгәреш дәвам итә. Начар якка гына үзгәрергә язмасын иде.

*24 май 2000 ел.*

РАДИО
УКВ 73,97
Курай
Яшь күңелле
дуслар өчен

# ВАТАННАН ЕРАКТА ТУГАН ҖЫРЛАР

*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире исеменә Мәскәүдән игътибарга лаек бер хат килеп төште. Аны Мәскәү дәүләт Халыкара мөнәсәбәтләр институтының кафедра мөдире, профессор Абдулхан Габдрахман улы Әхтәмҗан язган. Хатта мондый юллар бар:*

**«Хөрмәтле Равил Габдрахман улы!**

**Мин күп еллардан бирле Германия тарихы һәм, берочтан, заманында әсирлектә килеш нацизмга каршы аяусыз көрәшкән җәлилчеләр язмышын өйрәнәм. Күптән түгел Мәскәүнең «Особый» архивында кызыклы бер материалга тап булдым. Ул—Ватан сугышы елларында Берлинда латин имлясында чыгып килгән «Татар әдәбияты» дигән журналның бишенче саны. Ү. Науруз дигән кешенең (бәлки бу аның псевдонимыдыр) «Шагыйрь» дигән шигыре миндә аеруча зур кызыксыну тудырды. Хәлбуки, бу әсәр Муса Җәлилнең шул ук исемдәге шигыренә гаять аваздаш... Әлеге журналның алдагы саннарын әлегә таба алмадым. Һәрхәлдә, аның биш саны чыгуы бәхәссез...»**

*Абдулхан әфәнде, хаты белән бергә, «Татар әдәбияты» журналының тышлыгы, Ү. Науруз шигырьләренең ксерокопиясен һәм шул турыда махсус язган мәкаләсен дә җибәргән.*

*Чыннан да, Ү. Наурузның «Шагыйрь»е Муса Җәлил шигыре рухында язылган икән шул. Гүяки, аны М. Җәлилнең:*

*Төн утырып шагыйрь нәрсә язды?*
*Нинди хисләр аны ярсытты?*
*Язганнарын биреп җил иркенә,*
*Таңда үзе кая ашыкты?—*

*дигән сорауларына җавап рәвешендә язылган диярсең.*

*Без Мәскәүдә иҗади кимәлдә яшәүче, Татар мәдәни җәмгыятьләре Координация советы рәисенең беренче урынбасары, профессор Абдулхан әфәнде Әхтәм-җанның мәкаләсен (тәрҗемәдә) һәм сугыш елларында Германия башкаласында нәшер ителгән «Татар әдәбияты» журналында басылган Ү. Науруз әсәрләрен укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәргә булдык.*

## «Үлмәс җырын шулай тудыра!..»

**1944** елның язында нацистлар Германиясенең үзәгендә татар телендә басылып чыккан ошбу шигырь юллары, бер яктан, җанымны дулкынландырса, икенче яктан, сораулар да тудырды. «Шагыйрь» дип аталган бу әсәр кемгә багышланган? Анын авторы кем? 1944 елда Берлинда нәшер ителгән «Татар әдәбияты» дигән альманах көтмәгәндә кулыма килеп кергәч, миндә әнә шундый сораулар тууы табигый иде. Моңа кадәр мин «махсус» дип аталган архивта эзләнгәндә нацистлар Германиясенең төп идеологлары Розенберг һәм Геббельсның пропаганда органы булган «Винета» эшчәнлеге белән танышкан идем инде...

«Татар әдәбияты» (5 сан) латин хәрефләре белән басылган, зәңгәрсу-соргылт төстәге йомшак тышлык белән чыгарылган. Үзенчәлекле әдәби альманахның титул битенә, баш мөхәррир һәм нашир буларак, танылган эмигрант Г. Шәфи Алмас, әдәби мөхәррир буларак Г. Хәмиди кул куйган. Тышлыкның соңгы битендә журналның исеме һәм чыгарылыш мәгълүматлары немец телендә бирелгән. Журналның башка саннарын эзләү әлегә нәтиҗә бирмәде. Ул басмалар 1943 елның беренче яртысында чыккан булсалар, аларда Гумеровның, ягъни Муса Җәлилнең һәм аның көрәштәшләренең шигырьләре дә булырга мөмкин иде.

Бу басманың бишенче саны нәрсәсе белән игътибарны җәлеп итә соң? Анда Һ. Такташ әсәрләре, Һетенең ниндидер Рабига татарчага тәрҗемә иткән язмалары басылган. Әмма игътибарны иң җәлеп иткәне— «Яшь көчләр» дигән бүлектер мөгаен. Анда аһәңе белән Муса Җәлил шигырьләренә аваздаш әсәрләр басылган. Мәгълүм


TATAR ƏDƏBIATЬ

Tatar „kөrəş berlege" komitele tarafьnnan сьgarыla

Сьgarucь həm baş redaktorь
Ģ. ŞAFI ALMAS

№ 5

Berlin 1944.

Redaktor: Ģ. Xəmidi.

ки, Җәлилнең көрәштәшләре арасында сугышка кадәр үк шигырьләр язган әдип һәм журналистлар булган. Әмма бу басма дөнья күргән вакытта Җәлил группасы фашистлар тарафыннан кулга алынган һәм Алман рейхының хәрби куәтен какшатканнары өчен империя суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителгән инде. Муса Җәлил белән бергә Абдулла Алиш, Әхмәт Симаев, Гайнан Кормаш һәм башкалар җәзаланып үтерелә.

«Татар әдәбияты»ның бу санындагы шигырьләр астында инде башка исемнәр: Ү.Науруз, И. Хәйруллин, Р. Рабига, Г. Мокамай һәм легионер К. Шакиров. З. Танып дигән кешеләрнең шигырьләре аерым цикл итеп бирелгән. Алмания тарихын өйрәнүче буларак, шуны билгеләп үтәсем килә: шул замандагы нацистларның большевикларга каршы юнәлтелгән пропагандасы никадәр көчле булуга карамастан, әлеге журнал нейтраль позициядә тора, андагы әсәрләр, сагыну-сагыш, җирсү хисләре белән өртелгән. Татар шигърияте буенча белгеч булмасам да, миңа калса, әлеге шигырьләр нормаль әдәби телдә, кемгә дә булса ачу сакламыйча, «зур сәясәткә» кагылмыйча язылганнар. Алар гаилә җылысын, Ватанны ихлас сагыну хисләре белән сугарылганнар. Яшь шагыйрьләрнең бу шигырьләре «Моабит дәфтәре»ндәге әсәрләр белән шактый үк аваздаш. Кайбер авторларның үз исем-фамилияләре урынына псевдоним-тәхәллүсләрен куйганнарын чамаларга мөмкин. Ихтимал, профессионал әдәбият белгечләре әлеге шигырьләрнең тел-стиль чараларына, ритмика үзенчәлекләренә карап, аларның авторлары нинди шигъри мәктәпкә караганлыкларын билгели алырлар. Шигырь юлларын анализлау-тикшерү билгеле бер нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин. Әйтик, бу әсәрләр профессиональ шагыйрьләрнең хәрби әсирләр лагерьларына барып укыган шигырьләренең язмасы түгелме икән?

Арада Ү. Науруз исеме (ә бәлки тәхәллүсе) белән бирелгән «Шагыйрь» дигән шигырь аеруча тәэсирле. Ул Шагыйрьгә атап язылган, әмма аның лирик «Мин»е кем булуы билгесез. «Үлмәс җырын шулай тудыра!» - дип тәмамланган строфаның ике урында кабатлануы хисси гомумиләштерүне ассызыклый, шигырьгә «ачкыч» ролен үти сыман. Науруз шигыренең рухы, тел-сурәтләү чаралары Муса Җәлил лирикасы белән аваздаш кына түгел, алар охшаш, бер үк «ачкычта» язылганнар. Гүяки, лирик герой җәлилчеләрне хөкем иткән көннәрдә (шигырьләр астына да 15.03.44 ел дип куелган) Шагыйрьне искә ала, белә, хәтерли ул аның үлемсез җырларын. Авторның күз алдында - безнең өчен «Моабит дәфтәре»ннән мәгълүм, Муса Җәлил тарафыннан 1942 елның октябрендә үк язылган «Шагыйрь» шигыре. Бу ике шигырьнең аваздашлыгын ачыклау өчен кайбер юлларны чагыштырып уку да җитә.

Җәлил шигырьләрен тәрҗемә итүче шагыйрь Вил Ганиев белән бервакыт сөйләшкәндә Ү. Наурузның «Шагыйрь»е турында сүз чыккач, ул да башлап Муса Җәлилнең шул исемдәге шигырен искә алды.

Җәлилнең «Шагыйрь» шигыре рус укучысына, башлыча, Арсений Тарковский тәрҗемәсендә билгеле. Науруз шигырен укыган саен бер нәрсәгә һаман тирәнрәк төшенәсең: ул Шагыйрьнең үлемсез җырлар иҗат итүенә соклану белән бергә, аның үз якташлары язмышындагы, үз халкы намусын саклаудагы гаять зур ролен яхшы аңлап яза. Шигырьнең үлемсез җырлар язучы олуг татар Шагыйренә багышланганлыгы көн кебек ачык. Бит Муса Җәлил үзенең шигырьләрен нәкъ менә «җырларым» дип атаган лабаса. 1944 елның язында, тиздән киләсе Җиңүгә бөтен җаны белән ышанган Шагыйрь турында шагыйрь яза. Ә Науруз исеменә кем яшеренде икән соң? Әлегә бездә бу сорауга җавап юк. 1944 елда Берлинда «Шагыйрь» дигән шигырен бастырып чыгарган бу шагыйрьнең кем булганлыгына, «Науруз табышмагын» чишүдә, ихтимал, чит илләрдәге татарлар тормышын өйрәнүчеләрдән кем дә булса ачыклык кертә алыр?

**Абдулхан ӘХТӘМҖАН.**
*Мәскәү шәһәре*

## Ү. Науруз

### Шагыйрь

Кояш баткан. Бөтен шәһәр халкы
Күптән инде талып йоклаган.
Тиздән инде ярты төн авыша,
Ә ул нишләп һаман ятмаган?
Тышта җилләр,
Кышкы салкын җилләр
Тәрәзәгә килеп сугыла.
Ә күктәге аксыл кар болыты,
Белмим, кая шулай итеп ашыга?..
Моржаларны курай итеп җилләр
Аерым бер моң белән җырлыйлар.
Йә булмаса шайтан туе ясап,
Төн куркытып үкереп җылыйлар.
Шәһәр йоклый,
Тик ул гына ялгыз
Йокы качырып уйга күмелгән.
Фикерләрне сүзгә салу өчен
Иҗадына кереп төрелгән.
Бүген генә түгел,
Ул гел шулай
Төннәр буе уйлап утыра.
Яза. Боза. Уйлый...
Тагын яза...
Үлмәс җырын шулай тудыра.
Ул иленең, бөек милләтенең
Яхшы белә бөтен үткәнен.
Яхшы белә гасырлардан бирле
Халкы таңнан нәрсә көткәнен.
Бүген җирдә барган зур көрәштә
Урны ачык: халкын яклый ул.
Милләтенең тиздән җиңүенә
Канында зур өмет саклый ул.
Бүген генә түгел, ул гел шулай
Төннәр буе уйлап утыра.
Яза. Боза. Уйлый...
Тагын яза...
Үлмәс җырын шулай тудыра!
Таң атуга аның төнге уйлары
Шигырь булып илгә тарала.
Халкы алдында җыры хөрмәт белән
Алтыннан да кыйммәт санала.
Шәһәр йоклый,
Шагыйрь генә ялгыз.
Йокы качырып уйга күмелгән,
Фикерләрен сүзгә салу өчен
Иҗадына чумган, төренгән.

### Ил мәхәббәте

Дала, кырны авыр моңга күмеп,
Мәңге көрәш белән яшәгән,
Чабаталы явыз дошманнарга
Гәүдәң белән бәхет түшәгән
Газиз халкым,
Керсез күңелем гөле!
Җырларымны сиңа багышлыйм!
Синең теләк-уйны, гасырларны
Җырлап, юк, юк, мин һич ялгышмыйм!

I

Ата-бабаларның изге кабре
Синдә булган өчен якынсың!
Синнән куылып, гомерем буе читтә
Газап чиккәч, тәңгә ераксың.

Туган туфрак, имгән сөтем синдә,
Ярым синдә, шуңа ямьлесең!
Анам хәләл сөте кебек эчкән
Суым синдә, шуңа тәмлесең!

Сараеңда этләр, михрабта хач,
Тик шунлыктан миңа ямьсезсең.
Телем икмәк яшьсез каптырмыйсың,
Шуңар күрә миңа тәмсезсең.

Дәрт, уй, хыял, өмет, теләкләрем
Синдә туган өчен җылысың!

**Йөрәгемне кире каккан өчен**
**Үзең суык, үзең бозлысың!**

**И Туган ил!**
**Әйтче, ничек синнән**
**Бар яманың күреп ваз кичим!**
**Бәхтең өчен, иркең өчен ямьмый**
**Бу дөньядан ничек мин күчим!**

**Юк, юк, илем!**
**Моны уйласам да,**
**Теләсәм дә эшли алмыймын**
**Ничек кенә булма, тик мин сине**
**Ташлап, онтып яши алмыймын.**

**II**

**Батырларның аяк тавышлары,**
**Ишетәмсең, ничек яңгырый!**
**Җиңү көрәшенә чакыра барсын**
**Авазлары ничек ялкынлы.**

**Менә синең ямьле җир туфрагың**
**Тудырган бу бөек батырлар!**
**Гасырлардан бирле сине буган**
**Барлык богауларны ватарлар!**

**Күп йөз еллар бүе туфрагыңда**
**Шашып корбан йотар үлем дә,**
**Тир, яшь, каннар белән һаман-һаман**
**Киңлек сорап яткан күңлең дә—**

**Барсы да тиз,**
**Әйе, әйе, тиздән**
**Югалырлар, мәңге бетәрләр.**
**Биләүсә күк сине буып торган**
**Шанлы еллар синнән үтәрләр!**

**Һәм шуннан соң мәңге яшәр гөлле,**
**Сандугачлы бакча булырсың!**
**Тир, яшь, каннар коймый, бетмәс шатлык**
**Белән узар тормыш корышың.**

**И Туган ил!**
**Бар яманын күреп**
**Ничек итеп синнән ваз кичим!**
**Киләчәк шат дәврең күрмиенчә**
**Гамьсез, тыныч ничек гүр кочыйм!**

**Юк, юк, илем!**
**Моны уйласам да,**
**Теләсәм дә эшли алмыймын!**
**Ничек кенә булма, тик мин сине**
**Ташлап, онтып яши алмыймын!**

**Син матурсың,**
**Миңа бик якынсың,**
**Тугансың син,**
**Үги түгелсең!**
**Картлык көнен күрмәс мәңге язсың,**
**Мәңге бакча**
**Былбыл ямь-гөлсең.**

*19 сентябрь 1943 ел.*
*Берлин.*

*Хәсән Туфанның тууына 100 ел*

# МӘҢГЕЛЕК БӘХЕТ ЭЗЕННӘН

Хәсән Туфан—XX гасырда яшәгән һәм иҗат иткән фәлсәфи шагыйрьләрнең берсе. Аның фәлсәфи лирикасы тирән үзенчәлеккә ия. Бу, беренче чиратта, шагыйрь яшәгән чор белән бәйле. Туфан—Тукай, Дәрдемәндтән аермалы буларак—бөек Ислам тәгълиматы рөхсәт ителгән һәм аның изге тәэсире көчле булган чорда түгел, ә коммунистик идеология һәм материализм фәлсәфәсе чәчәк аткан чорда иҗат итә. Бу заманда яшәгән бөтен бер буынның аңына матдиятлелек фәлсәфәсе сеңдерелгән иде. Бер яктан Алланың барлыгын кире кагып, икенче яктан кешелеклелеккә, изгелеккә, иптәшлеккә чакырып коммунистлар шактый каршылыклы фәлсәфә тудырдылар. Әмма кеше күңелендә «илаһи очкын» яши һәм кеше «мин»е үзен бар кылган Илаһә белән бәйләнешен ахыргача югалта алмый иде... Шуңа күрә Туфан да Илаһи эзләнүгә үз рухи барлыгын биреп калдырды. «Матдә—беренчел, аң—икенчел» дигән идеяне тануга карамастан, Туфан үз шигъриятендә, аерым алганда фәлсәфи лирикада Илаһи Чакыруга тугры кала дип әйтергә була...

Күпмедер дәрәҗәдә бу тугрылык түбәндәге юлларда да күренеп китә:

Безнең җанда урын юк та инде
Һичбер нинди күккә, Ходайга,
Язмыш дигән нәрсә ил башына
Югарыдан төшә шулай да...

Бу, билгеле, Аллага булган бер ымсыну...

Әмма Туфанга хас Илаһи эзләнү, барыннан да бигрәк, матдиятлелек фәлсәфәсе җирлегендә табыла.

Мин—бу кырлар, сулар, җирләрдәге
Атомнарның иске туганы:
Материя мин, җаным,
Аның бары
Сөйли, җырлый, сагына торганы.

Күренгәнчә, Хәсән Туфан бу матдиятлелек темасына кешелекле, изгелекле күңеле белән килә...

Уйлап карасаң, бу гаҗәеп янәшәлек: Изгелеккә, Яхшылыкка, Сафлыкка омтылучы шагыйрь һәм матдиятлелек фәлсәфәсе!.. Ләкин шунысы ачык: матдиятлелек фәлсәфәсенең нигезләре ныклы түгел. Бу Галәмне, чәчәк атучы гөлләрне сагынучы, яратучы кешеләрне матдиятлелек фәлсәфәсенә генә кайтарып бетереп булмый...Барыбер, матдиятлелекне дә яраткан Изгелек һәм Рәхимлек чыганагы—Аллага килеп чыгасың... Матдиятлелек бит Алланы танымаса да, Чиксезлекне һәм Мәңгелекне танымыйча булдыра алмый!.. Алар—бар. Шулай булгач, аларны танудан Алланың барлыгын тануга да ерак түгелдер... Вакыттан һәм пространстводан өстен булган Илаһият һәрвакыт кала. Күңел күзе ачык булган кеше моны тоймыйча кала алмый. Бу, бигрәк тә, нечкә һәм фәлсәфи күңелле шагыйрьләргә кагыла...

Бәлки, Хәсән Туфанның зурлыгы, шагыйрьлеге шундадыр да: материалистик фәлсәфә хөкем сөргән шартларда да ул илаһи чакыруны ишетүдән туктамый... Моны аңлый белергә кирәк. Әледән-әле ул Матдәнең «аңлаешсыз» гүзәл серенә игътибар итә һәм шигъриятендә шул турыда хис һәм фикер аша тирәнтен уйлана...

Кем белә, бәлки, аның шигъри уйланулары матдиятлелек фәлсәфәсенең чынбарлыктагы барлык сорауларга җавап биреп бетерә алмавын аңлаудан тугандыр:

«Ничек?» диген һәрбер сорауга
Үз җавабын ачык әйтә фән.
Нигә? Нигә?—Боларына әле
Җавап бирә алмый фәлсәфән.

Һәм шагыйрь үзе шигырь аша чынбарлык турында уйланырга мәҗбүр... Шагыйрьнең чынбарлык турына шигъри уйланулары исә безнең өчен кызыклы тоела. Туфан аңы белән «матдә—беренчел, аң—икенчел» диган фикерне таныган кебек булса да, аның күңеле, күңел җимеше булган шигърияте «моны аңлый алмауны», һәм мона каршы чыгуны да белдерә кебек... Матдиятлелек фәлсәфәсе Туфан «мин»енең Илаһи сизенүләренә җитәрлек дәрәҗәдә каршы килә кебек. Бу бигрәк тә Мәңгелек Тормыш мәсьәләсендә күзгә ташлана...

Үлемнән кача-кача
Гомерләр сорый-сорый,
Синмени? Синең аша
Матдәнең үзе җылый...

Бу дүртьюллык шигырьдә дә матдиятлелек фәлсәфәсен кабул иткән кешенең үзе һәм яшәеше турында тирән уйланулары чагыла. Туфан Матдәне җанландыра, һәм чынында син түгел—«ә... Матдә җылый», ди... Әмма, ни өчен соң кеше гомере сорап, кеше аша Матдә җылый Аны һәм аны белдерүче кешене сыкрарга нәрсә мәҗбүр итә? Шигырьнең беренче ике юлыннан күренгәнчә, Матдә (һәм аны белдерүче кеше дә) беркайчан бетмәячәк Мәңгелек Тормыш тели...

Мәгълүм булганча, материалистик фәлсәфәдә Мәңгелек Тормыш мәсьәләсе үзенчәлекле чишелә. Материалистлар түбәндәгечәрәк фикер йөртәләр: матдә һәм энергия генә мәңгелек булганга, ә кешеләр матдә үсешеннән, эволюциясеннән барлыкка килгәнгә, кеше бу дөньяга миллионлаган очраклар җимеше булып кына килә, аннан янә туфракка әйләнә һәм аның тагын кайчак дөньяга киләчәген, ягъни, «мин»нең кайчан туасын белеп булмый. Бәлки бу миллиард еллар узгач кына мөмкин булыр...

Тудың... Үлдең... Бу хәл ни соң Мәңгелектә?
Бер атом су чумды күлгә, тормый күктә,
Бер бөртек җим артты Җиргә! Бары шул эш.
Тудың, тордың мизгел, инде—китеп барыш
Бу әүвәлсез һәм ахырсыз Мәңгелеккә.

Кешенең бу дөньяга килеп китүендә—Матдәнең мәңгелек хәрәкәтендә—абсурдлык тоела. Ә бәлки, Мәңгелеккә кагылышлы абсурдлык хисе кеше күңелендә генә туа аладыр да?! Чөнки, кеше Мәңгелекне тулысынча танып-белергә сәләтсез—Табигый, шагыйрь «мин»е аптырау, гаҗәпләнү кичерә...

Абсурдлыкка очрагач шагыйрь «мин»е илаһи борчылу хисе кичерә. Чөнки, шагыйрь эчендәге «мин» мондый юкка чыгу белән (ягъни, янадан үлеп матди әверелеш алу белән) килешә алмый, ул Мәңгелек Тормыш тели...

Туфан «мин»е Мәңгелек Тормыш турында үзенең җан сердәше булган таллар белән дә сөйләшә. Ул матдилелек фәлсәфәсеннән чыгып һәрнәрсәдә үзенең якынын күрә. (Идеалистлар һәм материалистлар төрле яктан килеп бөтен дөньяның туганлыгы турында сүз йөртәләр тәсле...) һәм Туфан иртәме-соңмы үләчәк талларда да Мәңгелек Яшәешне сагынып уйлану күрә... («Сүз кушасы килә талларга» шигыре).

Шундый уйчан аулак таннарда,
Танышларын күргән шикелле,
Туктый кеше, узып китешли,
Һәм баш ия монсу талларга,
Шундый уйчан аулак таннарда.

Ни өчен таллар монсу, уйчан? Алар урынына Туфан үзе җавап бирергә алына:

Сүз кушасы килә талларга:
—Сезне дәме матдә алдады
Чиксез өмет,
Чикле җан биреп,
Үзенең тик бер атламы итеп?
Чикләп шундый чая җаннарны,
Сезне дәме матдә алдады.

Димәк, Туфан «мин»е кеше барлыгында да, тал барлыгында да ниндидер бер үзенчәлекле «алданганлык» таба. Чиксез мөмкинлекләргә ия матдә ни өчен кеше, тал гына «ясаган?» (Бу строфада ниндидер бер логикасызлык та бар: әгәр җан матдәдән өмет вәгъдә итеп алдаган? Бәлки, бу «мин»нең мәңгелеген онытa алмаудан туган шигъри логикасызлыктыр?)

Кем белә соң, бәлки, Матдә кеше һәм талны үзенең бер атламы итеп югары бер үсеш кичерәдер? Һәм бу яфрак ярган, гүзәл тормышны белдергән яшел таллар...— алар бит бу яшәешнең изге мәгънәсен беләләрдер?!

—Сез беләмсез кая барганны?
Тере хәлгә китергән бу матдә
Каядыр бит бара, әлбәттә.
Яфрак ярып—санап заманны.
Сез беләмсез кая барганны?

Әйе, талларда, табигатьтә Мәңгелек Тормышка кагылышлы ниндидер бер изге мәгънә тоела. Алар, билгеле, сиңа кеше кебек җавап бирмәсләр... Алар һәрвакыт үзләрен тәкъдим итү аша сөйләшәләр төсле...

Уйга талган ялан таллары Дәшми генә яфрак яралар, Дәшми генә карап калалар Кеше кая китеп барганны... Уйга талган ялан таллары.

Туфан, билгеле, ачыктан-ачык үз җанын атомнардан аерып күз алдына китерергә мөмкин:

Мәңгелек сезнең гомер,
Мәңгелек, атомнарым...
Нигә соң шундый түгел
Атомнан туган җаным?!

Монда инде шагыйрь матдәнең түгел, ә үзенең ачыргалануларын белдерә. Димәк, матдә түгел, ә аннан туган җан үзенең мәңгелексезлеге өчен ачыргалана, әрнү, сыкрану китерә. Шул ук вакытта, икенче яктан, Матдә оешып үзе Мәңгелек Тормышка омтылган кебек. Бу ике дөреслек бер үк вакытта яшиләр дияргә була... Бер нәрсә ачык: матдәдән барлыкка килгән җан бар, һәм ул үзенең мәңгелексезлегенә юаныч эзли...

Әйтик, түбәндәге шигырьләрдәгечә:
Атомнарым минем мәнге үлмәс
Атомнарым мәнге калырлар,
Мәңгелекнең һәрбер дөньясында
Яшәр алар миллиард гасырлар.

Бу урында сорау туа ала: ә «мин» кая китә соң?

Атомнарым минем үлмәс тә бит...
Атомнарның хәтере бармы соң?
Кайда булса миңа очрасалар,
Алар Мине хәтерләрме соң?..

Монда ачык илаһи сикереш тоемлана: бу шигъри юлларда «мин» хисе Матдә эволюциясеннән чыгарылмый!.. Чөнки, Туфан үз «мин»енең барлыгын күпме генә матдә эволюциясеннән чыгарырга тырышса да, субъективлык тойгысы (!) яшәгән Чын Мин тавышыдыр...

Ләкин үз субъективлыгының мәңгелеген тоюга таба Илаһи сикереш ясалуга карамастан, Туфан үз «мин»ен атомнар эволюциясеннән чыгаруны дәвам итә. Чөнки, ул Мәңгелек Яшәү тели, ә моңа атомнарның үлемсезлеге аша гына ирешергә мөмкин дип фикер йөртә:

Юк, атомнар, мәңге аерылмабыз,
Һаман бергә яшәрбез кебек.
Сездә туган акыл канатында
Мәңгелеккә күчәр кешелек.

Материянен чиксез мөмкинлеген
Сутәр бер көн Вакыт, үчерер...
Һәм үзенен анга килгән гомерен
Мәнгелекнен эченә күчерер.

Шушындый юл аша Хәсән Туфан «мин»е өчен Мәңгелек Тормыш мәсьәләсе чишелә... Мондый чишелештә матдиятлелек фәлсәфәсенең генә түгел, ә күпмедер дәрәҗәдә Һегель объектив идеализмының да чагылышы ачык күренә. Ни генә булмасын, Хәсән Туфан «мин»е мондый чишелеш аша үзенә юаныч табарга тели.

Билгеле, Мәңгелек Тормыш, Мәңгелек Аң—Илаһәгә ышанганнар өчен генә. Әмма Мәңгелек аң, Мәңгелек җанлы тормыш матдә эволюциясе нәтиҗәсендә килеп чыга дигән фикерне кабул итеп булмыйдыр. Чөнки субъективлыкка ия «мин» матдәдән килеп чыга алмый, аны әүвәлгесе һәм ахыры булмаган Алла гына ярата ала...

Әмма матдиятлелек фәлсәфәсе хөкем сөргән чорда яшәгән шагыйрь Мәңгелек Яшәүгә омтылуда да шул фәлсәфәгә таянырга мәҗбүр...

Ике строфалы шигырь:

Дәү дә бит һәрбер кояш,
Кин дә бит Галактика,
Гомерләр кыскармаса,
Бүлмә дә ярап тора.

Бетәсе килми һич?
Нидән бу? Ничек? Нигә?—
Матдә ул мәңгелек ич,
Артмый да, кимеми дә!

Материалист фәлсәфәчеләр «матдә—мәңгелек, ул төрле үзгәрешләр генә кичерә һәм арта да, кими дә алмый»—диләр. Мәңгелек тормышка ашкынучы Туфан «мин»е өчен бу азмы-күпме Өмет, Юаныч. Ни генә булса да, матдиятлелек фәлсәфәсе Мәңгелек Яшәеш турында сөйли кебек: аның буенча, бернәрсә дә югалмый, кимеми, һәрнәрсә дә кала...

Билгеле ки, Туфан «мин»е матдиятлелек фәлсәфәсеннән чыгып, Мәңгелек Тормышның олугъ мәгънәсен аңларга алгысый. Әмма Туфан үзе «җавап бирә алмый фәлсәфәң» дип белдергән иде. Һәм менә матдиятлелек фәлсәфәсенә кагылышлы булган, күнелгә ниндидер бер тетрәнү алып килүче фәлсәфи робагыйлар:

—Артмыйм да мин, кимемим дә...—дисең, Матдә,—
Яшим, үсәм һәм үзгәрәм...—дисең, Матдә.
Бу Галәмдә бер атом да арталмагач,
Бу эшеннең төп мәгънәсе ни соң, Матдә?!

яки:

Һәр инкярне инкяр итеп үтәсең син,
Саннарыннан сыйфатларга күчәсең син.
Бу мәңгелек, бу чиге юк тәҗрибәннән
Әйтерсең лә нәтиҗәсен көтәсең син...

Бу робагыйларда—шагыйрьнең «аңлый алмавы», лирик-фәлсәфи аптыравы, хәйранлыгы, аның «мин»енең Мәңгелек Тормышка кагылышлы изге мәгънә эзләве... Бәлки, бу Галәмнәрнең Раббысы—Аллага ышанмаудан туган бер аптыраудыр?..

Кеше интеллекты Мәңгелекне һәм Чиксезлекне, димәк, Алланы тулысынча танып-белергә сәләтсез... Әмма, Аллага юл эзләү һәм омтылу—кеше яшәешенең төп мәгънәседер...

Аллага юл дөнья эчендәге тормышта табыла ала. Һәм Туфан «мин»е Мәңгелекне һәм Чиксезлекне күзаллый алмагач, тормышның изге мәгънәсен эзләүне бу дөньяда дәвам итә:

Чиксезлекне белмим, ни нәрсәдер?
Белгән заман, чорым бу—дөнья:
Уйлыйм, җырлыйм, фәкать тәэсир алып,
Дөньядагы хәлләр турында.

* * *

Кешене әйләндереп алган дөньяда, табигатьтә Мәңгелеккә, Илаһилыкка ишарә ясаучы күренешләр байтак. Һәм Туфан «мин»е ихлас күнелдән табигатькә омтыла да... Табигатькә кагылышлы тормышта ниндидер бер Изгелек тоя ул. Коръән Кәрим әйтә: үләннәр һәм агачлар Аллаһка сәҗдә кылалар. Болай дип тә әйтергә мөмкиндер: гөлләр Илаһә хакына чәчәк аталар...

Ә матдиятлелек фәлсәфәсе шагыйрьләре өчен: Табигать—чәчәк аткан Матдә кебек... Билгеле, алар тарафыннан Табигатьнен Кем чакыруы буенча чәчәк атуы турында сүз алып барылмый... Ни генә булмасын, Матдәнен Мәңгелек Тормышын «аңлый алмаган» Туфан «мин»е Яшәү эзләп Табигатькә омтыла...

Никадәрле төсләр чәчкәндә,
Никадәрле төрләр, шәкелләр—
Бу ижатың каршында синен,
без адәмнәр—бары шәкертләр.

Табигатьне илаһилаштырып карау һәм кешеләрне аның шәкертләре дип санау татар халкы шагыйре Туфан өчен очраклы хәл түгел, билгеле.

Табигатьне ихлас ярату, аңа баш ию, аңа иярергә теләү, гомумән, татар халкына хас нәрсә. Татар мәдәниятенә житәрлек дәрәжәдә Табигать рухы кагылган... Бу, мөгаен, табигать барлыгында Илаһилыкка, Мәңгелек Тормышка омтылучыны тоюдан киләдер. Татар халкы да үз рухи-мәдәни тормышында табигатькә ияреп, Илаһилыкка һәм аның белән бәйләнешле Мәңгелек Тормышка тугры калырга омтыла... Туфанның табигатькә багышланган шигърияте дә әнә шундый изге традицияләргә таяна.

Билгеле, ул монда да матдиятлелек фәлсәфәсенә тугры кала. Әмма ул бер хакыйкатьне дөрес ача: кеше өчен табигать Ана кебек...

Карый да кешегә,
Соклана Табигать;
Бар микән дигәндәй
Галәмдә шундый зат?

Һәм әйтә гүяки:
«Бу—минем киләчәк,
Шушы зат аша мин
Галәмне гизәчәк,

Гүя ул каядыр
Омтыла кешедә,
Саннардан сыйфатка
Күченә-күченә.

Абайла шуны син,
Абсолют Хакыйкать!
Сиңа юл салачак
Җирдәге табигать!»

Димәк, табигать һәм аның баласы кеше аша Абсолют Хакыйкатькә юл салыначак... Ни дигән сүз бу? Мөгаен, бу Җирдәге табигать белән бәйләнешле тормышта Мәңгелек Тормышка юл күрү. Мәңгелек Тормыш абсолют хакыйкатькә тиндәш дияргә була. Ни генә булмасын, Туфан «мин»е кешенең Илаһи тынычсызлыгында һәм Илаһи хакына чәчәк атучы Табигатьтә абсолют хакыйкатькә—Мәңгелек Тормышка изге юл күрә...

Туфанның Табигатьне җанландырып караган шигъри хакыйкате асылда чын хакыйкатьне тоюдан килеп чыга төсле. Ә Табигать Туфан өчен җанлы...

Соклана табигать
Ирекле дөньяга,
Чәчәкләр аркылы
Елмая—елмая...

Туфанның акылы матдиятлелек фәлсәфәсе тәэсирендә калуга карамастан, күңеле чәчәкләрнең терелеген, Илаһә белән бәйләнешле булуларын сизүдән туктамый:

Каядыр дәшәсез,
Нәрсәдер әйтәсез...
Жырымы матдәнен,
Чәчәкләр, әллә сез?

Күренгәнчә, Туфан «Чәчәкләр сөйли белә» дигән хакыйкатьне кабул итәргә

эзер... һәм бу шигъри хакыйкать кенә түгел, билгеле. Илаһи серләргә багышланган кешеләр чәчәкләрнең һәм бар Табигатьнең, чыннан да, сөйләшә алуын беләләр. Моның өчен күнел күзенең ачык булуы гына кирәк... Ә күңел күзе Изгелеккә, яхшылыкка, сафлыкка баш игән кешеләрнең генә ачыла ала. Туфан исә Изгелеккә алгысыган кеше булгандыр. Ни генә булса да, аның күңеле һәрвакыт аклыкка, яхшылыкка омтылгандыр. Шуңа күрә, матдиятлелек фәлсәфәсе тәэсирендә калуга карамастан, ул, барыбер, табигатьнең, чәчәкләрнең җанлылыгын тоюдан туктамый, туктый алмый... Ул Табигатьтә Изгелеккә омтылучы Тереклекне күрә, һәм турыдантуры чәчәкләр, диңгез белән сөйләшә, алар белән аңлашырга тели.

Бу аңлашырга теләү «сөйли торган материя» шигырендә дә бар. Шигырь түбәндәгечә башланып китә:

Каршы алып,
Башын иеп калып
Кин даладан узган ирләргә,
Юл читенә басып, уйга талып,
Карап тора гүзәл миләүшә.

Һәм шагыйрь шул гүзәл миләүшә чәчәге белән сөйләшә башлый. Ул аның үзен аңлаячагына ышана. Ни өчен? Чөнки, кеше һәм чәчәк бит яшәеш балалары, алар тереләр... Хәер, Туфан, «мин»е бу яшәеш туганлыгына матдиятлелек фәлсәфәсе белән килә:

Тартынма син, сеңлем, ятсынма син,
Сөйләшик бер утырып янәшә.
Ятлар түгел, сиңа минем аша
Бертуганын—матдә эндәшә.

Димәк, матдә туганлыгы ул гаҗәеп туганлык икән: ул житәрлек дәрәҗәдә кешеләр арасында булган туганлыкны, бергәлекне хәтерләтә, һәм бу туганлык бик ерактан килә.

Еракларддан, галактикалардан
Без бу җиргә, бергә килдек ич,
Без матдәнең безне тудырачак
Потенциаль көче идек ич.

Аннан бирле бик күп вакытлар узган, һәм алар төрле сурәтләргә кереп очрашканнар:

Ничә миллион гасыр үтте инде
Безнең шушы җиргә килгәнгә...
Син бер гөлгә инде әверелгәнсең,
Ә мин мена—кеше дигәнгә.

Ләкин бу монсу күренмиме? Юктыр. Алар икесе дә тормыш эчендә, алар икесе дә яшәешнең ләззәте һәм кыенлыгы арасында көн кичәләр.

Күрәм:

Син дә бөек яшьлек эшен,
Гүзәл хәлне хәтерләтәсең;
Җирдә тормыш дәвам итсен өчен
Тормышка син әзерләнәсен.

Туфан «мин»е үзенең туганы—миләүшә чәчәгенең бәхетле тормышына соклана, һәм үзенең тормышын да аңа сөйли: ул туган якларыннан читтә гомер уздырырга мәҗбүр, аңа хәтта сөйгән ярының исәнлеген дә белү мөмкин түгел. Ул шул турында уйлана, борчыла...

Мөгаен, Хәсән Туфанның бу шигъри әсәрендә дөнья хәятенең Илаһи Мәңгелек Хәяттән килеп чыкканлыгын тою бардыр. Чөнки, кеше, үлән, чәчәк, кырлар, сулар...—алар барысы да кайчандыр Илаһи Мәңгелек хәяттән килеп чыкканнар. Тик аларны матдиятлелек фәлсәфәсенә кайтарып калдырып булмый.—Тормыш Тормыштан килеп чыга...

Матдилек фәлсәфәсенә Изгелекле күңеле белән килеп Хәсән Туфан татар гомуми рухи традициясенә тугры кала кебек. Аның күңеленә абстракт системалардан

бигрәк яшәеш гүзәллеген тою хастыр. Ул нинди генә катлаулылыклар, авырлыклар, корбаннар булуга карамастан үзен әйләндереп алган тормышның чәчәк атуын күрә. Ул табигатьтәге, дөньядагы тормышның гүзәллеген аның мәхәббәт хисенә нигезләнгәндә генә яшәячәген тоя төсле. Бәлки, шуның өчендер, Туфан шигырьләренә ниндидер бер йомшаклык, кешелеклелек, яхшылык хас... Башкача булса Мәхәббәткә нигезләнгән тормыш, димәк, гүзәл тормыш кире кагылыр иде. Бу яхшылык хәтта Туфанның сыйнфый көрәш, коммунистик идеология белән бәйләнешле шигырьләрендә дә күзгә бәрелә...

Аның шигырьләрендә Такташтагы төсле динне сүгү, кимсетергә теләү юк. Туфан бары тик изгелек хисен коммунистик идеологиягә күчерә... Ул бу идеологиядә гаделлекне, изге һәм саф хисләрне, төшенчәләрне саклый алган бер көч күреп ала кебек. Башка очракта аның яхшылыкка, матурлыкка, изгелеккә омтылган «мин»е коммунистик идеологияне кабул итәр идеме икән?!.. Коммунистик идеология аның өчен кимсетелгәннәрне, яхшыларны, сафларны, акыллыларны, хезмәт сөючеләрне һәм гүзәл табигатьне, тормышны яклаучы, саклаучы кебек күз алдына килеп баса. Мәсәлән:

Хәбәр итеп килә һәр яңа көн
Ленин юлы мәңге икәнне,
Дөньядагы бөтен яктылыкны
Яшәтергә көче житкәнне.

яки:

Жирдә яз... таллар исе...
Һавада кошлар өне...
Кай елда иде икән
Гомернең шушы көне?..

«Ленин»,—дип беренче кат
Кем әйтте? Әни микән?

Апрельнең үземе соң,
Тургае әйтте микән?..

«Киләчәк көннән сиңа
Сәлам бул»,—дигән кебек,
Бу сүзне синме, кояш,
Кичерден нурга төреп?..

Туфан өчен Ленин, Октябрь, коммунизм изге сүзләр булып кала. Ул аларда тормышның изге көчләрен күрә... Ә бу шагыйрь өчен барыннан да мөһим. Чөнки, шагыйрьләр һәрвакыт үзләре изге дип тойган нәрсәләргә хезмәт итәргә омтылганнар... Туфанның да саф ихласлыгына шикләнергә урын юктыр...

Әйе, Туфан үз шигъриятендә гүзәллеккә, сафлыкка, кешелеклеккә баш ия. Кайбер вакыт бу үзенчәлекле Дон-Кихотлык булып та тоела. Чөнки, дөньяда изге нәрсәләрне яклап чыгу жиңел эш түгел. Әмма, кеше үз күңелендәге «Илаһи очкынга» тугры калырга тиештер бит? Туфанның «Кер чайкыйлар кызлар» төсле шигырьләрендә без әнә шундый тугры калуны күрәбез.

Әйе, Хәсән Туфан шигърияте үзенең кешелеклеге белән күңелгә кереп кала. Тормышта да Туфан шундый ук олы жанлы булган диләр. Димәк, аның күңеле шигъриятьтә ихлас чагылган...

Әйе, Туфан материалист шагыйрьдән бигрәк, идеалистик юнәлешле шагыйрь булып күз алдына килеп баса. Бу шагыйрь зур игътибар күрсәткән рухи кыйммәтләр белән, романтиклык белән бәйләнгән. Туфан үз шигъриятендә күбрәк матди кыйммәтләргә түгел, ә рухи кыйммәтләргә игътибар бирә. Шуның белән ул үзе дә сизмичә Рухны Матдәдән алда куя, шигырьләрендә сафлыкка, гаделлеккә, матурлыкка чакыру көчле. Аның ижатында табигатькә баш ию, аның жанлылыгын сизү көчле. Аның әсәрләрендә рухның, жанның, күңелнең мөһимлеген, кыйммәтен тою көчле... Аңарда Мәңгелек Яшәеш турында хыяллану бар...

Шуңа күрә, Туфанның фәлсәфи шигърияте матдиятлелек фәлсәфәсенә генә кайтып кала алмый. Аның шигърияте—шагыйрьнең үзе дә сизмичә илаһи эзләнүе. Ул—матдиятлелек идеясе белән килешергә теләмәгән Мәңгелек жан тавышы.

**Илшат ВӘЛИУЛЛА,**
*Волжск шәһәре*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Рецензияләр конкурсы*

## ТӘКЪДИРДӘН УЗЫП БУЛМАГАЧ...

Әдәбият сөючеләрне, гомумән укучыларны, язылган әсәрнең иң элек тормышчан булуы кызыксындыра. Әдәби әсәр узган яки гамәли тормышны дөрес чагылдыра икән—ул романмы, повестьмы яки хикәяме—укучыны үзенә җәлеп итә.

Моңа кадәр хикәяләре һәм повестьлары белән танылган Марат Әмирхановның «Тәкъдир» романы *(«Казан утлары» 10, 11 саннар, 1999)* әдәбият сөючеләрне битараф калдырмагандыр.

Романда коммунистлар партиясе хакимлек иткән җитмешенче еллардагы вакыйгалар тасвирланган. Автор үзе ул елларда Бөгелмә районы Карабаш урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән һәм укыту эшләре буенча җаваплы хезмәт башкарган. Шунлыктан мәктәп тормышы, укытучылар арасындагы мөнәсәбәтләр әсәрдә дөрес чагылыш тапкан.

Әсәрнең сюжеты артык катлаулы түгел. Биредә төп геройлар Мансур белән Җәмилә—егет һәм кыз—соңрак өйләнешеп, матур гына гаилә тормышы коралар, уртак шатлыклары булып кызлары туа. Ләйсән—чибәр, тере кыз—гаиләгә бәхет, нур өсти, әтисенең, әнисенең тормышлары, яшәешләре тагы да күңеллерәк, тулырак булып китә.

Тик шунсы кызганыч: тормыш гел күңелле көннәрдән генә тормый. Гомумән, бәхетле гаиләләрнең аз булуы һәрберебезгә мәгълүм. Соңгы елларда бигрәк тә.

Балаларның үз милләтенә тугры булырлык тәрбия алуларында аналарның роле турында Мансур урта мәктәп укытучылары алдында чыгышлар ясый. Әмма аның фикерләрен хуплаучы табылмый. Алай гына да түгел: укыту мәшәкатьләре, җәмәгатьчелек эшләре алып барган Мансур төннәрен йокламыйча тәрбия темасына багышланган диссертациясен дә тәмамлый. Ләкин җитәкчесе Габбас Ярмиевнең берүк теманы ике кешегә бирүе нәтиҗәсендә Мансурга үз хезмәтен яклап чыгарга мөмкинлек бирмиләр. Ярмиев үзе инде институттан киткән, аны пенсиягә озатканнар. Яшь укытучы Мансурның күпьеллык хезмәте шулай юкка чыга.

Күп мәшәкатьләр чигеп тә фәнни исем алудан кинәт кенә өметен өзгән Мансур институттан чайкала-чайкала чыгып киймага сөяләә, аннан соң аякларын көчкә өстерәп урам буйлап китә. Бераздан милиционерлар аны исерек иргә хисаплап «кара козгын» машинасына төрткәләп кертәләр һәм айныткычка китереп ябып та куялар.

Мансур бер гаепсезгә алкашлар янына килеп эләгүенә бик кайгыра, үртәләнә һәм гарьләнә. «Әгәр мәктәпкә аның айныткычка эләгүе турында белешмә килеп төшсәме? Юк, асылынып үлүең хәерлерәк. Болай да бөтен планнарының асты өскә килде. Инде әлкәш дигән даны чыксынмы?»—дип төшенкелеккә бирелә ул.

Әйе, менә шундый хәсрәтле уйлар кичерә Мансур һәм соңрак хатыны

Җәмилә, кызы Ләйсән хакына, үзенең абруе өчен көрәшергә тиешлеген күңеленә беркетә.

Ләкин әсәрнең бу урыны укучы буларак миндә каршылыклы фикерләр уятты. Хәзерләгән диссертациясенең юкка чыгуы Мансур өчен көтелмәгән хәл буларак аңа бик нык тискәре йогынты ясый, тетрәндерә, ди. Әмма ләкин яшь кенә ирнең аңын югалтыр дәрәҗәгә җитеп, трамвай юлына кереп адашып йөрүен күңел кабул итми. Ике милиционерның Мансурны эткәләп-төрткәләп машинага утыртып алып китүләре дә ышандырып бетерми. Милиционерлар әдәбиятта күп мәртәбә тупас итеп күрсәтелсәләр дә, алар исерек белән айнык кешене аера беләләр ич! Әлеге хәлнең көпә-көндез булуы да әсәрнең ышандыру көчен киметә. Һәрбер әдәби әсәрдә ышандыру көченең эзлекле дәвам итүе— иң әһәмиятле шарт икәнен минемчә беркем дә онытмаска тиеш.

Матур башланган гаилә тормышын бик күп кыенлыклар сагалап тора. Нишләмәк кирәк, мондый хәлләр еш кабатлана шул. Алты яшьлек кызлары Ләйсәннең яман шеш белән авырып вафат булуы, бу чирдән кызларын коткарып кала алмауларын, зур кайгы килүен автор ышандырырлык итеп тасвирлаган. Автор Ләйсәннең балаларга хас сөйләшүен дөрес тоемлап, сөйләм үзенчәлекләрен табигый итеп биргән.

Мансурны тормыш төрле яклап сыный. Ул Кормаш урта мәктәбендә укытучы, завуч, Чаллыда мәктәп директоры, күп тә үтми язмыш аны Казанга «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенә китерә, биредә дә ул югалып калмый, кыенлыкларны җиңеп абруйлы журналистларның берсенә әйләнә. Җәмилә дә Казан шәһәренә бик теләп күчә һәм үз һөнәре—укытучы хезмәтен дәвам итә. Әмма аларга җиңел түгел, чит кеше йортында фатирчы булып яшиләр.

...Менә журналист Мансур өлкә комитетының фән бүлеге мөдире урынбасары янына керә. Анда Мансурның элекке танышы Сафа бик эре кыяфәттә утыра, вәкарь белән генә сөйләшә. Мансурның: «Әллә син мине танымыйсыңмы?» дигән соравына Сафа: «Мансур иптәш, без агай-энеләр белән ресторанда утырмыйбыз. Бу—Обком! Монда фәкать эш турында гына сөйләшәләр» дип үзенең чын бюрократка әйләнүен күрсәтә. Автор ул вакытларда галимнәрнең кимсетелүен шул Сафа сүзләре белән хәзерге буын кешеләренә бик үтемле итеп җиткерә. «Мөштәри, Камай ише милләтчеләргә без партия матбугатында урын бирә алмыйбыз!»—ди тагын әлеге түрә.

Әйе, ул елларда безнең талантлы әдәбият-сәнгать әһелләре дә, галимголәмә дә коммунистлар партиясенең урынсызга басым ясаулары, чикләүләре астында яшәп, үзләренең иҗади мөмкинлекләрен күрсәтә алмадылар шул.

Автор Мансурны яхшы укытучы, булдыклы журналист итеп сурәтли. Гаиләдә дә аны үрнәк ир һәм ата итеп күзалларга мөмкин булыр иде. Әмма, дүрт аяклы ат та абына дигәндәй, автор аны җайлап кына «уҗымга» кертеп җибәрә. «Уҗым» дигәнебез исә—Рәшидә. Җәмиләнең бертуган сеңлесе, Мансурның балдызы.

Безнең татар халкында җизнәй булган кешеләрнең үз балдызларын яратулары булгалаган. «Балдыз сөю язык түгел җизнәкәй» дип җырлыйлар да... Автор шушы урында: «Җизни, синнән күңелем бизми», «Балдыз булыр балдай» кебек мәкаль, әйтемнәрне бик урынлы куллана. Әлеге гыйбарәләрне исенә төшергән Мансур: «Балдыз сөю татарда гаеп саналмый ләбаса» дип, хатыны Җәмилә каршында аклану өчен дәлилләр табылуына куана да.

Рәшидә дә «ирем Айдарны яратмыйм» дип, үз күңеленең җизнәсенә тартылуын гөнаһка санамый. Җизнәсен: «Айдар командировкада, Илсур кунакта, аулагөй, җизнәкәй» дип шатланып каршы ала. Рәшидәнең шәрә балтырлары, изүенең ачылып киткәләве Мансурны вәсвәсәле уйларга этәрә һәм ул Рәшидә чибәрнең җәтмәсенә эләгүен сизми дә кала. Шампан, коньяк шәрабларын парлап бер-бер артлы күтәрү, җыр, бию, уен-көлке, мәзәк сүзләр... Шунда Рәшидә «Җизнәкәй башым әйләнә» дип Мансурның алдына ава, гыйшык-мыйшык, мәхәббәт уеннары башлана...

Әмма биредә аянычы шул: Мансур авыру хатынының, чирле кызының хәлләренә кереп, хәсрәтләнеп йөрер чагында ваемсыз һәм гамьсез рәвештә гаиләсен оныта, балдызы белән мәхәббәт уены уйный.

Егет белән кыз кебек очрашу сәгатьләре билгели-билгели алар кабат-кабат очрашалар, ресторанда утырулар да дәвам итә. Ә авыру апасы Җәмилә каршында Рәшидә үзен аз гына да гаепле санамый. «Безгә никах укытырга кирәк, Мансур! Ходай каршында ир белән хатын булыйк», дип Рәшидә үзенең оятсыз тәкъдимен әйтергә дә кыенсынмый.

Әмма ир буларак бу минутларда Мансурда акыл көче өстенлек ала, ул Рәшидәне читкә этеп җибәрә. Тик, бик тә үҗәт, әрсез балдыз «апаның гомере санаулы, Лэйсәнгә миннән дә яхшы ана булмас» дип мәлҗерәп төшкән Мансурны үзенең тәкъдименә күндерә. Һәм алар Мансурның хатыны Җәмилә исән килеш Кабан күле буенда яшәүче мулла бабакайга барып никах укыталар. Автор сүзләре белән әйткәндә: «Мансурның аңлашуы никах белән тәгәлләнде.» Ә безнең, укучыларның, бу никахка күңеле риза түгел. Әдәби әсәрнең ышандыру көче менә шушы урында бик кими. Мансур—житди укытучы, тәрбияче, дөреслекне алга сөрүче көчле журналист. Аның авыру хатыны Җәмилә янында яшәгәндә үк балдызы белән никах укытуы тормыш, гаилә кысаларына хәзер дә сыймый, җитмешенче елларда исә бигрәк тә сыймый иде.

Алда язганымча Рәшидә «никахлашыйк» дигәч, Мансур аны этеп җибәрә. Менә шушы хәлдә Мансур ике арадагы мәхәббәт маҗараларын өзгән булса, әсәр тормышчан булып калыр һәм бу вакыйгалар укучыны ныграк ышандырыр иде.

Инде әсәрнең теленә килсәк—авылда туып үскән, урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булган әдипнең теле йөгерек, әсәр җиңел укыла. Романда урыны белән чигенешләр ясала, төрле тарихи белешмәләр китерү дә әсәрне тагы тулыландыра. Кормаш авылы турында язганда автор хәзерге Карабаш эшчеләр бистәсен күз алдында тота. Узган гасырларда Уфа, Оренбург якларына йөрүче сәүдәгәрләр Карабаш авылында атларын ашатып, кунып йөргәннәр. Шуңа күрә, юллар чатында торган Карабаш—бай тарихлы авылларның берсе.

Әсәрдә катнашучы геройлар һәм персонажлар шактый күп. Әмма аларның барсы да кирәк микән? Әсәрне эзлекле рәвештә алып баруда аларның тискәре йогынтысы сизелә.

Чәчмә әсәрләрнең ышандыру көчен арттыруда чагыштырулар, һичшиксез, уңай роль уйный. Күп еллар буе татар язучыларының әдәби әсәрләрен даими укып баручы буларак мин шуны сизәм: чагыштырулар хәзерге язучыларның кайберләрендә артык еш кулланыла. Әмма бу авторны мин андыйлар арасына кертергә теләмим.

«Бәбкәләрен саклаган ата каз шикелле галимнең муены алга сузылды.» «Кытайларныкы сыман кысык күзләре тегәрҗеп калынлыгында гына калды.» «Йортка кергәнче утка кер икән!» Менә болар—мәгънәле чагыштырулар һәм халкыбыз арасында киң таралган, дөрес әйтелгән гыйбарәләр! Әйе, мондый чагыштырулар, мәкаль, әйтемнәр романда күп очрый. Димәк автор халкыбызның фольклорын, мәгънәле гыйбарәләрен күңелендә саклый һәм әдәби әсәрнең кирәк урынында куллана белә. Ләкин, сирәк булса да, урынлы булмаган чагыштырулар очравы күңелдә канәгатьсезлек хисләре тудыра.

Төп геройның алда язылган фән бүлеге мөдире урынбасары белән әңгәмәсе вакытында автор: «Сафа уңган бала чүпрәгедәй төссез керфекләрен җилпештереп, Мансурга текәлде.» — дип яза. Үткен чагыштыру булсын өчен автор аны шулай итеп язган. Әмма уңган бала (?) чүпрәген төссез керфекләр белән чагыштыруны уңышлы дип кем әйтә алыр икән?

Шактый озынга сузылган бу романның азагы ничектер тиз тәмамлана. Автор аны: «Җәмилә Лэйсәннең елын үткәрә алмады. Тагын алты айдан баш очындагы Тума кошның канатлары киселеп төште. Тәкъдир аны кызы хозурына иңдерде» — дип тәгәлли.

Кызлары Лэйсәнне җирләгәч Мансурның Җәмилә белән алты ай дәвам иткән тормышын әсәрдә укучы күрә алмый. Мансурның Рәшидә белән никахы да бар бит әле, аларның ике арадагы мөнәсәбәтләре ничек дәвам иткән?!

Лэйсәннең үлемен әнисе Җәмилә дә, әтисе Мансур да бик авыр кичерә. Моңсы табигый хәл, мондый авыр кайгыга дучар булган ата-ананың

кичерешләре җиңел булмавын һәркем күз алдына китерә ала. Шулай да, танышларына, дусларына мөрәҗәгать иткән сыман «бәхил булыгыз» дип үзләренә-үзләре кул салырга җыенулары турында язу күңелдә ризасызлык тудыра.

Аерым гаиләләрдә җиткән егетләрнең, кызларның төрле фаҗигаләргә элэгеп, көтмәгәндә үлемгә дучар булуларын еш ишетәбез. Әмма ата-аналар бердәм булып зур кайгы-хәсрәтләрне бергәләп уздыралар, бик авыр булса да үзләренә кул салып фани дөньядан китмиләр. Мансур белән Җәмиләне бу фаҗигадән Галим белән Лилия килеп коткара. Алар килеп кермәсә нәрсә булыр иде?

Җәмиләнең яман шеш белән чирләп, авыр хәлдә яткан соңгы көннәре ничек узды икән? Ни кызганыч, әсәрдә бу мизгелләр тасвирланмаган...

Мансур авыру хатынының ятагы кырына утырып, яраткан Җәмиләсенең күзләренә карап соңгы сүзләрен әйтүен, бу минутта нәрсәләр кичерүен автор тетрәндергеч итеп язган булса, шушы гомерлеккә аерылышу алдындагы ир белән хатынның халәтен укучылар, бигрәк тә хатын-кызлар, йөрәкләренә якын кабул итәрләр, аларның күзләре яшьләнер һәм әдәби әсәрнең уңышы тагы да югарырак булыр иде.

Берничә сүз белән йомгаклаганда, Марат Әмирханов кызыксынып укырлык роман иҗат иткән, алда язылачак әсәрләре тагы да тормышчан, уңышлы булыр дигән өметтә калабыз.

Сәлах **ШӘРИПОВ**,
*Бөгелмә*

# АСЫЛЫБЫЗГА КАЙТУ

Хәзерге татар повестьлары арасында милли үзаң—милләтенне бөтен тирәнлеге белән аңлау, ярату, яклау, ихтирам итү, туган теленне, гореф-гадәтләренне, диненне чын-чынлап белү хисе тәрбияләүче һәм асылыбызга кайтырга, ягъни милләтне милләт итеп танытkан әби-бабайларыбызның йолаларына, тамырларына, нигезенә, теленә хөрмәт белән карарга чакырганнары да булу куандыра. Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәнис Яруллинның «Кайту» повесте *(Яруллин Ф. Сайланма әсәрләр, III томда. I т.: Повестьлар, кереш сүз.—Казан: «Мирас» кит. нәшр., 1994.—616 бит.)* шундый әсәрләрнең берсе. Бик тәэсирле итеп язылган бу повестьта каршылыклы чорыбызның катлаулы күренешләре үзенчәлекле рәвештә тасвирлана. Әсәрнең вакыйгалары үзәгенә хәзерге армия хезмәтендә үзләренең берданбер улларын югалткан ата-ананың ачы хәсрәте, тормышта булган чын хәл алынган. Үлгән Олег Шәйхетдиновның әти-әнисе Баулы районының Кызылъяр авылында туган. Әтисе—хәзер отставкадагы полковник, әнисе—шулай ук лаеклы ялда.

«Хәрби хезмәтен үтәгәндә 22 яшендә һәлак булган лейтенант Олег Шәйхетдиновка багышлыйм бу әсәремне»,—дип башлый автор. Аннары язучы атасының улына язган мөрәҗәгатен укучы игътибарына тәкъдим итә. Гомумән, кем соң ул—үлгән егетнең әтисе Фәрит Шәйхиев?

Күп балалы гаиләдә туып үскән ул. Балачагы мохтаҗлыкта узган. Иртән торуга гаиләдәге һәр кешене бер уй борчый: бүген нәрсә ашарга? Әтисе Миннетдин абзый балта остасы була. Туган авылында матур-матур йортлар, мунчалар сала, мич чыгара,

тегү тегә, сугым суя. Фәритнең әнисе дә бик тырыш: колхозда эшли, бригадир нинди эшкә кушса, шунда чаба.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Фәрит Саратов хәрби училищесына укырга керә. Өч елдан соң офицер киемнәрен киеп, иннәренә лейтенант погоннары тагып, туган авылына кайта.

Повесть геройлары Фәрит белән Халисә үткән заман авылының матур бер кичәсендә бер-берсенә гашыйк булалар. Ике ел хат алышалар һәм кавышалар. Бик тату яшиләр. Яшь гаиләдә көтеп алынган малай туа. «Малай ул шатлык кына түгел, бик зур горурлык та,—ди автор.—Малае юк атага кешеләр, ничектер, кимсетебрәк карачан. Хәрбиләр арасында бу нәрсә аеруча нык сизелә. Монда бөтен нәрсә Ватан язмышы белән үлчәнә. Ә Ватанның язмышы малайлар, ягъни булачак солдатлар кулында.»

Фәрит тә улының хәрби кеше булуын тели. «...Менә син ай үсәсен көн үсеп, әтиең кебек командир булырсың, шулаймы?»—ди ул. Улына үзе үк аңлы рәвештә урыс исеме куша. Шул рәвешчә, аны теленнән, милләтеннән, гореф-гадәтләреннән аера. Пермь шәһәрендә туган кара кашлы, кара чәчле, ачык зәңгәр күзле бу бала малай чагын хәрби шәһәрчектә үткәрә. Шулай итеп, гаиләсендә туган бу малай бишегеннән төшүгә үк солдатка әверелә. Уенчыкларның һәммәсе дә үтерү коралы: пистолет, автомат, пулемет, танк, самолет. Әтисе аны иртән «подъем» дип уята, «отбой» дип яткыра. Олег, әтисеннән үрнәк алып, һәркөн салкын су белән юына. Кыш көне алар, урамга чыгып, тәннәрен кар белән ышкыйлар, йөгерәләр, сикерәләр. Укырга кергән елны әтисе улына туган көненә пневматик пистолет бүләк итә. Үсә төшкәч аңа чын мылтык, чын автомат тотарга рөхсәт итә башлыйлар.

Кыскасы, Олег инде үзен хәрби тормыштан башка күз алдына да китерә алмый. Шуңа күрә ул, сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Свердловск шәһәрендәге Суворов училищесына укырга керә. Укуы җиңел булмый, казармада катгый режим. «Подъем белән торасың, отбой белән ятасың»,—дип яза Олег сөйгән кызы Маринага. Иртән торгач, йөгереп кайтулар, салкын су белән юынулар, хәлдән тайганчы спорт белән шөгыльләнүләр, дәресләр 15 яшьлек үсмер егет өчен җиңел булмый, әлбәттә. Начар укырга, «2» ле алырга ярамый. Әтисе аңа һәрвакыт: «Булачак офицер армия тормышының барлык авырлыкларын белергә тиеш»,—дип тукып тора. Аннары Олег Чиләбедәге югары танк училищесын тәмамлый, лейтенант була һәм аны Әрмәнстандагы Кировакан шәһәренә хезмәт итәргә җибәрәләр. Әмма биредә, хәрби хезмәттә, Олег тәртипсезлек, гаделсезлек, икейөзлелек, башбаштаклык белән күзгә-күз очраша. Җыелышта ул гаделсезлеккә каршы чыгыш ясый: «Бу җәһәннәм оясын күптән туздырырга вакыт иде инде. Без кайда? Совет Армиясендәме, әллә һәркем үз оясына нәрсәдер урлап ташучы диюләр патшалыгындамы? Өлкән командирлар кешеләрнең гомере бәрабәренә байлык җыя. Кече командирлар эчә. Полкта дедовщина. Беркем бернигә дә җавап бирми. Ә иң яман үрнәкне полк командиры үзе күрсәтә...»

Шулай итеп, Олег, үзе дә сизмәстән, Совет империясе армиясендәге дөреслекне ачып сала. Командирлар, фаш ителүдән куркып, аны юлдан алып ташлыйлар. Бозлавык көнне төзек булмаган машинага утыртып, йөк алып кайтырга станциягә җибәрәләр, янына ялланган үтерүчене утырталар. Ул Олегның башына тимер белән китереп суга. Чәчәктәй гомер әнә шулай өзелә.

Менә шушы хәлләрдән соң Олегның әтисе уйлана, үз хаталарын аңлый башлый. «Улым! Дошманнарыбыздан үч ала алмавым өчен мин синең алда бик гаепле. Ләкин мин, кулдан килгәнчә, тырышып карадым, хәтта президентка, оборона министрына хатлар яздым. Ләкин аларда кеше кайгысы булмаган икән. Моны үзебез табынган уртак Ватан таркалгач кына белдек. Кеше кадере юк илдә дөреслек була алмый икән. Мин шуны аңладым.»

Әйе, майор Шәйхиев үзе гадел, бик тырыш, намуслы, патриот кеше. Аның өчен иң изге нәрсә—Ватанга хезмәт итү, илгә тугрылык. Ул армия тормышы белән яши-яши Ватан һәм намус төшенчәсен янәшә куярга өйрәнгән. Шул ук вакытта ул—маңкорт, ягъни теленнән, диненнән, үз халкыннан аерылган зат. Дөньяда явызлык, мәкер дә барлыгын әйтеп тәрбияләмәгәннәр аны. Шәйхиев улын да үзе кебек гомерлек армия хезмәтенә әзерли. Ләкин югарыда күреп үткән олы фаҗигадән соң нык үзгәрә. Моның өчен кешегә ике зур югалту кичерергә кирәк булган икән:

улын, Ватанын югалту кирәк булган!

Шәйхиевнең манкортка әйләнүендә зур гаеп, һичшиксез, совет дәүләтенең милли сәясәтендә. Бу сәясәт «татар» исеменнән курку, хурлану хисен дистә еллар дәвамында халык аңына сеңдереп килде. «Менә мин үземнән генә алам. Татар авылында татар мәктәбе бетергән килеш хәрби училищега килеп кердем. Русчага күчү бик рәхәт булды дисеңме миңа? Белгән әйберенне дә сөйләп бирә алмый интегәсең. Ялгыш ычкынган сүзеңнән көләргә торалар. Кыскасы шул, әнкәсе, балага татар исеме кушмыйбыз. Бу татар авылы түгел. Хәрбиләр шәһәрчеге. Монда кешенең милләте юк.

—Милләтсез кеше буламыни?—диде Халисә.

—Милләт дип үзеннең үлеп бара торган гореф-гадәтләренә ябышып яту искелек калдыгы гына. Без коммунизмда яшисе кешеләр. Коммунизмда кешеләр бары тик Ленин телендә генә сөйләшәчәкләр.»

Хатыны Халисә иренә каршы килеп, баласын телсез, милләтсез калдырырга теләми. Ләкин ул, ата-баба йолаларын сакларга тырышып караса да, үз позициясендә тора алмый.

Ни өчен повесть «Кайту» дип атала? Чөнки Шәйхиев үз тамырына, асылына, ата-бабаларның гореф-гадәтенә, теленә, иленә авыр кичерешләр, олы корбаннар аша кайта. Аның милли үзаны уяна башлый.

«Соң булса да уң булсын дип, инде менә бабаларың янына алып кайтам. Читят туфракларда сөякләрең рәнжеп ятмасын. Үзебезнең йолаларыбыз белән догалар укып чын мөселманча итеп җирләячәкбез сине. Кешеләр исән чакта гына түгел, үлгәч тә үзенең нәсел-нәсәбенә якын булырга тиешләр. Шунда гына аларның җаннары тынычлык табачак. Ә җан барлыгына мин хәзер ышана башладым, улым... Бүген мин кайчандыр үзем ераклашкан нәрсәләргә якынаю сизәм. Үткәннәремә, тамырыма, асылыма кайтам. Бу бик авыр кайту, әлбәттә. Чөнки мин моны сине югалту бәрабәренә таптым»—дип уйлана ахырда әсәрнең төп герое.

Шулай итеп, язучы Ватан, армиядәге тәртипсезлекләр, аның эчтән җимерелүе, милли гореф-гадәтләр, йолаларның, милләтнең юкка чыгуы, татарларның маңкортлашуы кебек проблемаларны күтәрә һәм аларны укучыга зур тәэсир ясарлык итеп яктырта.

«Әйдәгез, барыбыз да үзебезнең асылыбызга кайтыйк, милләтебез өчен тырышыйк! Татар халкы белән горурланырга кирәк!»—дип чаң суга әсәр авторы Фәнис Яруллин. Повестьның актуальлеге әнә шунда.

**Илһам ФӘТТАХ,**
*Казан дәүләт университеты аспиранты*

*Сәнгать*

# МӘХӘББӘТ–БЕР ГЕНӘ!

Тамашачы, артистка Наилә Гәрәеваны сәхнәдә беренче тапкыр күргәндә үк, ана гашыйк булды. Дөрес, театр сәнгатенә бәя бирүчеләрнең фикере төрлечәрәк иде. Берәүләр Наиләне турыдан-туры Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим итү ягын алдылар, икенчеләре исә яп-яшь артистканы, татар телен камил белмәүдә гаепләп, аны сәхнәдән читләштерү таләпләре белән чыктылар. Тик бер хакыйкать кенә бүйсынмас хәлдә иде—беренче мәртәбә сәхнәгә аяк баскан Наилә Гәрәева һәръяклап игътибарга лаек шәхес иде. Бусы инде бәхәссез чынбарлык. Баш ватыгыз! Шәпме бу артистка, нинди кимчелекләре бармы—үзегез хәл итегез! Әмма ул бар иде инде! Аны, аның иҗатын беркая да яшереп калдырып булмый иде инде! Наилә Гәрәева дигән артистка бар иде!



*Наилә Гәрәева*

1960 *ел иде бу*. Камал театрының «йокымсырабрак» яшәгән дәвере. Ник, дигәндә, сәбәпләрне күп китерергә мөмкин булыр иде. Әмма иң мөһиме—иҗади коллектив шактый олыгайган: 17-18 яшьлек кызлар ролендә 50-60 яшьлек ханымнар уйнап йөри. Елыйсы урында көлеп, көләсе җирдә елап утырасың. Дөрес, яшь кадрлар әзерләнеп ята: Мәскәүнең Щепкин исемендәге студиясендә дә, үзебезнең театр училищесында да өр-яңа талант ияләре укыйлар иде. Әмма театр, бигрәк тә тамашачы уку елларын көтеп утыра алмый, аңа тамаша кирәк лабаса!

Артистлар сәхнәгә күп төрле юллар белән килеп керә. Гасыр башында, театрыбызның беренче адымнарында, кызлар ролендә уйнаучыларны табу аеруча кыен булган. Мина мәшһүр Фатыйма Ильская үзе сөйләгән иде:

—Мине бит тамаша карарга барган җиремнән алып калдылар... Театрны яратуымны сизгәннәр дә, тотындылар димләргә... Имеш, минем кыяфәтем дә шәп, күзләрем дә мәгънәле карый. Шулай үгетләп күндылар, рәхмәт төшкерләре!..

Икенче берәүләр һәвәскәр түгәрәкләрдән килеп кергән, башкалары, үзләре дә көтмәгәнчә, бөтен уку йортына «эләгә» алмыйча, театр институтына укырга барган да таланты дигәне шунда ачылган. Хәтта театр институтын тәмамлаганнан соң да сәхнәне ташлап китүчеләр бар. Кыскасы, сәхнә йолдызларыбызның язмышы күптөрле. Наилә Гәрәева исә үзе кичергәннәр турында бөтенләй башкача сөйли:

—Минем бит башка барыр юлым юк иде,—ди ул бик гади генә иттереп.—Мин башка һөнәр турында уйлый да алмадым, моңа минем вакытым да юк иде...

Бөтен хикмәт шунда ки, бу гаилә башлыклары—Хәким абый белән Рәуан ханым өйдә матурлыкка соклану даирәсе тудыра алганнар. Балаларны тәрбияләүдәге бөтен максат бер генә юнәлешкә буйсындырылган: балалар дөньяның матур ягын таный белсеннәр! Калганы—кечкенә мәсьәлә—тамак кайгысы да, өс-баш бүлдыру да, байлык туплау да—барысы да иң арткы якка куелган. Наилә кеп-кечкенә чагыннан ук шул хакыйкатькә мөкиббән китеп яши башлаган. Аның күз алдында абыйсы скрипкачы

булып өлгергән, апасы музыка мәктәбенә йөргән. Наиләне исә, курчактай нәп-нәни Наиләне өйдәге артисткага әйләндергәннәр. Гаиләгә берәр кунак килеп кердеме, беренче тамаша итеп Наиләдән шигырь сөйләткәннәр, җырлатканнар аны, биетеп тә караганнар. Кул чапканнар, сөендергәннәр баланы.

Аннары, инде үзен-үзе белештереп алгач, Наилә Гәрәева Казанның пионерлар сараена йөрергә тотынган. Монда ул катнашмаган бер генә түгәрәк тә калмаган. Кызчык төрледән-төрле ярышларга да катнашкан, откан да оттырган да. Шул яшендә ук сәхнә хезмәтенең татлы якларын гына түгел, «җинелү» кебек ачы җимешләрен дә татыган ул. Шулай да аның шул балалык елларында ук җину дигәне алдарак йөргән. Аны Татарстан радиосының балалар өчен оештырылган тапшыруларын алып барырга чакырганнар. Монда инде—сәхрә! Кыз үзе теләгән дәрьяда колачлап йөзгән.

Гаиләдә исә балаларны шул әүвәлге рәвештә тәрбияләү дәвам иткән. Үзе дә үзәкләрне өзләреп җырлаучы Рауан ханым һәм сәнгать дөньясындагы күп шәхесләр белән якыннан таныш булган ата кеше өйне кечкенә генә сәнгать дөньясына әйләндергәннәр. Хәким әфәнде Фәйзи Йосыпов, Хәким Сәлимҗанов белән һәрчак аралашып яшәгән. Камал театрында ату тавышы чыгара торган көрәнеш кирәксә, һәрчак Хәким агага мөрәҗәгать итә торган булганнар. Ул төп эше буенча ату кораллары белән эш иткән икән. Әмма...

—Безнең өйдә бер язу өстәле бар иде. Бөтенебезгә—шул бер инде ул. Хикмәт анда түгел. Ул өстәлгә утыру белән күз каршы якта гы диварга текәлеп кала. Анда исә—төрледән-төрле сурәтләр. Бер рәттә—дөньяның мәшһүр артистлары, икенчесендә—язучылар, аннары—галимнәр. Әти дә, әни дә безгә аларның кем икәнлекләрен, нинди иҗат итүләрен сөйлиләр. Без бу хакта яттан белә башлаганчы... Арада, әлбәттә, Һади Такташ, Габдулла Тукай рәсемнәре аерым урын алып тора иде. Тик...

Наилә ханымның бу сүзләрне «тик» дип түгәрәкләве шуна бәйле—өйдә күбесенчә урыс телендә генә сөйләшәләр. «Татарча белән генә ерак китеп булмый хәзер!»—ди Рауан ханым.

—Әнием минем белән бер генә тапкыр да татарча сөйләшмәде... Ярый әле дәү әни бар иде! Ул урысча бер авыз сүз дә ычкындырмый торган иде. Алгарак китеп булса да әйтим, минем татар артистлары әзерли торган училищега кергәнемне ишеткәч, дәү әнием озак иттереп, кеткелдәп көлде: «И-и, синнән нинди татар артисты чыксын: бер авыз татарча сүз белмисен бит син!?»—диде...

Дәү әнисенең «кирелеге»нә җавап йөзеннән диярсең, Наилә Гәрәева татар театр студиясенә укырга чакырыла. Дөрес, юл туры гына булып чыкмый. Аттестат алган кыз «күперенеп» Мәскәүгә ашкына әле. Рауан апа да каршы килми. Ул бу төпчек кызын кечкенәдән үк: «Син—артистка!»—дип тәгаенләп үстерә. Наилә урта мәктәпне тәмамлаган елны исә Мәскәүнең Щукин студиясенә ил буенча укучылар чакыралар. Наилә дә җыена. Мәскәү хәтле Мәскәүгә китәрлек булгач, әни кеше, кызын өстәл уртасына бастырып, өр-яңа ситсадан бик матур күлмәк тегәргә тәвәккәлли. «Солнце-клеш» дигән фасон бу, марҗалар «Ah!» итәрләр, ди-ди тегә ана бу күлмәкне. Шушы очып китәргә әзерләнгәндәй күлмәген киеп, Наилә, гомерендә беренче мәртәбә, Мәскәү каласына юл ала. Юк туганы, юк каршылаучысы, юк барып керер җире...

Әй тырыша, әй бөтен белгәннәрен күрсәтеп калырга ашыга кызыкай—юк, алмыйлар. Ә-әй, ул Мәскәүдә безнең Наиләләрне генә кире борганнармы соң? Хәтта сугышлардан йөреп кайткан Ефремовны да, урысның мәшһүр Ефремов дигән артистын да кабул итмәгәннәр бит анда. Курчак кебек татар кызына ни сан булсын, ди инде. «Иди, иди!—генә дигәннәр.—У вас там есть свои учебные заведения...»

Ачуыннан чатнар хәлгә килгән Наиләкәй, очып торган «солнце-клеш» күлмәген киеп, Казанына кайтып сыена. Бәхетенә нәкъ шул елны Качалов театры да үзенә кирәкле бер төркем укучылар җыя икән. Анда Наиләне җинел кабул итәләр. Әмма бераздан, мәшһүр режиссерыбыз Ширияздан Сарымсаков белән Празат Исәнбәт кызны татар төркеменә чакырып алалар. Наилә анда Ирек Баһманов, Мансур Шиһапов, Рәсим Салахов кебек, бүген дә сәнгатебез дөньясына фидакарь хезмәт күрсәтүче шәхесләр арасына эләгә. Бусы—бер бәхет. Тик кешегә бәхете дә, кайгысы да аерым-аерым гына килми, диләр, хак икән. Икенче курста укыганда ук Наилә Гәрәеваны Камал театрында куелырга тиешле өр-яңа спектакльгә чакырып алалар.

Баш рольгә! Бу спектакль артистка язмышында—бәхет ачкычы. Пьеса авторы

да «ор-яңа» кеше—Хәй Вахит, режиссерның да бу—беренче эше, режиссер—Рәфкать Бикчәнтәев, Наилә Гәрәева да—бу олуг сәхнәгә беренче тапкыр аяк баса. Спектакльнең исеме дә—«Беренче мәхәббәт»...

Туры килсә дә килер икән! Минем уемча, «мәхәббәт» дигән бөек хис бернигә була алмый. Ул—йә бар, йә юк инде. Аны саннар белән санап азапланырга кирәкми. Аны Ходай бер бирсә—шөкер ит, юк икән—вәссәлам. Наилә Гәрәевага әнә шул бөек хис тәкъдир булып килгән. Мен шөкер! Шул спектакль бөтен татар тамашачысын аякка бастырды. Театр «йокысыннан» уянды. Гәрәева-Рәхиләне күрер өчен Татарстанның әллә кай якларыннан килә башладылар. Спектакль Тукай бүләгенә тәкъдим ителде. Бер төркем иҗат әһелләре аны алдылар, тик Наиләгә, «әле борыны кипмәгән» дигәнрәк, урынсыз бер сәбәп белән бу бүләк тәтемәде. Гәрчә спектакльнең төп уңышы шушы яңа артисткаының ифрат дәрәҗәдә шәп уйнавы аркасында килгән иде бит! Талантлы артисткасына, әле студент килеш үк шундый зур дәрәҗәдәге бүләкне бирсә, татар буламыни инде ул?!

—Спектаклҗгә дәү әнине дә алып бардым,—дип исенә төшерә Наилә. Әй мактый артистларны, әй мактый башкаларны. «Дәү әнием, ник минем уеным турында бер сүз дә әйтмисең?»—дим. Колә генә дәү әнием. Ярый, ди дә, тагын башкаларны мактарга тотына. «Татарча ныклап өйрәнәсең бар!»—дип тә төрттерә...

Ни бәхет—Наилә Гәрәеваның иң оста, иң үтемле тәнкыйтьчесе үзе янында яшәгән. Аның иң яраткан дәү әнисе булган. Менә бит ул гаилә тәрбиясе! Үз-үзенне белә башлаганнан бирле бер юнәлешкә тотылган тәрбия кешенең гомерлек шөкеренә барып тоташа. Әле нибары икенче курста гына укыганда тәкъдим ителгән Тукай бүләген Наилә барыбер алды бит ул. Театрга Мәскәүдән «щепкинчылар» кайтканчы инде тәмам буын ныгытып өлгергән Наиләгә бер-бер артлы зур-зур рольләр тапшырыла килде.

Гади тамашачы артистлар эшенә сокланып карый-карый да әйтеп куя:

—Әй рәхәт тә яшиләр инде!—ди.—Күрче, җитмеш-сиксән яшькә чаклы тамаша куеп йөриләр бит, ә!..

Наилә дә белә бу мөнәсәбәтне. Аңлатырга тырыша:

—Һай ул яңа рольне өйрәнә башлагандагы авырлыклар! Үз яшендәгерәк, үз холкындагырак образ «әлләксә»—бер хәл әле. Режиссер синнән сорап тормый бит ул. Мина, мәсәлән, үнҗиде-унсигез яшьлек авыл кызы Диләфрүзне уйнаганда, кырыгым якынлашып килә иде...



*«Беренче мәхәббәт» спектакленнән күренеш*

Актерга һич котелмәгән рольне бик еш бирәләр. Көннәр, атналар үтә—теге рольдәге «кеше» белән һич уртаклык таба алмыйсың. Сәхнә образы—бөтенләй башка кеше бит ул, ә актер тамашачыга шуны тасвирлап бирергә тиеш. Менә «Шәҗәрә»дәге Сәлимә ролен генә алып карыйк. Наилә ул образдагы кичерешләрне бөтенләй белми. Күрмәгән дә, татымаган да. Эчми дә, тартмый да ул. Инде сәхнәдә Наилә башкарган Сәлимәне күз алдына китерегез! Артистка бу бәхетсез җанны шул кадәр «җелегенә төшеп» сурәтләп бирә ки, Наилә белән Сәлимә арасында һич-нинди аерма да тоелмый. Гүя Наилә үзе төрмәләр юлын узган, гүя Наилә, чыннан да, эчеп кенә җанын баса ала, гүя Наилә урам хәерчеләре белән генә аралашып яши.

Минем бу урында артисткаының җитешсез якларына да бик тукталасым килгән иде—таба алмадым, валлаһи, таба алмадым. Күрәсең, ул бар эшен дә йөрәге аша

уздырып, бөтен барлыгын биреп башкара.

—Ай, ул роль алганнан соңгы беренче вакытларда бәргәләнүләрем! Образ белән үз холкым арасында нинди дә булса бер охшашлык, тәңгәллек табарга тырышам. Репетициягә барам, юк, режиссер һаман бер үк таләпне кычкыра: «Гәрәева! Гәрәева! Алай түгел, эзлә, тап!..» Ниһаять, акрынлап аңлый башлыйсың: «Менә бит! Үземдә дә шул ук хәлләр ич!..» Режиссер да башканы таләп итми башлый, хәтта кайчак: «Ярый, ярый, яхшы!»—дип тә куя әле. Аннары инде иң зур сынауга, тамашачы алдына чыгасың. Соңгы билге-бәя—аныкы. Берәр сүзеннән соң кул чабып та куйсалар, соңыннан чәчәк тә бирсәләр—артисттан да бәхетле зат юк кебек...



*«Гүзәлем Әсәл» спектаклендә—*
*Әсәл ролендә Н. Гәрәева*

Алар арасында татар классикасы да, хәзерге заман татар драматургиясе үрнәкләре дә, урысчадан яки Аурупа илләре телендә язылган әсәрләр дә байтак. Шулай да тамашачы күңелендә, мөгаен, Зөбәйдә *(«Зөбәйдә—адәм баласы», Ш.Хөсәенов)*, Диләфрүз *(«Диләфрүзгә—дүрт кияү», Т. Миңнуллин)*, Зөбәрҗәт *(«Ай тотылган төндә», М. Кәрим)*, Изабелла *(«Чамасына күрә чарасы»)* кебек рольләр калгандыр. Шулай да арада үзәккә үткәннәренә аерым тукталмый булмый. Берара Наилә сәхнәдә күренмәс булды. Авыр еллар иде ул. Иҗади яктан гына түгел, хәтта матди хәлебез начарланды, безне тамак, өс-башны каплау хәсрәте биләп алды. Шундый чакта иҗат ягыннан да «кыса» башласалар—дөньяны матурлату турында гына хыялланып яшәгән кеше нишләргә тиеш иде соң? Мин Наиләдән бер интервью алдым.

—Хәлем—бөтен халыкныкы кебек,—диде ул. Сүзләре җәй уртасында коелган бөртек кебек иде.—Тамак кайгысы. Колхозга бәрәңгегә йөрибез...

Шактый сүзсез тордык, чөнки миндә дә аны тынычландырырлык сүз юк иде. Аннары Наиләкәем Тукай шигырен укый башлады. Ул бит, гомумән, бик күп укый, күп белә, күп уйлана. Таянычы итеп шуларга тотынган икән.—Нәкъ Тукайча инде,—диде:

... Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнен һич берен дә чөнки ак ди алмадым.
Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки ятимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.
Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч—шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым...

Шөкер, бу коточкыч авыр дәверебез артка чигенде кебек. Наиләгә бер-бер артлы яңа рольләр бирә башладылар. «Бичура» *(М. Гыйләҗев)* спектаклендә режиссер улы Фәрит Бикчәнтәев (Тукай бүләге лауреаты) аңа карчык ролен бирде. Бу—Наилә иҗатындагы өр-яңа адым булды. Аннары—«Хушыгыз!»дагы үлем хәленә җиткән Миләүшә. Миләүшәне Наилә гаҗәеп зур киеренкелек белән башкарды.

—Бу—минем язмыш. Мина мондый роль бүтән «эләкми» инде дип, сөенә-сөенә уйнады ул.

Дөресен әйткәндә, Миләүшә образы *(Т. Миңнуллин пьесасы, «Хушыгыз!»)*—бу гасыр гарасатларын кичергән һәр иҗат кешесенең язмышы ул. Үзәк өзгеч.

Әле ул гынамы? Тамашачы һич көтмәгәндә, театр «Шәҗәрә» спектаклен сәхнәләштерде. Ашкынып бардык. Сәер генә башланып киткән спектакль, мәсьәләләр куера барган саен, җанны һаман үзенә тарта торды. Әллә кай заманнарда бурычка

алган акчаны кемгә тапшырырга белми йөриләр. Кергән һәр өй акчадан баш тарта. Үзләре—барысы да Сәетбәковлар нәселеннән, әлеге акча биргән бай нәселеннән бит. Бер карасан, беренче ишектән үк умырып алып калырга тиешләр иде кебек. Юк. Алмыйлар. Чөнки гаиләнен тарихы катлаулы, куркыныч. Хәсрәтле. Өрку дигән хис бирсеннән дә чыкмаган. Акчасы да кирәкми, тик элекке «халык дошманы» дигән исем генә кире кайтмасын! Әмма бу ап-ачык хакыйкатьне нәселнен бер генә вәкиле дә ачыктан-ачык танымый.

Ниһаять «акча тәкъдим итүчеләр» япа-ялгызлыкта, эчеп, тәмәке тартып, үз көнен нибары үзе генә күреп ятучы Сәлимә-Наилә Гәрәева янына килеп керәләр. Бу—язмышнын Наиләгә биргән ин шәп роле дияр идем мин. Заманабызнын, бәхетсез илебезнен, мен жәфа чигеп кон күрүче газиз халкыбызнын бөтен язмышын ача да бирә ул. Тамаша залы бердән еларга тотынды. Чөнки Сәлимә—без ул. Безнен бичара тормышыбыз.

—Телемне оныттырдылар—өйрәндем,—ди Сәлимә.—Монымнан яздырырга теләделәр... әнә, мандолина алдым, өйрәнәм мин аны!..

«Шәжәрә» *(Т. Миннуллин пьесасы, Ф. Бикчәнтәев режиссурасы)*—бер Наилә Гәрәеванын гына түгел, театрнын гомуми, зур ачышы, минемчә. Гасырыбызнын фажигасе сәхнәдән бу дәрәжәдә шәрәләндереп күрсәтелгәне юк иде әле. Һәм хикмәтнен ин биек ноктасы—Сәлимә образында. Аны Наилә Гәрәева ифрат дәрәжәдә ихлас, ышандырырлык иттереп тасвирлап та бирә.

Иманым камил: шатлык белән кайгы һәрчак рәттән йөри. Наилә Гәрәеванын 2000 елдагы сезон ахырында кичергән яна шатлыгы—мәшһүр талант иясе Шәриф Хөсәеновнын «Әни килде» пьесасы буенча куелган «Әни килде» спектаклендәге Ана образы. Бу әсәр күпләргә таныш. Аны безнен Казанда гына да өч театр сәхнәләштерде. Режиссеры гел Марсель Сәлимжанов булды. Һәм, бәхетемә, мин һәр өч куелышны да күреп кала алдым. «Күреп кала алдым» дим, чөнки Качалов театрындагы беренче куелышта гажәеп рәвештә уйнаган Павлова да, Камал театрындагы беренче куелыштагы спектакльдә бу рольне башкарган Галимә ханым Ибраһимова да вафатлар инде. Драматургнын 60 яшьлегенә туры китереп әсәрне К. Тинчурин театры да сәхнәләштерде. Ана ролен күренекле артисткабыз Исламия Мәхмүтова башкарды. Хәзер берсе турында да һичнинди яман сүз әйтеп булмый. Әмма В. Павлованын рус сәхнәсендә татар хатынын шундый да шанлы боеклеккә күтәрүен драматург аеруча олы бәяләве хәтердә. Шәриф Хөсәенов, гомумән, үзенен бу әсәре турында зур фикердә калды. Әсәр Татарстанда гына «калмады», бөтен Русия «буйлап китте». Пьеса авторын күп шәһәрләргә чакырып кына торалар иде.



*Наилә Гәрәева «Әни килде» спектаклендә Ана ролендә*

Ниһаять, Камал театрынын 2000 елгы сезонында пьесаны кабат сәхнәләштерергә алындылар. И-и-и, «алындылар»гынамы сон?! Бу вакыйга безнен Камал театрынын ифрат дәрәжәдә кешелеклелеген дәлилләп күрсәтте. Пьеса авторы үзе 70 еллыгына әзерләнә, әмма үзе монарчы яшәп өлгерә алмаячагын белә иде бит инде. Шәриф Хөсәенов—табиб кеше. Ул үзенә ябышкан яман чирнен озак дәвам итмәслеген бик яхшы белә, әмма һич тә сыкрап-нитеп ятмый иде. Театр «Әни килде»не кабаттан сәхнәләштерергә алынганын белгәч тә: «Нәрсә, мин үлгәнче күрсәтеп калмакчы буласызмы?»—дип, шаяртып итты. Әни роленә билгеләнгән Наилә Гәрәеваны ихластан хуплады ул. Шифаханәдә очрашкач та:

—Ярый, ярый, тавышын да калынаеп киткән, әйдә, тырышып кара!—ди икән.

Шәриф Хөсәенов Наилә Гәрәеванын иҗатын баштан ук хуплап алды. Үзенең «Зөбәйдә—адәм баласы» пьесасында уйнавын ничекләр итеп мактап йөрүе—әле дә күз алдында. Драматург ана зур курчак бүләк итте. Бу бүләген безнең яндагы гына уенчыклар кибетеннән сатып алган иде—күрсәтергә кергән. Мин тиргәдем: «Тапкансың бүләк итәр нәрсә?—дим.—Бүгенге көндә хатыннарга шул курчак кына җитмәгән инде!»

—Бетмәс сезнең чүпрәк-чапрак!—диде ул.—Менә бирәм әле. Теләсә нишләтсен!

Еллар үтеп беткәч, сораган идем. Наилә әйтә:

—Ул курчак, минем иң кадерле әйберләрем белән бергә саклана,—ди.—«Әни килде» дә мин ике мәртәбә уйнадым бит: беренчесендә—Римма, хәзер—Ана. Бу рольләрдә начар уйнап булмый. Шундый әсәрләр бар—анда артист әллә ни өсти алмый. Бу драматургның осталыгына бәйле! «Әни килде»нең бу куелышын карарга элекке тамашачы килде. Алар әле Галимә апаны, Шамуковны, Шәүкәт Биктимеровны бик яхшы хәтерлиләр, безнең уенны шулар алымы белән чагыштырып утыралар иде. Тамашачының беренче реакциясе үзебезне дә аптырашта калдырды. Хәзер ияләндек инде. Яңа тамашачы алдында үзебезчә, рәхәтләнеп уйныйбыз... Шәриф абый гына юк. Ул пьесаның беренче куелышыннан соң, атна үтәр-үтмәс, мәңгелеккә күчте. Авыр туфрагы җиңел булсын. Миңа бер кочак ап-ак розалар бүләк итеп калдырды ул:

—Елаттың бит, Наилә—диде.—Миңа аның тарафыннан шуннан да зур мактау кирәкми иде инде...

Үзе теләмәсә дә, Наилә Гәрәевага мактаулар өзелми. Монарчы Татарстанның халык артисткасы исеме бар иде инде аның, ә 1967 елда, «Гүзәлем Әсәл» спектаклендәге Әсәл ролен әйбәт башкарганы өчен, ана Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген дә бирделәр. Быел исә, 2000 елда Президентыбыз Минтимер Шәймиев үзе ана «Халыклар дуслыгы ордены»н тапшырды.

Гаҗәп, кеше язмышы гел бер ноктага гына төбәлеп барса, барыбер дә олы бер юлга килеп чыкмый калмый. 1960 елның 14 январенда, үзе ышанган артисткасына, яраткан хатынына, бердәнбер уртак балалары Фәрит Бикчәнтәевнең өметле киләчәгенә ышанып күренекле режиссер һәм артист Рәфкать Бикчәнтәев Наиләгә бер альбом бүләк иткән булган. «... Бу эшен шушы олы альбомны тутырачак галереяның башлангычы булсын!»—дип язган ул анда. Сәхнәбездән бик иртә киткән талант иябез—Рәфкать әфәнденең бу изге теләге бүген тормышка аша.

Наилә Гәрәева—иҗатының иң җитди дәверенә килеп керде. Мин бу юлларны язганда, ул әле Финляндиядә гастрольдә йөри иде. Хәер, хикмәт бер аның иҗатында гына да түгел: аның бердәнбер улы Фәрит Бикчәнтәевкә дә без зур өметләр баглыйбыз. Аның режиссурасы татар тамашачысын бер баскыч өскәрәк күтәрер кебек. Өстәвенә, Фәритнең улы Йосыф та, әле сабый килеш, сәхнәгә аяк басты. Киленнәре Люция Хәмитне дә тамашачы яхшы кабул итә. Болар бары да Наилә Гәрәеваның, аның сәхнәгә булган бердәнбер мәхәббәтенең җимешләре!

**Кояш ТИМБИКОВА**

*Коръән татар телендә*

# 4—НИСА (ХАТЫННАР) СҮРӘСЕ

***(Ниса (Хатыннар) сүрәсе 176 аятьтән тора. Һиҗрәттән соң Мәдинәдә иңгән. Бу сүрәдә хатыннар турында, җәмгыять эчендә аларның хаклары, хокуклары, иҗтимагый мәйдандагы тоткан урыннары турында сөйләнгәнгә күрә, «Ән-Ниса», ягъни «Хатыннар» диеп аталган.)***

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, инсаннар! Сезне бер җаннан яралткан вә ана хатынны бар иткән, аларның икесеннән ир җенес вә хатын җенесен үрчеткән Раббы каршында гөнаһ кылудан куркыгыз. Исемен теләкләрегездә куллана торган Аллаһ алдында гаепле булудан һәм кардәшлек җепләрен өзүдән сакланыгыз. Шик-шөбһәсез ки, Аллаһ сезнең арттан күзәтеп торучыдыр.

**2.** Ятимнәргә малларын бирегез. Ятимнәрнең затлы малын үзегезнең начар малыгызга алыштырмагыз. Аларның малларын үз малларыгызныкы белән катыштырып ашамагыз. Чөнки бу олуг бер гөнаһтыр. **(3)** Әгәр аларга *(ятимәләргә)* гадел була алмам, дип курыксагыз, үзегезгә ошаган хатыннарга өйләнегез: икесенә, өчесенә, дүртесенә *(никахлаша аласыз)*. Әгәр гадел була алмау куркынычы бар икән, берсен генә алыгыз, алай да булмаса, сезгә сатып алган кәнизәкләрегез дә бик житкән. Бу—Аллаһ юлыннан тайпылмас өчен кулай эш.

*(«Җаһилият-наданлык-караңгылык чорында, ягъни Коръән-и Кәрим иңгәнгә чаклы заманнарда ирләр малларына кызыкканга күрә, үз карамакларындагы ятимә кызларга өйләнә торган булганнар. Берничә ятимә кызга өйләнгәннәр дә булгалаган. Яклаучысы булмаган ятимә хатыннарга ирләре рәнҗетүле мөгамәләдә булып, гаделсез гамәлләр кыла торган булганнар. Хәтта мирасларын алыр өчен аларның үлеп китүләрен теләгәннәр. Бу аять әнә шундый ятимәләрнең хокукын яклый. Исламнан әүвәлге заманнарда ирләргә ничә хатын алса да тыелмаган була. Унар хатынлы, хәтта аннан да артыкка өйләнүләр гадәти хәл булган. Ислам кануннары зинаны тыя. Шуңа күрә, зина кылуның мөмкинлекләрен бетереш кирәк. Ир кешенең гайрәтле һәм көр тормышлы булуы, хатынының зәгыйфь яки бала таба алмавы, дәртсез булуы, ирләрнең сугышларда күпләп һәлак булулары аркасында яки башка сәбәпләргә күрә, ирләрнең азаюы хатыннарның саны артуга китерә. Шуңа күрә, ирләргә бердән артык хатынга өйләнү зарурияте барлыкка килгән. Чөнки ирсез кызлар, ирсез хатыннар зина юлыннан киткән булырлар иде. Ләкин күп хатын белән, ятимәләр белән никахлашкан ир һәр хатынына гадел булырга тиеш».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**4.** Хатыннарга мәһәрне чын күңелдән, мул бирегез. Әгәр дә кин күңеллелек белән *(сез биргән)* мәһәрнең бер өлешен сезгә кайтарсалар, аны рәхәтләнеп ашагыз.

**5.** Терәк булсын дип, Аллаһ сезгә мал бирде, сез ул малны диваналарга *(мал тота белмәгәннәргә, акылы сәламәт булмаганнарга)* бирмәгез. Шул мал белән

---

Журнал өчен Рабит Батулла әзерләде.

андыйларны ашатыгыз-эчертегез һәм аларга юатучы сүзләр сөйләгез.

**6.** Балигълыкка ирешкәнгә кадәр ятимнәрне *(тәрбия кылыгыз, карап үстерегез)* сынагыз. Акылы өлгергәнлеген күргә үк, малларын үзләренә тапшырыгыз. Ул малны исраф итеп, кабаланып ашап бетермәгез. Бай кеше олпат *(гадел)* булырга тырышсын, *(ятим малына кулын сузмасын)*, фәкыйрь булса, тиешлесен генә ашасын. Малларын шаһитләр алдында тапшырыгыз. Юкса, Аллаһ һәркемнең гамәлен белеп, хисап алачак.

*(«Бер кеше Рәсүлулла саллаллаһү галәйһи вә сәлләмгә килеп: мин—фәкыйрь бәндә, диде. Әмма минем бер ятимем бар. Рәсүл әйтте ки: ятим малын тагын да арттырыр булсаң, артыгын кыланмыйча, син ятим малының бер өлешен тота аласың,—диде».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**7.** Ата-ана яки якыннары калдырган *(малдан)* ирләргә бер пай тия, ата-ана вә якыннары калдырганнан хатыннарга бер пай тия. Мал күп булса да, аз гына булса да тигез бүленергә тиеш. **(8)** Мирас бүлгәндә *(васыятьтә исеме әйтелмәгән)* якыннар, ятимнәр вә юксыллар булса, аларга да ризыклык өлеш чыгарыгыз һәм аларга ягымлы сүзләр әйтегез.

*(«Җаһилият дәверендә мирас малы хатыннарга бирелми иде, бу иске йоланы инкарь итеп, шушы ике аять иңдерелгән. Ерак туганнарга, ятимнәр вә мирас бүлешкәндә очраклы туры килгәннәргә дә өлеш чыгару—гаделлек кануны».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**9.** Үлем түшәгендә:

—Зәгыйфь, сабый балам кала, *(аны кемнәр генә карар инде, аны балалыкка алган кешеләр миннән калган малны ашап бетермәсләрме)*,—дип борчылган кешеләр кебек, *(ятимнәрне үз тәрбиясенә алып калганнар да)*, ятим малын ашаудан тыелсыннар. Аллаһның җәзасыннан курыксыннар вә дөрес сүз сөйләсеннәр.

*(Асрауга алынган ятим баланы химаяче (тәрбияче) үз баласы кебек багарга бурычлы. Чөнки көннәрдән бер көнне ул вафат булып, аның балалары да ятим калу ихтималы бар.)*

**10.** Хәйлә вә сылтау белән ятим хакын җыйган кешеләр карыннарына утлы кисәү тыккан кебек булачаклар, монысы хак, соңыннан алар ялкынлы утка барып керәчәк.

**11.** Аллаһ балаларыгыз хакында болай ди:

—Ир угланга ике кыз бала өлеше кадәр пай бирелер. Әгәр балаларның барысы да кыз җенесле булып, икедән артса, мәрхүм калдырган мирасның өчтән икесе аларга тиеш. Әгәр бер генә бөртек кыз бала булса, малның яртысы аңа тияр. Мәрхүмнең баласы калса, мәрхүмнең ата-анасына һәрберсенә аерым итеп, мирасның алтыдан бер өлеше бирелергә тиеш. Мәрхүмнең баласы калмыйча, ата-бабасы аның малына варис булыр, анасына өчтән бер өлеше *(атага калганы)* булыр. Мәрхүмнең *(бертуган)* кардәшләре булса, аның васыятен үтәп, бурычларын түләп бетергәннән соң, анасына алтыдан бер өлеш *(калганы кардәшләренә)* булыр. Атагыз да, балаларыгыз да файда китерү мәсьәләсендә кайсысы сезгә якынрак икәнлеген сез Аллаһ билгеләгәнчә белмисез.

Хактыр ки, Аллаһ гыйлем вә хикмәтләр хуҗасыдыр.

*(«Ни өчен Коръән мирас өлешен ирләргә күбрәк бүләргә боера?—дигән сорауга җавап будыр ки: ирләрнең тормыш чыгымнары хатыннарныкына караганда күбрәк. Өйләнгәндә мәһәр бирү ир якның бурычы, туй чыгымнарын да ирләр тарафы каплый. Өйләнгәннән соң да ирләр—кирәксә, мохтаҗлыктагы якын туганнарына ярдәм итүче, кирәксә хатыны, балаларын караучы. Аларны ашау-эчү, кием-салым, торак белән тәэмин итү ирләр җилкәсендә. Шул сәбәпле ирләрнең пае хатыннарныкына караганда артыграк».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**12.** Хатыныгыз вафат булып, баласы булмыйча, малы калса, васыяте

үтәлгәннән соң һәм бурычлары кайтарылганнан соң калган малның яртысы сезгәдер. Балалары калган булса, малның дүрттән бер өлеше сезнеке. Балагыз булмаса, сез калдырган малның дүрттән бер өлеше хатыннарыгызга. Балагыз булса, васыятьне, бурычларны башкарганнан соң, хатыннарыгызга сигездән бер өлеш чыгар. Әгәр дә мәрхүмнең яки мәрхүмәнең ата-анасы вә балалары булмаган хәлдә ир туганы яки хатын-кыз кардәше булса, һәрберсенә алтыдан бер өлеш чыгарылыр. Икедән артып китсәләр, мирасның өчтән бер өлеше тигез бүленер. Васыять шартларын һәм бурычларын үтәгәннән соң, һичкемгә дә зыян китермәстән, мирас малы тигез итеп, Аллаһ хөкем иткәнчә бүленергә тиеш.

Аллаһ бар нәрсәне дә белеп торучы һәм гадел.

**13.** Болар Аллаһ куйган *(кануни)* кысалардыр. Кем Аллаһка вә аның Пәйгамбәренә итагать итсә, Аллаһ аны үзәннәреннән чишмәләр агып ята торган җәннәтләргә урнаштырачак, алар анда озакка калачак, менә шул бөек котылыш булыр.

**14.** Кем дә кем Аллаһка вә аның Пәйгамбәренә каршы гыйсъян күтәрсә вә әлеге чикләрне бозса, Аллаһ аны мәңгелек утка ташлаячак, бу *(гөнаһкяр өчен)* хурлыклы җәза булыр.

**15.** Уйнаш кылган хатыныгыз өстеннән арагыздан сайланган дүрт ир шаһит булсын. Әгәр алар шаһитлек кылса, хатынны үлгәнчегә кадәр яки Аллаһ бер җай чыгарганчыга чаклы өегездә ябып тотыгыз. **(16)** Арагыздан икәү бергә зина кылса, икесенә дә җәза бирегез, әгәр дә тәүбә итсәләр, үкенсәләр, җәзалаудан ваз кичегез. Аллаһ тәүбәләрне кабул итүче һәм ярлыкаучыдыр.

*(«Телдән аларны: зина кылганда ничек Аллаһтан курыкмадыгыз, ничек, оялмадыгыз?— дип ачуланырга кирәк. Ибне Габбас хәзрәтләре язганча, андый зиначыларны сүз белән дә, кул белән дә кыйнарга кирәк. Хәсән Басри хәзрәтләре болай ди: зина кылучылар икесе дә никахлы булса, җәзалары таш белән ату булыр. Әгәр дә берсе никахлы, икенчесе никахсыз булса, никахлыга—таш, никахсызга таяк хөкем ителә. Тәфсирчеләр исә бу аятьләрнең берсе хатын белән хатын зинасы (дус хатыннар арасындагы гайре табигый гыйшык уены), икенчесе исә ирләр белән ирләр кылган зина (күтләклек) турында, дип язалар. Хатын белән ир арасындагы зина өчен җәзалар «Нур» сүрәсендә күрсәтелә.*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**17.** Наданлыгы аркасында гына яманлык кылган кеше соңра исенә килеп, тиз тәүбә итсә, Аллаһ аның тәүбәсен кабул итәр. Аллаһ бар нәрсәне дә белүче хикмәт ияседер. **(18)** Юкса, *(гомере буе)* яманлыклар кылып та, якасыннан үлем килеп тоткач кына:

—Мин инде тәүбә иттем!—дигәннәргә һәм кяфер булып үлгәннәр өчен ярлыкау юк. Андыйлар өчен әче газап хәзерләнгән.

**19.** Әй, мөэминнәр! Хатыннарны ирексезләп мирас итүегез хәләл түгел. Ачыктан-ачык хыянәт *(зина)* итмәгән булса, аларга, *(китәргә теләсә)* мәһәренең бер өлешен үзегезгә алу максаты белән, хатыннарны ирексезләп тотмагыз *(аерып җибәрегез)*. Хәтта сез хатыннарыгызны яратмасагыз да, аның белән яхшы мөгамәләдә булыгыз. Әгәр дә сезгә ул ошамый икән, димәк, сез Аллаһ аңа биргән сөйкемлелекне *(андагы мөмкинлекләрне)* күрмисез.

*(«Бу аять хатыннарның дәрәҗәсен арттыра. Сез ошатмаган хатыныгыз сезгә гайрәтле балалар табып бирер, йә булмаса, тора-бара сез шушы хатыныгызны чын сөю белән сөя башларсыз».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**20.** Әгәр дә сез хатыныгызны аерып, башкасына өйләнергә уйласагыз, *(аерасы хатыныгызга бирелгән)* мәһәрдән берни дә алмагыз. Сез аңа нахак яла ягып, ачыктан-ачык хаталанып, биргән мәһәрегезне кире алырсызмы?

*(«Җаһилият вакытында ирләр, хатыннан мәһәрен алып калыр өчен, гөнаһсыз хатынына нахак яла яга торган булганнар. Аять шул гаделсезлекне тыя».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**21.** Вакытында сез бер-берегез белән кушылып яшәдегез, вәгъдәләр бирештегез, шуннан соң да ничек итеп сез хатын малын кире алырсыз икән?

*(Ягъни хатының белән син гүзәл итеп яшә, яки яхшылык белән аерыл.)*

**22.** Буласы булган инде, әмма әүвәлге кебек, атагыз аерган үги анагызга өйләнмәгез. Чөнки бу—оятсызлык, җирәнгеч бер гамәл һәм яманлыктыр.

*(Ислам кануннары иңгәнче гарәпләр арасында атасыннан калган хатынга (үги анага) өйләнү гадәте булган.)*

**23.** Аналарыгыз, кызларыгыз, кыз туганнарыгыз, апаларыгыз, туталарыгыз, кардәшләрегезнең кызлары, сезне имезгән сөт аналарыгыз, сөт кардәшләрегез, хатыннарыгызның аналары, хатыннарыгызга иярә килгән үги кызларыгыз сезгә харам кылынды. Әгәр никахлашып та хатынызыз белән якынлык кылмаган булсагыз, аны аергач, ул хатынның башка ирдән туган кызына өйләнүнең гаебе юк. Үз угыллары-гызның хатыннары вә ике кыз кардәшне берьюлы никахлап алу харам кылынды. Узган заманнарда сез шулай кыла идегез. Аллаһ, хакыйкатән, ярлыкаучы, кичерүчедер.

**24.** Башка ир никахындагы барча хатыннар да сезгә харам *(сугышта әсир алынган хатыннар-җарияләрдән башка. Ул хатыннарның үз илләрендә калган ирләре белән булган никахлары бозыла. Аларны хатын итеп алу мөселманнар өчен харам түгел).* Аллаһның сезгә әмере шулдыр. *(Никахлы хатыннардан)* башкасын намуслы рәвештә вә зина кылмыйча гына, малларыгыз ярдәме белән *(мәһәр әзерләп)* теләгән хатын белән никахлашу хәләл ителде. Аларны файдаланганыгыз өчен алдан килешенгәнчә мәһәр бирегез. Моннан соң ни кылсагыз да, гөнаһ булмас. Хактыр ки, Аллаһ гыйлем иясе вә хикмәтләр хуҗасыдыр. **(25)** Мөселман хатыннарга өйләнергә малы җитмәгән кеше, боерыгыгызда булган, иман китергән җарияләргә өйләнә ала. Аллаһ сезнең иманыгызны бик яхшы белә. Сез икегез дә тигез *(иманлы җарияләр, кәнизәкләр, колиһәләр дә сезнең кебек үк адәм баласы).* Шулай итеп, хуҗаларыннан рөхсәт алып, зина кылмаган, яшерен сөяркәләре булмаган, намуслы җарияләргә өйләнегез. Мәһәрләрен дә җитәрлек микъдарда бирегез. Никахтан соң зина кылса, андыйларга ирекле хатыннарга бирелә торган җәзаның яртысы бирелер. Бу—гөнаһтан курыкканнар өчен. Сабырлык сезнең өчен хәерледер. Аллаһ ярлыкаучы вә кичерүчедер.

**26.** Белмәгәннәрегезне белдермәк һәм сездән алда яшәгән изгеләр *(Ибраһим белән Исмәгыйль)* юлына күндермәк өчен, Аллаһ гөнаһларыгызны ярлыкарга тели. Шик юктыр ки, Аллаһ белеп торучы хөкем вә хикмәт иясе.

**27.** Чыннан да, Аллаһ сезнең тәүбәләрегезне кабул итәргә тели. Җенси теләкләренә кол булган кешеләр исә сезне, мотлак, юлдан яздырмакчы булалар.

**28.** Аллаһ сезнең йөгегезне җиңеләйтергә тели, чөнки инсан куәтсез итеп яралтылган.

**29.** Әй, мөэминнәр! Малларыгызны үзара сату итеп, килешеп кенә ашагыз. Харам юл белән, әшәкелек белән *(тартып алып)* малларыгызны ашамагыз. Бер-берегезне үтермәгез. Шик юк ки, Аллаһ сезне ярлыкаучы.

**30.** Кем дә кем хаксызлык белән шулай кылса, *(харам ризык җыйса, адәм үтерсә)*, аны утка атачакбыз. Бу эш Аллаһ өчен бик тә җиңел.

**31.** Әгәр тыелган олы гөнаһлардан качсагыз, сезнең башка ялгышларыгызны кичерербез вә сезне шәрәфле бер җиргә урнаштырырбыз.

**32.** Аллаһ кешеләрне бер-береннән өстен куйды, аларның өстенлекләренә кызыкмагыз. Ирләрнең тапканы *(савабы, гөнаһысы)* үзенә, хатыннарның тапканы *(савабы, гөнаһысы)* үзләренә. Аллаһның рәхмәтен сорагыз, шик юк ки: Аллаһ һәрнәрсәне дә белеп тора.

**33.** Һәркемне *(ирне, хатынны)* ата-анасыннан вә туганнарыннан калган малга мирасчы итеп куйдык. Антлашканнарга үз өлешләрен бирегез. Аллаһ һәр нәрсәне күреп тора.

**34.** Аллаһ кешеләрне бер-берләреннән өстен куйганы сәбәпле, ирләр хатыннарның җитәкчесе һәм саклаучысы, туйдыручысы-киендерүчесе. Шуңа күрә, иманлы хатыннар әдәпле. Алар Аллаһ сакларга кушкан серне *(гыйффәтлелек вә намусларын)* саклаучылар. Буйсынмау галәмәтләре күренсә, хатыныгызны үгетләгез, ятакта ялгыз калдырып китегез, *(шулай да игә килмәсә, шурләрлек итеп)* сугыгыз. Әгәр хатын игә килсә, аны кимсетә торган чара эзләмәгез. Аллаһ—олуглыр, Ул—бөектер.

*(«Гаилә ул—бер дәүләт. Дәүләтнең төзек бер тәртибе булырга тиеш. Аның җитәкчесе, рәисе, идарәчесе булырга тиеш. Дәүләттәге кебек, гаиләдә дә итагать булырга тиеш. Әнә шул итагать чикләрен бозып, итагать кысаларыннан чыкканны үгетләү, аңа тиешенчә җәза бирү—идарәченең бурычыдыр. Монда хатыннарның гаилә кануннарын бозуы турында сөйләнә. Хәзрәти Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең беркайчан да хатын кыйнаганы булмаган. Ул: ишәкне кыйнаган кебек хатын кыйнап, кич белән шул кыйналган хатынның кочаклап яту ир кеше эшеме?—дип өммәтенә сабак биргән зат. «Кыйнау» кәлимәсен эт итеп, имгәткәнче, җәрәхәтләгәнче кыйнау, дип аңламаска кирәк».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**35.** Ир белән хатынның аерылышу мәсьәләсе килеп чыкса, әмма татуланырга теләсәләр, ир ягыннан бер гадел кешене, хатын ягыннан икенче гадел бер кешене сайлап алыгыз. Аллаһ аларны килештерер. Шик юк ки, Аллаһ барысын да белүче, барыннан да хәбәрдар.

**36.** Аллаһка гыйбадәт кылыгыз һәм Аңа һичбер тиң зат эзләмәгез. Ата-анага, туганнарга, ятимнәргә, фәкыйрьләргә, якын күршеләргә, ерак күршеләргә, якын аркадашка, юлчыга, боерыгыгызда булганнарга *(кол, җария, хезмәтче һәм башка шундыйларга)* яхшы мөгамәләдә булыгыз. Аллаһ үз-үзенә гашыйк тәкәбберләрне, өзлексез мактанган кешеләрне сөйми. **(37)** Андый кешеләр саран була, башкаларны да саран булырга котырта, Аллаһ биргән нигъмәтләрне алар яшереп тота. Без андый кяферләр өчен чыдый алмаслык җәза хәзерләдек. **(38)** Аллаһка, Ахирәт көненә инанмаган килеш, малларын кешеләргә күрсәтер өчен генә *(менә мин дин өчен аш уздырам, чыгымнар түгәм, дип)* сарыф иткәннәр дә *(Ахирәттә газапка дучар булыр)*. Шайтан берәрсенә иптәш була икән, бик тә яман иптәш ул. **(39)** Аллаһка вә Ахирәт көненә иман китереп, үзләренә Аллаһ тарафыннан бирелгәнне *(дин юлында)* сарыф итсәләр, ни була иде инде? Аллаһ аларның хәлен бик яхшы белеп тора.

**40.** Шик юк ки, Аллаһ сезгә тузан бөртеге кадәр дә гаделсезлек кылмас. Игелек кылучыны кат-кат бәяләр. Аллаһ зур бүләк бирер.

**41.** Һәрбер өммәттән бер шаһит, шулар өстенә сине дә шаһит итеп китергәч, тегеләрнең (яһүд, кяфер, монафикъларның) хәле ничек булыр икән?

*(Ахирәттә пәйгамбәрләр кешеләрнең бу дөньяда яшәешләре, кылмышларына шаһит булачаклар.)*

**42.** Азгын юлга төшеп, Пәйгамбәрне тыңламаганнар ул көнне *(Кыяматтә)* үзләрен җир белән тигезләүне теләрләр һәм һичбер кылганнарын яшерә алмаслар.

*(Дүртенче, ягъни Ниса сүрәсенең 43 нче аятенә кучканче куп кенә тәфсирләр вә тәрҗемәләрдә еш кулланылган «сәрхуш, исерек» кәлимәләре хакында фикер алышыйк.*

*Чөнки бәгъзеләре: «бераз аракы эчеп, намаз укырга ярый икән», дип, үзләренә аклану юлын карыйлар. Әмма татар телендә «исерек» сүзе бары тик хәмер, аракы эчеп исерү мәгънәсен генә үз эченә алмый; «үлем исереклеге», «йокы исереклеге», «мунчада ис тиеп исерү» кебек мәгънәләрне дә бирә ала, шулай булгач, бу сүзне гел генә туры һәм бер мәгънәдә генә аңларга һич тә ярамый; бәхәсләр чыганагы булган бу аятьне галимнәр төрлечә тәрҗемә итә.*

*Лондон нөсхәсендә: «О, вы, верующие, не приступайте к Молитве, когда вы не в полном обладании своими чувствами, пока не будете знать, что говорите...»*

*Пороховада: «О вы, кто верует! Не приближайтесь к совершению молитвы внездравом состоянии ума, пока не сможете понять, что говорите».*

*Ногманида: «Ий мөэминнәр, исерткеч эчеп исереп ни сөйләгәнегезне белмәсәгез, намазга якын бармагыз! (Ул вакытта хәмер хәрам түгел иде, шул сәбәпле кайбер сахәбәләр исерек хәлдә намаз укып, аятьне хата укыдылар.)*

*Бу мәсьәләгә Америка нөсхәсе менә ничек карый, 214 бит: «Существуют разногласия относительно того, что значит здесь слово* ***сукара****. Буквально, слово* ***сакаран*** *(единственное число) означает «одурманенный», однако, некоторые считают, что здесь имеются в виду одурманенные напитком, другие же полагаеют, что речь идет об одурманенных сном. Слово* ***сакр****, несомненно, может быт употреблено в послелнем смысле, ибо буквальное значение—«останавливать». Кроме того, это слово применяется, когда речь идет о помутнении рассудка. Священный Коран говорит о* ***сакрат ал-маут****, то есть о состоянии, когда человек, приближающийся к смерти, утрачивает власть над своим рассудком. Выражение* ***сакрат ал-хамма*** *описывает состояние, когда человек теряет рассудок из-за великой скорби.* ***Сакрат ал-наум****— это такое состояние, когда из-за неодолимой сонливости человек не вполне владеет рассудком. Использованное здесь слово может иметь любое из этих значений. Запрет молиться в состоянии опьянения был шагом к полному запрещению спиртного».*

*Америка нөсхәсенең 100 битендәге «хәмер» сүзенә бирелгән аңлатманы укысак, эш тагын да ачыклана төшәр:*

*«Слово кхамр означает «вино» или «виноградная лоза».*

*Шулай итеп, «хәмер елгалары» дигән гыйбарәне «йөзем суты, ширбәт елгалары» дип тә тәрҗемә итеп була икән.*

*Димәк, шушы галимнәрнең шәрехләренә күрә, киләчәктә Коръәннең бу аятен тәрҗемә иткәндә Лондон нөсхәсен һәм Порохова тәрҗемәсен, Мәүланә Али аңлатмасын һич икеләнмичә кулланырга була икән. Һәм без ул аятьнең мәгънәсен менә шулай хуп күрдек):*

**43.** Әй иман китергән кешеләр! Йокы исереклегендә яки зиһенегез таркау чакта ни сөйләгәнегезне белмәслек дәрәҗәдә башыгыз томанлы булса, башыгыз сафланганга чаклы намазга якын килмәгез. Шакшыланган булсагыз, сәяхәттә булсагыз, госел тәһарәте алмыйча намаз укымагыз. Хаста булып яки сәяхәттә булсагыз яки бәдрәфтән чыксагыз, хатыныгыз белән якынлык кылганнан соң, су булмаганда, таза туфрак белән тәяммүм итегез, йөзегезгә вә кулларыгызга туфрак сирпегез. Шик юк ки, Аллаһ юмарт рәвештә ярлыкаучы, гөнаһларны гафу итүчедер.

*(Тәһарәт яки госел коену кирәк булганда, су кытлыгында туфрак, ком белән тәяммүм тәһарәте алу ярый. Тәяммүм тәһарәте, госел коенуны да алыштыра, су кулланырга ярамаган хаста кеше дә, су булган урында да су кулланмас, тәяммүм алыр.)*

**44.** Үзләренә Китап өлешләре иңдерелгәннәргә *(имансызларга)* баксана! Бозыклыкны сатып алалар вә сезне дә юлдан яздырырга маташалар.

**45.** Аллаһ сезнең дошманнарыгызны үзегездән дә яхшы белә. Чынлыкта, сезгә Аллаһның дуслыгы һәм ярдәме җитәр.

**46.** Яһүдләрнең бер төркеме *(китап)* сүзләрнең урыннарын *(Тәураттагы Рәсүлулла саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнең вазифаларына кагылышлы өлешләрен)* алмаштырдылар. Телләрен юри көрмәкләндереп, динебезне мыскыл итеп:

—Ишеттек *(Коръән сүзләрен)*, әмма каршы килдек, ишетмәгәненне ишет, рәгыйнә,—диделәр.

Әгәр алар:

—Ишеттек, итагать иттек, тыңла вә безгә күз-колак бул,—дигән булсалар иде, шик юк ки, үзләре өчен тагын да яхшырак булыр иде, ләкин кирелекләре аркасында, Аллаһ аларны каһәрләде. Аларның бик азы гына иман китерде.

*(«Яһүдләр Аллаһ тарафыннан иңдерелгән Тәүратны боздылар. Сүзләрен, мәгънәләрен үзгәрттеләр, соңгы Пәйгамбәр Мөхәммәд саллаллаһү галәйһиссәләмнең Аллаһтан илче булып киләчәге турындагы хәбәрне юкка чыгардылар. Хәзрәти Мөхәммәд Пәйгамбәр булып килгәч, аның турында җыен юк-бар гайбәт, мыскыллы сүзләр тараттылар. Әйтик, «рәгыйнә» сүзе «безгә күз-колак бул» мәгънәсендә йөри. Шул ук сүзне озын итеп, «рәгый-инәә» дип әйтсәң, «безнең көтүчебез» мәгънәсен ала».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**47.** Әй, Китаплы кавем! Йөзегезне каралтмас борын, кара йөзләрегезне артка каерып куйганчы, шимбә көнне Аллаһ хөкемен бозганнары өчен каргалганнар кебек ләгънәт алганчы, үзегезгә бирелгәннәрне *(Тәүрат, Инҗилне)* дөреслап, иман китерегез.

Аллаһның әмере, һичшиксез, җиренә житкезеләчәктер.

*(Аятьнең гарәпчәсендә телгә алынган «сәбт-суббота» шимбә көн дигән сүзне аңлата. Шимбә көнен хөрмәтләмәгән яһүдләргә Аллаһ ләгънәт ора.)*

**48.** Аллаһка тиңдәш эзләүчеләрне Аллаһ хупламас, моннан башка гөнаһлы булганнарны, Үзе теләсә, ярлыкар. Аллаһка тиңдәш эзләүче иң зур гөнаһка батып, ялган уйлап чыгарган кеше булыр.

**49.** Үз-үзләрен намуслы итеп күрсәтергә тырышканнарны күрденме? Хәер, Аллаһ Үзе теләгәнне пакьләр вә һичкем хөрмә төшенен җепселе кадәрле дә хаксызлык күрмәс.

**50.** Бак, Аллаһ турында нинди генә ялганнар уйлап чыгармыйлар денсезләр, көн кебек ачктыр ки: бу алар өчен житәрлек гөнаһ.

**51.** Үзләренә Китап иңдерелгәннәрне күрденме? Потларга *(таш сыннарга, агач сыннарга)*, шайтанга ышаналар, соңыннан кяферләр өчен:

—Болар Аллаһка иман китерүгә караганда турырак юл,—дип сөйлиләр.

*(«Китап иңдерелгәннәр, ягъни әһле китап кешеләреннән берәүсе Мәдинәдән Мәккәгә килеп, мөшрикләрне хәзрәти Мөхәммәдкә һәм мөселманнарга каршы сугышырга котырта башлый. Шунда мөшрикләр: безнең динебез дөресме, әллә Мөхәммәднең динеме, кайсыбыз тугры юлда?—дип сорыйлар. Сез тугры юлда!—ди баягы җасус. Җибт белән Тагут исемендәге ике пот—сын-һәйкәл бар иде. Җибт дигәне, имеш, киләчәкне әйтүче, Тагут дигәне, имеш, сихерче. Тагут—сихере белән кешеләрне аздыручы. Аллаһ аларның барысын да инкарь итте. Бу аять шушы вакыйгага ишарә итә».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**52.** Алар—Аллаһ каһәрләгән бәндәләрдер. Аллаһның ләгънәтен алганнарга ярдәмче табылмас. **(53)** Әллә аларның хакимлеккә кодрәтләре бармы? *(Андый кодрәтләре булса)* алар кешеләргә хөрмә төшенең сызыгы кадәр дә өлеш бирмәс иде. **(54)** Әллә алар Аллаһ юмартлыгы белән кешеләргә бирелгәннән *(Коръән вә нигъмәтләрдән)* көнләшәләрме? Юкса, без бит Ибраһим токымына да Китап вә хикмәтләр бирдек һәм аларга бөек хөкемдарлык тапшырдык. **(55)** Аларның бер өлеше аңа ышанды, кайсылары аннан йөз чөерде. Андыйларга хәтәр утлы җәһәннәм житәр. **(56)** Шик юк ки, аятьләребезне инкарь итүчеләрне утта яндырачакбыз. Тиреләре көеп беткәч, газап дәвам итсен өчен, яңасы белән алыштырачакбыз. Аллаһ һәрвакыт өстен вә хөкемдар.

**57.** *(Аллаһка)* инанып, игелекле булганнарны мәңге яшәр өчен, үзәннәреннән чишмәләр агып ятучы җәннәтләргә кертербез. Анда алар өчен сафпакь ярлар булыр, аларны рәхәтлек бирүче агач күләгәләрендә яшәтербез.

**58.** Сезгә әманәт ителгән малларны ияләренә кайтаруыгызны вә кешеләр арасында хөкем йөрткәндә гаделлек белән эш итүчегезне Аллаһ сезгә әмер итте. Менә шулай, Аллаһ сезгә гүзәл рәвештә үгет бирә. Хактыр ки, Аллаһ барысын да ишетеп, күреп тора.

*(«Хәзрәти Мөхәммәд Мәккәне алгач, Госман бине Талха исемле кеше Кәгъбә тарафына ачыла торган капканы бикләп куя. Кәгъбә янына чыгып, ачкычны бирмичә, хәзрәти Мөхәммәдкә: пәйгамбәр икәнеңә инансам, ачкычны сиңа бирер идем,—ди. Хәзрәти Гали ачкычны талап ала. Капканы ача. Хәзрәти Мөхәммәд эчкәре керә дә, ике рәкәгать намаз укый. Чыкканда абыйсы Габбас ачкычны һәм мәртәбәле вазифа саналган Кәгъбә сакчылыгын үзенә тапшыруын үтенә. Менә шушы мөнәсәбәт илә шушы аять иңдерелде. Пәйгамбәребез хәзрәти Галигә: ачкычны хуҗасына кайтар һәм аннан гафу сора!—диде. Шуннан соң Госман бине Талха да мөселман булды».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

*Аңлатмадан соң аятьне яңадан укыгыз!*

**59.** Әй, иман китергәннәр, Аллаһка итагать итегез. Пәйгамбәргә вә үз арагыздан сайлап куелган идарәчеләрегезгә буйсыныгыз. Әгәр нинди дә булса аңлашыл-маучылык килеп чыкса, Аллаһка вә Ахирәткә инанган булсагыз, хәл итүне шәригать кушканча башкарыгыз. Бу хәерле дә, нәтиҗәле дә булачак.

**60.** Сиңа иңдерелгәнгә *(Коръәнгә)* вә сиңа чаклы иңдерелгәннәргә *(Тәүрат, Зәбур, Инҗилгә)* инанабыз, дип әйтүчеләрне күрмәдеңмени? Ләкин үзләре *(Аллаһтан башка берәүне)* Тагутны *(сихерчене)* хаким итәргә телиләр, гәрчә аларга Тагутка баш орырга кушылмаган. Хәлбуки, шайтан аларны бозык юлга кертеп, еракка илтеп, адаштырмак тели.

*(**Тагут** дип аздыручы, адаштыручы, бозык кешегә, яман куәт иясенә карата әйтелә, шайтанны да «Тагут» дип йөртәләр.)*

**61.** Аларга:

—Аллаһ иңдергәнгә *(Китапка)* вә Рәсүлгә юнәлегез *(ышаныгыз)*!—дип әйткәч, монафикъларның синнән тиз ераклашканнарын күрерсең. **(62)** Куллары белән башкарган эшләре *(гөнаһлары)* аркасында аларга берәр бәла-каза килсә, Аллаһ исеме белән ант итеп:

—Без фәкать игелек кылырга, үзара ярдәмләшергә теләдек,—дип сиңа ничек килерләр икән?

*(Монафикъләр тарафыннан салынган Исламга зарарлы мәчетне Мөхәммәд (галәйһиссәлләм) җимерде.)*

**63.** Икейөзлеләрнең күңелләрендә ни булса, шуны Аллаһ белә, алар белән дуслашма. Аларны үгетлә һәм аларга үзләре турында тәэсирле вәгазь укы. **(64)** Без һәр пәйгамбәрне, Аллаһ рөхсәте белән, аңа итагать итсеннәр, диеп күндердек. Әгәр дә алар үзләренә зыян эшләп, синең янга килеп, Аллаһтан ярлыкау сорасалар, пәйгамбәр дә алар өчен гафу сорап, Аллаһка ялварса иде, Аллаһ артыгы белән аларны ярлыкар иде, кичерер иде. **(65)** Хәер, Раббың исеме илә ант итәм, үз араларында чыккан каршылыкларны тәртипкә китерер өчен, алар сине хөкемче итәрләр, соңыннан синең хөкемеңә чын күңелдән риза булып, һич каршылыксыз мөселман булырлар, шуңа кадәр алар иман китермәс.

*(«**Иман**—буш сүздән генә тормый, чын күңелдән инану, димәктер. Аллаһ белән Рәсүлгә инандым, дип тә аларның хөкемнәреннән риза булмау, тач монафикъәлык галәмәтедер. Шәригать кануны кискән бармак авырмас, диләр: чыннан да гадел хөкем рәнҗешле булмас, чөнки мөэминнең йөрәгендә ул рәнҗешне оныттыра торган бөек Иман бар».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**66.** Әгәр аларга:

—Үзегезне корбан итегез яки йортларыгызны ташлап чыгыгыз,—дип боерсак, аларның бик азы гына әйткәнне үтәгән булыр иде.

Әгәр дә алар боерыкны җиренә житкезеп башкарсалар иде, алар өчен бик

тә хәерле һәм дә иманнарын тагын да ныгыту булыр иде.

*(«Әсхабе Кирамнан байтак кына кешеләр дин юлында шәһид китте, исәннәре йортларын ташлап китәргә мәҗбүр булды. Яһүдиләр белән монафикълар исә алай эшләмәделәр, киресенчә, алар милләттәшләрен үтерделәр, аларны йортларыннан куып, сөреп чыгардылар».*
Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

*«Үзегезне үтерегез, бер-берегезне үтерегез»* гыйбарәсенең күп төрле тәрҗемәсе бар. Крачковский: *убейте самих себя.* Кочигит: *үзегезне үтерегез.* Лондон нөсхәсе: *убейте близких ваших.* Мөхәммәд Али: *пожертвуйте своей жизнью.* Йазыр: *нәфесегезне үтерегез, ягъни хөсетлегегезне, туймас нәфесегезне үтерегез, диелә».*

**67.** Шул вакытта, әлбәттә, аларга тарафыбыздан олы бүләк бирер идек. **(68)** Һичшиксез, аларны тугры юлга чыгарыр идек.

*(«Хәзрәти Гайшә болай сөйли. Имеш, бер кеше Рәсүлулла янына килеп: Ий, Аллаһның Рәсүле, сине үземнән артык, бала-чагамнан да артык сөямен. Өемдә чакта син исемә төшсәң, сабырым төкәнә, ашыгып синең янга йөгерәм. Без икебез дә үләчәкбез. Син җәннәткә керәч, башка пәйгамбәрләр белән дәрәҗәле урыннарга менгезеләчәксең. Мин, хәтта җәннәткә керсәм дә, сине очрата алмаячакмын, дигән. Хәзрәти Пәйгамбәребез бу самими адәмгә җавап бирми. Шуннан соң бу (69 нчы аять) иңдерелде».*
Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**69.** Кем Аллаһка вә Рәсүлгә итагать итсә, менә шулар Аллаһ тарафыннан хуп күрелгән пәйгамбәрләр, гадел вә тугры булган ситдикъләр, шәһидләр вә игелекле адәмнәр белән бергә булачаклар. Алар гаҗәеп аркадашлар. **(70)** Бу юмартлык Аллаһтандыр. Аллаһның белгәне житкән.

**71.** Әй, иман китергәннәр, уяу булыгыз, саф-саф булып сугышка чыгыгыз яки бөтенегез берьюлы барыгыз.

*(«Тынычлыкта яшәргә теләсәләр дә, кавемнәр үзләрен дошманнардан саклар өчен сугышка әзер булырга тиеш булган. Әзер бул син сугышка, әгәр теләсәң исән-иминлек, диләр. Иминлекне саклар өчен, Җир йөзеннән золымны, яулап алуларны себереп түгәр өчен, чын дин вә вөҗдан азатлыгын саклар өчен, Ислам сугышырга рөхсәт бирә, мөселманнарны Җиһадка чакыра. Мөселманнарның вазифасы—азатлык сугышына, бары тик азатлык сугышына һәрвакыт әзер булу».*
Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**72.** Сезнең арагызда кичегүчеләр дә *(Җиһад сугышына соңгаручылар яки төрле сылтаулар табып, сугышка бармаучылар да яки тәүбәгә килергә соңгаручылар да)* бар. Сезгә берәр афәт килсә:
—Аллаһ миңа рәхмәтле булды, *(ярый әле)* мин алар белән *(сугыштагылар белән)* бергә булмадым *(юкса, үлгән яки яраланган булыр идем)*,—дияр.

**73.** Әгәр Аллаһ сезгә берәр мөлкәт бирсә *(сугышта җиңеп, үлҗә, ганимәт малы бирү)*, әйтерсең лә, арагызда дуслык булмаган кебек:
—Аһ, әгәр мин дә сезнең белән бергә булса идем, мин дә зур уңыш казанган *(күп малга ия)* булыр идем.—дияр иде.

**74.** Аллаһ юлында Ахирәтне бу дөнья бәһасенә сатып алучылар сугышсын. Аллаһ юлында сугышкан кешегә, шәһит булган кешегә яки җиңгән кешегә Без озакламый олы әҗер бүләк итәчәкбез. **(75)** —Сезгә ни булды? Ни өчен сез Аллаһ юлында сугышмыйсыз? —Раббыбыз, безне залим халыклы шәһәрдән чыгар, безгә бер яклаучы, ярдәмчене җибәр,—дип ялваручы бичара ирләр, хатыннар вә балаларны яклап нигә сугышмыйсыз?

*(«Мәдинәгә күчеп китә алмаган мөселманнар Мәккәдәге мөшрикләрдән күп җәзалар-җәфалар күрә, шунда алар ярдәмче җибәрүен үтенеп, Аллаһка ялвара башлый. Аять шул вакыйгага ишарә итә. Ягъни, дөньяның кай төшендә генә булсалар да, золым астында яшәүче,*

*гаделсезлеккә дучар мөселманнарга ярдәм итү, кирәксә, аларның азатлыгы өчен сугышу зарурлыгы аңлашыла».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**76.** Иман китерүчеләр Аллаһ юлында сугышырлар, имансызлар исә Тагут *(шайтан)* юлында сугышырлар. Шуңа күрә, шайтанның дусларына каршы сугышыгыз, шик юк ки, шайтан корган тозак чыдамсыз.

**77.** —Кулларыгызны *(сугыштан)* тыегыз, намаз укыгыз, зәкят бирегез,— диелгәннәрне *(ишетмәдегезме)* күрмәдегезмени? Соңыннан аларга сугышу фарыз кылынгач, араларыннан бер төркем, Аллаһтан бик нык курыккан кебек итенеп, хәтта артыгы белән курыккандай, инсаннардан курка башладылар:

—Раббыбыз, ни өчен син безгә сугышырга куштың? Безне *(сугыштан)* беразга гына булса да кичектерсәң, булмасмы?—диделәр.

Син аларга әйт:

—Дөнья тормышы кыска,—диген.—Аллаһтан курыкканнар өчен Ахирәт хәерлерәк вә сезгә кыл кадәрле дә хаксызлык эшләнмәс. **(78)** Кайда гына булсагыз да, үлем сезне тотар. Биек вә ныгытылган кальгаларда булсагыз да. Үзләренә бер игелек килсә:

—Бу—Аллаһтан,—диләр. Башларына бәла килсә:

—*(Ий, Мөхәммәд)* бусы—синнән,—диләр.

—Барысы да Аллаһтан,—диген.

Бу адәмнәргә ни булган? Әйткәнне аңламыйлар.

**79** Сиңа килгән игелекләр Аллаһтан. Башыңа килгән бәлаләр үзеңнән. Сине кешеләргә илче итеп күндердек. Аллаһның шаһитлеге житәр.

*(Игелек тә, яманлык та Аллаһтан килә. Тик беренчесе Аллаһның ихтыярында, икенчесе исә бәндәнең гамәленнән тора. Бәндәләрнең күбесе уңыш казанса, баеса, нәтиҗәсен үзләренең булдыклылыгыннан күрә. Бәла, фаҗига, уңышсызлык артыннан уңышсызлык килә башласа, кешеләр шул яманлыкларны башка берәүдән күрә башлый, үзләрен гаепле санамый. Чынлыкта боларның барысы да, игелеге дә, яманлыгы да Аллаһтан килә. Ләкин Аллаһ һичбер кемгә махсус рәвештә яманлык кылмый, кешеләрне хаксызга бәлагә батырмый. Бәндә шул яманлыкны эшләргәме, юкмы, дигән юл чатында кала. Аллаһ аңа ирек куя, яман юлдан китсә дә, яхшы юлдан китсә дә—кеше ирекле. Бәндә эшләгән һәр гөнаһысы, гаебе, хатасы вә кылган яманлыгы өчен Аллаһ каршысында үзе җавап бирә. Шуңа күрә: яманлык та Аллаһтан килгәч, мин гөнаһлы түгел, дип үз әшәкелекләрен акларга маташучылар алай гына котыла алмас. Ул яманлыкны эшләмәсәң дә була иде бит.)*

**80.** Рәсүлгә итагать иткән кеше, чынлыкта, Аллаһка итагать иткән булыр. *(Ул итагатьтән)* йөз чөергәннәргә килгәндә, сине алар артыннан күзәтүче, сагалаучы итеп җибәрмәдек. *(Син алар өчен җавап бирмисең.)*

**81.** Алар:

—Башөсте, без итагать иттек!—диләр. Әмма синнән аерылгач та, аларның бер өлеше төннәрен яшертен-пошыртын гына син әйткәннәрнең киресен эшли. Аллаһ та аларның яшертен эшләрен язып бара. Син алардан аерыл. Аллаһка тәвәккәлләү. Вәкил буларак, сиңа Аллаһ житәр.

**82.** Ни өчен кешеләр Коръән турында дөрес фикерләмиләр икән? Әгәр дә ул *(Коръән)* Аллаһтан башка зат тарафыннан күндерелгән булса, анда *(Коръәндә)* каршылыклар булыр иде.

**83.** Аларга иминлек яки куркыныч хәбәр килсә, алар моны башкаларга сөйли; хәлбуки, бу турыда Рәсүлгә яки үзләренең хөкемдарларына житкерсәләр иде, эшнең асылын аңлаганнар, аның ни икәнен белгән булырлар иде. Аллаһ сезгә нигъмәт бирмәсә, рәхмәтле булмаса иде, һичшиксез, бик азыгыздан башкасы шайтанга ияреп китәр иде.

**84.** Аллаһ юлында сугыш. Үзеңә йөкләтелгәннән башкасына син җаваплы түгел. Мөэминнәрне үгетләп рухландыр. Бәлки Аллаһ кяферләрнең һөҗүмен тыяр. Аллаһның кодрәте вә җәзасы дәһшәтледер.

**85.** Кем берәр игелеккә арадашчы булса, ул эштән аңа да өлеш *(савап)* чыгар. Кем әшәкелек кылучыга арадашлык итсә, аның да өлеше шул әшәкелектән булыр. Аллаһ һәрнәрсәгә хакимдер.

**86.** Сәлам *(бүләк)* биргәнгә сез аннан да матуррак *(артыграк)* сәлам *(бүләк)* бирегез. Яки аны тигез сәламләгез *(бүләкләгез)* Шик юк ки, Алаһ һәр нәрсәне хисапта тота.

*(Ислам дине килгәнгә кадәр гарәпләр исәнләшкәндә: хайяк Аллаһ!—дип сәламләшә торган булалар, ягъни: Аллаһ сиңа озын гомер бирсен, дигән сүз. Җәфа белән, интегеп, юксыллыкта озын гомер кичерү бәхет була алмый. Сәламәт булып, муллыкта, сәгадәттә яшәү бәхет. Шуңа күрә, исламда: әссәләмүгаләйкүм! Ягъни, дөньяда да, Ахирәттә дә сәламәт яшәгез! рәвешендә сәлам бирү канунлаштырылды. Берәрсе безгә: әссәләмүгаләйкүм вә рахмәтуллаһ, дисә, без аңа җавап итеп: вә бәрәкәтүһү, дип өстәп куярга тиешбез. Яки: әссәләмүгаләйкүм, дисәләр, без: вә гәләйкүм әссәләм, дибез. Ягъни: сиңа, синең йортыңа, бу дөньяда да, Ахирәттә дә иминлек, сәламәтлек телим, дигәнгә без: сиңа да шуны ук телим, дибез икән. Бу аять бары тик сәлам бирешү, сәлам алышу турында гына түгел. «Сәлам» сүзендә игелек, яхшылык мәгънәләре дә бар. Сәламгә җавап—сәлам бирү, ул игелеккә җавап итеп, игелек эшлә, дигән сүз дә».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**87.** Аллаһның Үзеннән башка Илаһи кодрәткә ия һәм Тәңре булырдай һичберкем юк, әлбәттә, Ул сезне Кыямәт көнендә бергә туплаячак; монда бернинди дә шик булуы мөмкин түгел. Сүздә тору мәсьәләсендә Аллаһтан да вәгъдәлерәк кем бар?

**88.** Сезгә ни булды? Монафикъләр мәсьәләсендә икегә аерылдыгыз. Гәрчә, Аллаһ кылмышларына күрә аларны йөзтүбән китерде. Аларны Аллаһ җибәргән тугры юлга кире бормакчы буласызмы? Аларны Аллаһ адаштырган юлдан чыгарырга тугры юл табалмассыз.

**89.** Үзләре кебек кяфер булуыгызны теләгәннәр белән дуслашмагыз. Алар йортларын ташлап чыкканга *(Аллаһ юлы белән башка җиргә күчеп киткәнгә, һиҗрәт иткәнгә, ягъни мөселманлыкка күчкәнгә)* чаклы. Әгәр дә алар йөз чөер*(еп, сезне сатса, сезгә хыянәт ит)*сә, аларны тотыгыз, тоткан җирдә үтерегез вә аларның берсен дә дус яки булышчы итеп алмагыз, әгәр дә **(90)** алар сезнең белән солых төзегән халыктан булмаса яки алар, пошаманга төшеп, сезнең белән дә, үз халкы белән дә үзара да сугышмаска карар кылган булмасалар. Аллаһ ихтыяр итсә, аларның күңеленә сугышу теләге кертер иде, алар сезнең белән сугышыр иде. Әгәр дә алар сугыштан баш тартып, читкә китсәләр, сезне солыхка чакырсалар, ул вакытта Аллаһ сезгә аларга каршы барырга юл куймас.

*(Бу урында Пороханың аңлатмасын бирү урынлы булыр. «Тәүәлләү» сүзен Саблуков та, Крачковский да «йөз чөерү яки баш тарту» дигән мәгънәдә тәрҗемә иткәннәр. Башка тәфсирләрдә дә шуңа якынрак аңлатмалар бар. Ләкин игътибарга лаек гарәп тәфсирләрендә ул сүз «солыхка, сугыш кырындагы хыянәт» дип языла килә. Әлбәттә, хыянәтчене тоткан җирдә үтерергә кирәк. Бер карашка гаделсез, рәхимсез күренгән аятьнең мәгънәсе әнә шулай ачыклана.)*

**91.** Сезнең ышанычны, үз халкының да ышанычын казанырга тырышучыларны да очратырсыз. Андыйларны фетнәгә кыстасалар, баш-аяклары белән фетнәгә катнашырлар. Әгәр алар сездән ераклашмасалар, солых тәкъдим итмәсәләр, сезгә кулларын озайтсалар *(һөҗүмнәрен туктатмасалар)*, аларны якалагыз, очраткан җирдә үтерегез. Менә шулай итеп, сезгә шундый мөмкинлек бирдек.

**92.** Ялгышлык белән булмаганда, мөселманны мөселман үтерергә тиеш түгел. Ялгышлык белән мөселманны үтергән кеше бер мөселман колын азат итәргә

тиеш вә мәрхүмнең гаиләсенә кан салымы түләргә тиеш, әгәр мәрхүмнең гаиләсе, киң күңелле буларак, ул салымнан баш тартса гына инде. Үтерелгән мөэмин сезгә дошман гаиләдән булган чакта, бер мөэмин колны азат итү зарур. Мәрхүм сезнең белән дус кавемнән булса, гаиләсенә кан салымы һәм бер мөэмин колны азат итү тиеш. Бу шартларны үти алмаган кеше исә, аның тәүбәсен Аллаһ кабул итсен өчен, ул кеше тоташтан ике ай ураза тотарга тиеш. Аллаһ барысын да белә, Ул—хикмәт ияседер. **(93)** Кем дә кем мәкер белән кеше үтерсә, эчләрендә дөрләп ут янган җәһәннәм аның мәңгелек җәзасыдыр. Аллаһ аңа газап бирер, ләгънәт орыр вә аның өчен авыр җәза хәзерләр.

(*«Исламның җәза кануннарына күрә, бер мөселманны хаксызга яки мәкер белән үтергән кешенең җәзасы: үлемгә—үлем. Мәрхүмнең гаиләсе үтерүчене гафу итә ала. Гаилә үлемгә—үлем урынына кан салымы таләп итү мәрхүм гаиләсенең ихтыярында. Бер мөэминне ялгышлык белән, мәсәлән, ау вакытында, сугыш вакытында дошман дип белеп үтергән кешегә дә һәм мәгънәви, һәм Ахирәт җәзалары бар. Мәрхүмнең гаиләсе мөселман булса, ике җәза тиеш. Мәрхүмнең гаиләсенә биреләчәк кан салымы: йөз дөя яки башка төрле маллар белән түләнә. Кан салымын үтерәннең гаиләсе түли. Бу бәһане түли алмаса, ул дәүләттән ярдәм сорый. Икенче җәза, ялгышлык белән кеше гомерен өзгән үтерүче бер мөселман кешесен коллыктан азат итә, мөселман санын тулыландырыр өчен. Кол азат итәргә көче җитмәгән үтерүче ике ай тоташтан ураза тотар»*.

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**94.** Әй, иман китергәннәр, Аллаһ юлында сугышырга чыкканда сак булыгыз. Сезгә сәлам биргәнгә, фани дөньяның вакытлыча малына кызыгып:

—Син мөселман түгел!—димәгез.

Чөнки Аллаһның хозурында бик күп мал бар. Әүвәлендә сез дә шундый идегез, әмма Аллаһ сезгә рәхимле булды. Шуңа күрә, акны карадан аера белегез. Шик юк ки, Аллаһ бөтен кылмышларыгыздан хәбәрдар.

**95.** Сәбәп белән *(сугышка бармый)* калган мөселманнардан башка, өендә *(сәбәпсез)* утырып калган мөселманнар Аллаһ юлында малларын, җаннарын кызган-мыйча, Җиһад сугышына биргән мөселманнар белән бер тигез булмас. Аллаһ Җиһад юлында малларын, җаннарын кызганмаганнарны өйдә утырып калганнардан өстен итте. Гәрчә, Аллаһ аларның барысына да гүзәллек *(оҗмах)* вәгъдә итсә дә. Әмма мөҗәһидләрне *(иман өчен сугышучыларны)* өйдә калганнарга караганда гаять олы әҗер белән бүләкләячәк. **(96)** *(Аларга)* Аллаһ дәрәҗәләр, ярлыкаулар вә рәхмәт бирде. Аллаһ ярлыкаучы вә гөнаһларны кичерүчедер.

**97.** Үзләренә үзләре кыенлыклар китергәннәрнең җаннарын алганда фәрештәләр:

—Нәрсә генә эшләдегез соң сез?—дип сорарлар. Алар исә:

—Без Җир йөзендә *(кяферләр арасында)* бичара идек,—дип җавапланыр.

Фәрештәләр:

—Аллаһның биргән җире сезгә киң түгел идемени? Һиҗрәт итәргә кирәк иде,—дип әйтерләр.

Менә шундыйларның барачак җире—тәмугтыр. Аһ, ул бик тә хәтәр җирдер. **(98)** Бичарадан гаҗиз булып, мескенлектә булган ирләр, хатыннар, балаларны, күченергә көче җитмәгәннәрне **(99)**, бәлки, Аллаһ гафу да итәр. Аллаһ ярлыкауга әзер тора, Ул—кичерә белүче.

**100.** Аллаһ юлында һиҗрәт иткән кеше Җир йөзендә үзенә яшәрлек матур урын һәм муллык таба алыр. Кем Аллаһ вә Рәсүленә йөз тотып, һиҗрәт итәр өчен, өен-ватанын ташлап китеп, шунда үз үлемен тапса, аның әҗере Аллаһ тарафыннан бирелер. Аллаһ—юмарт ярлыкаучы вә кичерүче.

(*«Кяферләрнең рәнҗетүләренә чыдый алмыйча, мөселманнарның йорт-җирләрен, малларын ташлап, Мәккәдән Мәдинәгә күченеп китүе «Һиҗрәт» дип атала. Милади белән 622 елда сәхабәләре белән хәзрәти Мөхәммәд Мәдинәгә күчә. Аллаһ өчен, иман саклау максаты илә Рәсүлгә ияреп, алар яңа җирдә яңа тормыш корып яши башлыйлар. Кяферләр золымында яшәүче башка җирдәге мөселманнар да торган урыннарын ташлап, Мәдинәгә күченәләр.*

*Хәлсезләр, хасталар, көчеп китәргә матди-бәдәни көче җитмәгәннәрдән башка, барча мөселманнарга да һиҗрәт итү зарур кылынды. Күчәр мөмкинлекләре булган хәлдә дә, иманнарын коткарып калу форсатыннан файдаланмыйча, малларын кызганып, йорт-җирен калдырасы килмичә, кяферләр арасында калып, нинди җәфалар, кимсетүләр кичерергә мәҗбүр булганнарга киная. Һиҗрәт турындагы аятьләр иңгәчтен, Мәккәдә яшәүче бер хаста мөселман күп акча биреп, үзен Мәдинәгә чаклы күтәреп барырга кешеләр яллый. Ләкин юлда барганда үлә. Бохариның бер хәдисендәгечә, мөселманнар Мәккәне алганнан соң, һиҗрәт зарурлыгы да юкка чыга. Шартлар үзгәрә торган саен, зарурлыклар да үзгәрә».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**101.** Дөнья буйлап сәяхәт иткән чагыгызда кяферләр тарафыннан сезгә һөҗүм куркынычы яныйи икән, намазны кыскартып укысагыз, гөнаһ булмас. Шик юк ки, кяферләр сезнең ачык дошманнарыгыз. **(102)** Мөэминнәр белән бергә булып, аларга намаз укытканда, аларның бер өлеше, коралларын яннарына куеп, синең белән бергә намаз укысын. Шулай итеп, намазда сәҗдә иткән чакта башкалары арка тарафта сакта торсыннар. Соңра намаз укымаганнары синең янга килеп, намаз укысыннар вә алар да саклану йөзеннән коралларын яннарына алсыннар. Кяферләр алар сезнең коралларыгыз, кирәк-яракларыгызның саксыз калуын чамалап, өстегезгә ташланырга әзер тора. Әгәр дә сез янгырдан җәфа чиксәгез яки хаста булсагыз, коралларыгызны бер кырга куеп торудан сезгә гөнаһ юк. Ләкин барыбер сак булыгыз. Шик юк ки, кяферләргә хур итүче газап әзерләнгән. **(103)** Намазны бетергәч, аягүрә дә, утырып та, уң якка кырын ятып торганда уегыз Аллаһка юнәлгән булсын. Иминлек вакытында да намазны калдырмагыз. Чөнки намаз мөселманнарның төгәл вакытларда укылырга фарыз ителгән гыйбадәтедер.

(*«Сәфәрдә, сәяхәттә йөргәндә дүрт рәкәгатьле намазлар ике рәкәгать белән укыла. Сиксән-туксан чакрым арага юлга чыккан һәр мөселманның шулай кылырга хокукы бар. Сугыш вакытында, дошманның һөҗүм итү куркынычы булганда, гаскәрләрнең бер өлеше сакта тора, икенчеләре бер рәкәгать намаз укый, аннан соң алар чиратлашып алмашалар».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**104.** Дошманнарыгызны эзәрлекләгәндә ару-талуны белмәгез. Сезгә читен булса, аларга да читен бит. Шулар өстенә сез Аллаһтан алар өмет итә алмаганнарны өмет итә аласыз. Аллаһ—гыйлем вә хикмәтләр ияседер.

**105.** Хактыр ки, кешеләр арасында Аллаһ өйрәткәнчә хөкем йөртсен дип, сиңа Китап иңдердек. Хаиннәрне *(хәтта мөселман булса да)* якларга алынма.

(*«Зафәр угылларыннан Тагмә бине Убәйрык исемле мөселман күршесе яһүд Катабәнең бер җиз көбәсен (сугыш киемен) урлый, аны он капчыгына сала. Капчыкны Зәед бине Сәмин атлы бер яһүднең өенә яшерә. Капчыкның төбе тишек булып, он юл буйлап сибелеп бара. Тагмә көбәне алмадым, дип ант итә. Яһүди дә көбәне алмаганы турында әйтә. Зафәр угыллары Тагмә файдасына шаһитлек кылып, Рәсүлүлла саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнән Тагмәне аклавын таләп итәләр. Пәйгамбәребез бу таләп алдында каушап калган кебек була. Ул Аллаһтан хәбәр көтәргә карар кыла һәм шуннан соң бу аятьләр иңдерелде».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**106.** Вә Аллаһтан ярлыкау сора, чөнки Аллаһ ярлыкаучы вә мәрхәмәтле.

**107.** Үзләренә хыянәт иткәннәрне яклама, Чөнки Аллаһ хаинлекне һөнәр итеп сайлаганнарны һәм гөнаһкярларны сөймәс.

**108.** Кешеләрдән яшерә алсалар да, Аллаһтан яшерә алмаслар. Гәрчә төннәр буе Аның ризасына каршы сүзләр сөйләп, астыртын эшләр маташтырсалар да, Аллаһ алар янында булыр. Аллаһ хыянәтчеләрнең гамәлләрен чорнап алучыдыр.

(*«Тагмә мөселман иде. Угрылык кылмадым, дип ант итте. Рәсүлебез аның сүзенә ышанган кебек булды. Яһүдләр төннәрен бер урынга җыелып: мөселман булганына күрә, Мөхәммәд Тагмәне яклаячак, гөнаһысы булмаса да, яһүдне хөкемгә тарттырачак, дип сөйләшәләр».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**109.** Ярый, сез дөньяда аларны якладыгыз, ләкин Аллаһка каршы *(ягъни ялган шаһитлек кылган, алдашкан, урлашкан, зина кылган)* кешеләрне Кыямәт көнендә, вәкил буларак, кем якларга алыныр?

**110.** Яманлык кылып та, үзенә зыян эшләп тә, соңра Аллаһның гафу итүен теләсә, Аллаһ ярлыкар, гафу итәр.

**111.** Гөнаһ эшләгән кеше үзенә зыян эшләгән кеше булыр. Аллаһ барысын да белә, Ул—хикмәтләр ияседер.

**112.** Кемдер ялгышмы, ялгышмыйчамы хаталанса яки гөнаһ кылса, соңыннан гаебе булмаган кешегә үз кылганын сылтаса, хактыр ки, яла ягучы зур гөнаһка тарган кеше булыр.

*(Хата, ялгыш—гөнаһ түгел. Аллаһ хаталарны, ялгышларны бәлки кичерер. Иң куркынычы—зур гөнаһлар.)*

**113.** Әгәр дә Аллаһның сиңа булган мәрхәмәте вә химаясе булмаса иде, аларның бер өере сине юлдан яздырырга тырышкан булыр иде. Алар бары тик үзләрен адаштырдылар. Сиңа һичбер зарар эшли алмадылар. Аллаһ сиңа Китап вә хикмәтләрне иңдерде вә сиңа белмәгәненне өйрәтте. Аллаһның рәхмәте сиңа, чыннан да, киң булды.

**114.** Яшертен чыш-пыш килгәннәрнең күбесеннән файда юк. Садака бирү, кешеләрне татулаштыру турында сөйләшкәннәр болар санына керми. Аллаһның хуплавын теләп, шушы эшләрне башкарган кешегә Без озакламый олуг әҗер бирәчәкбез.

**115.** Тугры юлны *(Исламны)* табып та, Пәйгамбәргә каршы чыгып, тугры юлдан язып, яман юлга керсә, аны ярдәмнән ташларбыз, җәһәннәмгә кертербез. Аһ, бик тә хәтәр җир ул җәһәннәм.

*(«Алда искә алынган Тагмәне яклаучылар яшерен җыеннар җыеп, Тагмәне аклатыр өчен чаралар күрә башлыйлар. Аларның тырышуларына карамастан, Рәсүлуллаһ Тагмәне Мәккәгә куа. Һәм аннан ваз кичә. Тагмә моннан сабак алмый, һаман каракләша. Ахыр килеп, ул дивар ташлары астында калып һәлак була».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**116.** Аллаһка тиң этләгәнне Аллаһ кичермәс. Аннан башка гөнаһларны, теләгән кешесен гафу итәр. Аллаһка тиң этләгән кеше—туры юлны табалмас дәрәҗәдә адашкан иң зур гөнаһкяр булыр.

**117.** Алар *(мөшрикләр)* Аллаһны инкарь итеп, бары тик бер төркем т е ш е л ә р г ә табына башладылар, алар бары тик үҗәт шайтанга ияреләр.

*(**Теше**—ана җенесле пот, таш сын, агач һәйкәл. Элек ана сыннарга табыну гадәте булган. Ярдәм сорап, теләкләр теләп, дога уку, Аллаһтан башка затка ялвару—иң зур гөнаһ. Теше—ана, саулык, сыер, бия, сарык, кәҗә, дигәннәрне дә үз эченә ала.)*

**118.** Аллаһ шайтанга ләгънәт орды. Шайтан әйтте:

—Ант итәмен ки, колларыңнан үз өлешемә тигәнен алырмын. **(119)** Аларны, һичшиксез, аздырачакмын, җенси бозыклык хыялларына атармын, катгыян аларга әмер итәчәкмен: хайваннарның колакларын кисәрләр, шик юк ки, аларга Аллаһ яралтканнарны *(китапларны, динне)* үзгәртергә боерачакмын,—диде. Аллаһны инкарь итеп, шайтанга ияргән кеше зур зарарларга дучар булыр.

*(Потпәрәстләр бер потка багышлап чаласы корбан хайванының колагына тамга сала торган булганнар.)*

**120.** *(Шайтан)* аларга сүз бирер вә аларны *(ялган вәгъдәләре илә)* өметләндерер, гәрчә шайтанның вәгъдәләре ялганнан башка була алмый. **(121)** Менә шундыйларның урыны—җәһәннәмдер. Аннан качып котылырлык җир таба алмаячаклар.

**122.** Иман китергәннәрне вә игелек кылганнарны мәңге шунда яшәр өчен үзәннәреннән чишмәләр агып яткан җәннәтләргә урнаштырачакбыз. Аллаһ боларны хакыйкать буларак вәгъдә итте. Сүз бирү һәм вәгъдәдә тору ягыннан Аллаһтан да гадел кем бар?

**123.** Бу *(җәннәткә керү-кермәү)* сезнең хыялларыгыздан тормый, бу китап тотканнарның хыялыннан да килми, яманлык кылган кеше кылганының җәзасын күрер вә Аллаһтан башка дус та, ярдәмче дә табалмас.

(*«Кайбер мөселманнар белән китаплы халык: гөнаһ кылсак та безне пәйгамбәребез коткарачак, без газап күрмәячәкбез, дип хыяллана».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**124.** Ир кешеме ул, хатынмы—игелекле эш кылган һәр мөселман җәннәткә керер вә зәррә кадәр дә хаксызлык күрмәс.

*(Зәррә—матдәнең иң кечкенә кисәкчеге атом, бөртек.)*

**125.** Гадел эшләр кылып, үзен Аллаһка багышлап, Ибраһим хәнифнең Аллаһны бер дип таныган динендә булган кешедән дә мәһабәт дини кеше булырмы икән? Аллаһ Ибраһимны үзенә дус итте.

**126.** Күкләрдә вә Җирдә ни булса—барысы да Аллаһның милкедер. Аллаһ барысын да Үз кочагында *(идарәсендә)* тота.

**127.** Синнән хатыннарга кагылышлы шәригать хөкемнәрен сорыйлар. Әйт син:

—Аларга кагылышлы хөкемнәрне сезгә Аллаһ болай аңлата. Аларга Китапта язылганны *(мирасны, мәһәрне)* бирмичә никахлашырга теләсәгез, ятим хатыннар, бичара балалар вә үксезләр белән гадел мөгамәләдә булырга тиешлегегез хакында сезгә укылган аятьләр бар. Гаделлек кылсагыз, Аллаһ аны белеп тора,—диген. **(128)** Әгәр бер хатын иренең үзен ошатмавын сизсә яки үзеннән бизгәнен аңлап та, үзара килешенеп, аерылмыйча яшәсәләр, гөнаһ юк. Килешү һәрвакыт хәерлерәк. Кешенең эчендә һәрвакыт көнләшү-саранлык яши. Әгәр татуланып, *(хатыныгызны рәнҗетүдән)* саклансагыз, игелек кылып, яхшы яшәсәгез, хәерлерәк булыр. Шик юк ки, Аллаһ сез кылганнардан хәбәрдар. **(129)** Бик теләсәгез дә, сез хатыннарыгызның барысына да тигез гаделлек итә алмассыз, берсенә генә тартылып, башкаларын ирле килеш, тол хәлендә мәхрүм калдырмагыз. Әгәр араларыгыз татуланса, гөнаһтан курыксагыз; шик юк ки, Аллаһ ярлыкар вә кичерер.

(*«Берничә хатын белән гомер кичерү ир кешенең гадел булуын таләп итә. Һәм матди яктан ир кеше хатыннарын тигез карарга, торыр-ятар урыннар, ашау-эчү, бизәнү, киемсалым, бүләк-санак тигез булырга, икәүдән-икәү генә калу вакытларын да ир кеше тигез бүләргә тиешле. Хис вә мәхәббәт мәсьәләсендә, әлбәттә, аларның барысын да тигез ярату мөмкин түгел, әмма бар нәрсәнең дә аларга тигез бүленүе зарури».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**130.** Әгәр ир белән хатын аерылыр булса, Аллаһ аларны әүкатьле итәр өчен, икесенә дә үзенең чиксез хәзинәсеннән мул өлеш бирер. Аллаһ чиксез юмарт, хикмәтләре төкәнмәс.

(*«Бар чараларны куллануга карамастан, ир-хатын арасы төзәлмәсә, өй эче җәһәннәм кебек булачак, шуңа күрә, ул җәһәннәмнән котылу өчен, аерылу мөмкинлеге дә бар. Аллаһ капкаларны ачар».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**131.** Күкләрдә, Җирдә ниләр булса—барысы да Аллаһның милке. Сездән элек яшәп киткәннәргә дә, Китаплы булганнарга да:

—Аллаһтан куркыгыз!—дип боердык.—Инкарь итсәгез, белегез, күкләрдә, Җирдә ни булса—барысы да Аллаһныкыдыр. Аллаһ чиксез бай, чиксез мактауга лаек. **(132)** Күкләрдә вә Җирдә ни булса—барысы да Аллаһныкы. Химаяче буларак, Аллаһ берүзе җитәрлек *(башка уйдырма тәңрегә ихтыяҗ юк)*. **(133)** Һәй, кешеләр, Аллаһ сезне юкка чыгарып, башкаларны бар итә ала. Аллаһ мондый кодрәткә ия.

**(134)** Кем дә кем дөнья нигъмәтләрен теләсә, ул нигъмәтләр дә, Ахирәт әҗерләре дә Аллаһ хозурындадыр. Аллаһ барысын да ишетә, барысын да күрә.

**135.** Һәй, иман китергән кешеләр, гаделлекне бозмыйча, үзегезгә зыян булса да, ата-анагыз вә туганнарыгызга каршы килеп булса да, Аллаһ кушканча, дөрес шаһитлек кылучылар булыгыз. *(Гаделлектә шаһитлек иткәннәр)* бай булсалар да, фәкыйрь булсалар да, Аллаһ каршында алар тигез. Хискә *(нәфесегезгә)* бирелеп, тугры шаһитлектән качмагыз, дәлилләрне иеп-бөгеп бозсагыз яки шаһитлектән баш тартсагыз, Аллаһ барысын да белеп торыр. **(136)** Һәй, иман китергәннәр, Аллаһка, Пәйгамбәренә, аңа индерелгән Китапка, аннан алда индерелгән китапларга да иман китерегез. Кем Аллаһны, фәрештәләрен, китапларын, пәйгамбәрләрен вә Кыямәт көнен инкарь итә, шул тәгәл мәгънәсендә кире чыга алмаслык дәрәҗәдә юлдан язган булыр. **(137)** Иманга килеп тә, соңыннан *(Аллаһны)* инкарь итеп, аннан соң тагын иман китереп, янә кяферлеккә күчкәннәрне Аллаһ ярлыкамас та, аларны тугры юлга да кайтармас. **(138)** Монафикъларлардан «сөенче ал»: аларга әче җәза газаплары әзерләнгән. **(139)** Мөселманнарны ташлап, кяферләрне дус иткәннәр: алар янында мәртәбә казаныр-быз, дип өметләнәләрме? Белеп торсыннар ки, бөтен мәртәбәләр бары тик Аллаһ кулында гына. **(140)** Ул *(Аллаһ)* Китапта сезгә шуны иңдермеш ки, Аллаһның аятьләрен инкарь итеп яки аларны мәсхәрәгә калдырырга тырышып сөйләүчеләрне ишеткәч тә, алар башка бер сүз башлаганчыга чаклы кяферләр белән бергә утырмагыз, юкса, сез дә алар кебек булырсыз. Әлбәттә, Аллаһ монафикъларның вә кяферләрнең барысын җәһәннәмгә туплаячак. **(141)** Сезнең кылмышларыгызны күзәтеп торучылар *(монафикълар)*, Аллаһ сезгә җиңү китерсә:

—Без дә сезнең белән бергә булдык бит,—диярләр.

Әгәр дә кяферләргә җиңү килсә, алар:

—Мөселманнарны җиңәргә ярдәм иттек, мөэминнәрдән коткарып калдык түгелме?—диярләр.

Кыямәт көнендә Аллаһ арагыздагы бу бәхәсне хөкем итәчәк вә мөэминнәргә зыян китерерлек юлны кяферләргә бирмәячәк. **(142)** Шик юктыр ки, монафикълар хәйлә корып, Аллаһны алдарга өметләнә, гәрчә, Аллаһ аларның хәйләләрен үз башларына каплаячак. Алар намазга иренеп кенә торалар, кеше күрсен өчен генә *(дога)* укыйлар. Аллаһны бик сирәк искә алалар. **(143)** Алар арасында аптыраган-йөдәгән булып йөрүчеләр дә күп. Ни боларга *(мөселманнарга)* иярмиләр, ни тегеләргә *(кяферләргә)* сыенмыйлар. Шундый адашканнарга чыгар юл табылмас.

**144.** Әй, иман китергәннәр, мөэминнәрне ташлап, кяферләрне дус итмәгез. Алай эшләп, сез Аллаһка каршы икәнлегегезгә дәлил хәзерләрсезме?

*(Мәҗбүрият булганда, уртак эш корганда кяферләр белән мөэминнәр арасында килешүләр, татулык булырга тиеш, әмма дуслык тирәнрәк мәгънәне үз эченә ала.)*

**145.** Шик юк ки, монафикълар җәһәннәмнең иң аскы катында булачак. Аларга инде һичбер ярдәмче табалмассың.

**146.** Бары тик тәүбә итеп, хаталарын төзәткәннәр, катгыян Аллаһка сыенганнар, Аллаһ өчен генә дин тотканнар башка кавемнән булыр. Андыйлар мөселманнар белән бергә булыр.

Озакламый Аллаһ мөэминнәргә олы әҗер бирәчәк. **(147)** Әгәр сез иман китереп, шөкерләр кылсагыз, Аллаһ сезне ни өчен газапка салсын, ди! Аллаһ шөкер итүчеләрне бүләкли. Ул барысын да белеп тора.

**148.** Сүгенү сүзен кычкырып әйткәннәрне Аллаһ сөймәс. Фәкать гаделсезлеккә дучар булган кешедән башка. Аллаһ барысын да ишетеп, күреп тора.

*(«Жирәнгеч сүз, кеше артында сөйләү, гайбәт сүзе йөртү, нахак яла тагу, ялган сөйләү, мыскыл сүзе—барысы да көфер сүзләрдер. Әйтәсе килгән чакта да ул сүзләрне әйтүдән тыелып калу яхшы. Бары тик хаксызга рәнҗеш, кимсетү күргән кеше генә, чыдар әмәле калмагач, гаепле кеше өстеннән яза ала, сөйли ала, аның турындагы начар фикерен кычкырып әйтә ала».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**149.** Игелекле эшегезне башкаларга бәян итсәгез дә, ул турыда дәшми калсагыз

да яки ямանлыкны да *(кешегә сөйләмичә)* гафу итсәгез дә була. Шөбһәсез, Аллаһ артыгы белән гафу итүче һәм кодрәт ияседер.

**150.** Аллаһны, пәйгамбәрләрне инкарь иткәннәр вә Аллаһ белән пәйгамбәрләрне бер-берләреннән аерырга теләгәннәр:

—Бу пәйгамбәргә инаныгыз, бусына инанмагыз,—дип әйтүчеләр, шулай итеп, аерым бер *(ни урталай, ни пурталай)* юлны тотарга теләүчеләр юкмыни? **(151)** Менә чын кяферләр шулардыр. Һәм без ул кяферләргә үзәкләрне өзә торган җәзалар әзерләдек.

**152.** Аллаһка, пәйгамбәрләргә иман китергәннәргә һәм аларны берберсеннән аерып карамаган адәмнәргә килгәндә, менә шуларга инде Аллаһ Тәгалә көннәрдән бер көнне олуг бүләк тапшырачак. Аллаһ—юмарт ярлыкаучы вә кичерүчедер.

**153.** Китаплы халык үзләренә Күктән Китап *(белем)* индерелүен тели. Алар Мусадан монысыннан да зурракны таләп иткәннәр иде.

—Безгә Аллаһны күрсәт,—диделәр.

Шул көферлекләре аркасында аларны яшен сукты. Соңра ачык дәлилләр килгәч тә, алар бозау сынын тәңре иттеләр. Без моны да гафу иттек. Һәм Мусага ап-ачык хөкем итәр өчен дәлил *(Тәүратны)* бирдек. **(154)** Аларны ант иттерер өчен өсләренә Тур тавын кордык та аларга:

—Баш иеп капкадан узыгыз. *(Тыелганны эшләп)* шимбә көн чикләреннән чыкмагыз,—дидек. Үзләреннән ант сүзе алдык. **(155)** Антларын бозып, Аллаһның аятьләрен инкарь итеп, хаксыз рәвештә пәйгамбәрләрне үтергәннәре өчен вә:

—Күңелләребез каплаулы,—дигәннәренә күрә, *(аларга ләгънәт ордык, башкаларына бәлаләр китердек. Аларның күңелләре каплаулы түгел иде)* көферлекләре сәбәпле, Аллаһ ул күңелләргә йозак салып куйды, аларның бик азы гына иман китерер. **(156)** Аллаһны инкарь итеп, кяфер булганнары өчен һәм Мәрьям турында әшәке гайбәт таратканнары өчен *(җәзаладык).*

*(Мәрьям Гайсә (галәйһиссәлләм)не тапкач, яһүдиләр: Мәрьям уйнаштан бала тапты, дип ялган хәбәр тараттылар.)*

**157.**—Аллаһ илчесен—Мәрьям углы Гайсәне үтердек,—дигәннәре өчен *(аларга ләгънәт ордык).* Гәрчә, аны үтермәделәр дә, асамадылар да, фәкать *(үтерелгән бәндә)* аларга Гайсә булып күренде.

Аның турысында бәхәс кузгатучылар икеләнеп калдылар, шикле фаразларыннан башка, алар кулында һичнинди дә дәлил юк, чынын да, алар аны үтермәде.

*(«Яһүдләр хәзрәти Гайсә пәйгамбәрне үтерергә булдылар. Алардан качып, хәзрәти Гайсә бер өйгә керде. Дошманнар аны куа килеп, Гайсә кергән өйгә бер кешене кертеп җибәрделәр. Ләкин бу вакытта Аллаһ Гайсәне күккә күтәреп өлгергән иде инде. Кергән кеше Гайсә кыяфәтендә өйдән чыкты, тегеләре аны Гайсә диеп белеп, тотып алдылар да, үтереп, ботынчатын аерып, агачка кадаклап куйдылар. Аллаһ Тәгалә Нух пәйгамбәрне Туфан суыннан, Ибраһим галәйһиссәлләмне—уттан, хәзрәти Мусаны—Фиргавеннән, Мөхәммәд Мостафаны мөшрикләр тозагыннан коткарганы кебек, Гайсә хәзрәтне дә яһүдләр кулыннан коткарды. Тегеләргә ялагайланып, Гайсәне саткан хаинне Гайсә сурәтенә кертеп, Аллаһ аннан да үч алды».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**158.** Юк, аны үтермәделәр. Аллаһ аны үз хозурына алды. Аллаһ гыйззәт вә хикмәт иясedер. **(159)** Китаплы халыктан һәр кеше үлеме алдыннан, мотлакан, *(Гайсәгә)* иман китерәчәк *(ләкин аларның тәүбәсе кабул булмас).* Кыямәт көнендә ул *(Гайсә)* аларга каршы шаһит булачак.

**160.** Золым иткәннәре өчен, күп кешеләрне Аллаһ юлыннан яздырганнары өчен, яһүдләргә элек хәләл ителгән саф вә затлы нәрсәләрне харам кылдык. **(161)** Аллаһ тарафыннан катгыян тыелган булса да, риба алганнары, хәйлә белән кеше малларын әрәм итеп, ашаганнары өчен, алар арасындагы кяферләргә сызландыргыч җәзалар әзерләдек.

**162.** Ләкин араларында тирән белемле булганнарга вә мөэминнәргә: синә

индерелгәнгә вә синнән элек индерелгәннәргә иман китерүчеләргә, намаз укучыларга, зәкят бирүчеләргә, Аллаһка вә Ахирәт көненә инанганнарга озакламый олуг бүләкләр бирәчәкбез.

*«Араларында тирән белемле булганнарга» тәгъбирен тәфсирчеләр төрлечә аңлата. Ногманида «белемгә ирешкән Ислам галимнәре» диелгән. Крачковскийда: «твердые в знании из них», диелгән. Ягъни белемле яһүдләргә киная итә кебек. Хәсән Чантай һәм Али Өзәк тәфсирләрендә дә алар, ягъни яһүдләр «мөэминнәр» сүзе белән аерым килә. Уфа китап нәшриятында чыккан тәрҗемәсеннән ул тирән белемлеләр яһүдме, мөселманнармы икәне ачык күренми. Пороховада тирән китап гыйлеменә ия булган яһүдләр турында әйтелә. Исламны кабул итмәсәләр дә бу галимнәр Мөхәммәднең якын дуслары булган, имеш.)*

**163.** Без Нухка вә аннан соң килгән пәйгамбәрләргә вәхий кылган кебек, сиңа да вәхий күндердек. Һәм Ибраһимга, Исмәгыйльгә, Исхакка, Ягъкубка, торыннарына, Гайсәгә, Әйюбкә, Юныска, Һарунга вә Сөләйманга вәхий күндердек. Даутка да Зәбурны бирдек.

**164.** Синнән әүвәл килгән байтак кына пәйгамбәрләр турында сиңа сөйләдек, байтаклары турында сөйләмәдек. Вә хактыр ки, Аллаһ Муса белән, чынлап та, сөйләште.

*(Хәдисләрдә Җир йөзенә меңнәрчә пәйгамбәрләр килеп киткәнлеге турында сөйләнә.)*

**165.** Сөенечле хәбәрләр ташыр өчен, кисәтүче хәбәрләр китерер өчен, пәйгамбәрләр күндердек; бәндәләр пәйгамбәрләрдән соң Аллаһ каршында *(без моны белмәдек, безгә Китап иңдерелмәде, рәсүлләрне без күрмәдек, без ул эшнең гөнаһ икәнен белмәдек, белгән булсак, эшләмәгән булыр идек, дип)* сылтау табып, акланмасыннар өчен. Аллаһ гыйззәт вә хикмәт ияседер.

**166.** Сиңа *(Коръән)* иңдергәнгә бары тик Аллаһ шаһит, аны Үз гыйлеме белән иңдерде. Фәрештәләр дә шаһитлек итәчәкләр. Гәрчә, шаһитлектә Аллаһ җитәр.

**167.** Инкарьчылар, башкаларны да шул юлга күндерүчеләр, шөһбәсез, тугры юлдан еракка кереп адашканнар. **(168)** Инкарь итеп, игелексез гамәлләр кылучыларны Аллаһ ярлыкамас. Андыйларны башка бер юлга да күндермәячәк. **(169)** Аларның юлы җәһәннәмгә китереп чыгарачак. Алар анда мәңгегә калачак. Аллаһ өчен бу эш бер дә кыен түгел.

**170.** Әй, инсаннар, Рәсүл сезгә Раббыгыздан хакыйкать китерде, үз файдагызга иман китерегез. Әгәр *(Аллаһны)* инкарь итсәгез *(ихтыярыгыз)*, Күкләрдә вә Җирдә ни булса, шөбһәсез, барысы да Аллаһныкыдыр. Аллаһ—чиксез гыйлем вә хикмәтләр иясседер.

*(Ул сезнең инануыгызга мохтаҗ түгел, иман ул сезнең үз файдагыз өчен.)*

**171.** Әй, китаплы халык, динегездә артыгын кыланмагыз вә Аллаһ хакында чыннан башкасын сөйләмәгез. Мәрьям углы Гайсә *(Мәсих)*, ул бары тик Аллаһның рәсүледер, Аллаһның Мәрьямгә урнаштырган сүзе:

*( —Бар бул!—дигәненең нәтиҗәседер.)*

Шул сүздән рух пәйда булды. Шулай булгач, Аллаһка вә пәйгамбәрләргә иман китерегез. *(Тәңре)* «өч», дип әйтмәгез, үзегезгә хәерле булсын өчен, алай әйтүдән ваз кичегез. Аллаһ бер генә. Ул бала атасы булудан азат. Күкләрдә, Җирдә ни булса, шулар Аныкыдыр. Химаяче буларак, Аллаһның кодрәте чиксез.

*(«Христианнар бер Аллага ышануга килеп җитмәделәр. Алар Алла белән пәйгамбәрне бутый. Хәзрәти Муса, хәзрәти Гайсә китап әһелләренә тәүхид (Алланы бер дип тану) китерсә дә, хакыйкатьне кабул итмәделәр. Христианнар: Ходай—ата, Ходай—угыл һәм Ходай—Изге Рухтан торган Тәңре,—диләр. Ягъни, аларча, Аллаһ өч Ходайның берлегеннән хасил булып чыга. Алар өчесе аеры, өчесе берьюлы бер Аллаһ, янәсе».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән).

*(Динегездә артыгын кыланмагыз» тәгъбире Мәүланә Алидә: не нарушайте границы религии вашей; Валерия Пороховада: В религии своей излишеством не предавайтесь; Суат Йылдырымда: динегездә хәттин ашмагыз, диелгән. Бу тәрҗемәләр нигездә якын булса*

*да, аларның сизелер-сизелмәс аермалары да юк түгел. Диндә артыгын кылану фанатизмга китерсә, үз динеңнең чикләрен бозу тагын да хәтәррәк гөнаһка илтә, ике мәгънәсе дә гыйбрәтле.)*

**172.** Мәсих тә, Аллаһка иң якын торган фәрештәләр дә Аллаһның коллары булудан читенсенмиләр. Аллаһка кол булудан баш тартып, тәкәбберләнгәннәрнең барысын да Аллаһ озакламый үз хозурына туплаячак.

*(**Мәсих**—Гайсә пәйгамбәрнең бүтән исеме.)*

**173.** Иман китереп, игелек кылганнарга Аллаһ тиешенчә әҗер бирәчәк вә аларга үз хәзинәсеннән тагын да бүләк өстәячәк. Аллаһтан йөз чөергән вә тәкәбберләргә исә хәтәр газап бирер. Алар үзләре өчен Аллаһтан башка бер дус та, бер ярдәмче дә табалмас. **(174)** Әй, бәндәләр, шөбһәсез ки, сезгә Раббыгыздан катгыян бер дәлил килде вә сезгә ап-ачык бер нур иңдерелде.

*(**«Катгыян дәлил»**—ул—Мөхәммәде Рәсүлулла, «нур» исә—Коръән».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән).

**(175)** Аллаһка иман китереп, Аңа аркаланганнарны рәхмәтеннән аермыйча, нигъмәт дәрьясына чумдырачак вә аларны тугры юлга кертәчәк.

**176.** Алар синнән күрсәтмәләр көтә. Әйт син:

—Аллаһ атасы вә баласы булмаган кешенең мирасы хакында болай хөкем йөртә, диген. Баласы булмаган кеше үлсә һәм аның кыз кардәше булса, калган малның яртысы аныкы булыр. Кыз кардәш үлеп, баласы булмаса, ир кардәше аңа варис булыр. Ир үлеп, кыз кардәшләр икәү булса, калган малның өчтән икесе аларга. Әгәр дә ирле-хатынлы, тагын башка кардәшләре булса, ирнең хакы, ике хатын өлеше кадәр булыр. Ялгышмасыннар өчен, Аллаһ ачыклык кертә. Аллаһ барысын да белә.

آمين الله اكبر

## Алдагы саннарда укыгыз!

Егерменче гасырның соңгы елы төгәлләнергә дә күп калмады. Озакламый, хөрмәтле укучылар, сез кулыгызга журналның ике меңенче елдагы соңгы уникенче санын алачаксыз. Язучыларыбыз һәм редакциянең иҗади коллективы Сезне бу санда да яңа, мавыктыргыч әсәрләр белән куандырырга җыена. Ә редакция папкасында алар шактый күп. Чәчмә әсәрләр бүлегендә, мәсәлән, әдәбиятыбыз аксакалы **Аяз Гыйләҗевның "Күңелем серләре"** дип исемләнгән истәлекләренең ахыры, **Флүс Латыйфиның "Бәйсез этләрне атарга!" дигән романы** һәм **Әхсән Баяновның "Хәтер дәрьясында" парчалар** циклы дөнья күрәчәк. Поэзия сөючеләрне шагыйрьләрдән **Шәүкәт Галиев, Гәрәй Рәхим, Нур Әхмәдиевләрнең** яңа шигырьләре белән очрашулар көтә. Сәнгать бүлеге хезмәткәрләре исә татарның атаклы композиторы Салих Сәйдәшевнең тууына 100 ел тулуга багышлап музыка белгече **Шамил Монасыйповның "Сәйдәш" дип исемләнгән рухи-фәлсәфи тикшеренүен** әзерләделәр. Казан консерваториясе аспиранты **Луиза Ильясованың "Җырлыйк Төмән көйләренә"** дип исемләнгән язмасы укучыларыбызны Себер татарларының гаять тә үзенчәлекле җыр фольклоры дөньясына чакыра.

Журналда шулай ук заманыбызның үткен проблемаларын яктырткан публицистик язмалар, бүгенге әдәбият хәлләрен анализлаган тәнкыйть мәкаләләре, юмор һәм сатира әсәрләре дә урын алачак. 2001 елда беренче класс балаларының латин имлясында укый башлаячагын күздә тотып, журнал әдәби мирасыбызның иң яхшы үрнәкләрен латин имлясында бастырып чыгаруны дәвам иттерә.

*Хәтер*

# ФРОНТ ХАТЛАРЫ

*Язучы Афзал Шамовның архивында Бөек Ватан сугышы чорына караган әллә никадәр документаль материаллар ята икән: унбиш фронт блокноты, 1943-1945 нче елларда Калинин һәм Беренче Балтик буе фронтларында язучы үзе очраткан һәм алар турында материаллары булган сугышчылар исемлеге (биш йөздән артык исем!), дистәләрчә фронт газеталары, фронтта төшерелгән рәсемнәр, сугышчан листовкалар, гади солдат хатлары һәм фронтлардагы каләмдәш дусларыннан килгән хатлар...*



*Афзал Шамов. Май 1947 ел.*

*Хат авторлары арасында—сугыш кырында ятып калганнары да, сугыштан соң арабыздан киткәннәре дә бар.*

*Солдат хатлары, гадәттә, гади карандаш белән язылганнар, кайберләре, еллар үтү белән, танымаслык хәлгә килгән. Бу хатларның тагын бер кимчелеге: аларның күбесе гарәп хәрефләре яисә яңалиф белән язылганнар. Аларны укый алырлык кешеләр, бигрәк тә гарәп хәрефләре белән язылганнарын, кимегәннән кими бара. Бик күп хатлар вак, хәтта чамадан тыш вак хәрефләр белән төрле кәгазьләргә (тәмәке кәгазенә яисә әйбер төрә торган сары кәгазьгә) язылган.*

*Тылда калган язучылар да фронтовик язучылар белән һәрвакыт элемтәдә булган. Аларның хатлары исә яхшы кәгазьгә язылган, алары да бу архивта саклана.*

*Ләкин фронтовик язучылардан килгән хатлар әле башкаларыннан күбрәк тә. Мәгълүмдер ки, сугыш елларында ут эчендә йөрүче татар язучылары һәм шагыйрьләре бер-берләре белән даими рәвештә хат язышып торган. Бу хатлар язучыларның фронттагы тормышын, аларның уй-хисләрен, омтылышларын, каләмдәш иптәшләренең язмышларын, кайгыртучанлык тойгыларын, үзара иҗади дуслыкларын ачык күрсәтә. Болар—истәлекле, әдәби кыйммәткә ия хатлар...*

*Бу хатлар барысы да язучы Афзал Шамовка язылган.*

*Язучы Афзал Шамов (1901-1990) 1943 елның 5 февралендә үзе теләп фронтка китә һәм сугыш чорында татар телендә чыгып килгән «Алга, дошман өстенә» исемле хәрби газета хәбәрчесе булып хезмәт итә. Бу газета Калинин шәһәреннән Кенигсбергка (хәзерге Калининград) кадәр зур, авыр һәм каты сугышларда данлы тарихи юл уза. 1295 километрга сузылган бу юл—Калинин, Ржев, Духовщина, Невель, Витебск, Полоцк, Паневежис, Шауляй, Мемель (хәзерге Клайпеда), Кенигсберг, Пиллау шәһәрләре аша үтә. Башта ул Калинин фронты, аннары Беренче Балтик буе фронты газетасы санала.*

*Көнчыгыш Пруссиядән, Лабиау шәһәреннән башлап, 1945 елның 5 июнендә «Алга, дошман өстенә» газетасының татар редакциясе тулысынча Байкал Арты фронтына күчерелә. Японнарга каршы сугыш хәрәкәтләре башланыр алдыннан бу фронтта «Суворовча кысрыклау» газетасы оештырыла. Бу газетаның хәрби хәбәрчеләре Читадан башлап, Монголия далалары, соңыннан каты сугышлар белән Зур Хинган тауларын һәм Маньчжурия кырларын үтеп, Сунгари елгасының суын эчеп, Маньчжуриянең башкаласы Чаньчуньга кадәр барып җитә. Кытай җирләрен япон самурайларыннан азат иткәч, бу газета Хабаровск шәһәренә 1945 елның 25 ноябрендә килеп җитә. Язучы Афзал Шамов армиядән демобилизацияләнеп 1946 елның 27 апрелендә Казанга кайта.*

## Ибраһим Гази хатлары[1]

*Күренекле каләм остасы Ибраһим Гази (1907-1971) язучы Афзал Шамовның якын дусты иде. Алар 1931 елдан Казанда Татар дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында бергә озак еллар бер бүлмәдә эшләгән, бер үк вакытта фронтка киткән. И. Гази башта Көньяк, аннары Дүртенче Украин фронтларында «Сталин байрагы» исемле газета редакциясендә хәрби хәбәрче булып хезмәт итә. Аның шул вакыттагы адресы: кыр почтасы 19640-А. 1944 елның сентябрендә бу газета чыгудан туктый һәм И. Гази Беренче Белоруссия фронтында 1944 елның ноябреннән 1946 елның февраленә кадәр татар телендә чыга торган «Кызыл Армия» газета редакциясендә хәрби хәбәрче була.*

*Түбәндә мин Ибраһим Газиның язучы Афзал Шамовка язылган кайбер хатларын укучылар игътибарына тәкъдим итәм һәм аларны әдәбият сөючеләр кызыксынып укырлар дип өметләнәм.*

**Әлфия ШАМОВА,**
*Афзал Шамовның кызы.*

### Беренче хаты

*4 август, 1943 ел*

Эх, малай, Әбжәлттин, Әбжәлттин![2]

Сагынуның әче шәрабын мин дә касә тутырып эчәм аның, малай, шуңа күрә сине больше чем анлыйм. Кайвакытта, малай, әйтергә оят, тамак төпләре кытыкланып китә. Беразга гына булса да кайтып килергә мөмкин булса, Казан каласына дүрт аякланып керер идем, яна солдатский чалбарым буяла дип тормас идем. Менә ничек, малай!

Ләкин сезнең хәл—җәннәт, минеке белән чагыштырганда... Җәннәт кенә дә түгел—рай. «Ник?» дисең инде син. Кайтам дисәң, кайтаручысы бар, ара якын, аннан, ни әйтсәң дә, үз кешеләр. Это много значит. Мин бит жиде ят арасында. Житмәсә, үзем—певец, үзем—жнец, үзем—в дудку игрец. Безнең икенче литературный сотрудник каләме әлифне таяктан гына аера. Бөтен авырлык миндә—терпи минем бөкре. Ә Клиблинең *(Клибли—Гани Клеблеев; Бөек Ватан сугышы елларында башта Көньяк фронтта, аннары 4 нче Украина фронтында чыккан «Сталин байрагы» исемле татар газетасы редакторы.)* телен беләсең... Аннан ул гажәп кызык политика тота: бернәрсә дә эшләми, буквально бернәрсә дә; бер җөмлә әйбер язмый, бер кәлимә тәржемә итми. Аның б ө т е н эше—макет оештыру, ул да чиле-пешле. Калган вакытын я йоклап, я авырып, врачларга йөреп үткәрә. Мин макандировкага*( Макандировкага—командировкага. Ибраһимның, якын иптәшләре белән сөйләшкәндә, шаяртып, кайбер сүзләрне бозып, үзгәртеп әйтә торган гадәте бар иде. Хатларында да ул кайбер сүзләрне үзгәртеп яза.)* киткәч, алар бер газета чыгарганнар. Укып карау өчен жибәрәм. Аяк мәкалә *(Аяк мәкалә—баш мәкалә. Шаяртып әйтүе.)* —аның тәржемәсе. Клибли, малай, туйда [...][3]. Ләкин аның да бер яхшы ягы бар: ул бер эшкә дә тыгылмый, ягъни мешать итми—шул ягы жөдә (үзбәкләрнең «бик» дигән сүзе) яхшы. Алты ай дигәндә звание кундырдылар—младший лейтенант. Ана да бик канәгать—акчасы бар. Аннан минем хәлне беләсең бит син. Синеке белән чагыштырып булмый—жәяүле[4] идем бит мин. Менә шулай. Пауза.

---

[1]Хатларның оригиналлары язучы Афзал Шамов архивында саклана. И. Гази хатлары (№ 1, 3-6) Афзал Шамов һәм (№ 2, 7-9) Әлфия Шамова тарафыннан әзерләнде, искәрмәләр дә алар каләме белән язылды. Тарихи истәлек буларак, хатлар үзгәрешсез—редакцияләнмичә бирелә.

[2]Ә б ж ә л т т и н - Әфзалетдин, Афзал Шамов; гади халыкча әйтелеш. Ибраһим Гази мине шулай атап йөртә иде. Моның кыска гына тарихы да бар. Утызынчы елларның башында ул, минем фатирыма килгәч, әнинең мина Әбзалеттин дип эндәшүен ишетте дә, моны бик ошатып, мине шулай атап йөртә башлады, тик «з» хәрефен «ж» белән генә алыштырды.

[3]Хатларны матбугатка әзерләгәндә төшерелгән сүзләр, җөмләләр квадрат җәяләр эчендәге нокталар белән күрсәтелде.

[4]Ж ә я ү л е - бу урында рядовой мәгънәсендә.

Болай, барысын бергә җыеп алганда, ничего торабыз. Берничә (!) хикәя яздым. Берничә ай эчендә бит, ә элек ничәмә елга берәү дә язылмый иде. Материал бар да, тынычлык җитеп бетми. Ни әйтсәң дә, сугыш бит инде.

Мин сезгә бернәрсә дә җибәрә алмыйм *(Калинин фронтында чыга торган «Алга, дошман өстенә» исемле татар газетасында аның хикәяләр, мәкаләләр белән катнашуын үтенгән идем. Сүз шул хакта бара.)*, чөнки язганнарым санаулы. Миңа гел тәрҗемә белән (русчадан татарчага һәм киресенчә) шөгыльләнергә туры килә. Әгәр син җибәрә алсаң, бик яхшы булыр иде.

Ласипед[1] дигәнең кайтты шикелле инде. Ул аны илтеп бирә алмагандыр, бездә тора торгандыр. Ләкин аның тәгәрмәче өчен *(1942 елны Ибраһим, минем велосипедны алып торып, Лаеш районындагы Мирәтәк авылына барган иде, юлда велосипедым ватылган һәм ул аны авылда калдырып кайткан иде. Сүз шул турыда бара.)* синнән *(синнән бигрәк, Гадиләдән[2])* уңайсызланып торам. Сугыш бетеп, исән-сау калсак, җайларбыз.

Үзең син берәр хикәя яздыңмы, ә?

[...]

Менә шулай, малай, ят-чит җирләрдә, тәмсез су эчеп, бомбалар сызгыруы астында, кайчан муены сына инде бу Гитлерның дип, өмет белән яшибез.

Тагын берәр елга түзсәк, шаять, очы-кырые күренә башлар иде инде.

Гыймадига*(Минһаҗ Гыймадиев (1903-1970), журналист, «Алга, дошман өстенә» газетасы редакторы.)*, А. Әхмәткә *(Абдулла Әхмәт (1905-1976), язучы, шул ук газетаның штаттагы хәрби хәбәрчесе.)* сәлам!

Дусларча сәлам белән Ибраһим.

## Икенче хаты

*1 гыйнвар, 1944 ел*

Әбҗәлттин дус!

Исәнме, малай! Синең сыер теледәй хатыңны алып, күнелемнән үрле-кырлы сикердем.

Бүген 1 нче гыйнвар, (яңа ел була түгелме) бездә коеп яңгыр яуды, кыш бабаң шыр җибәреп качты, ә безнең өчен барыбер... Яңа ел—шунсы важно.

Украинаның булмыш гарный хлопецы![3] Син кечтеки генә брешешь—үткәннең бер атнасына гомеренне бирмәс идең. Ул вакытның үзенә күрә матурлыгы булса, хәзергенең үзенә күрә яме бар. Впрочем, оныта язганмын. Синең теге (исеңдәме, тагын бер күрергә дип ярты юлдан борылып кайткан) кызыңны *(Әтием 1920 елның августыннан гражданнар сугышына үзе теләп китә. Ул курсантларның 3 нче Киев бригадасы составында башта акполякларга, аннары барон Врангель гаскәрләренә каршы сугыша. Шул вакыт аңа бер украин кызы ошый. Ибраһим абый менә шул турыда шаяртып яза.)* очраттым бит, Әбҗәлттин! Картайган! Балаларын мимеч алып киткән. Алай да онытмаган сине, теге бөдрә чәчле, зәп-зәңгәр күзле, гарный хлопец кайда ул хәзер?—ди. Мин әйтәм, тегендә дим., Ш. Маннур *(Шәйхи Маннур (1905-1980), язучы. Ул «Алга, дошман өстенә» газетасы редакциясендә 1942 елның 23 декабреннән 1943 елның мартына кадәр эшли. Афзал Шамов шул ук газетада 1943 елның 7 февраленнән эшли. 1943 елның 20 мартында аны редакциянең штатына алалар, ә Ш. Маннур икенче фронтка күчә. Хәмит Ярмигә язган хатында: «... Мин теге (Калинин—Ә. Ш.) фронтта чакта передовойда булуым сәбәпле, өч айлык стаж белән кандидатлыкка үткән идем, ә монда килгәч, ул бер еллыкка әйләнде—икенче эшелон бит. Сагынып сәлам белән—Маннур (Шыяп солдат). 28.06.43.)* белән сугыша-сугыша, наконец, аны доканать итте(ләр) дим.

Гариф (*Гариф Галиев (1903-1985), язучы, Мәскәү хәрби округында «Кызыл сугышчы» исемле татар газетасы хәрби хәбәрчесе (1943 елның гыйнварыннан 1944 елның июненә кадәр бу газета чыга).)* миңа яза, шәрә батырлык күрсәткән, ди. Нинди штансыз *(Штансыз батырлык—«шәрә» сүзен шаяртып әйтүе.)* батырлык инде ул тагы? Хәрби сер булмаса, миңа да язып җибәр әле.

Син бәхетле черт возьми. Илгә *(Татарстанга, Казанга. Әтием 1943 елның октябрендә бер атнага Казанга командировкага, Калинин фронтындагы батыр татар*

[1] Ласипед - велосипед.

[2] Гадилә - тормыш иптәшем.

[3] Гарный хлопец - украин телендә «красивый хлопец».

*сугышчылары һәм офицерлары турында «Нәфрәт көче» исемле хәрби очерклар җыентыгына договор төзү өчен кайта.)* кайтып килдең, ә мина Казанны не видать, как своих ушей. Җир тишегендә торам бит. Аннан соң, бәхетме, бәхетсезлекме, мина газетаны ташлап китәргә мөмкинлек юк. Ни өчен икәнен язган идем инде.

Шулай итеп, бабасыр *(Бабасыр—сүз язучы Фатих Хөсни (1908-1996) турында бара. Ул 1943 елда бер-ике ай чамасы «Сталин байрагы» исемле фронт газетасы редакциясендә командировкада була.)* иң кәттә егет булып калган диген, ә? Җыен чатан, җыен кәкре-бөкре арасында булса да булыр. Хәер, ул Марфугасыннан *(Марфуга—Фатих Хөснинең тормыш иптәше.)*артмыйдыр әле.

Ф. Кәрим *(Фатих Кәрим (1909-1945), шагыйрь. Бөек Ватан сугышында Өченче Белоруссия фронтында алгы сызыкта була. Фатих Кәримне Беренче Балтик буе фронтында чыга торган «Алга, дошман өстенә» газетасы редакциясенә алу мәсьәләсен политуправление алдына куйган булганнар. Ләкин, «никадәр тырышсак та, аны хезмәткә ала алмадык»,—дип яза әтием истәлекләрендә, чөнки кече офицерларны бер фронттан икенче фронтка күчермиләр икән. Габдрахман Әпсәләмовлар да (Карелия фронтындагы чыга башлаган «Ватан өчен сугышка» исемле татар газетасы редакциясе) Ф. Кәримне эшкә алырга омтылып караганнар, ләкин, кызганычка каршы, алар да максатларына ирешә алмаганнар.)*сездә (булачак) дип ишеттем. Анда булса, сәлам әйт тә сора: минем рекомендацияне алдымы икән ул?

Гыймадига үзе буе сәлам күндер. А. Әхмәтнең газета төргәгенә язган сәламен алдым. Рәхмәт. Үзенә Кабан күле буендагы тире-яры техникумы кадәр сәлам әйт. (Тире-ярымы, әллә киез итекме—оныттым).[1]

Рахман *(Рахман Хөсәенов (19.. билгесез—1943), яшь шагыйрь һәм язучы. Башта Калинин, аннары Беренче Балтик буе фронтларында гвардия лейтенанты булып хезмәт иткән. Аның шигырьләре һәм очерклары «Алга, дошман өстенә» газетасында басылып чыккан. Дүрт очеркы «Нәфрәт көче» исемле җыентыкка кертелгән. Монда сүз аның батырларча һәлак булуы турында бара.)* кызганыч.

Баян *(Нур Баян (1905-1945), шагыйрь. Бөек Ватан сугышында дивизия газетасы редакторы.)* турында хәбәрең бармы?

Бакировка *(Госман Бакиров (1896-1982), язучы. Шул чорда Беренче Украина фронтында миномет батареясе командиры, хәрби частьнең партия оешмасы җитәкчесе.)* хат язган идем. «За выбытием адресата...» дигән булып кире борып кайтарганнар. Син хәбәр иткәч, тагын яздым.

Әсгать Айдар *(1906-1959, шагыйрь.)* безнең фронтта. Бүләкләнде. Партиягә кандидат.

Я, кочакларга рөхсәт ит үзенне.

Күптин күп сәлам белән иске дустың Ибраһим.

### Өченче хаты

*5 май, 1944 ел*

Әбҗәл!

Ярты елга бер хатың килде. Ул да булса 23 мартта, ягъни моннан ай ярым элек язылган хат. Минем хатлар үгез белән барсалар (синең сүзләр), синекеләр кыслага (рак) атланып киләләр. Ничек булса, шулай булды, ләкин хатың килде—рәхмәт!

Кырым шәһәрләренең берсеннән агачтагы чәчәкләр санынча, безнең яндагы тау биеклегенчә, безнең яннан гөрләп ага торган тау елгачыгының төбендәге чуер ташлар санынча сәлам үзенә (беркадәресен А. Әхмәткә, Минһажга, Әхмеровка *(Котдус Әхмеров, (1906-1975), журналист, 1944 елның февраленнән «Алга, дошман өстенә» газетасының тәрҗемәчесе.)* дә бүлеп бир, ярыймы?). Мин инде ни уйларга да белми идем: ни булды бу Әбҗәлттингә? Үпкәләде дисәң, сәбәп юк шикелле—язмый да язмый. Җавап алмагач, минем дә күнел сүрелә... Ә үзе дөньяда бар: «Өзелгән кыллар»ны язды, Тәүгилденен*(А. Тәүгилде, әдәби псевдоним.)* бүтән нәрсәләрен дә укыштырдым, ә үзе, үч иткән кебек, тавыш бирми. Аннары болай уйладым: бөтен

[1] А. Әхмәт сугыш алдыннан берничә ел төрле техникумнарда укытучылык итә: татар телен һәм әдәбиятын укыта.

уйлаганны, әйтергә теләгәнне язып булмый, хатлар үгездә йөри, аннары—барып житүенә дә ышаныч юк,—шуңа күрә язмый инде бу дип уйлыйм. Күп вакытны минем үземнең дә хат язарга кул күтәрелми.

Язу-язмау турында. Хәлемне ничек аңлатыйм икән. Әйтик, менә син редакциядә тәржемәче дә—үзең (русчадан татарчага һәм киресенчә), литредактор да—үзең, корректор да—үзең, язучы да—үзең, ди. Ә редактор, тегене тәржемә ит, моны яз, дип әйтә дә ятып йоклый, ди, ә литсотрудникның бөтен язганын сиңа яңадан эшләргә туры килә, ди; корректордан соң гранканы да, полосаны да үзең укыйсың, ди; шуннан соң гына үзең бирәр нәрсә язасың, ди. Менә минем хәл шул. Шул ук вакытта алар «тәти абыйлар» каршында 100 процентлы булып күренеп, редакция, гомумән алганда, яхшы работниклар белән тәэмин ителгән санала («тәти абыйлар» шулай саный). Безнең хәл үз редакциябез эчендәге сер булып кына кала. Тыштан бөтенесе «аллага шөкер», асылда «ходаем, үзең коткар». Мин моңа инде күнеккән. Күнегүен күнеккән, ә газетага бу начар тәэсир итә.

Ярый, бетсен.

Тылдагы иптәшләр миңа бик сирәк язалар. Жүбесеннән хат алмаганга ярты елдан артык. Шунысы кызык—язган хатка җавап бирмиләр. Нишләмәк кирәк: шуның өчен алар иптәш, ә иптәшлек бездә үзең беләсең... Я, житәр, әллә нәрсә әйтеп куюым мөмкин.

Я, хуш әлегә!

Яз дип әйтмим, язгала дип кенә әйтәм. Иптәшләрдән хат алсаң, күңел рәхәтләнеп китә.

Сәлам белән Ибраһим.

Дүртенче хаты

*9 сентябрь, 1944 ел.*

Әбжәлттин!

Исәнме-саумы, малай! Синең 8 июльдә язган хатыңны 8 сентябрьдә алу бәхетенә ирештем. Менә шуннан соң хат язарга ничек итеп каләм күтәрелсен инде! Ике ай бит! Ул ике ай эчендә мин Кырымнан Карпат тауларына кадәр килеп життем. Бер атна Казанда булып, хикәяләремә договор төзеп, хатынны-баланы кочаклап, Казанка буйларын әйләнеп килдем. Ә синең хатың килгән дә килгән.

Карпат таулары арасында йөри хәзер синең абыең. Кичә генә Фәйзи *(Әхмәт Фәйзи (1903-1958), шагыйрь, «Сталин байрагы» газетасының хәрби хәбәрчесе.)* белән алгы сызыктан кайттык: тузан тулмаган тишек калмады, тирләп, сасып беттек.

Мин хужа *(Мин хуҗа—Г. Клеблеев хезмәтеннән алынгач, И. Гази газетаның вакытлы редакторы итеп билгеләнгән иде. Сүз шул турыда бара.)*, ләкин хужаның хужалыгы гына юк. Без өйләнгәч, төн кыскарды—бетерделәр, яптылар *(Яптылар—газетаны чыгарудан туктаттылар.)*. Алдагы көндә кайда эшләрмен—билгесез. Имеш, монда татарлар аз...

Инде, малай, хикәяләр язуга кучәргә дә вакыт иде. Сугышның очы күренә шикелле. Материал—муеннан! Вакыт бирелсә, әллә ниләр язарга мөмкин.

Синең немец тотуыңа *(Язучы Афзал Шамов 1944 елда Белоруссиядәге җәйге һөҗүм сугышлары вакытында, бер төркем немецларга бер ялгызы очрап, посып яткан җиреннән аларга кинәт һөҗүм иткәннән соң, җидесен әсир иткән. Аларны НКВДга илтеп тапшырган. Менә бу язма: «Расписка. Дана начальнику конвоя капитану Шамову в том, что от него на имя в/ч 20 НКВД принято 7 чел. (семь человек) военнопленных. Зам. нач. пункта Строколов. 30.6.44». А. Әхмәтнең «Уйламаганда» исемле язмасы шушы вакыйга турында («Кызыл Татарстан» газетасы: 1944 ел, 21 июль.) И. Гази шул турыда шаярып яза.)* мин болай карадым (Казанда ишеткән идем): чолганышта ята-ята ачыккан, хәлдән тайган бер төркем немец юл кырыена чыгып утырганнар—плен алыгыз, зинһар!—диләр. Берәүнең дә вакыты юк—кул селтәп узып китәләр. Ә син... синең печтик вакытың бар. Ерактан гына кычкырасың (якын килсәң, тешләүләре бар):—әйдәгез, комрадлар, мин сезне плен алыйм. Алар әйтәләр—битте, битте,—диләр. Син, бер кулыңда атмый торган наган, икенчесендә—яза торган каләм, китәсең алып. Шулайрактыр кебек тоелган иде миңа. Ләкин сугышкач та, һәм авыз тутырып—7

мимечны плен алдым дия торган булгач—дөрестер... ягъни чын мимечләрне алгансын... Поздравляю. Күкрәкнең теге жирен спирт белән сөртеп куй —орден урыны чистарак торсын.

Баян *(Нур Баян (1905-1945), шагыйрь, Бөек Ватан сугышы вакытында дивизия газетасының редакторы.)* Бухарестта хәзер. Аның адресы: 08739-Ч.

Сәлам белән дустың.

P. S. Фәйзидән сәлам. Эх, күрешәсе иде бер! Менә сөйләшер идек.

Бишенче хаты

*21 ноябрь, 1944 ел*

Әбжәлттин!

Калын (?) жилкәнә атланып, муеныңнан кочам үзеңне! Элекке кебек, урамдагы исерек түбәләшүчеләрне аерып, милициягә илтергә яратучы батыр, таза, гайрәтле, куәтле, дәһшәтле (беттеме, әллә тагын бармы?) һәм добродушный Әбжәл булсаң, бу наянлыгымны, шуклыгымны, шаянлыгымны (үзең сайлап куй!) гафу итәрсең. Иптәшләрне сагынып искә алганда, сине Аеруча (48 ж. баш) *(48 пунктлы кара баш хәрефләр; типография билгесе, эре хәрефләр белән җыярга кушу.)* юксынып, искә алам. Әллә бик озак заманнар тәржемә өстендә бергәләп «бөкре чыгаргангамы» (минеке һаман чыга да чыга!) һәм бергәләп «тирес башын» актаргангамы, *(«Тирес башын» актаргангамы—Татарстан китап нәшриятында безнең кулга эшләнеп бетмәгән әдәби әсәрләр, начар тәржемәләр еш кына килеп керғәли иде. Шундый кульязмалар өстендә эшләүне без «Тирес башын актару» яисә «тирестән энҗе-мәрҗән эзләү» дип атый идек. Бу очракта Ибраһим шуны искә ала.)* әллә үзең шундый добродушный адәм булгангамы, син минем күңелдә аерым (курсив) урын тотасың. «Менә кызык!»—диярсең инде син. «Торып-торып торҗагүн, исән торасыңмы! 40 яшькә житкәч (40 бик тиздән! Ә синекен әйтергә дә куркам инде мин—цензура кызлары, куркып, хатны ташлаулары мөмкин!), кырыкка житкәч,



*Ибраһим Гази, Зәкия Садыйкова, Афзал Шамов.*

безнең Ибраһим гакылга җинеләйгән, ахры, үзенең иске дусларына мәхәббәт изһар итә башлады»,—диярсең. Теләсәң нәрсә әйт. Күнелдә барны яздым.

Мин, Карпат тирәсендә тау төшә, тау менә бераз йөргәч, пайтәхеткә чакырылып, 1 нче ак руска *(Беренче Белоруссия фронтына.)* бәрәңге ашарга озатылдым. Резерв дигән җан биздергеч җирдә бераз кыйналгач, 1 нче ак рустагы тастымалның *(Тастымалның—газетаның. Татар телендә чыккан «Кызыл Армия» газетасы күздә тотыла.)* бер почмагыннан барып тоттым. Тиздән, бәлки, сез безнең тастымалга кул (кул гынамы!) сөртә башларсыз.

Теге немецлар өчен алган(мы?) орденың белән котларга рөхсәт ит. Инде сиңа орден тегеләй дә, болай да бирелергә тиеш, чөнки син—Шиһабетдин үгезе *(Шиһабетдин үгезе—бу исемнең дә үзенә күрә тарихы бар. Сабый чагымда мине абыйларым үз яшемдәге күрше малайлары белән көрәштерергә яраталар иде, хәтта сөзештерәләр дә иде. Олылар кушкач, җитмәсә, мактау сүзләре әйтеп, дәртләндереп, котыртып та торгач, без чын күңелдән бирелеп, күзләребездән утлар чәчрәгәнче тырышып сөзешә идек. Сөзештергәндә мине Шиһабетдин үгезе дип атыйлар иде (әтием Шиһабетдин). Бервакыт мин, бала чагымны искә төшергәндә, моны Ибраһимга сөйләгән идем. Аңа, һәртөрле шаянлыкны, уйнап-көлеп сөйләшүне яратучы дустыма, бу җитә калды, шуннан соң ул кайвакытларда, бигрәк тә авыр эш эшләгәндә, мәзәкләп, Шиһабетдин үгезе дип атый башлады.)*—газетагызда вол урынына эшләп килдең һәм күчеп-нитеп йөрмәдең. Ә 7 мимечны да плен алгач, берәр йолдыз (күктән алып булса да) бирәсе иде. Мин булсам, йолдызын да, аен да бирер идем сиңа. Анысы инде, малай, берәүгә йолдызы, ә синең белән миңа: «Йом күзен»—маңгаеңа сукканда чәчрәп чыкмасын. «Яшәсен аркадагы бөкре!» Тагын бераз үссә, айга да, йолдызга да барып тияр!

Нәрсә булса да язасыңмы? Синең дәшми ятуыңнан курка башладым инде мин; дәшми-дәшми торып, өстәлгә, шалт иттереп, берәр роман чыгарып саласыңмы инде син! Алдан ук әйтеп куям: көнләячәкмен! Көнләячәкмен, ләкин сөенәчәкмен. Әгәр инде тагы очерклар тупламасы гына булса, шулай ук алдан әйтеп куям, минем кашлар җыерылган булыр. Ә күзләр күзлек өстеннән ачулы карарлар.

Кутуй *(Гадел Кутуй (1903-1945), язучы, югарыда телгә алынган газетаның хәрби хәбәрчесе. Бөек Ватан сугышыннан соң хәрби госпитальдә вафат булган.)*, язарга комачаулап, уң ягымда сөйләнеп утыра. Сәлам язарга кыстый. Сәлам аңардан. Ярмәки *(Ярулла Ярмәкиев (1905-1968), журналист, шул ук газетаның редакторы.)* сөйләнмичә генә сул ягымда утыра. Күзлеген әле сала, әле кия—кигәчме яхшырак күрә, салгачмы—әйтми.

Я, бир кулыңны. Сау бул!

Гыймадига сәлам әйт. Абдуллага да сәлам күндер.

Хат көтеп дустың Ибраһим.

Адресым болай: 48251-А.

### Алтынчы хаты

*14 гыйнвар, 1945 ел*

Әбҗәлттин!

Үзең язмагансың да, озын колаклардан ишетеп кенә белдем. Не хруша[1], егет! Орден алуың түгел, әйтмәвең не хруша![...]

Әллә минем хатлар барып җитми, әллә син хат яза белми башладың, һич кенә минем хаттагы мәсьәләләргә җавап язмыйсың.

Нәрсә дә булса берәр нәрсә (мәсәлән, повесть, руман![2] Тылдагылар руман язалар!) язасыңмы, әллә вак-төяккә чәчелеп бетәсеңме? Минем «Алар өчәү иде»не укыдыңмы? Ник берәр сүз әйтмисең? Язучының күңеле мактау көтә бит, каһәрен...

Минем планнарым зур, ләкин үзең беләсең: план—это люди, это мы с вами, ә мин хәзергә «люди» түгел, «люд» та түгел, ә люди кушканны эшләп кенә йөри торган бәндә... Бу сугышта йөрү бик күп нәрсә бирде, малай: вакыт булса, хәзер хикәяне коймак урынына (коймакның хәзер еш пешмәгәнен дә искә алганда)

---

[1]Не хруша— не хорошо.

[2]Руман—роман. Соңгы ике сүзне, гадәтенчә, шаяртып әйтүе.

пешерер идем. Повестьлык та материал бар. Синең дә күптер инде хәзер, ә?

Синең күкрәктә берәү (котлы булсын!), күршесендә тагын ике урын әзер—көтеп торалар. Яшәсен киң күкрәк! *(Бу хатта Ибраһим абый этиемә дусларча шаяру рәсемен (шарж) ясаган. Сүз шул рәсем турында бара.)*



Гыймадига, Абдуллага сәлам сөйлә.

Минем моннан элек сиңа мәхәббәт изһар итеп язган хатымны алдыңмы? Ник җавап язмыйсың?

Кара әле, Әбҗәл, ходай язып, Казан каласында, синең, я минем бүлмәдә (шкафтан китаплар карап тора!) очраша калсак, московский-особыйны өстәлгә утыртып (кызыл-мызыл бер якка китсен, интеллигентлар һәм кызлар эчемлеге!), бер рәхәтләнеп сыйланыр идек, ә? *(... сыйланыр идек—Ибраһим градуслы эчемлекләрне бервакытта да эчмәде. Бу аның: «Эчмәүчеләрдән булсак та, явыз дошманны тәмам җиңгәннән соң, шатлыгыбыздан шулай да синең белән бер эчәр идек»,—дип язуы. Гаеплебез: Бөек Җиңү көнен, бик олылап, күп мәртәбәләр искә алсак та, аны беркайчан да аракылы касәләр белән үткәрмәдек.)*

Я, хуш! Мә минем ябык кулны!

Дустың Ибраһим.

## Җиденче хаты

*3 июнь, 1945 ел*

Әбҗәлттин!

Иптәшләрдән иң сагына торган, иң якын күргән кешем син минем. (Хат саен мәхәббәт игълан итеп аптырыйм инде!) Бергә бик озак эшләгәнгәме, әллә синең характерыңдагы кеше кайгысын кайгырта белү хосусыятеме,—нәрсәдер, мине сиңа бәйләде. Исән-сау булып, синең белән күрешергә туры килсә, сөйләр сүз, серләшер сер Берлин шәһәреннән дә зуррак. (Бу да чагыштыру булды янәсе!) Берлин дигәннән, таш кала инде ул. Бик ватылды. Гел бакча эчендә—ямь-яшел. Рейхстаг шулай ук ватылды, янды. Артык нәрсә әйтим? Калганын кайтып Казанка буена баргач *(Әтием Ибраһим абый белән ял көннәрендә Казанка буйларын әйләнеп йөргән, үзләренең фикерләре, хыяллары белән уртаклашкан.)* ишетерсең инде, Аллаһ боерган булса... Аллаһ шулай боерсын иде инде. 45 нче елда 41 нче ел яңадан башланмаса, ни әйтер идең.

Фатихның *(Фатих Кәрим (1909-1945), шагыйрь, Кенигсберг крепосте һәм шәһәре өчен барган каты сугышта 1945 елның 19 февралендә батырларча һәлак була.)* үлүен ишеткәч, күземнән яшь чыкты. Нәрсә дим, нинди сүзләр белән аңлатып бирим... Зур кайгы, зур бәла инде бу. Ләкин бу таш күңелле дөнья нинди генә трагедияләрне күрмәгән? Нинди генә кешеләрне бөтәрләп кабергә тыкмаган... Килер бер көн ... без дә ... күңелсез. Үлем куркынычыннан түгел, ә Гыймад абзый *(Гыймадетдин Шамов (1902—19? билгеле түгел), әтиемнең бертуган абыйсы. Ул 1935-1937 елларда Пермь өлкәсендәге Кизель шәһәрендә китап кибетендә эшләгән, 1937 елда кулга алынган. Шуннан бирле туганнарга хаты-хәбәре юк. Әти аны Союз күләмендә эзләткән, әмма кулга алынган кешеләр исемлегендә булмаган. Кайберәүләр аны Бөек Ватан сугышы фронтында күрдек дип сөйләгәннәр. Кыскасы, аның исәнлеге турында да, вафат булуы турында да ачык мәгълүмат юк.)* кебек үлү куркынычыннан күңелсез... Син мине аңлыйсың! Ә шулай булу бик мөмкин.

Я, ташлыйк. Минем күңелемдә хәзер хәсрәт бар: шуңа күрә мин бераз хандрить итеп алдым. Килер көннәр бәхетле булсын инде. Үткәне... үткәнен үзең беләсең...

Я, хуш.

Исәнлектә күрешик.

Дустың Ибраһим.

Сигезенче хаты

*21 июль, 1945 ел*

Берлин коласы [1]

Әбҗәлттин!

Синең җир тишегеннән *(... җир тишегеннән—Читадан. 1945 елның июнендә «Алга, дошман өстенә» газетасының редакциясе тулысынча Байкал Арты—Амур хәрби округына күчерелә. Японнарга каршы сугыш хәрәкәтләре башланыр алдыннан бу фронтта «Суворовча кысрыклау» газетасы оештырыла. Газетаның редакторы Минһаҗ Гыймадиев, хәрби хәбәрчеләр: язучылар Афзал Шамов, Абдулла Әхмәт, журналистлар Котдус Әхмеров, Фазыл Басыйров.)* язган хатыңны алдым һәм, дөресен әйтим, кызганып куйдым үзеңне. Ходай тәгалә үзенең бәндәләрен кайларга гына илтеп олактырмый!

Казанга кайткач, берәр баганага ябышып, китмим дип ник дәгъвалмәдең соң? Безнең карт сөякләргә, минемчә, инде пора на покой! Чита! Ходай үзе сакласын! Аннан Владивостокка, аннары Формоза[2] яисә Хонсю атавына [3] да ерак түгелдер, җүләр малай әйтмешли. Тьфү, тьфү, әйтмәгәнем булсын, авызымнан җил алсын!

Без монда Берлинга өйрәнеп беттек инде. Немецчәне дә, с помощью бармага *(бармаклар ярдәме белән)*, сөйләшә башладык. Аптырап торган юк. Шушы тирәдә тәмамларга ходай язсын инде, дип телим алладан. Ничек булыр.

Кутуй вафат! Скоротечная чахотка! Ике ай эчендә—кеше юкка чыкты. Госпитальдә бик җәфаланып үлде.

Тагы бер корбан!

Безнең бүләкләр әлегә күкрәктә түгел, ә кәгазьдә генә әле. Кайчан әйләнептулганып килеп чыгар, билгесез.

Я, хуш, малай. Газета җибәрдек.

Дустың: Ибраһим.



*«Алга, дошман өстенә» исемле татар газетасы редакциясе. Рәссам— лейтенант Владимир Минаев, капитан Афзал Шамов, капитан Минһаҗ Гыймадиев, өлкән сержант Фазыл Басыйров, кызылармияче Абдулла Әхмәт. Смоленск өлкәсе, 5 май 1943ел.*

[1] Берлин коласы— Берлин каласы. Шаяртып әйтүе.

[2] Формоза —Тайвань атавы исеме.

[3] Хонсю атавы —Япониянең ин зур атавы.

Тугызынчы хаты

*1 сентябрь, 1945 ел*

Потсдам

Әбжәлттин!

Синең 5 августта Читадан язган хатыңны бүген, беренче сентябрьдә Потсдам каласында алдым. Моннан алда да мин сиңа бер хат язып, ул хатта сиңа Кореядә урын ымлап куйган идем. Дөрескә чыкты. Әйдә инде, без күрмәгән шәһәрләр, без күрмәгән җирләр калмасын. Соңыннан бик барасың килер дә, җибәрмәсләр. Германиянең иң матур шәһәрләренең берсендә йөрим мин хәзер. Яшәгән икән без без дә, Казанда, шуны шәһәр дип атаганбыз... Бетте, көфер, сүз ычкын...

Әдәбиятка кул да орындырмыйм, чөнки тастымал чыгарып гомер үтә. Аны бетерсәләр дә кайту юк әле миңа—армиягә генә күчерәчәкләр.

Котлый алмыйсың әле син мине дә, минем иптәшләрне дә. Кәгазьләр кайдадыр гизәләр, әллә бәлки югалып та беткәннәрдер инде.

Кутуй tbc дан[1] үлде. Бик тиз: ай ярым—ике ай эчендә бетте дә китте. Без түгел, ул үзе дә үзенең авыру икәнен белмәде: инде тәмам вакыт үткәч кенә белдек. Нишләмәк кирәк?

Редакциягә хәзер генә Гариф әфәнде Гали *(Гариф Галиев (1903-1985))* килде. Ул минем каршымда корректура карап утыра. «Митингысында» *(бу сүзгә искәрмә бирелмәгән)* сүзенең язылышы ана охшамый. Ярмәки дә килеп, геморроен кашый-кашый, өскә линотип[2] янына менеп китте. Обедтан соң, шулай итеп, эш башланды. Минем хат язуымны бүлдереп, чит ил хәбәре тәрҗемә иттерделәр. Тулмаган тишекне *(Тулмаган тишекне—газетаның буш урыннарын.)* тутыралар.

Менә шулай.

Казаннан иптәшләр бер дә язмыйлар. Алар нишләп яталардыр. Хәзер дөнья түгәрәк инде аларның.

Хуш әлегә. Хат яз.

Тын океан атауларына ук барып чыгарга туры килсә (килмәс!) минем өчен дә диңгезгә бер таш ыргыт.

Ибраһим.

*(Текст эчендә курсив хәрефләр белән А. Шамов һәм Ә. Шамова искәрмәләре бирелде).*

[1] tbc - туберкулез. Медицина термины.

[2] Линотип - хәреф җыю машинасы.

# *Татар шагыйрьләре– Сәйдәшкә*

## Xəsən Tufan

***

... Məclestə şunsı küņelle:
Səğətneņ tuqtağanı,
Duslarnıņ uyau bulğanı,
Ətəçneņ yoqlağanı.

İņ safın, insaflırağın
Kütərik əle tağın:
Canlı ber buket şikelle
Nurlanıp torsın tabın.

Az da tügel, küp tə tügel,
Tağı barırlıq əle:
Salix Səydəş køylərenə
Biep alırlıq əle.

Səğətlər ütər də kitər,
Yaqtı eş kəne citər;
Ber iskə alırlıq itep,
Sağınırlıq itep kütər.

*1939.*

## Məxmüt Xəsəyen

### Salix Səydəşevkə

Soldat bulıp zur poxodlar üttek,
Evropanıņ uzdıq yartısın.
Alğa ilttek yarsu yərəklərdə
«Naemşik»nı – tuğan yaq təsen.
Məskəw aşa yotılıp tıņlıy idek
Okoplarda sineņ moņnarnı.
Sineņ marşıņ – «Səydəş marşı» belən
Ciņel üttek awır yullarnı.
Sugış tındı.
Bez Qazanğa qayttıq.
Ə ber kənne, oçrap uramda,
Ozaq qulıņ qıstıq,
Køylərenneņ
Ğəmere şulay ozın bulğanğa.
Sin – qoyaşlı cırlar icatçısı,
Tuqayı sin køyle dənyanıņ,
Rəxmət siņa ruxlandırğan øçen
Eşkə xirıs xalqıņ ullarıņ.

Mənge ülməs monnar bülək itten,
Arabızda bergə sayraşıp,
Xalıq məxəbbəte laureatı -
Səyeklebez Salix Səydəşev!

*1950.*

## İldar Yuziev

### Səydəş uramında uylanu

İsən çakta sine kürəlmədem,
Baralmadım sinen yanına.
Əmma künel,
Kənnər ütkən sayın,
Yaqın dustay sine sağına.
Gəllər,
Nazlı gəllər,
Yazmı sağınıp çəçək atalar.
Uram.
Xəsrətlərne bik küp kürgən uram
Sinen isemen belən atalğan.
Yaqın duslarınnan ayırılıp,
Bu uramnan küpme ütten sin?
Uramnarda ğına tügel, künellərdə
Küpme mon qaldırıp kitten sin!
Menə berəw
Cillər isüenə
Tərəzəsen açıp quyğan da
Əzelep-əzelep sinen kəyne uynıy,
Çumğan kileş tirən uylarğa.
Yuq,
Ber bez genə tügel, kəyləren də
Sağına sine—yazlar cırçısın.
Salix abıy,
Qabatlanmas ber maturlıq bulıp
Sin tormışnı bizəp torırsın.
Üze kebek tıynaq qına uram
Kəylərennən anın nurlanğan.
Menə Səydəş,
Süngən künеldə də dərt uyatıp,
Marş bulıp uza uramnan.
Ul mon bulıp yəşi künellərdə,
Can dustıday kerə əylərgə.
İx,
İsən çaqta sine kürəlmədem,
Süzem bik küp ide səylərgə...

*1955.*

## Rədif Ğataş

### Cannın qayçaq...

*(Səydəşne uylağanda)*

Qayçaq — kilə tormış awazların
şaşıp
üzenə iş itəse!
Kilə —
gəcəp monnar, ennər işetəse!
Əmma yanğırıy, kətməgəndə,
uram tulıp,
matəm muzıkası...

Səydəş... —
(Bax ul yəki Şopen!..)
ezelgən də ğemer, yazmış —
in neçkə qıl,
bu qayğıdan
Sazım inri — ezelergə yaqın!

Əy, dənya, ber balan bit min;
mina tormış cırlarının
barısın da
canğa üz itəse...
Nigə awır ana bügen?
Uramımda yanğırıy, yanğırıy... matəm —
işetəm:
Səydəş muzıkası!

*1969.*

## Mars Şabayev

### Səydəşne tınlağanda

Ap-aq tüşe balqıp-balqıp kitə,
Əytersen lə qara qarlığaç.
Sin kiləsen ana buysınırğa,
Kenlek məşəqəttən arınğaç.
Künelenne iərtep alıp kitə
Üze genə belgən monnarğa.
Dənya üze, ber mizgelgə tınıp,
Qalır tesle anı tınlarğa.
Qul-qanatı tınğan zal estendə —
Güyə menə ğələm estendə —,
Uynaqlıy da oça...
Qullar xakim

Xıyalıŋa sineŋ, xisenə.
Kütərelə, kütərelə moŋnar
Həm sine də bergə kütərə
Waqlıqlardan, ıgı-zıgılardan,
Biekkərək – ruxi küklərgə.
Alıp kerə qara urmannarga,
Adaştıra qışqı buranda,
Naz bərki də ğaşiq bulgannarga,
Yoldız çəyə yalgız uramğa.
Kükrəp uza bəxet yaŋgırları...
Soŋğı akkord –
Qanat-qul –
yəşen!
Dənya tına...
İrken zal yaqtıra...
Sin sərtəseŋ, aşıgıp küz yəşeŋ.

*1974.*

## Ravil Fəyzullin

### Zatlılıq

*Vəcdan xəkemen belməgən canğa*
*Xaq-dəreslek belən Yalğan – ber.*
*Dənyağa – keşeleklelek belən*
*intellekt citmi qalgan gel...*

Xalıq ruxı sayıgunı belməs.
Can tartılır uçaq gel kirək.
Zamananıŋ cillərenə qarap,
yalqınlawı bula tərlerək.
Əmma Keşe hərçaq omtılaçaq
Maturlıqqa, Çınğa, Xaqlıqqa;
qayğılardan sıgılıp təşkən çaqta,
cineləygən çaqta şatlıqtan –
buşanırğa kirək bula aŋa –
küŋelendə, əydə, taŋ atsın,
sabıy bala kebek sadələnsen,
keşelege artsın, yaŋarsın!
Səŋğət – ilahi ber uçaq. Anıŋ
ber balqışı Səydəş buldı bit!
Kəy tılsımı belən xalkıbıznıŋ
küzənəklərenə tuldı bit.

Talant – sirək. Tik alar bar. Kemneŋ
məŋgelekkə kilməs qalası.
Sirək arasınnan ber gəühəren
xalıq üze saylap ala şul.
Elegrək tə, Səydəş çorında da

talantlar tua kilgənnər.
Fəyzük, Motiğilar—zamanında
yəzek qaşı kebek yərgənnər.
Ə soŋraq Səydəş qalqıp çıqqan,
yaqtı yoldız bulıp yanırğa.
Əkiəttəge sulmas çəçək kebek,
küŋellərdə məŋge qalırğa.
Ə nik Səydəş? Nigə bütən tügel?
Taw qədərme ällə xezməte?
Eşe gel güzəlme? Çiksez məllə
üzen zurlata alu qədrəte?
Gel alay uq tügel... Xikmət, axrı,
talantınıŋ təbiğatendə.
Şəxes bulıp yəşəw rəweşendə,
səyləşüendə, hər ğədətendə,
keşelərgə yağımlılığında,
dənyağa mənəsəbətendə...
Berkem əytməs: Səydəş dorfa ide,
kənçel buldı yəki üçle dip,
Çordaşları əytə: açıqlığı,
ğədellege, intelligentlığı,
keşelege belən keçle, dip.
İlahi zur talant əstəwenə,
sirpep torğan annan zatlılıq!
Küŋeleŋdə qoyaş bulsa ğına,
çəçep bula ilgə yaqtılıq.
Yaqtı başlığa da, zatsız ikən,
xalıq tormas ide tartılıp...

İntellegentlıq həm zatlılıq! -
bik defisit beznen zamanda!
Uylabraq baqsaŋ, bu sıyfatlar
kübebezdə bik tə çamalı!..

İke-əç şiğer, berər kəy yazıp,
«bəyeklənep» yərgənnər yuqmı?
Baxus babayğa bəten sawlığın,
bar talantın birgənnər yuqmı?
Başnı tekə totası urında,
səbəpsez ielgənnər yuqmı?
Teləsə nindi boyırıq aldında
tezlənep biegənnər yuqmı?
səğət sayın fikeren üzgərtep,
məlkətkə tiengənnər yuqmı?
... Xalqıbıznıŋ borınğıdan kilgən
zatlılığın onıtıyqmı?

Xalıq berdəm bulıp üz itüe—
Bəyekleknəŋ anıq bilgese.
İntellegentlıq, zatlılıq disək,
Səydəş anıŋ kürkəm əlgese!

*1980*

## Зиннур Мансуров

### Сәйдәш ялгышы

*Баллада*

Әллә нинди шомлы буран чыкты–
бүтән хисләр, бүтән тоем да.
Фәрештәләр, дәррәү котырышып,
бии төсле пәри туенда.

Тазарткандай һәрбер тәрәзәне,
тиеп китә ап-ак канатлар.
... Авыл йорты. Хушлык. Бүген монда
куна калган олуг кунак бар.

Хәйям белми киткән чүнник сыен
җибәрәләр «бәлеш асты»на.
Сәйдәш кенә һаман тыныч түгел:
«Кызган саен нигә җан туна?..»

Фәрештәләр бии фанфарага–
туктар микән бу туй өч көннән?!
Композитор гына ишетерлек
тавыш килә... буран эченнән...

Адашкандыр берәү... авылына
кайткан чакта кара буранда.
Кайтаваздай инри «коткарыгыз!»
камертоннан сизгер бу җанда.

Гарасатта йөрәк гажизләнсә,
ала иң югары нотаны...
Бәргәләнеп буран ятьмәсендә,
әллә бәгырь... Кәрим[1] ятамы?!

Фәрештәләр бии фанфарага,
өзгәләнә Сәйдәш ят моннан:
«Халык чыксын, әйдә, эзләп табыйк–
тавыш килә амбар ягыннан!..»

Эзләделәр өмет өзелгәнче,
иләделәр карны он итеп...
Әүлиядай затның ялгышуын
мөмкин булса икән онытып!

Мәэюсләнеп калды маэстро:
«Якны бутаганмын... карт юләр!..»
Мәрхүмкәйне мәгъриб тарафыннан
буран тынгач табып кайттылар.

Авылдашлар анлый алдылармы
җаны көйгән сабый ир хәлен?!
... Ап-ак кардан Сәйдәш бара төсле,
тартып бара кара роялен...

*1998*

## Зөлфәт

* * *

Татарның бу көйгән туфрагына
Мулдан сипкән серләр орлыгын.
Гамәлдәге исемнәре генә
Төрле монда шыткан җыр-моңның.

Төсне тылсым иткән затларның да
Исемнәре генә төрледән.
Безнең туфрак Сәйдәш, Тукай булып,
Шаляпиннар булып терелгән.

Кан белән дан, хурлык белән зурлык
Төпкә кадәр сеңгән җир ласа!
Гаҗәпмени Шаляпины булып
Шушы туфрак бер көн җырласа?!

[1]Кәрим Тинчурин күздә тотыла.

Гаҗәпмени бер көн Сәйдәш булып,
Төкәнмәс нур булып сирпелсә,
Шул нурлардан хәтта мәңгелекнең
Аръягыннан хәбәр ишетелсә?!

Татар туфрагы? Анда бары
Кан да сугыш кына, дисәләр...
Туфрак кына түгел безнең туфрак!—
Ул—уй колачламас мәңгелекнең
Аръягыннан килгән бер хәбәр.

Җирдән саркып килгән илаһият—
Даһи шаукым тисен, кагылсын!
Дөньялыкта җир бердәнбер җырчы
Һәм бердәнбер бөек назымчы...

Гел эндәшер безгә туган туфрак...
Ул дәшкәндә җиһан таң калыр.
Бөек шагыйрь булып күрсенер ул,
Бөек җырчы булып уфтаныр...

Ходай Тәгаләнең уфтануы
Илаһи көч булып тетрәгәч,
Аваз салган безнең шушы туфрак
Йә Шаляпин булып, йә Сәйдәш.

Җир тетрәме, купмый зилзиләләр...
Борынгы бу утлы туфракта.
Нинди янгыр, нинди җилләр шундый
Бөек моңсарларны уята?

Дулап узды канлы, данлы чорлар,
Җыр барыбер җирне тетрәтте!
Ходай үзе якын күргәненә
Бирә җиркәйнең җыр куәтен.

Әйтерсең лә бөркеп тора һаман
Ходай сулышының җылысы—
Яңа Сәйдәшләрнең сулышы бу,
Яңа Шаляпиннар сулышы!

Күңлендәгөн әйткән бөек җырчы:
—Татар җырын тыңлап яшәдем,—
Бәгъремнән саркый яшьлегемне
Тетрәндергән татар аһәңе!

Туган туфрак өчен ике моңсар
Кадерле һәм газиз, тиңдәш тә!
Көне килер...
Моңсар бу Шаляпин
Сәлам бирер моңсар Сәйдәшкә!

*1999.*

*Котлыйбыз!*

# ЗУРЛЫК

## ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ ЭНГЕЛЬ НИГЪМӘТУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Моннан ун ел элек Республикабыз горур рәвештә үзенең бәйсезлеген игълан иткәч һәм исеменең татарча да, урысча да «Татарстан» диеп йөртеләчәген белдергәч—Мәскәү һәм аның бирелдәге куштаннары безгә ачу итеп гел дә гел дә «Татария» диеп кабатлый иде. Янәсе бу инде аларның: «Сез элек ничек бәләкәй булсагыз һаман да шул килеш кала бирәсез—юкка көчәнмәгез!»—дию кебек иде.

Менә вакыт уза тора. Ә Татар иле, дусларын сөендерә-сөендерә, бөтен-дөнья күләмендә үзен һәммә яктан матур күрсәтә килә. Шуларның нәтиҗәсе буларак әлеге «Татария» диеп өрүчеләрнең дә ризасызлык авазлары тоныклана бара түгелме соң?!

Әйе, без хәзер авыз тутырып:

—Татарстан!—диеп әйтәбез. Горурлык белән!

Республикабыз матбугаты битләрендә һәм радио белән телевидениедә соңгы елларда бу юнәлештә байтак эшләр эшләнә. Әле менә «Мирас» журналы битләрендә дә үткән елның 8, 9 һәм быелның 1 санында бик кызыклы хезмәт дөнья күрде. Ул «Татарлар һәм Европа» дип исемләнгән. Авторы филология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университеты доценты Энгель Нигъмәтуллин.

Бу хезмәттә Европа галимнәренең һәм күренекле шәхесләренең татарлар турында әйтелгән, язып чыгылган бик күп фикерләре китерелгән, тарихи вакыйгалар тасвирланган. Ә алынган чыганакларның яңалыгына һәм үзенчәлегенә исләрең китәрлек! Монда инглизчә, немецчә, французча басылган китаплар да бар, шулай ук бик күп илләрнең һәм шәһәрләрнең борынгы хәзинәләрен саклап ятучы серле архивлар, фәнни китапханәләр дә.

Ул өзекләрне укыган чагында кайчандыр Европа һәм Азия киңлекләрен бер итеп яшәгән зур халык—уңган һәм тырыш, тынгысыз һәм батыр халык күз алдына килеп баса. Аның тормышын һәм көнкүрешен тагын да ачыклый төшкән байтак кызыклы яңалыклар, фактлар мәгълүм була. Ирексездән күңелне горурлык хисе били.

Әйе, халкыбыз турында, аның олы дөнья белән киң бәйләнеше турында шушындый бай һәм тирән эчтәлекле хезмәт язган Энгель ага үзе дә олуг шәхес. Ә аның әтисе исә—атаклы әдәбият галиме һәм педагог Галимҗан Нигъмәти.

Менә шушындый гаиләдә туган Энгель, әлбәттә, кечкенәдән үк бәрәкәтле рухи туфракка эләгә. Бу гаиләгә шул чорның күренекле әдипләре һәм галимнәре еш кына килеп йөри. Галимҗан Нигъмәтинең хатыны, Энгельнең әнисе Жанна (мулла кушкан исеме Мәһиҗиһан) ханымның ачык йөзле, киң күңелле һәм зыялы зат булуы кунакларны тагын да күбәйтә. Кичләрен бу йортта кызыклы әңгәмәләр куерып китә торган була, музыка коралларында да уйнап җибәрәләр. Нигъмәтиләрдә атаклы шагыйрьләр Такташ белән Туфанның да еш булуы билгеле.

Болар барысы да, билгеле, бәләкәй Энгельгә дә, аның апасы хәзер атаклы галимә, филология фәннәре докторы Йолдыз Нигъмәтуллинага да нык тәэсир

иткәндер. Аларның барыр юлларын әнә шул чагыннан ук билгеләп куйгандыр.

... 1930 елның 6 ноябрендә туган Энгель 1948 елда урта мәктәпне тәмамлый һәм Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Аннары ул Алтай краенда һәм Новосибирск, Казан мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Ә инде 1972 елда Энгель Нигъмәтуллин филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый, Казан дәүләт университетының рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасына ассистент итеп билгеләнә. 1977 елдан шул ук кафедрада доцент булып эшли башлый.

Яшь галим 1968 елда, читтән торып укып, М. Торез исемендәге Мәскәү чит телләр институтын да тәмамлый.

Энгель Нигъмәтуллинның чит телләрне яхшы белүе аның уй-фикер офыкларын киңәйтә, тора-бара ул Европа әдипләренең һәм фикер ияләренең татар рухи дөньясына тәэсирен өйрәнә башлый. Бигрәк тә гасыр башында яшәгән татар әдипләре иҗатына мөрәҗәгать итә. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан иҗатларын ул әнә шул күзлектән карап тикшерә, бу проблеманы үзәккә куйган мәкаләләр язып, аларны матбугатта бастыра. Ә инде 1977 елда Татарстан китап нәшриятында Энгель Нигъмәтуллинның «Раздвигая века и границы: к вопросу о связях татарской литературы первой половины XX века с литературой Западной Европы» дигән күләмле генә китабы басылып чыга.

Галимнең шушындый яңа һәм кызыклы юнәлештәге эшчәнлеге республикабыз зыялылары арасында зур яклау таба, 1981 елда аны Татарстан язучылары үз сафларына кабул итәләр. Иҗади берлеккә әгъза булып алынган Энгель Нигъмәтуллин хәзерге әдипләр иҗаты турында да байтак кына әдәби тәнкыйть мәкаләләре бастырды һәм язучылар алдында әдәбиятның җитди мәсьәләләренә багышланган чыгышлар ясады. Шул ук вакытта Казан дәүләт университетында укытуын да дәвам итте, яшь буынга әдәбият серләрен өйрәтте.

Яше инде шактый өлкән булса да Энгель ага хәзер дә актив иҗади тормыш белән яши. Ул күптән түгел Гайшә Рорлихның «Идел буе татарлары» дигән хезмәтен инглизчәдән турыдан-туры татарчага тәрҗемә итеп «Мирас» журналында бастырды. Шулай ук «Фәнни Татарстан» журналындагы ул әзерләгән «Пушкин турында татарлар» дигән язма да кызыклы иде. «Мирас» журналын алдыручылар аның күренекле әдип Мөсәгыйт Хәбибуллин иҗатына багышланган хезмәтен дә яратып кабул иттеләр.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: татар мәдәнияты күгендә Нигъмәтиләр йолдызы бүген дә якты яна. Егерменче-утызынчы елларда танылган галим һәм педагог булган Галимҗан Нигъмәтинең кызы Йолдыз ханым Нигъмәтуллина да, улы Энгель Нигъмәтуллин да әтиләренең юлын лаеклы дәвам иттерәләр.

Бу айда 70 яше тулу уңаеннан Энгель аганың үзен исә юбилее белән ихлас котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

# АЛТЫН АЧКЫЧЛЫ «РЕЗИДЕНТ»

ЗӨФӘР ФӘТХЕТДИНОВКА 60 ЯШЬ ТУЛУ УНАЕННАН

Детектив әдәбиятка Россиядә озак еллар дәвамында тискәре караш булды. Янәсе, ул—сәнгатьлелектән шактый ерак, чын рухи кыйммәтләр бирә алмый торган юнәлеш. Россиядә тумаган, тамыры рус җирлегендә булмаган күп рухи яналыкларга, бигрәк тә совет идеологиясе чорында, шундый караш яшәп килде. Кирәгеннән дә артык сак булырга өйрәнеп бетә язган татар язучысы, әлбәттә, мондый караш һәм мөнәсәбәт белән чакмага чакма килеп көрәшеп маташмады. Ул, тауны урап үтү хәерлерәк дип, бу жанрның маҗара тармагында җин сызганып эшләргә керешә һәм, әйтергә кирәк, уңышларга да ирешә...



Ләкин без чын детектив жанрына килергә тиеш идек, чөнки әдәбиятыбызның дөнья әдәбиятындагы барлык казанышларны да үзләштерерлек җегәре бар иде. Һәм килдек тә. Модага бирелеп кенә түгел, ә Заһир Бигиев, Галимҗан Ибраһимовларның шушы юнәлештә ясаган беренче адымнарын дәвам итеп. Безнең бу хәрәкәтне, минем карашымча, беренче чиратта Зөфәр Фәтхетдинов роман, повестьлары белән бәйләргә ныклы нигезебез бар.

Сиксәненче еллар башында Зөфәр әфәнденең «Тайна стоит жизни» дигән зур күләмле повесте Татарстанда һәм Россиядә укымый калган кеше сирәк булгандыр. Казан тирәсендәге монастырьларның берсе белән бәйле серле хәлләр, үтерешләр тасвирлана анда. Шуларны ачарга тырышучы чекистларга, милиция хезмәткәрләренә ияреп, әллә нинди серле, куркыныч мохиткә килеп эләгәсең һәм, үзең дә сизмәстән, прокуратура тикшерүчесе булып «эшли» башлыйсың. Бу—чын детектив әсәрләргә хас үзенчәлекләрнең иң мөһиме, дияр идем мин. Авторның үзеннән дә уздырып җинаятьнең серен ачарга, җинаятьчеләрне фаш итәргә омтылыш билән ала икән, димәк, синең кулыңда сәнгатьлелеге чамалы булган әсәр түгел, ә барлык хисләреңне акылың белән тоташтырган чын әдәби әсәр. Конан Дойлның, Жорж Сименонның, Агата Кристиның, йә булмаса бертуган Вайнерларның, Юлиан Семеновның әсәрләре шундыйлардан түгелмени?!

«Тайна стоит жизни» повесте (мин аны роман дип билгеләр идем) «Казан утлары» журналы 1983 елда «Ачылган серләр» исеме астында бастырып чыгарды. шушы ук журналда авторның «Ак «Жигули» эз югалта», «Кем—кемне...» повестьлары һәм «Үлем элмәге» дигән романы дөнья күрделәр. «Үлем элмәге» детектив жанрның барлык таләпләренә туры килгән хәлдә, һичшиксез, аның кысаларына гына сыешмаган әсәр. Аны тарихи жанр белән детектив һәм маҗара жанрларының матур бер эретмәсе дип билгеләргә дә мөмкин. Батька Махно эмиссарларының Казан алтынын кулга төшерү өчен алып барган эшчәнлеген, җирле җинаятьчел төркемнәрнең мәкерле хәрәкәтен, гыйш-гыйшрәт үеннарын, житди сәяси вакыйгаларны, Гражданнар сугышы чорындагы төрле социаль төркем кешеләренең тормышын, аларның сәяси һәм әхлакый аның, психологиясен зур осталык белән, ә кайбер очракта үзәк өзгеч итеп сурәтләгән бу роман, әлбәттә, аерым бер тикшерүгә лаеклы әсәр. Әгәр дә татар әдәби тәнкыйтенә янадан җан керсә, бәлки, З. Фәтхетдинов әсәрләре һәм, гомумән, татар әдәбиятының детектив юнәлешенә багышланган мәкаләләрне уку бәхетенә дә ирешербез. Культуралы әдәбият үзенең һәр күренешен, һәр яңа әсәрен барлап, тикшереп, аларга бәя йә диагноз куеп барырга тиеш.

Аннары Зөфәр Фәтхетдинов кин катлам укучыларны Казанда, Мәскәүдә, Ленинградта нәшер ителгән «Убийство в старом доме», «Сквозь страх», «Резидент» «Черная вдова», «Десятый мертвец» дигән роман һәм повестьларе белән сөендерде. «Десятый мертвец» повесте моннан берничә ел элек Казанны гына түгел, бөтен Россияне тетрәндергән Республика махсус элемтә үзәгендә тугыз фельдъегерьның ерткычларча үтерелүен тикшерүгә нигезләнгән әсәр. Ул вакыттагы Казан прокуроры Сәйфихан Нәфиевнең бу шау-шулы җинаятьне ничек ачуын, Искәндәр Галимов җитәкчелегендә Казан милициясенең ничек прокурорга ярдәм күрсәтүен автор документаль тогәллек һәм сәнгатьлелек ярдәмендә кин гомумиләштерүләргә һәм әхлакый, эстетик әһәмияткә ия булган чын әдәби әсәргә әверелдерә алган. Азмыни ул бездә күләме белән генә журнал мәкаләләреннән аерылып торган повестьлар, хәтта романнар һәм рифмаланганга күрә генә поэма, баллада, шигырь дип йөртелгән газета публицистикасы?!

Зөфәр Фәтхетдинов әсәрләре берничә күркәм үзенчәлеккә ия. Беренчедән, аларның хокук саклау органнары эшен эчтән дә, тыштан да яхшы белгән юрист тарафыннан язылуы, ягъни, аларның канунны, кеше хокукларын яклавы, кем әйтмешли, мичкә керсә, койрыгыннан күренеп тора. Персонажларның теле, сөйләшү манерасы, төрле ситуациядәге гамәлләре—барысы да төгәл һәм ышандыргыч. Хәер, монда артык гаҗәпләнәсе юк, чонки автор Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлаганнан соң берничә еллар дәвамында Костромада прокуратура тикшерүчесе, аннары прокурор ярдәмчесе булып эшләгән һәм төрле җинаятьләрне ачуда үзе катнашкан кеше.

Икенче үзенчәлеге—ул һәр китабында диярлек күренекле татар зыялылары, кайбер сәхнә, сәнгать әсәрләре хакында үзенең сокланулы хисләрен белгертергә урын таба. Аның роман, повестьларында Мәрҗани, Насыйри, Тукай, Сәйдәш, Урманче, Җиһанов кебек классиклар турында афористик әйтемнәр очратасың. Бүгенге сәнгатьнең күренекле әһелләре Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев, Вафирә Гыйззәтуллина һәм башка сәхнә осталары турында да Зөфәр әфәндедән ихлас фикерләрен укыйбыз... Шушы да булдымы үзенчәлек, диярләр кайберәүләр. Әйе, бу—үзенчәлек. Дөрес, без конкрет шәхесләр турында истәлекләр дә, мәкаләләр дә (бигрәк тә юбилейлар уңаеннан) язарга яратабыз, ләкин бик сирәгебез генә драма, роман, поэмаларыбызга замандаш каләмдәшләребезне кертеп зурларга батырчылык итә. Ә аларга читләтеп кенә тибеп үтәргә, кимсетеп узарга дигәндә, без—осталар...

Тагын бер үзенчәлек—Зөфәр әфәнде үзенең әсәрләрендә дөньякүләм мәшһүр философлар, язучылар, галимнәрнең аксиома дип кабул ителә торган фикерләре белән бәхәсләшергә ярата. Әйтик, Ларошфуко, Горький, Гюго, Берже белән ул исемнәрен күрсәтеп бәхәсләшә. Әмма күп очракта—әйтмичә генә. Дәүләт төзелешенә, сәясәткә багышланган максималарында аның большевизм һәм фашизм классиклары, бүгенге «демократлар» белән бәхәсе аеруча кискен. Гомумән, аның әсәрләре афористик фикерләргә, кочле гомумиләштерүләргә бик бай. Менә «Уңынчы мәет» повестеннан берничә үрнәк: «Хокукый булмаган дәүләтләрдә урын-дәрәҗә белән җаваплылык арасындагы мөнәсәбәтләр кире тәртиптә төзелә: урын-дәрәҗә түбәнрәк булган саен җаваплылык арта бара, урын-дәрәҗә югарырак булган саен җаваплылык кими». «Әдәп-әхлаксыз сәясәтчедән дә кансызрак, астыртын үткенлектә олы масштабка ирешкән башка җинаятьче юк.» Мондый максималар Зөфәр әфәндедән китапларына күпләп сибелгәннәр һәм алар, әсәрләрне җитди ямь белән бизәп, ин кирәкле урыннарда балкып алалар.

Зөфәр Фәтхетдинов осталыкка ирешкән язучы гына түгел, ул—танылган галим, юридик фәннәр докторы, Мәскәү, Казан университетларының профессоры, данлыклы «Новый Мир» журналының редколлегия әгъзасы. Галимгә галим белән бәхәсләшү авыр түгел, галимгә надан белән бәхәсләшү кыен, чонки бу —мәгънәсез эш.

Соңгы елларда Зөфәр Фәтхетдинов талантының тагын бер ягы ялтырап китте. 1991 елда Ленинград нәшриятларының берсендә аның «Откровения XX века» дигән китабы чыкты. Бер меннән артык афоризм һәм максималардан торган китапка күренекле экономист академик Станислав Шаталин, мәшһүр казакъ шагыйре Олжас

Сөләйманов фатиха биргәннәр һәм бу илкүләм әдәби вакыйгага һәм анын авторына сокланууларын белдергәннәр. 1996 елда Татарстан китап нәшрияты шушы мәҗмуганын тулыландырылган басмасын чыгарды. Ул инде 2300 дән артык миниатюраны туплаган һәм «Афоризмы и максимы или откровения XX века» дип атала. 16 бүлектән торган бу китап халык, дәүләт, кеше яшәешенен барлык тармакларын да нигездә колачлаган дисәм, әлләни хата булмастыр. Академик Шаталин сүзләре белән әйткәндә, китапка кергән «афоризмнар һәм максималарнын күбесе фикернен тирәнлеге һәм социаль-сәяси, әхлакый, хокукый, психологик, идарә һәм кайнап торган тормышыбыздагы башка бик күп проблемаларны ачу-яктыртуда яналыклары белән гаҗәпләндерәләр.»

Афоризмнар китабын повесть йә хикәя укыган кебек укып булмый. Һәр афоризмны укып чыкканнан сон, кагыйдә буларак, туктап уйланырга мәҗбүр буласын. Уен тирәнгәрәк киткән саен афоризмны янадан укыйсын, анын төбенә төшеп җитмәк буласын. Ә афоризмнын төбе юк. Ул шушы хасияте белән шигырьгә охшаган. Афоризм, шигырь кебек үк, кеше күнелендәге мен йозакка ачкыч. Бер үк афоризмны төрле кеше төрле очракта укып, фәкать үзенә генә тиешле гыйбрәт ала. Әлеге хасият тә бертуган бу әдәби жанрларнын тыгыз уртаклыгы хакында сөйли.

Татар әдәбиятында афоризмнарны махсус язган әдипләр бар. Өч-дүрт ел элек кенә «Үлгәннәрнен каберен бел, исәннәрнен кадерен бел!» дигән канатлы мәкальнен авторы Шәүкәт Галиевнен дә тапкыр фикерләрдән төзелгән калын китабы чыкты. Ул да мәдәниятыбыз күгендә йолдыз булып кабынырга лаеклы китап, ләкин, әлеге дә баягы, мәртәкә киткән әдәби тәнкыйтебез аркасында ул игътибардан читтәрәк калды.

Зөфәр Фәтхетдиновнын әлеге китабы махсус, ягъни, афоризм һәм максималарны мостәкыйль жанр итеп карап, язылган булулары белән генә түгел, ә XX гасырнын төп катаклизмнарына, проблемаларына, казанышларына, җитешсезлекләренә, кыскасы, бөтен илләрне, ә Россияне, беренче чиратта, инләп алган вакыйгаларга катгый бәя бирүләре белән башкалардан аерылып тора. Аларда— заманыбыз сурәтенен чәчелеп яткан төп кыйпылчыклары. Алар, мозаиканын тупланган өлешләре кебек үк, замана портретын танырлык итеп күз алдына китереп бастыралар.

Зөфәр әфәнде язган утызлап афоризмнын 1999 елда Мәскәүнен «Гамма» нәшриятында чыккан һәм дөнья халыкларынын ин яхшы әйтемнәрен, мәкальләрен үзенә туплаган «Антология афоризмов» дигән китапка кертелүе дә татар язучысы тарафыннан иҗат ителгән тапкыр сүзләрнен югары сәнгатьлелеге, фәлсәфи тирәнлеге, кабатланмаганлыгы, яналыгы турында сөйли.

Зөфәр Фәтхетдиновнын берничә ел дәвамында Федерация Советы Рәисе урынбасарынын кинәшчесе (советнигы) булып эшләве, заманасында РСФСР Конституциясен язуда катнашуы, бүгенге көндә дә икенче класслы Дәүләт советнигы чинын (ике йолдызлы генерал дәрәҗәсе) йөртүе, әлбәттә, сәяси, социаль, әхлакый тормышыбызнын төпкеленә үтеп кереп, андагы күп вакыйгаларнын асыл тамырларын күрергә һәм аларга, кыю язучы буларак, бәя бирергә ярдәм итә. Кырыс аналитик, кешечә, хөкем итмичә генә анларга һәм анлатырга тырышучы юрист, үзе ихтирам иткән кешеләргә ярдәм итәргә әзер дус, һәр очракта да чын зыялы, джентльмен булып кала белгән кеше—болар барысы да Зөфәр Фәтхетдиновнын асыл сыйфатлары һәм шулар аны кызыклы шәхес, зур язучы итеп таныттылар да.

Өстәрәк мин афоризмны, мәкальне мен йозакка яраклы ачкыч белән тинләгән идем. Шул фикерне дәвам итеп, бүгенге көндә өч меннән артык афоризм һәм максима язган Зөфәр Фәтхетдиновка минем «Алтын ачкыч ясаучы «резидент» дигән исем бирәсем килә. Чынлап та, ул үзенен әдәби дөньясында бик күп кызыклы һәм куркыныч, акыллы һәм хәйләкәр, нәфис һәм башкисәр персонажлар белән оста идарә итүче, укучыларына шул дөньядан гыйбрәтле һәм матур хәбәрләр җибәреп торучы «резидент» та...

**Ренат ХАРИС**

*Безнең календарь*

# ГУМАНИСТЛЫК ҮРНӘГЕ

ЭДУАРД КАСЫЙМОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Кайсы төбәктән язучылар чыгасын алдан ук берәү дә әйтә алмый. Эдуард Касыймов татар теленең төп сөйләмнәреннән берсен тәшкил иткән Нократ сөйләменең үзәгендә—Нократ авылында 1930 елның 9 ноябрендә дөньяга килә. Әтисе укымышлы, заманына күрә алдынгы, актив зат буларак, авыл советын да житәкли, колхозны да оештырып йөри, гомеренең соңгы елларында мәктәп директоры вазифаларын башкара. «Соңгы елларында» дип әйтүем сүз уңаеннан гына түгел: колхозлашу заманында рәнжетелгән берәү моны бик оста гына «чага» да—мәктәп директоры Салихжан Касыймов «халык дошманы»на әйләнә, кулга алынып, шул ук 1937 елны атыла да...

Кара тамга сугылган гаиләгә Нократ авылында көн бетә: һәркем акаеп карый, болар белән аралашсам, гәп куертсам, үземне дә «чагулары» бар бит әле, дип шүрли. Яшь буынны тәрбияләргә лаек түгел, дип, «халык дошманы»ның хатынын эштән куалар. Алар төялешеп, Малмыжга китәргә, туган-тумачага сыенырга мәжбүр була.

... Университетка укырга керүчеләрнең дә кайсы язучы булырын алдан әйтү һич мөмкин түгел. Кайчагында әле нәселдән килгән язучылык сәләтенен төрле сәбәпләр аркасында ачылмый калуы бик ихтимал. Ә инде Эдуардның туган төбәгендә ана телен өйрәнеп үсүе, бик яшьли кайгы-хәсрәт күрүе, ятимлекнең ачыгыйсын татуы әйләнә-тирәгә ачык күз белән карарга, кеше танырга өйрәтә. Адым саен гаделсезлек күрүләр, намуссызлыкка юлыгулар Эдуардның күңелендә каршылыклы уйлар һәм хисләр тудыра. Өстәвенә җәмгыятебездә бер төрле сөйләп тә, бөтенләй икенче төрле эшләүнең хуплануы, ялагайларның юл яруы, икейөзлелекнең, гомумән, чәчәк атуы әлеге хисләрне көннән-көн көчәйтә. Әмма болар барысы да булачак әдипнең эчендә генә җыела, аның тормыш багажына әйләнә, өермә булып тышка бәреп чыгарга ашыкмый.

Чыннан да, буран кубару өчен, өермә күтәрү өчен, иң әүвәл, көч сынап карарга кирәк. Ныгытып сугарга хәленнән килмәсә, куәтең җитмәслек зур күсәк күтәрүдән ни файда?!

Һәм Эдуард Касыймов вак-вак хикәяләр язарга керешә. Ул хикәяләрне «яшь язучыбызның үз тематикасы, үз теле бар», дип, вакытлы матбугатта басып та чыгаргалыйлар. Әмма ул хикәяләр әле камиллектән ерак була, автор әле зур проблемалар күтәрүдән ерак тора, кая барып бәрелергә белми, тел чарлау белән генә чикләнергә мәжбүр—ул фәкать эчендә бөтерелеп килгән өермәгә буйсынып кына иҗат итәргә керешә.

Миңа калса, Эдуардның чын-чыннан әдип булып җитлегүенә 15-20 елдан соң да әлеге дә баягы кара тамганың ныклап җәелүе сәбәпче була, хәлиткеч рольне уйный. Касыймов дигән студентның аспирантурага каласы, галим булып китәсе һәркемгә аңлашылгандай тоелса да... аны аспирантурага якын җибәрмиләр. Әнә шул хәлне Эдуард фаҗига буларак кичерә. Ничек була инде: бер яктан ул намуслы комсомол, курсыбызның иң әйбәт укучы студентлары рәтендә, зур фикер иясе, эрудит; икенче яктан, халык дошманы токымы, фәнгә үтеп керергә хакы юк!.. Нәкъ менә шушы каршылык яшь әдипнең күңелендә өермәне куертып җибәрүгә сәбәпче булганын хәзер инде шикләнмичә әйтергә мөмкин... Әмма әлеге өермәнең тышка бәреп чыгуын тоткарлап торырга, үз-үзенне тагын «авызлыкларга» туры килә иҗат кешесенә.

Илленче елларда безнең мәктәпләрдә татар теле дәресләре кимегәннән-кими барды, шунлыктан күбебезгә урыс теле укытырга тәкъдим иттеләр. Үзара сүз куешып, Эдуард Касыймов, Вакыйф Зыятдинов, Рәсыйх Кәшәпов һәм бу юлларның авторы Чулманның аръягына, нефтьчеләр төбәгенә китәргә ниятләдек.

Ул арада шәхес культы мәсьәләсе ил күләмендә күтәрелеп, «халык дошманы» дигән кара тамгаларның уйдырма икәнлеге ачыкланды. Университетта безгә

фольклордан лекцияләр укыган мәрхәмәт һәм шәфкать иясе Хәмит ага Ярми безнең Эдуардыбызны Түбән Шөннән эзләп таба һәм аспирантурага кабул итә. Хәмит ага әле сабакташыбыз Әбрар Кәримуллинның да фән юлына кереп китүенә сәбәпче була: университет китапханәсеннән куылгач, берәүдән дә куркып тормыйча, аны үз бүлегенә эшкә чакыра.

Фольклорны өйрәнү, фәнни хезмәтләр язу һәм диссертация яклау белән генә чикләнми Касыймов, һинд язучысы Прем Чандның бер китабын тәрҗемә итеп чыгара, повесть һәм хикәяләр иҗат итә. Әмма бу әсәрләрендә әле авторыбыз кешеләргә изгелек итү—фидакарьлекне тасвирлау, шәфкатьле-миһербанлы, әдәпле-инсафлы булу үрнәкләрен күрсәтү, гуманистик идеяләрне алга сөрү белән чикләнә.

Килер вакыт, әдипнең күңелендә еллар буе җыелган һәм бөтен табигатен бөтереп алырга әзер торган каршылыклы хисләр—гарьләнү һәм әрнү, мәхәббәт һәм нәфрәт хисләре—өермәдәй бөтерелеп, ташкындай ургылып чыгар әле. Тик ул анда да, канлы яшьләр түксә дә, үзенең калебенә-кыйбласына һич тә хыянәт итмәячәк, гуманистлыктан ваз кичмәячәк.

Ә өермәнең кубуы «Гомер ике килми» романына бәйләнгән. Татарстан китап нәшрияты әле күптән түгел генә «халык дошманы улы» дигән кара тамга тагып йөргән талант иясенә әтиләренең үткәнен яшь буынга үрнәк вә гыйбрәт булырлык итеп гәүдәләндерүгә заказ бирә. Китап язар өчен материал эзләгәндә яшь әдип әтисенең йөргән юлларын, хезмәт иткән—тир һәм кан түккән җирләрен тәгаенләргә мәҗбүр була һәм... Һәм шул чагында советлар хакимияте өчен янып көрәшкән, колхозлар оештыру эшендә активлык күрсәткән, сабый балалар белән уртак тел тапкан коммунист мәктәп директорының бернинди гөнаһсыз кулга алынганы, бинахак атылганы ачыклана. Өстәвенә әле аның ач-ялангач калган гаиләсеннән көлгәннәр: ул вәхшиләр, Салихҗан Касыймовның 1937 елда ук атылганын белә торып, әтиегез безнең төрмәдә утыра, ана хат алышырга гына ярамый, дигән сылтау белән, озак еллар буе ризык ташытканнар. Сабыйларның авызыннан өзеп бит...

Менә шунда инде язучының бөтен күңелләре актарыла, монарчы җыелып килгән каршылыклы хисләргә янә дә хәтәррәкләре өстәлә һәм, ниһаять, өермә күтәрелә.

Эдуард Касыймовның шәхес буларак кодрәте шунда ки, гәрчә үзенә әйтеп бетергесез читенгә килсә дә, күңелендә купкан өермәне үчләнү-зәһәрләнү өчен файдаланмый, үзенең кыйбласына хыянәт итми, әлеге өермәне гуманистик юнәлешкә җибәрергә үзендә көч таба. Менә ни сәбәпле «Гомер ике килми» романы лирик әсәр буларак яңгыраш ала. Бу романда авторның бөтен эрудициясе, тел байлыгы, галимлеге, Нократ сөйләменең үзенчәлекләре гаять матур чагылыш таба.

Хәйран кызык кеше иде дустым Эдуард! Чын-чыннан иҗат кешесе иде. Ирешкән уңышларына, яулаган казанышларына һич масая белмәде. Кая ул масаю, хәтта әле канәгатьләнергә дә уйламады. Биографиясеннән бер генә мисал. Хәмит ага Ярми белән бергә фәнни экспедицияләргә йөри, әкиятләр җыеп, китап итеп чыгара, диссертациясе әзер, Хәмит ага аны үз урынына фольклор бүлегенә җитәкче итеп, пенсиягә китәсен игълан итә, докторлык диссертациясенә материалы әзер, китаплары чыга тора... Шуларга шөкрана кылып, тыныч кына Казан каласында яшисе иде дә бит канә, юк шул менә! Бервакытны Эдуард тормышның кайнап торган җиренә, Чулман аръягына бөтен гаиләсе белән күченергә ниятли. Анда, Алабуга шәһәрендә яшәп, җирле халыкның яшәешен-көнкүрешен өйрәнә, повесть-хикәяләр яза, Бондюг химиклары хезмәтенә багышлап «Томан аша», «Һаваларда тургай» исемле роман-дилогиясен иҗат итә, педагогия институтында лекцияләр укый... Шунда тыныч кына картаясы иде дә бит инде, әмма Чаллы автогиганты калкып чыга, анда бөтен илдән яшьләр җыела, һәм, әлбәттә инде, тормышның кайнап торган җиренә беренче әдип булып Касыймов барып төпләнә. Тәҗрибә туплаган язучы «урра-патриотизм»га артык бирешмичә, шул төбәктәге авыл халкының ата-баба нигезеннән ваз кичәргә мәҗбүр ителүе кебек кире якларга бәгырькәйләре әрнеп, зур проблемалар кузгатып, роман арты роман иҗат итә. Әмма шунысы да бар бит әле: тормышчан әсәр язам дип, гамәли хәлләрне турыдан-туры күчереп утырткан тәкъдирдә... укучы сиңа ышанмаячак, син язган китапны укымаячак! Эдуард Касыймовның әсәрләренә сәнгати дөреслек, әдәби дөреслек хас, һәм әнә шул хасият аның романнарын укучыга якынайта, тормышчан итә.

Әдәбиятыбызны үстерүгә үзеннән саллы гына өлеш керткән Эдуард Касыймов 1986 елның 21 мартында вафат булып, Чаллы зиратына күмелә. Аның китаплары киләчәк буыннарга мирас булып кала.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

*Балаларга укыгыз*

## Нәзифә Кәримова

# ИПИ ПЕШЕРДЕК

—Бездә ипи беткән көнне күршеләрдә дә шул хәл. Ике-өч кадак кына әҗәткә алып торырмын дигән идем, булмады...—Куәс төбендәге әче камырны җебетә-җебетә әни шулай сөйләнде.—Үзебезгә ипи салырга туры килә инде... Хәзер изеп куйсам, төшкелеккә кайткач мичкә салыр идем дә бит, эштән кайтканчы мичтә ятсалар ике катланып бетәчәкләр. Нәрсә эшләргә соң?—диде ул әтигә карап.

—Өй саклаучы олы кызың бар бит синең. Мичтән ипи чыгарырга да ярамагач, нигә ашатабыз соң без аны? Әйеме кызым?—Әти миңа күз кысып куйды.

—И-и-и... Әйе шул. Алай бергәләп пешерәсе булгач, бер чүмеч сөт тә өстим әле. Онны да ваграк иләктән иләргә кирәк, тәмлерәк булыр...

Миңа канат чыккандай булды. Ипи пешерү уен эш түгел! Мин хәзер кул арасына керә башладым инде, әни шулай ди. Алар мактагач үземә дә рәхәт. Тизрәк үсәсе килә. Мондый эшләрне бәләкәй кешегә кушмыйлар. Хәзер бәрәңге дә әрчи беләм, идән дә юам. Әни мине өйрәтеп кенә тора. «Эшләвең безнең өчен булса, өйрәнүең үзең өчен»,—ди. Бәрәңге әрчегәндә янымда утырмаса да, сизә ул минем тәҗрибәм юклыкны.

—Кызым, әллә бик калын әрчисең инде?—дип куя.

—Каян беләсең?

—Әрчүеңнән тураган тавыш килә. Башлаганда юка гына ал, кабыгын өзмәскә тырыш. Үзеннән-үзе юка әрчелер.

Их, булмый шул! Бәрәңгеләре дә шулкадәр эреләр. Кулга да сыймыйлар. Аптырагач сәке йөзлегенә куям да юнам гына. Әрчегән бәрәңгеләрем минем кулга сыярлык кына булып калалар.

Ә менә бүген, үз гомеремдә беренче мәртәбә ипи пешерергә булышачакмын. Бу инде бәрәңге әрчү генә түгел—ипи салу иң зур эш ул безнең өйдә.

Әни алты олы, бер бәләкәй ипи әвәләп куйды. Бәләкәй ипинең уртасына тамга салды.

—Монысын кендек әбиеңә кертерсең, яме кызым?

Әни ипи пешергән саен шулай итә. Кендек әби минеке генә түгел, безнең очтагы байтак балаларның кендек әбисе—күршедә генә торучы Мөгаллимә әби. Ул берүзе яши. Хәзер картайган инде, күзләре дә начар күрә башлаган. Без кызлар белән аңа чишмәдән су алып кайтабыз, идәнен юабыз, өен җыештырабыз, аннары ул безнең барыбызга да «тәти кулың кайсысы?»— дип сорый-сорый йә чикләвек, йә конфет өләшеп чыга да, озын-озын итеп рәхмәтләр укый.

Ә менә бүген мин—ипи пешерүче.

Әни ашыга-ашыга ипиләрне мичкә тыкты.

—Кабармыйча да йөдәтте... Нәрсә булып чыгар болар... Эшкә соңга калам бугай инде. Карале, кызым, морҗа ябылмаган икән, әйтәм аны мичкә тыгуга ипиләрем җәелеп китте. Бар, тизрәк яп морҗаны, башта тәлинкәләрен капла, аннары гына юшкәсен этәрсең.

Боларын әни әйтмәсә дә беләм. Беренче тапкыр гына морҗа ябу түгел. Әгәр башта юшкәсен этсәң, мичтән торбага чыга торган кызулык кулны өтеп кенә ала. Бер-ике тапкыр кулың пешсә, бутамаска өйрәнәсең аны!

—Ярый, мин киттем, — диде әни алъяпкычын алыштырып.—Сәгатьнең минутлыгы дүрткә җиткәч мич капкачын ач та, күмерләрне кече учакка күчер, яме кызым? Ә инде минутлык уникегә җиткәч, ипиләрне мичтән чыгарырсың.

Әни йөгереп өйдән чыгып китте.

«Уфф!»

—Берүк вакытында чыгарырга оныта күрмә! Ишетсен колагың! Ипиләрне мичтән алмыйча урамга чыкма!

Боларын әни урамнан, ачык тәрәзәдән кычкырды.

—Ярар, ярар!

Тагы бер мәртәбә «уфф» дидем дә, сәгать каршысына утырып минутлыкның уникегә җиткәнен көтә башладым.

Сәгать йөри йөрүен, тик минутлыгы ник кенә урыныннан кузгалсын. Карап тора-тора күзләрем авыртып бетте. «Келт-келт, келт-келт. Чык-кит, чык-кит» дип котырта мине сәгать.

Кинәт урамнан безнең якка таба якынаеп килүче җыр, гармун, кыңгырау тавышлары ишетелде. Ачык тәрәзәдән чебен кермәскә дип куйган марляны күтәреп урамга карасам... Әннекәем!.. Әллә иртәгә сабан туе микән? Сөлгеләр, яулыклар белән бизәлгән атлар! Аларга ияргән бала чага!

Ул атларны күрсәң! Йөгәннәрендә дә әллә ничә кулъяулык! Ул сөлгеләр дисеңме, чуклы дилбегәләр! Безнең турыдан аз гына үтүгә, арбадан коелып төштеләр дә, кемнедер ... Ә-ә-ә... Хатипның абыйсын икән —һавага чөяргә тотындылар! И-и, бүген бит аны армиягә озаталар! Алар турысындагы кешене күрсәң!..

Ай! Тәрәзәдән егылып төшә яздым. Күпме генә сузылып карасам да, барысы да күренми шул. Аларның да өйләре безнең якта, җитмәсә Сәмигулла абыйның бурасы ярты урамны каплаган. Их, ничек кенә чыгасы урамга! Әй, шушы сүз тыңлаулар харап итә кешене!

Ул арада күзләрен тасырайтып, йөгерүдән тыны беткән Диләрә килеп җитте.

—Нишләп өйдә утырасың, тиле! Әйдә, Хатиплар турына!

—Әй, бик чыгар идем дә бит, — дидем мин үрсәләнеп.- Әни мичкә ипи салып киткән иде, шуны чыгарасым бар! Урамга шундый чыгасы килә үзе!

—Әйдә, әйдә. Чыгар тизрәк ипиләреңне!

—Минутлыгы уникегә җиткәч кенә чыгарасы шул. Ә минутлык урыныннан кузгалырга уйламый да.

Сәгатькә карасам...

—Юк, юк күчкән икән азрак. Бигрәк әкрен йөри безнең бу сәгать. Ничек кенә тизләтергә инде моны?

—Сәгатьне тиз йөртер өчен нәрсә эшләргә икәнен дә белмәгәч! Ипи пешерәм дигән була тагы! Сәгать гиренә авыррак әйбер асарга кирәк!

—Асты ди менә!

—Беләсең килсә, безнең әбиләрнең сәгатьләрендә ике кадаклы гер, аннары трактор гайкасы, тагы әллә нәрсәләр эленеп тора. Бабай әйтә, хәзер моңа арба күчәре генә тагасы калды инде, ди. Менә күрсәң, аларның сәгатьләре йөгереп кенә йөри, үскәнкәем!

—Йөгерде ди сиңа! Стена буйлап йөгерәмени, шулхәтле авыр әйберләр белән?

—Әй, көлгән була тагы, киттем мин алайса...

—И, малай, тукта инде, көт мине дә. Әннекәем, минутлыгы дүрткә җиткән бит! Менә, дөрес йөрми дигән идең !

Урамда җырлаган, көлгән, гармун уйнаган тавышлар һич тынмый.

Диләрә кул гына селтәде дә, чыгып йөгерде. Мин ипи йөзе китерергә куелган күмерләрне күчерергә дип мич янына атылдым. Бәрелә-сугыла чыгып йөгергән Диләрә артыннан башта «шап» иттереп ишек, аннары деңгердәп капка ябылып калды. Әти өйдә булса, «баганасын аударды!» дип кычкырыр иде.

Мич капкачын ачсам! Ипиләр кызарып чыккан. Ярый әле болары сәгатькә карап тормый, пешүләрен беләләр.

Мин яңадан тәрәзәдән башымны тыктым. Яшь кызлар да җыелган ахры. Шап-шоп биегән, кул чапкан тавышлар ишетелә. Их, үзләрен күреп булмый шул!

Ул арада Диләрә тагын кереп җитте. Әни әйтмешли, күзләре урыныннан купкан моның, үзе кабалана, үзе сөйли:

—Һаман утыра! Хәзер тагын урам әйләнәчәкләр! Күрми каласың бит! Әй, сезнең бу сәгать сәгатьмени! Шуңа ышанып ипи пешерергә!.. Әйдә әле, әзрәк ярдәм итик үзенә!

Без икебез сәгатьнең ике ягына бастык та, сәгать телен мин Диләрә ягына, Диләрә минем якка атындырырга тотындык. Диләрә сәгать теленә бәргән саен, «тизрәк-тизрәк» дип кабатлый.

—Тегеп куйганнармы әллә моның минутлыгын? Һаман бер урында тора! Тавышын гына тыңлап кара әле син аның. Аксак-туксак йөри бит бу сәгать. Әмене болай итсәк...

Диләрә ике куллап сәгать геренә тотынды да, аска тартып тора башлады.

—Күрдеңме, ничек шәп йөреп китте! Тавышы да гел икенче. Рәтле сәгать шулай йөрергә тиеш! Берәр авыр әйбер тап әле, хәзер төзәтәбез аны. Мин болай асылынып торсам, бернәрсә дә күрми калам бит.

Йөгерә-йөгерә өй бетереп авыр әйбер эзли башладым.

—Аш чүмече ничек булыр микән?

—Бара-бара! Китер тизрәк! Бу гына аз әле! Тап инде авыррак бер нәрсә.

—Ә самавыр капкачы?

—Китер монда, хәзер бәйләп асабыз.

Сәгать чынлап та кызурак йөргән сымак итә, тырыша мескенкәем. Ул да ипи пешерә бит.

Әй, урамда җырлыйлар!

Яшь гомерне үтә диләр,
Үткәнен күрсәң иде,
Үткән чакта тотып алып
Кирәген бирсәң иде.

—Их, күрми калабыз бит! Ничек итеп кирәген бирәләр икән ул яшь гомернең! Син ипиләреңне кара, мин тиз генә әйләнеп керим әле!

Диләрә очып диярлек чыгып йөгерде.

Мин кара кайгыда, ә урамда җыр, көлеш. Нинди генә хәйлә уйлап табасы моңа! Аптырадым бу сәгать белән. Ничек кенә уникегә җиткерәсе үзен? Таптым-таптым! Тиз генә урындыкка бастым да, сәгатьнең минутлыгын уникегә җиткердем дә куйдым. Менә бәхет булгач! Җиңел күчә икән ул. Әни әйткәнчә булды хәзер. Сәгатьне җиткереп куйдым, ипиләр пешкәннәрдер инде. Син ашыкканда ул кабалана диләрме әле? Кисәү агачы, йә мич төбендәге кирпечкә эләгә, йә ипи эченә кереп китә. Көчкә-көчкә, пешә-пешә ипиләрне чыгарып, сәкегә тездем дә, урамга йөгердем...

Без таралганда, авыл тынып калган, кич булган иде инде. Өйдә нихәлләр бар икән? Капкадан әкрен генә кердем дә, өйалды ишеген шыгырдатмаска тырышып, сак кына ача башладым.

Кече якта әни белән кендек әби тавышы. Ишек ярыгыннан аларның сөйләшкәне ишетелә.

—Менә монысы сиңа, Мөгаллимәтти,—диде әни тамгалы ипине кендек әбигә тоттырып.- Кызың пешергән. Пешкәне дә шушы бер бәләкәй ипи.

—И-и-и, кызың үсте, Мәүлидә,— ди кендек әби.-Шушындый олы эшкә ярагач...

—Үсте, үсте үсмәгән кая! Әнә, армиягә егетләр озатып йөри. Шуны әйтеп торам бит. Бер мич чиле-пешле ипине чыгарган да тезгән. Валчыгын да калдырмый ашатам үзләренә. Икенче юлы аң булыр. Нишләтергә инде бу кызны? Әйтеп киттем бит, минутлыгы уникегә җиткәч кенә ал мичтән ипиләрне дидем. Сәгатькә күз сал әле син. Ничаклы әйбер аскан. Ничек кадагы сынып сәгате идәнгә төшмәгән диген.

Мин атылып өйгә кердем.

—Әни, уникегә җиткердем бит мин минутлыкны. Бик җиңел күчә икән ул. Ипиләр пешмәгәнмени?..

Әни бер сүз әйтә алмыйча, лапылдап урындыкка утырды да, ачулы күзләре белән миңа текәлде. Аңламассың боларны. Мин тырыштым, сәгать тырышты, ә ипиләр чи калган.

Кече яктан кулына ипи тотып, әти килеп чыкты. Ну, эләгә дә соң хәзер...

—Ярар инде әнисе, — диде әти мине гаҗәпкә калдырып.- Беренче коймак табага ябыша диләрме әле? Чиерәк булса да, ашамаслык түгел бу. Кыерчыгы бигрәк тә тәмле. Кызым пешергән ипи бит, әйеме кызым?

Шулчак кинәт йөгереп килеп әтине кочаклап аласым килде... Әйттем бит, ипи пешерү уен эш түгел ул.

## Укучы сүзе

* * *

Хөрмәтле редакция!

«Казан утлары» журналын даими укып барам. Ул минем өчен дустыма да һәм ана телемне камилләштерүдә остазыма да әйләнде. Чөнки минем мәктәп елларым туган төбәгемнән еракта узды.

Хәтта Казанга кайткач та яшьлек, студент елларым да рус мохитендә үтте. Милләтем белән горурланып яшәсәм дә, аның телен яхшы белми торып, чын татар була алмавымны аңладым. Бөтен көчем белән кызымны татар мәктәбенә хәзерли башладым. Балама тел өйрәнүдә «Салават күпере» журналы, ә үземә «Казан утлары» журналы ярдәм итте. Ана телендә укып рухи ләззәт тою, жан шатлыгы кичерү шигърияттән башланды. Алар мине татар прозасына, зур әсәрләргә алып чыкты.

Әмма соңгы елларда күп кенә әсәрләрдә телебезнең чуарлануы, гүзәллеген, сыгылмалыгын югалта баруы күңелне борчый. Өстәвенә сюжетларында күбрәк женси азгынлык, төрле тупаслыклар гайрәтне чигерә. Андый әсәрләрне укыйсы да килми шул. Һәр нәрсәдә чама хисен югалтмаска иде. Бигрәк тә матур әдәбиятта. Күзәтүләремнән чыгып әйтәм, күпчелек укучы шундый матур әдәбиятны ярата. Матур әдәбиятны!

Ә менә журналыгызның җиденче саны бик тә уңышлы дип әйтер идем. Андагы ике өр-яңа автор—Г. Галиеваның «Тулгак» повестен, Нурзилә хикәяләрен һәм миңа таныш булмаган язучы Гариф Галиевнең «Каракош сыртында» хикәясен бастырып чыгаруыгыз нур өстенә нур булган.

Минем бу язмамда аерата истә кала торган «Тулгак» әсәре турында үз фикерләремне әйтәсем килә. Иң беренче мине әсәрнең исеме уйга салды. Ниндидер бер, хатын-кызга гына хас булган, кызыксыну белән укый башладым. Теленең сафлыгы, матурлыгы, жөмләләрнең төгәллеге, гадилеге, әсәрнең мавыктыргыч вакыйгаларга бай булып үрелеп кенә баруы күңелемне әсир итте. Тәмам ахырына кадәр житмичә кулдан төшерә алмадым мин аны. «Тулгак» бер сулышта укыла торган әсәр, баштарак исеме белән килешә алмасам да, тора-бара шулай исемләү кирәклеген авторның тирәнтен төшендерә алуы сокландырды.

Чыннан да, бөтен тормышыбыз заманның авыр тулгаклары белән тулган ич. Мондый әсәрне билгеле инде, үзе ана булган хатын-кыз гына яза ала дип уйлыйм мин. Укуын тиз укысам да, әсәрдән аерыла алмыйча, андагы вакыйгалар эчендә кайнавым атналар буена сузылды. Яңадан журналны кулыма алырга мәжбүр булдым. Инде бу юлы ашыкмыйча, кайбер урыннарына кире кайта-кайта рәхәтләнеп яңадан укып чыктым.

Рәхмәт сезгә! Киләчәктә ижатыгызга зур уңышлар телим.

**М. ВӘЛИЕВА**,
*Казан.*

## БЕРГӘ БУЛЫЙК!

Хөрмәтле укучыларыбыз! 2001 елның беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. «Казан утлары»ның индексы—73210, ярты елга язылу бәясе 42 сум.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар игътибарына тагын бер яңалык: быелдан башлап «Казан утлары»на «Горпечать» киоскларында язылырга мөмкин. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

Әдәбиятыбызның, гомумән, мәдәниятебезнең елъязмасы, рухи көзгесе булган «Казан утлары»на язылырга онытмагыз! Яңа гасырда да бергә булыйк!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

Количество комплектов:

на 2001 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

ПВ | место | ли-тер

на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплек-тов |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на 2001 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### КАЗАН ТУРЫНДА ЗУРДАН СӨЙЛӘШҮ

Октябрь аенда Мәскәүдә РФ Президенты Владимир Путин рәислегендә Рәсәй Федерациясе Дәүләт Советы президиумынын икенче утырышы булды. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев анын әгъзасы булып тора.

Президиум әгъзалары РФ Дәүләт Советы утырышына чыгарылачак мәсьәләләрне әзерләүнен барышы турында белдерү ясадылар. Шул ук көнне Рәсәй Президенты Владимир Путин Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашты. Очрашу барышында Казаннын 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек мәсьәләләре җентекләп тикшерелде. Владимир Путин РФ хөкүмәте әгъзаларына юбилейга әзерлеккә бәйле боерыклар бирде. Очрашуда РФ хөкүмәте рәисе урынбасары, финанс министры Алексей Кудрин һәм Казан хакимияте башлыгы Камил Исхаков катнашты.

### ИҢ ЯХШЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ

Мәскәүдә Рәсәй Архитекторлар берлегенен V съезды кысаларында «Рәсәй архитектурасы. 1000 еллык йомгаклары» күргәзмәсе булды. Анда Татарстан экспозициясе иң яхшылардан берсе дип табылды.

Күргәзмәдә республиканын Болгар заманнарыннан бүгенге көнгә хәтле архитектура тарихы материаллары күрсәтелде. Тарихи шәһәрләр генә түгел, яшь шәһәрләр дә тамашачылар игътибарына тәкъдим ителде. Казан Кремле аерым урын алып тора. Ихтимал, тиздән ул ЮНЕСКО карамагына кертелер. Күргәзмә кысаларында Татарстан, Мәскәүне исәпкә алмаганда, бөтен төбәкләрдән бердәнбер буларак, үзенен Республика көнен уздырды. Музыка яңгырап торды, шигырьләр сөйләделәр, артистлар чыгыш ясады, рәссамнарның әсәрләре, декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре, Салих Сәйдәшев, Федор Шаляпин турында фильмнар күрсәтелде. Кунакларны милли ризыклар да сокландырды.

### ПРЕЗИДЕНТ КОТЛЫЙ

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясен Евразиянен өченче телефорумында җиңү яулавы белән котлады— «Панорама» иҗади берләшмәсенен «Лев Гумилев. Жизнь вопреки» дигән документаль-публицистик фильмы әлеге телефорум бүләгенә лаек дип табылды.

Президент, шулай ук, «Эфир» телекомпаниясенен «Шәһәр» информация программасын алып баручы Айгөл Мирзаянованын төбәк телекомпанияләре арасында үткәрелгән абруйлы конкурста Гран-при яулавы уңаеннан ана тәбрик телеграммасы юллады.

### СӘЙДӘШКӘ—ЯДКАРЬ ТАШ

Югары Ослан районынын Кызыл Байрак авылында бөек композитор Салих Сәйдәшевкә истәлек ташы ачу тантанасы булып узды. Әлеге ядкарь Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры коллективы тарафыннан әзерләнде. Тантанада мәдәният министры Илдус Тарханов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, композиторнын улы Альфред Сәйдәшев, Камал театрынын баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов, Татарстаннын халык шагыйре Равил Фәйзуллин (ташһәйкәлнен Иделгә караган ягына анын шигъри юллары уелган) чыгыш ясады.

Кызыл Байрак авылындагы истәлек таш Идел ярларынын күрке булып, композиторнын 1920—1940 елларда җәй айларында биредә яшәвен искәртеп, анын рухын саклап торыр.

### БЕЗ КАЙДА ДА БАР

2000 елнын март аеннан Украина татарларынын тулаэсез тарала торган, тиражы 10 мен данә булган «Дуслык» газетасы чыга башлады. Шулай ук, Бөтен Украина татар мәдәни үзәге әйдәүчеләре инициативасы белән «Украина татарлары. Үткәне һәм бүгенгесе» дигән китап та әзерләнә.

### ТАТАР МУЗЫКАСЫН ЯРАТУЧЫЛАР ӨЧЕН

Казанда Нәҗип Җиһанов исемендәге татар музыкасы клубы ачылды. Күптән түгел аны оештыручыларнын беренче утырышы булып үтте.

Әлеге клубны оештыру фикере Казан дәүләт консерваториясе профессоры, Татарстаннын атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Шамил Шәрифуллиннан чыккан иде. Анын бу фикеренә композиторлар Резидә Ахиярова, Мәсгудә Шәмсетдинова, Риф Гатауллиннар да кушылды. Төрле фестивальләр, татар музыкаль фольклоры турында әңгәмәләр циклы һәм «Нәҗип Җиһанов исемендәге татар музыкасы клубын тәкъдир итү», «Минем тормышымда Нәҗип

Жиһанов: композиторлар сөйли», «Татар композиторлары иҗатында Салих Сәйдәшев» исемле музыкаль кичәләр һәм башка чаралар шушы клубта үтәчәк.

## МИЛЛИ КӨЙЛӘР, МИЛЛИ ҖЫРЛАР...

Быел Татар сәнгатенең иң яхшы музыка әсәрләре тупланган «Каз канаты» дигән компакт-диск дөнья күрде. Ул классик музыка, халык музыкасы, Татарстан композиторларының җырлары дигән өч бүлектән тора. Классик музыка бүлегендә Фәрит Яруллин, Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Рөстәм Яхин, Нәҗип Жиһанов, Фасил Әхмәтов әсәрләре; халык музыкасы бүлегенә «Иске кара урман», «Галиябану», «Каз канаты», «Олы юлның тузаны» кебек җырлар; Татарстан композиторларының җырлары дигән бүлеккә—«Туган җирем—Татарстан» *(Г.Зәйнәшева шигыре, А. Ключарев музыкасы)*, «Казан кызы» *(Н. Арсланов шигыре, З. Хәбибуллин музыкасы)*, «Урман кызы» *(Һ.Такташ шигыре, Ж. Фәйзи музыкасы)*, «Әдрән диңгез» *(Т. Гыйззәт шигыре, С.Сәйдәшев музыкасы)* һ. б. бик күп җырлар кергән. Өч бүлеккә 65 әсәр тупланган. Барысы да күренекле җырчылар, иң яхшы оркестрлар башкаруында язылган.

## АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР

Быел июль аенда Казан дәүләт университеты һәм Татарстан Милли китапханәсенең Берләштерелгән археографик экспедициясе доцент Җәүдәт Миңнуллин җитәкчелегендә Пермь өлкәсенең Октябрь, Пермь, Барда районнарына керә торган 26 татар авылы һәм Пермь, Кунгур, Октябрьск шәһәрләрендә тикшерү эшләре алып барды. Экспедиция дәвамында XVII-XX йөз башына караган һәм фәнни әһәмияткә ия булган 292 берәмлек тарихи һәм әдәби кульязма чыганак тупланды. Шулай ук татар, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендәге 96 иске басма китап, 1913 елны 24 сан «Шура» журналы да Казанга алып кайтылды. Иң кыйммәтле тарихи, әдәби җәүһәрләр арасында Кол Галинең мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» дастанының 3 кульязмасы, XIV йөзгә караган «Кыйссаи Аук» дастанының 2 нөсхәсе бар.

## ГАКЫЙЛЬ—ҖИҢҮЧЕ

Мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү оешмасы игълан иткән конкурста катнашып, Самара өлкәсендә яшәүче шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сәгыйров лауреат исеменә лаек булды. Әлеге бәйгедә Россиянең 62 төбәгеннән, Австрия, Израиль, Венгрия, Беларусь һ. б. илләрдән бер мең инвалид катнашкан. Ә Г. Сәгыйров исә үзенең график рәсемнәре белән катнашып җиңү яулады.

Мәскәүдә ОРТ телеканалы ачы язмышка дучар ителгән милләттәшебез хакында фильм да төшерде.

## ИСӘННӘР ӨЧЕН КИРӘК

ТР Прокуратурасында сәяси репрессия елларында зыян күргән татарстанлыларга багышланган «Мертвым не больно. Больно живым» дигән китапны тәкъдир итү булды.

Танылган язучылар, журналистлар, тарихчылар Булат Солтанбәков, Алексей Литвин, Марсель Зарипов һ. б. очерклары һәм публицистик мәкаләләре республиканың Прокуратура, Дәүләт иминлеге комитеты, Эчке эшләр идарәсе архив материалларына нигезләнеп язылган.

Авторлар арасында репрессия дәһшәтен үз башлары аша үткәргәннәр дә бар. Җыентыкта күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләре Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Хәсән Туфан турында материаллар урын алган. Китапны төзүдә Прокуратура һәм Дәүләт иминлеге комитеты хезмәткәрләре катнашкан. РФ Конституция суды рәисе Сәйфихан Нәфиев сүзләренә караганда, бу хезмәт киләчәктә дә дәвам иттереләчәк.

## ИСКӘ АЛУ

15 сентябрьдә Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның (1925—2000) якты истәлегенә искә алу кичәсе булды.

Анда Татарстанның күренекле әдәбият, сәнгать әһелләре катнашты, китап күргәзмәсе оештырылды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбияты өлкәсендәге уңышлы хезмәте өчен шагыйрә **Лена Галимҗан** кызы **Шакирҗановага** (Лена Шагыйрҗан) «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдәге уңышлары өчен язучы, Татарстан язучыларының Әдәби фонды директоры **Салихов Данил Хәбибрахман** улына «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Салих Сәйдәшев портреты—рәссам Вил Шәрәфетдинов эше.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Рауль Мирхәйдәров.

# Мәдәни ҖОМГА

## Сезнең ихтыяҗларны канәгатьләндерә торган газета

Безнең индекс
54129

Әгәр Сезне:
— бүгенге тормышыбызны дөрес итеп чагылдырган мәкаләләр;
— чын-хак хәбәрләр;
— мәдәният, тарих, туган телебез, дин турындагы язмалар;
— танылган җырчылар, артистлар, композиторлар, рәссамнар һ.б. сәнгать әһелләренең чыгышлары;
— мавыктыргыч әдәби әсәрләр;
— сөю-мәхәббәт серләре;
— гыйбрәтле хатлар;
— дөньядагы кызыклы хәлләр;
— мәзәкләр;
— сорау-җавап һәм файдалы киңәшләр;
— криминаль көндәлек;
— йолдызнамә;
— кроссворд;
— телерадиопрограмма;
кызыксындырса,
өегезгә
«Мәдәни җомга»
газетасын алдырыгыз.
«Мәдәни җомга» —
татар телендә 24 битле булып чыгучы иң саллы һәм күләменә карата бәясе шактый арзан атналык басма.
«Мәдәни җомга» —
Ислам диненә караган китаплар,
Татар мөселман календарьлары,
Коръәнне үз телебездә чыгара.



«Мәдәни җомга» газетасы «Роспечать» каталогына да кертелгән.

Индекс 73210



Рауль Мирхәйдәров

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)